АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

Из сокровищницы научных экспедиций

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Татары Пензенской области*

КАЗАНЬ · 2024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ

*Пенза өлкәсе татарлары*

КАЗАН • 2024

**УДК 39(=512.145)(470.51):930.2:811.512.145:7**
**ББК 63,5(2Тат):63,2:81.2Тат:82.3(2Тат):85**
**М 48**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

*Проект «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау»*
*Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында*
*гамәлгә ашырыла*

**Редколлегия:**
***И.И. Халиков** (рәис), **О.Р. Хисамов,***
***Л.М. Гыйниятуллина***

**Төзүче һәм фәнни мөхәррир**
*филология фәннәре кандидаты **И.И. Ямалтдинов***

**Рецензентлар:**
*тарих фәннәре докторы **Г.М. Дәүләтшин,***
*филология фәннәре докторы **И.Г. Закирова***

**М 48 Милли-мәдәни мирасыбыз: Пенза өлкәсе татарлары.** – Казан, 2024. – 480 б. – (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән; егерме дүртенче китап).
ISBN 978-5-93091-501-3

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә дөнья күргән чираттагы китап Пенза өлкәсендә яшәүче милләттәшләребез, аларның гореф-гадәтләре, тел-авыз иҗаты, сөйләш үзенчәлекләре, көй-музыкасы, җирле осталарның кул эшләре, археографик һәм эпитафик мирасы турында бай мәгълүмат бирә.

**УДК 39(=512.145)(470.51):930.2:811.512.145:7**
**ББК 63,5(2Тат):63,2:81.2Тат:82.3(2Тат):85**

**ISBN 978-5-93091-501-3**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2024

*Тел – уйлауның коралы, уйның – калыбы...*
*Миллият бинасының нигез ташларыннан*
*иң ныклысы – тел... Телнең эчендә халыкның рухы,*
*моңы, уй һәм тойгысы яшеренгән.*

Галимҗан Ибраһимов

---

*Язык – это инструмент мышления,*
*форма мысли… Самый прочный камень*
*в фундаменте бытия нации – язык… В языке*
*сокрыты душа народа, его мысли и чувства.*

Галимджан Ибрагимов

# КЕРЕШ

Һәр төбәкнең табигать тә, анда яшәүче кешеләр дә, аларның ышанулары һәм дөньяга карашлары да йогынты ясый торган язмышы, йөзе, рухи үзәге-асылы бар. Шушы үзенчәлекне тою-аңлау өчен, әлеге төбәктә яшәү, һич булмаса, андагы тормышны өйрәнү һәм халык белән аралашу кирәк. Болар төбәкнең хәзерге хәл-халәтен күзалларга мөмкинлек бирә.

Үткән-тарих исә күпмедер күләмдә чыганакларда саклана. Аларны археологик тикшеренүләр үткәреп тергезәләр; архив документларыннан һәм тарихи һәйкәлләрдән, ташъязмалардан эзлиләр. Археолог галимнәр борынгы кешеләр турында мәгълүмат сакланган урыннарда разведка уздыра, казу эшләре оештыра һәм, табылдыкларга нигезләнеп, бик ерак тарих хакында төгәл мәгълүматлар бирә. Археологик тикшеренүләр вакытында эралар-чорлар да, шул заманнарда билгеле бер урында яшәгән кешеләрнең кайсы халыкка каравы, көнкүреше, һөнәрләре, нинди технологияләргә ия булуы, ышанулары да, күпмедер күләмдә зәвыгы, мәдәни казанышлары да ачыклана. Алар язма тарихи чыганаклар булмаган ерак заманнарны кабат күзалларга мөмкинлек тудыра, архив материаллары, документлар, эпиграфик һәйкәлләр һ. б. исә безгә якынрак чорлар хакында сөйли.

Алар да күрсәтә алмаган бик күп сәхифәләрне шәҗәрәләр һәм гаилә истәлекләре дә; төбәк кешеләре хәтерендә буыннан буынга тапшырылып килгән мифлар һәм легендалар, җырлар һәм бәетләр дә; халыкның тел-сөйләм, әдәби фикерләү хасиятләре, көнкүреш һәм мәдәни үзенчәлекләре; матди һәм

# ВВЕДЕНИЕ

У каждого региона есть свой неповторимый облик, своя судьба, особая духовная составляющая, которые формируются под влиянием местной природы, живущих там людей, их мировоззрения, привычек и верований. Чтобы понять и почувствовать это своеобразие, необходимо здесь пожить или хотя бы понаблюдать местное жизнеустройство и пообщаться с людьми. Только так можно получить представление о современном состоянии региона.

Страницы прошлого в какой-то степени раскрываются в исторических источниках, их восстанавливают посредством археологических исследований, находят в архивных документах и исторических памятниках. Ученые-археологи проводят исследования в местах, сохранивших следы пребывания древних людей, организуют раскопки и, опираясь на сделанные находки, способны представить точную информацию об очень далеких эпохах. Во время археологических изысканий выясняются возраст рассматриваемых объектов, принадлежность населения данной местности к тому или иному народу, особенности их повседневного быта, используемые технологии и ремесла, их верования, эстетические предпочтения и культурные достижения. Археологи дают возможность представить те далекие времена, о которых нет исторических источников.

Исторические источники (архивные материалы, документы, эпиграфические памятники и др.) рассказывают о ближайших к нам эпохах. Многие страницы истории, которые не получили отражение в источниках, сохранились в родословных, семейных преданиях; в передаваемых из поколения в поколение

мәдәни кыйммәтләр дә үзендә саклый. Боларны күрә, аңлый, өйрәнә һәм аңлата белергә генә кирәк. Гаҗәеп күренеш: археологик һәм тарихи чыганакларда сакланмаган мәгълүматлар еш кына кешеләр хәтерендә, төбәкләрнең тормыш-көнкүрешендә яшәвен дәвам итә. Аларны төрле тармак галимнәре төбәкләргә экспедиция-сәфәрләр уздырып барлый, таба, өйрәнә... Аннары бу материаллар кабат халыкка кайта, шушы урынның, төбәкнең һәм бердәм татар милләтенең тарихи-мәдәни байлыгына әйләнеп яши бирә.

Татарстан галимнәре, тарихи, археологик тикшеренүләр белән бергә, төбәкләргә чыгып, урыннарда халыкның яшәешен, көнкүрешен, матди һәм мәдәни хәл-халәтен өйрәнү белән һәрвакыт шөгыльләнә. Мондый тикшеренүләр XIX–XX гасыр чикләрендә үк аерым татар зыялылары инициативасы белән уздырыла башлый: бик күп татар җырларын, әкиятләрен, мәкаль-әйтемнәрен, миф-легендаларын язып алырга, татарларның тел-сөйләм үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Мәсәлән, К. Насыйри беренчеләрдән булып татар халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, тарихи-этнографик тикшеренү эшен башлап җибәрә, 1871 елдан үзенең «Казан календаре»нда фольклор үрнәкләре бастыра. Бу эшкә Р.Ф. Фәхреддин, Г.Н. Әхмәрев, Х.Б. Бәдигый, Җ.Җ. Вәлиди һ. б. кушыла.

XX гасырның аерым чорларында мондый тикшеренүләрне оештыруда активлык күзәтелә. 1920–1930 елларда – бигрәк тә Гыйльми үзәк эшчәнлеге белән бәйле махсус экспедицияләр фәнни нигездә уздырыла башлый. Н.И. Воробьев, А.С. Башкиров, Ф.И. Терегулов, М.С. Гобәйдуллина, К.С. Гобәйдуллин, С.Г. Вахиди һ. б. тарафыннан Арча, Әлки, Балык Бистәсе, Мамадыш, Минзәлә, Спас, Чаллы, Чистай төбәкләрендә шундый кыр тикшеренүләре үтә; аларда этнография, фольклор, сәнгать, тарихи-мәдәни мираска караган материаллар туплана.

Мондый эшчәнлек хәтта Бөек Ватан сугышы чорында да тукталмый. 1940–1980 елларда аерым тармак галимнәре махсуслаштырылган экспедицияләргә еш чыга. Бигрәк тә эпиграфик (Һ.В. Йосыпов), археографик һәйкәлләрне (С.Г. Вахиди, М.И. Әхмәтҗанов, М.Г. Госманов һ. б.), диалектларны

мифах и легендах, песнях и баитах, в специфике разговорной речи и литературного мышления; особенностях повседневной жизни и культуры; в материальных и культурных ценностях населения данного региона. Нужно только увидеть, понять, изучить и правильно интерпретировать эти явления. Удивительно то, что материалы, не сохранившиеся в археологических и исторических источниках, часто продолжают жить в памяти людей, в повседневном жизненном пространстве населения данной местности. Ученые и специалисты в различных областях знаний во время экспедиций в регионы находят, собирают, изучают эти особенности… А затем эти материалы, после комплексного изучения, возвращаются к народу и продолжают жить, став частью общего историко-культурного наследия татарского народа и данного региона.

Академическая наука Татарстана, наряду с историческими и археологическими изысканиями, всегда держала в центре своего внимания изучение жизни, быта, особенностей материального и культурного состояния татарского народа, проживающего в том или ином регионе. Подобные исследования проводились во время экспедиционных выездов по инициативе представителей татарской интеллигенции, на рубеже XIX–XX веков было записано много татарских песен, сказок, пословиц и поговорок, мифов и легенд; зафиксированы местные особенности татарского языка и речи. Например, К. Насыри одним из первых начал собирать материалы по устному творчеству татарского народа и по исторической этнографии; с 1871 года он регулярно публиковал образцы фольклора в своем «Казанском календаре». К этой работе присоединились Р.Ф. Фахретдинов, Г.Н. Ахмеров, Х.Б. Бадиги, Дж.Дж. Валиди и другие представители татарской интеллигенции.

В отдельные периоды XX века наблюдалась особая активность в организации подобных исследований. В 1920–1930-е годы начинают проводиться специальные научные экспедиции, что было связано с деятельностью созданного Академического центра. Подобные полевые исследования осуществляли Н.И. Воробьев, А.С. Башкиров, Ф.И. Терегулов, М.С. Губайдуллина, К.С. Губайдуллин, С.Г. Вахиди и др. в Арском,

(Л.Җ. Җәләй, Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова һ. б.), төрки-татар фольклорын (Х.Х. Ярмөхәммәтов, И.Н. Надиров, Х.Ш. Мәхмүтов, Л.Ш. Җамалетдинов һ. б.) җыю-барлау максатыннан, Татарстанда һәм аннан читтә яшәүче татар авыллары һәм шәһәрләрендә тикшеренүләр уздырыла. Экспедицияләрдә тупланган материал «Татар халык иҗаты» (1951, 1954), «Татар халык әкиятләре», 2 томда (1946, 1956), «Татар халык җырлары» (1965), «Татар халык иҗаты», 12 томда (1976–1988), «Татар халык сөйләшләре», 2 томда (2008), «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (2009), «Татар халык сөйләшләренең атласы», «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) кебек фундаменталь хезмәтләр, мәдәният-сәнгать тарихы, милли һөнәрчелек, кулъязма һәм басма китап тарихы һ. б. өлкәләр буенча күпсанлы китаплар нигезендә ята.

XXI гасыр башында, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең системалы эшчәнлеге нәтиҗәсендә, бу эш яңа баскычка күтәрелә: һәр елны милләттәшләребез яшәгән төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештырыла башлый. Комплекслы рәвештә өйрәнгәндә, тел, әдәбият, фольклор, сәнгать юнәлешенең төбәк хәзинәсендә булган барлык төр байлыгы – буыннан буынга тапшырыла килгән авыз иҗаты үрнәкләре, бәйрәмнәре, йола-гадәтләре, музыкасы, бәйләүчигү кебек кул эшләре осталыгы, йорт-каралты бизәкләре, кием-салымы, тел үзенчәлекләре, эпиграфик һәм археографик мирасы – һәрберсе барлана-туплана һәм җентекләп анализлап бәяләнә. Татарстанда Актаныш (2009), Апас (2010), Кукмара (2011), Чүпрәле (2012), Мамадыш (2013), Арча, Әтнә (2016), Минзәлә, Мөслим (2017), Буа (2019), Азнакай (2019, 2021), Баулы һәм Балтач (2022), Ютазы (2023), Бөгелмә (2024) районнарындагы татар авыллары һәм поселокларында шундый кыр тикшеренүләре уза.

Татарстаннан читтә: Түбән Новгород, Курган, Оренбург өлкәләре (2010), Мари илендәге Бәрәңге районы (2011), Удмуртия Республикасы (2012), Пермь краендагы Барда районы һәм Әстерхан өлкәсе (2013), Омск һәм Самара (2014), Оренбург

Алькеевском, Рыбно-Слободском, Мамадышском, Мензелинском, Спасском, Челнинском, Чистопольском районах, собирая при этом материалы по этнографии, фольклору, искусству, историко-культурному наследию данных регионов.

Эта работа не прекращалась даже в годы Великой Отечественной войны. В 1940–1980-е годы широкое распространение получили специализированные экспедиции. В Татарстане и за его пределами, в местах компактного проживания татар, проводились исследования по сбору эпиграфических (Х.В. Юсупов), археографических (С.Г. Вахидов, М.И. Ахметзянов, М.Г. Усманов и др.) памятников, изучению диалектов (Л.Дж. Заляй, Л.Т. Махмутова, Н.Б. Бурганова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова и др.), образцов тюрко-татарского фольклора (Х.Х. Ярмухаметов, И.Н. Надиров, Х.Ш. Махмутов, Л.Ш. Замалетдинов и др.). Собранные в экспедициях материалы легли в основу таких фундаментальных трудов, как «Татарское народное творчество» (1951, 1954), «Татарские народные сказки», в 2-х томах (1946, 1956), «Татарские народные песни» (1965), «Татарское народное творчество», в 12 томах (1976–1988), «Татарские народные говоры», в 2-х томах (2008), «Диалектологический словарь татарского языка» (2009), «Атлас говоров татарского народа», «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) и многочисленных книг по истории культуры и искусства, народных ремесел, истории татарской рукописной и печатной книги и др.

В начале XXI века, благодаря системным усилиям Академии наук Республики Татарстан, эта работа вышла на новый уровень: началась организация комплексных экспедиций в регионы проживания представителей татарского народа. В ходе комплексного изучения собираются, тщательно оцениваются и анализируются все богатства духовной сокровищницы региона: язык, литература, фольклор, искусство, то есть все то, что передавалось из поколения в поколение – образцы устного творчества, праздничные традиции, обрядовая культура, музыка, искусство вышивки, убранство домов, одежда, особенности языка, эпиграфическое и археографическое наследие. В Татарстане подобного рода полевые исследования были проведены

һәм Томск (2015), Чиләбе өлкәләре, Казакъстан Республикасы (2016), Новосибирск өлкәсе, Башкортстан Республикасының Стәрлебаш районы (2017), Ульяновск (2017, 2018), Иркутск, Киров (2018) өлкәләре, Үзбәкстан Республикасы (2019), Төмән (2019, 2020, 2021) һәм Пенза өлкәләрендә (2019, 2021, 2022), Красноярск краенда һәм Чувашстан Республикасы (2022), Кемерово өлкәсе (2023), Мордовия Республикасы (2023, 2024), Бурятия Республикасы һәм Пермь крае (2024) җирләрендә булып, анда яшәүче милләттәшләребезнең тел-сөйләш үзенчәлекләрен, тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен, сәнгатен, кульязма һәм ташъязма мирасын барлау, аларны фәнни эшкәртү, тикшерү эше җайга-системага салына.

Экспедициядә җыйган материалларны тикшерү, өйрәнү, фәнни әйләнешкә кертү белән бергә, шушы вакыттан Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында 1940–2000 елларда шул ук төбәкләргә, авылларга уздырылган экспедиция материалларын барлау, яңа кайткан мәгълүматлар белән чагыштыру башкарыла. Шул җирлектә фәнни хезмәтләр әзерләнә. Әйтик, бүгенге көндә «Татар халык иҗаты» 25 томлыгының 11 томы дөнья күрде.

Элегрәк җыелган һәм яңа гына алып кайтылган материалларны бергә туплау «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә «Милли-мәдәни мирасыбыз» гомуми исеме астында фәнни-популяр китаплар әзерләү эшен башлап җибәрергә этәргеч була. Бу эшнең максаты – халыкның рухи байлыгын үзенә кайтару, аны популярлаштыру, тарихка кертеп калдыру, шушы мәгълүматлар ярдәмендә татар халкының милли үзаңын ныгыту.

Бүген инде бу сериядән 20 дән артык китап дөнья күрде, яңаларын әзерләү дәвам итә. Китапларда экспедиция үткән һәр төбәкнең мәдәни тарихы, танылган нәселләр, авыллар-шәһәрләрнең үткәне, гореф-гадәтләре һәм тел үзенчәлекләре төрле яктан яктыртыла. Шулай ук шәҗәрәләр, җирле кул осталарының эш үрнәкләре, кызыклы экспонатлар турында бай мәгълүмат бирелә.

в деревнях и селах Актанышского (2009), Апастовского (2010), Кукморского (2011), Дрожжановского (2012), Мамадышского (2013), Арского, Атнинского (2016), Мензелинского, Муслюмовского (2017), Буинского (2019), Азнакаевского (2019, 2021), Бавлинского и Балтасинского (2022), Ютазинского (2023), Бугульминского (2024) районов.

За пределами Татарстана также налажена системная работа по сбору, научной обработке, изучению особенностей говоров, повседневного быта, культуры, искусства, рукописного и эпиграфического наследия татар, проживающих в Нижегородской, Курганской, Оренбургской областях (2010), Параньгинском районе Марий Эл (2011), Удмуртской республике (2012), Бардымском районе Пермского края и Астраханской области (2013), Омской и Самарской (2014), Оренбургской и Томской (2015), Челябинской областях и Республике Казахстан (2016), Новосибирской области и Стерлибашевском районе Республики Башкортостан (2017), Ульяновской (2017, 2018), Иркутской и Кировской областях (2018), Республике Узбекистан (2019), Тюменской (2019, 2020, 2021) и Пензенской областях (2019, 2021, 2022), Красноярском крае и Чувашской Республике (2022), Кемеровской области (2023), Республики Мордовия (2023, 2024), Республике Бурятия и Пермском крае (2024).

Наряду с исследованием, изучением и введением в научный оборот материалов, найденных в экспедициях, ведется работа по сопоставлению новых сведений с материалами, которые были собраны в этих местах ранее – в 1940–2000-х годах и хранятся сейчас в архиве ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. На их основе готовятся серьезные научные труды. К слову, на сегодняшний день увидели свет 11 томов 25-томного свода «Татарское народное творчество».

Проведенные исследования на основе объединения всего комплекса собранных материалов позволили начать работу по подготовке научно-популярных книг под общим названием «Национально-культурное наследие» из серии «Из сокровищницы научных экспедиций». Возвращение народу духовного наследия, популяризация и сохранение его в анналах истории

Татар халкының рухи асылын, тарихи-мәдәни сыйфат-билгеләрен бербөтен итеп күзаллау һәм тергезүнең иң нәтиҗәле һәм ышанычлы ысулы булып фәнни экспедицияләр, кыр тикшеренүләре тора. Чөнки бу яшәеш бик борынгыдан килә, татар халкы Евразиянең гаять киң территориясендә формалашкан. Төрле табигый, тарихи, конфессиональ шартларда, төрле этник тирәлектә (төрки халыкларның төрле төркемнәре, фин-угор, славян этнослары янәшәсендә) татарларның этнотерриториаль (Идел-Урал буе, Себер, Әстерхан татарлары), субэтник (Казан, Касыйм татарлары, мишәрләр), субконфессиональ (керәшеннәр, иштәкләр, нагайбәкләр) төркемнәре барлыкка килгән. Бу төркемнәр кая гына яшәвенә карамастан, гомумтатар милли үзаңына ия. Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты уздыра торган экспедиция материаллары нәкъ шул хакта сөйли, һәр сәфәр шушы фикерне куәтли.

Әлбәттә, уртак милли үзаңның нигезен татар теле тәшкил итә. Төрки телләрнең кыпчак төркеменә караган татар теле иң борынгы телләрдән санала. Татар теленең төп лексик, фонетик, грамматик үзенчәлекләре борынгы төрки телдә үк формалаша. Шуңа күрә дә дөньяның төрле кыйтгаларында яшәүче татарларның, төрле сөйләш вәкилләре булсалар да, тел-сөйләмнәре уртак лексик, фонетик, грамматик калыпларга-кануннарга нигезләнә. Шуңа күрә без борынгы рун язулы истәлекләрне укып, эчтәлегенә төшенә алабыз, казакъ, үзбәк, азәрбайҗан һ. б. төрки телләрне дә аңлыйбыз, татар теленең төрле диалектларында да зур аермалар сизмибез.

Татар милли әдәби теле исә XIX–XX гасырлар чигендә Казанда, Уфада, Оренбургта, Троицкида, Әстерханда һ. б. шәһәрләрдә һәм алар тирәсендәге авылларда гомумхалык теле булып оешып җитә. Тукай теле, Туфан теле, Еники теле – барыбыз өчен дә уртак байлык. Татар әдәби теленең үсеше барышында кайбер традицион хасиятләр һәм формалар югала, әмма алар сөйләшләрдә сакланып кала. Димәк, төрле урыннарда компактлы яшәгән татарларның сөйләшләре борынгы уртак

способствует укреплению национального самосознания татарского народа.

На сегодняшний день увидели свет более 20 книг из этой серии, продолжается подготовка новых. В книгах представлены обширные сведения по истории региона, в прошлом известных татарских родов, деревень и городов, а также об обычаях, традициях и языковых особенностях татар. Вместе с тем в книгах дается богатая информация о родословных, работах местных умельцев и других интересных экспонатах.

Единственно надежным и достоверным способом составления общего представления о духовных основах и историко-культурных особенностях татарского народа является организация научных экспедиций и полевых исследований. Это связано с тем, что образ жизни татар формировался с древних времен и на очень обширной территории Евразии. Различные этнотерриториальные (татары Волго-Уральского региона, сибирские, астраханские татары), субэтнические (казанские, касимовские татары, мишары), субконфессиональные (кряшены, иштяки, нагайбаки) группы татар сформировались в разнообразных природных, исторических, конфессиональных условиях и в сложном этническом окружении (рядом с разными группами тюркских народов, финно-угорскими, славянскими этносами). Несмотря на то, что данные группы татар проживают на различных территориях, они все объединены общетатарским национальным самосознанием. Каждая экспедиция ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ и собранные материалы неуклонно подтверждают это.

Разумеется, фундаментом общего национального самосознания является язык. Татарский язык, относящийся к кипчакской группе, считается одним из самых древних языков. Основные лексические, фонетические, грамматические особенности татарского языка сформировались уже в древнетюркском языке. Именно поэтому татар, проживающих в разных местах и являющихся представителями разных говоров, объединяет единая основа – общие лексические, фонетические, грамматические закономерности. Благодаря этому мы можем понять самые древние рунические письмена, понимаем казахский,

телебезнең үзенчәлекләрен югалтмавы белән дә кадерле. Экспедицияләр материалы безгә шул хакта да сөйли.

Татарларның мәҗүси заман ышанулары ислам дине белән бәйле күзаллаулары белән беррәттән бүген дә халык арасында яши. Бигрәк тә безнең халкыбыз тарихында мең еллык урыны булган ислам диненең һәм матди, һәм мәдәни тормышка йогынтысы халыктан җыелган материалларда аермачык күренә. Каберташ язмалары, борынгы китаплар һәм кульязмалар, шәкерт дәфтәрләре, күчереп язылган текстлар, әдәп-әхлак кагыйдәләре, йола-гадәтләр, ышанулар һәм күзаллаулар, бәйрәмнәр һәм ырымнарда татар халкының барлык этник төркемнәре өчен уртак булган мәдәни мирас чагылыш таба. Ислам мәдәнияте гадәти көнкүреш һәм кеше тормышындагы иң мөһим вакыйгаларга (туу, исем кушу, өйләнү, гаилә, бакыйлыкка күчү) бәйле йолаларда этник мәдәнияткә үрелеп китә. Вакытны күрсәткән азан тавышы, намаз-догалар, җомга көнне бәйрәм дип карау белән бергә, татар халкының мәдәни хәтеренә бәетләр, мөнәҗәтләр, дини-суфичыл текстлар кереп урнаша. Традицион йолалар һәм бәйрәмнәр: Сабан туе, Җыен, Корбан гаете, Ураза гаете, өмәләр, Карга боткалары һәм Яңгыр боткалары – болар да уртак байлыгыбыз һәм татарлыгыбызның аерылгысыз билгеләре.

Комплекслы экспедицияләр вакытында төрле җирлекләрдә кием-салым, һөнәрләр, азык-төлек әзерләү рәвеше, архитектура, музыка сәнгате буенча да күзәтүләр ясала. Әйтик, төрле җирләрдә яшәүчеләрнең киемнәрендә үзгәлекләр булса да, татарларның традицион гомуммилли өс киеме Казан татарларыныкы йогынтысында формалашкан дигән фикер безнең материаллар белән дә тагын бер тапкыр раслана. Татарлар кайда гына төпләнмәсен – мәчет торгыза. Халкыбызның һәрчак белемгә омтылышы, балалар тәрбияләүгә зур әһәмият бирүе, олыларга аерым бер хөрмәт белән каравы, туган җир һәм нәсел-ыруның һәр кешене саклаучы-яклаучы көч дип санавы, шигъриятькә-иҗатка тартылуы да кыр тикшеренү нәтиҗәләрендә чагылыш таба.

узбекский, азербайджанский и другие языки, не ощущаем большой разницы между диалектами татарского языка.

Становление татарского литературного языка в качестве общенародного происходит на рубеже XIX–XX веков в городах Казань, Уфа, Оренбург, Троицк, Астрахань и др., а также окружающих их селах. Язык Тукая, язык Туфана, язык Еники – это наше общее богатство. В ходе развития татарского литературного языка теряются некоторые его традиционные свойства и формы, но они сохраняются в говорах. Поэтому говоры татар, компактно проживающих на разных территориях, ценны для нас сохранением особенностей нашего древнего общего языка. Материалы экспедиций говорят именно об этом.

В народе и сегодня продолжают сосуществовать древние домусульманские верования татар и представления, связанные с исламом. Материалы экспедиций особенно ярко демонстрируют влияние ислама на материальную и культурную жизнь нашего народа на протяжении его тысячелетней истории. Общее культурное наследие всех этнических групп татар ярко выражены в надгробных памятниках, древних книгах и рукописях, тетрадях шакирдов, списках литературных произведений, нравственно-этических нормах, обрядах и обычаях, представлениях и поверьях, праздниках и верованиях. В моменты самых важных событий человеческой жизни (рождение, имянаречение, свадьба, семейная жизнь, похороны) традиции исламской культуры тесно переплетаются с обрядами этнической культуры. Наряду со звуками азана, по которым определяли время, с молитвами, с обычаем считать пятницу праздничным днем и т. д. в культурную память татарского народа вошли баиты, мунаджаты, религиозно-суфийские тексты. Наши традиционные обряды и праздники: Сабантуй, Джиен, Курбан байрам, Ураза байрам, коллективные помочи (өмә), обряды вызывания дождя и встречи весны – все это тоже наше общее наследие и то, что делает нас татарами.

Во время комплексных экспедиций в различные места проживания татар изучаются одежда, ремесла, традиции приготовления пищи, архитектура, музыкальное искусство и т. д. Например, наши материалы ещё раз подтвердили мысль о том, что, несмотря на некоторые различия в одежде татар разных

Республикабыздагы күтәрелеш татар дөньясының җанлануына, милли үзаң уянуга, татарларның үзләрен бердәм халык итеп тоя башлавына китерде. Хәтта элек-электән туган җирләре, ватаннары бик еракта – әйтик, Польшада яки Литвада, Әстерханда яки Иранда, Уралда яки Себердә, Кытайда яки Финляндиядә булса да, уртак тарих, уртак мәдәният һәм Казан, Татарстан татарларны берләштереп торган үзәк булып кала.

Һәр милләт булып җитешкән бердәмлек төрле мәдәниятләрнең хасиятләрен үзенә туплый. Бу – аксиома. Көчле мәдәният үз тирәсенә башкаларны тарту сәләтенә ия. Алтын Урда чорында ук «татар казаны» күп кабиләләрне кайната, шул исәптән болгарларны да татар политонимына юнәлдерә.

Татар тарихы сикәлтәле, б. э. к. III гасырдан башлап язма истәлекләрдә эз калдыра. Шул ерак гасырлар чоңгылында Бөек кытай диварыннан төньяктарак төрки телле һуннарның империясе төзелә. II гасырда ул хәзерге Казакъстан далаларына күченә. Идел һәм Урал арасында угорлар белән укмаша, IV гасырда Европага юнәлә, халыкларның Бөек күчешен башлап җибәрә. Һуннарның нәсел тамгасы – казан – безнең башкалабыз Казанның да үзәгендә, Казансу буеннан милләттәшләребезне сәламли.

V гасырда Һун империясе таркала – Бөек кытай диварыннан Дунайга кадәр җирләрдә Бөек Төрки каганлык калкып чыга. Аның җимерелүеннән соң исә Болгар цивилизациясе чәчәк ата. Көнчыгышта куәтле татар халкы үзенең даншөһрәтен яңгырата. Алтын Урда таркалгач, аның варислары ханлыклар төзи. Бүген алар касыйм, әстерхан, себер татарлары, мишәрләр, керәшеннәр, нагайбәкләр һ. б. атамалар белән исемләндереп йөртелгән төркемнәр буларак билгеле. Аларны бер тел, бер югары мәдәният – Мәрҗани фәһеме, Тукай шигырьләре, Сәйдәш музыкасы, Урманче сурәтләре берләштерә.

Татар асылын, аның рухи үзәген, татарлыкның гомуми һәм үзенчәлекле сыйфатларын аңлау-төшенү өчен, һичшиксез, тарихи барышны гына түгел, бәлки халыкның хәтерендә яшәгән

регионов, очевидно, что традиционная национальная татарская одежда сформировалась под влиянием казанских татар. Где бы ни селились татары, они воздвигали мечети. Стремление народа к знаниям и просвещению, большое внимание, которое они уделяют воспитанию детей, особое уважение к пожилым, почитание родной земли и своего рода – как оберегающих и защищающих сил, склонность к поэтическому творчеству – все это отражается в материалах полевых исследований.

Разумеется, современная жизнь татар, где бы они ни жили, связана с Татарстаном. Общественный и духовный подъем в нашей республике способствовал оживлению татарского мира, пробуждению национального самосознания, осознанию татарами себя как единого народа. Даже для татар, чьей родиной давно является Польша или Литва, Астрахань или Иран, Урал или Сибирь, Китай или Финляндия, средоточием общей истории, общей культуры и единым связующим звеном остаются Казань и Татарстан.

Каждая общность, достигшая уровня нации, вбирает в себя свойства различных культур. Это – аксиома. Сильная культура обладает способностью консолидировать вокруг себя другие. В эпоху Золотой Орды в «татарском котле» перекипели многие племена, по той же причине название «булгары» стало татарским политонимом.

Перипетии татарской истории нашли отражение в письменных источниках, начиная с III века до нашей эры. В те далекие времена к северу от Великой китайской стены формируется тюркоязычная империя хуннов. Во II веке они переселяются в степи современного Казахстана. Сплотившись с уграми между Волгой и Уралом, они устремились в Европу, начав процесс Великого переселения народов. Не случайно родовая тамга рода хуннов – казан – сегодня приветствует наших соотечественников на берегу реки Казанки в центре Казани.

В V веке Хуннская империя распадается, и на землях от Великой китайской стены и до Дуная возникает Великий Тюркский каганат. После его распада получает расцвет Булгарская цивилизация. Могучий татарский народ во весь голос заявляет о себе на востоке. После распада Золотой Орды ее наследники

рухи кыйммәтләрне дә барларга, өйрәнергә кирәк. Татарстан Фәннәр академиясе, аның институтлары, шул исәптән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре әлеге юнәлештә эшлиләр. Дөрес, татарлар элек-электән күпләп яшәгән барлык урынчылыклар да өйрәнелгән дияргә иртәрәк әле. Димәк, бу эш дәвам итәргә тиеш.

Фәнни күзлектән караганда, борынгы һәм бай тарихлы, үз әдәби теле, профессиональ әдәбияты һәм сәнгате булган бердәм татар милләте без. XX гасырда татар мәдәнияте, мәгариф һәм фән югары үсеш ала. Бу процесста төрле җирләрдә яшәгән, төрле этнографик төркемнәргә караган татарларның өлеше зур. Безнең көчебез – бердәмлектә!

* * *

Пенза өлкәсе Россия Федерациясенең Европа өлеше көньяк-көнчыгышында, Идел буенда урнашкан. Татарлар Белинский, Вадинск, Городище, Исса, Каменка, Кузнецк, Лопатино, Лунино, Неверкино, Пачелма, Сосновоборск, Спасск һәм Шемышейка районнарында компактлы яшиләр. Милләттәшләребезнең күп өлеше катнаш составлы торак пунктларда тупланган. Өлкәдә татар халкы гомер иткән торак пунктларның саны 50 гә җитә.

Татарларның ата-бабалары элек-электән Идел Болгары һәм Алтын Урда составына кергән Сура елгасы үзәнендә урнашкан Урта Идел Буе төбәгендә яши. Рус дәүләте составына кертелгәннән соң, XVII гасырда чик сызыклары төзелү сәбәпле, Пенза өлкәсе территориясенә Алатырь, Арзамас, Темников шәһәрләреннән йомышлы татарлар актив рәвештә күченә башлый. 1630 елларда алар Югары һәм Түбән Ломов, Керенск (хәзерге Вадинск), 1660–1680 елларда Городище, Мокшан, Пенза ныгытылган пунктларын нигезләүдә катнаша[1].

[1] Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации: справочник / Институт татарской энциклопедии и регионоведения им. Ш. Марджани АН РТ. Казань, 2016. С. 111–113.

создают отдельные ханства. Сегодня их потомки живут как касимовские, астраханские, сибирские татары, мишари, кряшены, нагайбаки и другие группы. Их объединяют общий язык, общая высокая культура – интеллект и разум Марджани, поэзия Тукая, музыка Сайдашева, творения Урманче.

Для понимания сути народа, его духовной сущности, общих и специфических особенностей татарства, безусловно, надо изучать не только историю, но и сохранившиеся в памяти народа духовные ценности. Академия наук Татарстана, ее институты, в том числе ученые ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, работают в данном направлении. Естественно, ещё не все местности и регионы исторического проживания татар охвачены и изучены. Значит, эта работа должна продолжаться.

Если судить с научных позиций, то мы – единая татарская нация с древней и богатой историей, имеющая свой литературный язык, профессиональную литературу и искусство. В XX веке культура, просвещение и наука татарского народа достигли очень высокого уровня. В этом процессе незаменима роль татар, проживающих в разных регионах и представляющих различные этнографические группы. Ведь наша сила – в нашем единстве!

* * *

Пензенская область расположена на юго-востоке европейской части России, в составе Приволжского федерального округа. Татары компактно проживают в Белинском, Вадинском, Городищенском, Иссинском, Каменском, Кузнецком, Лопатинском, Лунинском, Неверкинском, Пачелмском, Сосновоборском, Спасском и Шемышейском районах. Значительное число татар проживает в населенных пунктах со смешанным составом населения. Всего в области около 50 населённых пунктов с татарским населением.

Предки татар издавна населяли Среднее Посурье, входившее в состав Волжской Булгарии и Золотой Орды. После включения в состав Русского  государства, в связи со строительством в XVII в. засечных черт, территорию Пензенской области начали активно заселять служилые татары из гг. Алатырь,

Пенза өлкәсе татарларының мәдәнияте белән галимнәр инде берничә дистә еллар дәвамында кызыксыналар. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Пенза өлкәсенә махсус экспедицияләре XX гасырның 50 нче еллары ахырыннан ук оештырыла.

Төрле елларда (1958–1960, 1964, 1969) татар диалектологлары Л.Т. Мәхмүтова, Ф.С. Баязитова Пенза татарлары сөйләшләрен өйрәнү өчен берничә тапкыр экспедициягә чыгалар. Бу төбәк татарларының тарихы, тормышы һәм көнкүреше, гореф-гадәтләре, тел үзенчәлекләре галимнәрнең күпсанлы фәнни, фәнни-популяр хезмәтләрендә чагылдырыла.

1958 елда танылган фольклорчы Х. Ярми җитәкчелегендә Пенза өлкәсенә фольклор экспедициясе оештырыла. Х. Ярми, Х. Гатина, Э. Касыймов, Ә. Рәшитов, И. Надиров, Р. Кәримов халык иҗаты үрнәкләрен язып алып кайталар, Институт архивын баеталар. Өлкәдә җыелган материалларның бер өлеше татар халык авыз иҗаты әсәрләренең 12 томлык җыелмасында (1976–1988) дөнья күрә. Пенза өлкәсе татарларыннан язып алынган җырларга, мәкаль-әйтем, әкият, бәетләргә әлеге томнарда зур урын бирелә.

XXI гасыр башында (2019, 2021, 2022 елларда) Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Пенза өлкәсендә кабат тикшеренүләр уздырды. Аларның максаты – татар халык авыз иҗаты, язма һәм музыкаль мирас, татар халкының тел үзенчәлекләрен җыю һәм өйрәнү.

2019 елда И.И. Ямалтдинов (экспедиция җитәкчесе, фольклорчы), Л.М. Шкляева (сәнгать белгече), Э.М. Галимова (музыка белгече), М.Р. Булатова (диалектолог), А.И. Әхмәтова (археограф) катнашындагы экспедиция Неверкино районының Али, Кырнавар, Мансур, Биги, Бикмосеевка (Бикбулат), Сарбай, Исәкәй, Җәлил, Мазарлы, Дөмавыл, Кунчерово; Кузнецк районының Бистән, Пәлдәнге, Татар Кынадысы, Ялгаш, Дәхтәрни; Сосновоборск районының Индерка, Әлмәш, Сәләмәс авылларында – барлыгы 19 торак пунктта эшләде.

Арзамас и Темников. В 1630-х гг. они участвовали в основании укреплённых пунктов Верхний и Нижний Ломовы, Керенск (современный Вадинск), в 1660–1680-е гг. – Городища, Мокшана, Пензы[1].

Традиционной культурой пензенских татар ученые интересуются на протяжении нескольких десятков лет. Специализированные экспедиции Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова работали в Пензенской области с конца 50-х гг. XX века.

Для изучения говоров пензенских татар в разные годы (1958–1960, 1964, 1969) татарские ученые-диалектологи Л.Т. Махмутова, Ф.С. Баязитова несколько раз выезжают в экспедиции. История татар Пензенской области, традиции повседневности, обряды, верования, особенности языка – все это нашло отражение в многочисленных научных и научно-популярных трудах татарстанских ученых.

В 1958 году в Пензенскую область была организована фольклорная экспедиция под руководством известного фольклориста Х. Ярми. Члены экспедиций – Х. Гатина, Э. Касимов, А. Рашитов, И. Надиров, Р. Каримов – записали большое количество образцов устного народного творчества татар и существенно пополнили архив Института. Часть этих материалов увидела свет в составе 12-томного собрания произведений татарского устного народного творчества (1976–1988). Песням, пословицам и поговоркам, сказкам, баитам, записанным у татар Пензенской области, в этих томах отведено значительное место.

В начале XXI века (2019, 2021, 2022) Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ были организованы новые экспедиции в Пензенскую область. Целью комплексных экспедиций были сбор и изучение фольклора, письменного, художественного и музыкального наследия, языковых особенностей татарского народа.

Экспедиция 2019 года в составе И.И. Ямалтдинова (руководитель экспедиции, фольклорист), Л.М. Шкляевой (искусствовед),

---

[1] Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации: справочник / АН РТ, Ин-т тат. энцикл. и регионоведения. Казань, 2016. С. 111–113.

2021 елда комплекслы экспедиция составына түбәндәге белгечләр керде: И.И. Ямалтдинов (экспедиция җитәкчесе) һәм Р.Ф. Сафиуллина (фольклорчылар), А.А. Бәдртдинова (диалектолог), Н.Х. Нургаянова (музыка белгече), Г.Н. Зәйниева (археограф), А.Ф. Борһанова (сәнгать белгече), В.М. Усманов (эпиграфика буенча белгеч). Алар 12 торак пунктта тикшеренүләр алып барды: Городище районы Югары Әләзән (Аембура), Урта Әләзән, Түбән Әләзән; Лопатино районының Селәү, Иске Вершаут, Иске Карлыган, Берлек авыллары; Шемышейка районы Оз авылы; Исса районы  Югары Салмука, Каменка (Плетневка), Шеркәвич (Кильмаевка); Лунино районы Шыкша (Синорово) авыллары.

2022 елда И.И. Ямалтдинов (экспедиция җитәкчесе) һәм Р.Ф. Сафиуллина (фольклорчылар), Ә.К. Булатова (тел белгече), Н.Х. Нургаянова (музыка белгече), Ф.Г. Фәйзуллина (археограф), А.Ф. Борһанова (сәнгать белгече), В.М. Усмановтан (эпиграфика буенча белгеч)  торган төркем Каменка районының Кикин (Кикын), Тәләтен, Мачали, Кобылкин, Кочалейка (Ятмис);  Белинский районының Кутеевка (Качкару); Пачелма районының  Решетин, Татар Никольское; Вадинск районының Татар Шуриновкасы (Шуринка), Мучали, Татар Лакасы, Вадинск, Чудовка (Чудилка); Спасск районының Шалдавыч, Белоозерка авылларында эшләде.

Галимнәр кыр тикшеренүләре барышында Пенза өлкәсенең 13 районындагы 50 гә якын торак пунктны өйрәнделәр. Нәтиҗәдә, татар халкының теленә, фольклор, сәнгать, музыка, археография, эпиграфика, шулай ук традицион мәдәниятенә караган материаллар тупланды.

Җыентыкта экспедиция вакытында табылган, шулай ук басылган яисә архив материалларына чагыштырма аспектта анализ ясалган фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләр, халык иҗаты үрнәкләре, Пенза өлкәсе татарлары археографик мирасы тасвирламалары һәм башка документлар урын алды. Алар барысы да – халык авыз иҗатының, теленең, милли сәнгатенең, мәдәниятенең һ. б. тере яшәешен үз күзләре белән күреп, белгеч күзлегеннән бәя биреп язылган мәкаләләр.

Э.М. Галимовой (музыковед), М.Р. Булатовой (диалектолог), А.И. Ахметовой (археограф) провела исследования в 19 населенных пунктах. Изучены села Алеево, Карновар, Мансуровка, Бигеево, Бикмосеевка, Сулеймановка, Исикеево, Джалилово, Октябрьское, Демино, Кунчерово Неверкинского, Бестянка, Татарская Пенделка, Татарский Канадей, Большой Труев, Малый Труев Кузнецкого, Индерка, Альмяшевка, Татарский Сыромяс Сосновоборского районов Пензенской области.

В состав комплексной экспедиции 2021 года вошли 7 специалистов: И.И. Ямалтдинов (руководитель экспедиции) и Р.Ф. Сафиуллина (фольклорист), А.А. Бадртдинова (языковед), Н.Х. Нургаянова (музыковед), Г.Н. Зайнеева (археограф), А.Ф. Бурганова (искусствовед), В.М. Усманов (специалист по эпиграфике). Ими были исследованы 12 населенных пунктов: Верхняя Елюзань, Средняя Елюзань, Нижняя Елюзань Городищенского, Суляевка, Старый Вершаут, Старый Карлыган, Берлик Лопатинского, Усть-Уза Шемышейского, Верхняя Салмовка, Татарская Плетневка, Кильмаевка Иссинского, Синорово Лунинского районов Пензенской области.

В 2022 году И.И. Ямалтдинов (руководитель экспедиции) и Р.Ф. Сафиуллина (фольклористы), А.К. Булатова (языковед), Н.Х. Нургаянова (музыковед), Ф.Г. Файзуллина (археограф), А.Ф. Бурганова (искусствовед), В.М. Усманов (специалист по эпиграфике) провели исследования в 15 населенных пунктах: Кикино, Телятино, Мочалейка, Кобылкино, Кочалейка Каменского, Кутеевка Белинского, Решетино, Татаро-Никольское Пачелмского, Вадинск, Татарская Шуриновка, Мочалейка, Татарская Лака, Чудовка Вадинского, Татарский Шелдаис, Белоозерка Спасского районов Пензенской области.

В ходе полевых исследований ученые исследовали около 50 населенных пунктов в 13 районах Пензенской области. Собранные ими материалы – это образцы фольклора, особенности говоров, произведения искусства, образцы археографического наследия, эпиграфики, а также информация, касающаяся татарской народной традиционной культуры. В сборник вошли научные и научно-популярные статьи, посвященные анализу образцов духовного и материального наследия, собранных во

Шушы төбәктән табып алып кайтылган яңа материаллар, җыентыкта урын алып, нигездә, беренче мәртәбә фәнни әйләнешкә кертелә.

Китап тарихчы галим Р.В. Шәйдуллинның Пенза өлкәсе татарлары тарихына багышланган фәнни мәкаләсе белән ачыла.

Экспедицияләр эшендә актив катнашып, халкыбызның рухи җәүһәрләрен туплауда үзләреннән зур өлеш керткән информантларга һәм әлеге игелекле чараны оештыруда зур ярдәм күрсәткән Пенза өлкәсенең Неверкино, Кузнецк, Сосновоборск, Лопатино, Шемышейка, Городище, Исса, Лунино, Каменка, Белинский, Пачелма, Вадинск, Спасск районнары җитәкчеләренә һәм җирле үзидарә башлыкларына, мәдәният хезмәткәрләренә олуг рәхмәтебезне белдерәбез.

время экспедиций, описания археографического наследия татар Пензенской области, а также архивные материалы и документы, имеющие отношение к теме. Все это – труды, написанные специалистами, которые исследовали устное народное творчество, язык, национальное искусство, культуру, непосредственно контактируя с их носителями. Многие материалы, обнаруженные во время экспедиций, впервые вводятся в научный оборот.

Сборник открывается научной статьей ученого-историка Р.В. Шайдуллина, посвященной истории татар Пензенской области.

Выражаем искреннюю благодарность информантам, которые приняли деятельное участие в экспедиционной работе ученых, а также руководителям Неверкинского, Кузнецкого, Сосновоборского, Лопатинского, Шемышейского, Городищенского, Иссинского, Лунинского, Каменского, Белинского, Пачелмского, Вадинского, Спасского районов области, главам местного самоуправления, работникам культуры за огромную помощь и поддержку в проведении исследовательской работы.

# ПЕНЗЕНСКИЕ ТАТАРЫ: ИСТОРИЯ И СОВРЕМЕННОСТЬ

*Рафаиль Шайдуллин*

Пензенская область – это регион, где на протяжении столетий переплетались история, культуры и судьбы тюрко-татарских, финно-угорских и славянских народов. Колыбелью этнокультуры ее коренных народов являются села и деревни, не просто географические точки на карте региона, а живые свидетельства истории и самобытной культуры их многонационального населения, хранители исторической памяти предков. В области сохранилось множество сельских поселений, где до сих пор живут потомки тех, кто когда-то приехал сюда из других регионов и основал села и деревни, занялся различными формами хозяйственной и социокультурной деятельности.

На землях современной Пензенской области тюркские народы, этническая история которых восходит к периодам Западно-Тюркского и Хазарского каганатов, жили с древнейших времен. Позднее их тюркские и буртасские предки входили в состав Волжской Булгарии. Во времена Золотой Орды татары колонизировали значительную часть современной Пензенской области. Во второй половине XIV века на этих землях возник Улус Мукша, где чеканились монеты, активно развивались различные формы хозяйственно-предпринимательской деятельности. Его правители играли определенную роль во внутриполитической жизни Золотой Орды. Поступательное развитие хозяйственного освоения земель по рекам Сура и Мокша было прервано войнами, начавшимися между золотоордынским ха-

ном Токтамышем и среднеазиатским эмиром Тимуром в конце XIV века. После разорения войсками Тимура места обитания татар пришли в упадок и опустели. Выжившие татары переселились к северу, в более безопасные лесные районы. Эти земли опустели и превратились в «дикое поле», представлявшее собой буферную территорию между русским государством и татарскими ханствами, возникшими после распада Золотой Орды. Фактически эти земли стали местом брани между оседлыми и кочевыми народами, где хозяйничали кочевники и крымские татары, часто совершавшие набеги на русские и мордовские земли. Причиной этому был не только разлад экономических и торговых связей, произошедший после падения Большой Орды, Казанского и Астраханского ханств, но и длительная засуха и голод, эпидемии и массовый падеж скота в Крыму и степных районах Северного Причерноморья. В результате многочисленные отряды кочевников, промышлявшие грабежом пограничных селений, захватом и продажей на невольнических рынках их жителей, сконцентрировались на южных границах русского государства.

Оправившись после страшного Смутного времени начала XVII века, русское государство приступило к укреплению своих южных границ и заселению этих территорий. Наряду со строительством засечных рубежей, из-за сильного обезлюдения приграничья московские правители были вынуждены направить к засечным оборонительным линиям новых переселенцев. Этот процесс затронул и татар, которые с началом строительства пограничных засечных черт на южных рубежах русского государства привлекались для защиты от набегов крымских татар, ногайцев и других народов. Темниковских и другие группы татар начали массово переселять на засечные территории и наделять их землями.

Самое активное участие в освоении Примокшанья и Посурья приняли касимовские князья и мурзы, владевшие помещичьими имениями. На территории Касимовского ханства проживало большое количество татарских помещиков. Так, в Темниковском уезде в 1612 году насчитывалось более 450 помещичьих владений, большинство из которых были

татарскими (примерно, более 80 %). В конце XVII века в этом уезде из 647 помещиков свыше 500 были татарскими мурзами и князьями. По данным 1678 года, среди представителей татарской родовой знати отмечено 57 человек из мурз и князей Еникеевых, 50 – князей Акчуриных, 32 – Девлеткильдеевых, 31 – Кудашевых, 19 – Тенишевых, 18 – Бибарсовых, по 17 – Токшейковых и Тугушевых, 15 – Дашкиных, 7 – Кугушевых, по 5 – Макуловых и Мансыревых, по 4 – Дивеевых, Ишеевых, Кулунчаковых, Шихмаметевых.

Первоначально часть касимовских князей и мурз осела около гг. Кадом, Темников и Шацк, а затем переселилась на юг и юго-восток. Вместе с кадомскими, темниковскими и шацкими татарами осваивали новые земли и другие народы, такие как мордва, русские. В ходе укрепления южных границ на пензенские земли переселились татары и их мурзы из Темникова, Алатыря, Арзамаса, Кадома. В 1630-е годы московское правительство приступило к освоению и заселению территорий около рек Мокша, Инсар, Исса, Ломовка, Нор-Ломовка, Вад и их притоков. Для их хозяйственного освоения были направлены служилые люди, в числе которых находились и татарские князья, мурзы со своими рядовыми соплеменниками.

Заселение служилыми людьми территорий по рекам Ломов и Вад велось по двум направлениям: со стороны Шацка, Темникова и Кадома. В 1635 году были построены города-крепости Нижний и Верхний Ломов, в сторожевых гарнизонах которых были и татары, прибывшие из Темниковского уезда. В 1636 году было основано с. Козляцкий Брод (Козлятское), среди его первопоселенцев числились и темниковские татары. Позже село пополнялось новыми служилыми людьми, в том числе татарами. Напоминанием об обрусевших татарских предках жителей села в наши дни служат фамилии Тамбулатов, Урмашов. В конце 1630-х годов служилые татарские мурзы вместе с русскими и мордовскими служилыми людьми на реке Вад основали такие деревни, как Татарский Шелдаис, Щербаковка, Татарская Шуриновка, Керенский.

В 1646–1649 годы татарские переселенцы участвовали в основании около двух десятков деревень в западной части

современной Пензенской области, среди которых Садакаевка (ныне Судакаевка), а также ими были подселены села и деревни Горенка, Кочетовка, Татарская Лака. Во второй половине XVII века в Примокшанье татарскими мурзами были основаны деревни Мочалейка (1675), Танкаевка (1683) и др. После возведения в 1663 году города-крепости Пенза на одноименной реке, около впадения ее в реку Сура, и возникновения нового крупного Пензенского уезда начался период интенсивного освоения территорий Посурья. В 1681 году было основано с. Средняя Елюзань, которое со временем превратилось в самый крупный татарский населенный пункт в России. Неподалеку от нее появились еще две деревни: Верхняя и Нижняя Елюзань. В 1683 году к устью реки Уза переселили 20 саранских и темниковских татар, которые основали у реки Куля д. Усть-Уза – единственное татарское селение на весь Шемышейский район. В начале XVIII века в Узинском стане Пензенского уезда насчитывалось более 20 татарских и смешанных селений. С той поры существуют современные татарские села Бигеево, Берлик, Джалилово (раньше называлось Погорелый Чирчим), Пакаевка, Старый Вершаут, Старый Карлыган, Суляевка и др.

Одновременно татар заселяли на землях, на которых уже жили мордовские переселенцы. К ним относятся казенные деревни служилых татар, расположенные восточнее реки Кадада и около реки Труев, где обосновались мордовские переселенцы. Позднее они превратились в такие крупные татарские населенные пункты, как Татарский Канадей, Бестянка и Большой Труев (все три – в Кузнецком районе). В 1685 году часть мордовских земель была передана служилым татарам за участие в обороне русского государства от крымского и ногайского ханов. Они основали на реке Пенделка казенную д. Пенделка (ныне с. Татарская Пенделка в Кузнецком районе). На территории современного Сосновоборского района, заселенного преимущественно мордвой, было два татарских села: Индерка и Татарский Сыромяс, в Никольском районе – с. Усть-Инза (ранее Усть-Анза). Согласно легенде, первыми жителями этого села были две татарские семьи, высланные из покоренной Иваном

Грозным Казани, к которым была приставлена для пригляда русская семья.

[1] *4 пот 20 фунт* (4 пуда и 20 фунтов): (4×16,38 кг)+(20×0,4095 кг) = 65,52+8,19 кг = 63,71 кг. Очевидно, на некоторых камнях указывали вес для того, чтобы основываясь на этих данных расчитать стоимость перевозки на то или иное растояние исходя из веса. Например, от Хвалынска до Кобылкино.

некоторых современных «башказык» вырезаны имена и фамилии усопших или инициалы (с. Синорово Лунинского района). Редко на некоторых могилах устанавливают свежеспиленный ивовый прут (кол), верх которого завязывается белым платком (например, на кладбище с. Усть-Уза Шемышейского района).

Многие памятники старины под воздействием отрицательных факторов медленно разрушаются и поэтому есть настоятельная необходимость документирования путем фотофиксации для дальнейшего составления каталогов с целью более детального изучения татарских эпиграфических памятников и истории Пензенской области.

Наши предки оставили богатое культурное наследие, в том числе эпиграфическое, исчезающее с каждым годом по причине отрицательных природных воздействий. Задача ученых выявить, зафиксировать, описать и опубликовать данные об этих памятниках, вводя их в научный оборот и сохраняя для последующих поколений.

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ЯЗМА МИРАСЫ: ЭКСПЕДИЦИЯ КӨНДӘЛЕГЕ ЭЗЛӘРЕННӘН (ПЕНЗА ӨЛКӘСЕ)

*Гөлнара Зәйниева*

Татар халкының изге саналган, әби-бабайларыбыз кадерләп саклаган гарәп графикасындагы китапларны, язмаларны барлау, саклау, туплау җәһәтеннән эзләнүләр алып бару фәндә бик мөһим. Һәр төбәктәге татар авылларын да фән күзлегеннән өйрәнү зарур. Китапның тарихи кыйммәте һәрвакыт зур булды һәм шулай булып кала да. Күп кенә татар йортларында аны кадерләп, яулыкка төреп, иң өске киштәләрдә саклыйлар, кайберәүләр исә, язуын аңламаганга, әби-бабай истәлеге итеп кенә, чүплеккә ташларга гөнаһ санап, чорма, сарай ише урыннарга, сандыкка салып куялар, һәм еш кына иске китаплар дым тартып ята. Археографик табыш булырдай мондый материалларның көннән-көн азая баруы күзәтелә. Беренчедән, тиешле шартларда сакланмау сәбәпле, кәгазь бозыла, уала, ертыла, икенчедән, аларны саклаган кешеләр дә олыгаеп, киләчәк буыннарның аларга мөнәсәбәте нинди булыр? дигән сорау туа, өченчедән, гарәп графикасын танымау аркасында, кирәкмәс саналып, яндырылулары да бар. Ә гомумән алганда, халыкта гарәп язуына хөрмәт зур булган. Гарәп графикалы һәм гарәп телле теләсә нинди басманы Коръән телендә диеп саклаучыларны еш очратабыз.

Татар халкының язма һәм басма чыганакларын барлау, теркәп калдыру максаты белән татарлар яши торган төрле төбәкләргә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать

институты тарафыннан күп еллар инде комплекслы фәнни экспедицияләр оештырыла.

2021 елгы экспедиция вакытында (29 июнь – 8 июль көннәрендә) Пенза өлкәсенең Городище, Лопатино, Шемышейка, Исса, Лунино районнарында эзләнүләр алып барылды. Шул районнарда урнашкан Югары Әләзән, Урта Әләзән, Түбән Әләзән, Селәү, Иске Вершаут, Иске Карлыган, Оз (Усть-Уза), Югары Салмука, Каменка (Плетневка), Ширкәвич (Килмаевка), Шыкша (Синорово) авыллары өйрәнелде.

Һәр авыл үзенең кунакчыллыгы белән аерылып торды. Халыкның олысы-кечесе татар телендә сөйләшә. Бик матур каршы алып, уңай мөнәсәбәтләрен күрсәтеп, ярдәм итеп, информантлар янына алып барып, таныштырып йөргән кешеләргә зур рәхмәтләребезне җиткерәбез.

Археографик табышларга килгәндә, күпчелекне басма китаплар тәшкил итә. Иң еш очрый торганнары, гадәттә, «Коръән», «Коръән тәфсире», «Кыйссас әл-әнбия», «Мөхәммәдия», «Алты бармак», «Исме әгъзам», «Шәраит әл-иман», «Фән тәҗвид», хикәя җыентыклары, грамматика дәреслекләре.

Еллар узган саен мондый археографик табышлар сирәгәя баруны искә алганда, һәр язманы, һәр китапны теркәп калдырырга тырышылды. Пенза өлкәсендәге сәфәребезне көндәлек рәвешендә тәкъдим итәбез.

## 29 июнь, 2021 ел
## Пенза өлкәсе Городище районы Югары Әләзән авылы

Югары Әләзән – Пенза өлкәсенең Городище районына керүче зур татар авылы. Халыкта авылны Аембура (каен бурасы мәгънәсендә дип сөйләделәр) дип йөртәләр. Анда өч мәчет эшләп килә. Авыл халкы арасында, үзләре чын татар булсалар да, русларныкы белән охшаш фамилияләр дә очрый: Медведев (Аюев фамилиясеннән барлыкка килгән дигән фараз бар), Салмин (Салман исеме белән бәйле, яки күрше мордва һәм русларның йогынтысы булган дигән фараз бар), Богданов (Ходайбирдиннан үзгәртелеп), Пономарев, Слашкин һ. б.

Авыл эчендәге бүленеш халык телендә үзенчәлекле чагылыш тапкан: Салма очы (Салминнар яшәгән өлеше), Бәлчек очы (ул якта карьер булу белән бәйле), Каһәр очы (бик уңган булдыклы кешеләр яши, кулларында «ут яна» торганнар), Зәрәт очы (зират булганга), Рогатка очы (ул җирдә икегә аерылып китә торган урын), Мунчали очы.

Үзенчәлекле диалекталь сүзләр кулланып, үзләренә генә хас мишәр диалектында аралашалар: *игәч* – апам, *карточкага сук* – фотога төшер, *бак* – кара, *орлык яру* – көнбагыш ашау, *ястык* – мендәр, *эстул* – урындык, *дәлбегә* – дилбегә һ. б.

Үзәк мәчет имамы Фидаил хәзрәт әйтүе буенча, халык үзендә булган күпчелек кулъязма китапларны мәчеткә тапшырган, бер өлеше исә 1950–1965 елларда әлеге төбәккә оештырылган экспедицияләр вакытында таралган.

*Ишмаева Нурзилә Аббяс кызы (1974 елгы)* Пенза педучилищесын һәм Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган, хәзерге вакытта Үзәк мәчеттә балалар һәм олыларны гарәп теленә, Коръән уку кагыйдәләренә өйрәтә.

Ул сөйләгәннәрдән: *Авыл тарихында Үзәк мәчет һәрвакыт эшләгән. Әләзән авыллары арасында хәзерге вакытта кушаматлар йөри: Югары Әләзән халкы – сибиряклар. Иван Грозный Себергә таба китеп, үз сәясәтен уздырганда, чукындырудан качып, Төмән өлкәсеннән берничә гаилә күчеп китә. Ике ел дәвамында юлда булганнар. Шушы җирлектә урнашалар, һәм шуңа аларны шулай атап йөртәләр дә. Беренче кешеләре – Әлмин исемле булган.*

Үзенең кулъязма дәфтәрләре бар, шулардан авыл хакында язмасы бар:

*Каенбура – Аембура.*

*Безнең авыл Аембура дип атала. Ләкин элек безнең авыл урынында каен урманы булган. Кешеләр үзләренең өйләрен каеннан бураганнар диеп картлар әйтә иде. Шуннан ул Каенбура дип әйтелгән. Безнең авылда күбесе руслар булган. Безнең авылга килгән Кырым татары Ильмеев Әлмин авылны төзи башлаган, күп русларны авылдан куган. Безнең авылда ул казышкан Әлмин кизләве хәзер дә бар.*

*Безнең авыл Каенбура*
*Бик күптәннән төзелгән,*
*Хәзер инде кем дә белми*
*Кемнәр аны төзегән.*
*Безнең авыл зур булмаган,*
*Әүвәлдән бик кечкенә,*
*Эчә торган суы булган*
*Кечкенә инеш кенә.*
*Аны төзәтеп торучы*
*Ильмеев Әлмин булган,*
*Аның исемен биләгән*
*Әлмин кизләве калган.*
*Хәзер инде авыл үсте,*
*Зур-зур биналар булды,*
*Биналарның эчендә*
*Матур җиһазлар булды.*
*Мәктәбебез – урта мәктәп,*
*Авыл уртасында мәчет,*
*Күпдин-күп кибетләребез*
*Һәрчак ачык торалар.*
*Һәрбер өйдә телевизор,*
*Кер юу машинасы.*
*Хәзер киемнәр киндер түгел,*
*Матур киемнәр кия,*
*Матур киемнәр кигәндә*
*Йә Рабби, шөкер, дия.*
*Бу тормышка риза булып,*
*Аллага шөкер диик,*
*Иртә-кичләр намаз укып*
*Аллага зикер кылып.*
*Тәсбих тартыйк, намаз укыйк,*
*Көннәребез буш узмасын,*
*Ходай каршына барганда,*
*Дәфтәребез буш булмасын.*
*Киләчәк көнебездә дә*
*Тормышыбыз яхшы булсын,*
*Раббым, үзе рәхим кылсын,*
*Өебез нур белән тулсын.*

Нурзилә Ишмаева ике кулъязма китапны Язма мирас үзәгенә тапшырды. Сакланышлары бик начар, китапларның уң кырые ут беләнме, су беләнме бозылган. Икесе дә гарәп телендә, тышлыксыз, дини эчтәлекле. Коръән тәфсирләре дип фаразлап була. Ишмаева Нурзилә ханымга бу китаплар каенанасыннан калган.

*Медведев Кязым Насыбулла улы (1952 елгы)* – хәзрәт, «Нур» мәчете имамы. Язма мирас үзәгенә ул өч язма тапшырды. Барлык китаплары да хатынының бабасы Ахунов Әхмәдсафа Латыйф улыннан калган (1899–1983, шушы авылда хәзрәт вазифасын башкарган). Өйләрендә төрки-татар әдәбиятында дини-суфичыл эчтәлекле ядкәр – Рабгузиның «Кыйссас әләнбия» (1310, «Пәйгамбәрләр тарихы») әсәренең Казанда 1908 елда нәшер ителгән 2 нче басмасы саклана. Институт мирасханәсенә түбәндәге язмаларны тәкъдим итте:

• Кулъязма, башы-ахыры юк, берничә бит, дини эчтәлекле, сакланышы бик начар.

• Басма китап, берничә бит, башы-ахыры юк, дини эчтәлекле.

• Халык авыз иҗатына караган кульязма. Дәфтәр битенә язылган «Ана бәете», авторы, елы күрсәтелмәгән.

*Ана бәете*

*Аналар үрә тормый, вакытсыз кермиләр гүргә,*
*Бу ни гаҗәб, бу ни хикмәт, ананы сөймиләр бер дә,*
*Анага бала бит татлы, тугачдан тәнләрен пакьли,*
*Бу ни гаҗәб, бу ни хикмәт, ана күңелен бала табмый.*
*Балакаем, ике күзем, караб туймыйм синең йөзең,*
*Бу ни гаҗәб, бу ни хикмәт, бирче алган минем сүзем,*
*Тугыз ай карынымда йөретдем, тугачтан ак сөтем бирдем,*
*Балаларымны асраган соң рәхәт көнләр күрем, дидем,*
*Балаларым үсеб йиткәч, күтәргесез михнәт күрдем.*
*Бу ни гаҗәб, бу ни хикмәт, күтәргесез михнәт күрдем.*
*Бишекләрен тирбәткәндә тала минем беләккәем,*
*Бу ни гаҗәб, бу ни хикмәт, әрни дуслар йөрәккәем,*
*Торыб чыгам тышка, серемне сөйләмимен,*
*Уйлыймын да хәйран калам – гомерләрем үткән бушка.*
*Аллаһы белә дә, үзем беләм мине кимсеткәнләреңне,*
*Киленкәем, үзең дә күр миңа күрсәткәнләреңне,*
*Киленкәемдән ишеткән сүзләрне төенләб куйдым орлыкка,*
*Балаларың үсеб йиткәч, син дә төшәрсең хурлыкка.*
*Иртә торыб, тышка чыкдым – хөкүмәт бума будыра,*
*Бу ни гаҗәб, бу ни хикмәт, өемдән кудыра,*
*Балаларымны асраганда тәмле тәгамтәләр[1] капмадым,*
*Анай бик күб ашый диб, орсана тамагымны,*
*Анай юкда ашарбыз диб, җыеб куя арзыкны[2],*
*Җыйсалар җыйсынлар арзыкны, аларга да килер бу көн.*
*Ризыкларын җыйган чакда исләренә төшәр әле,*
*Улым ишек ачыб кергәч, акаеб карый күземә,*
*Бу ни гаҗәб, бу ни хикмәт, күренмә, дия, күземә.*
*Иртә торыб, тышка чыкдым, кояшы нурындан бага алмыйм,*
*Бу ни гаҗәб, бу ни хикмәт, бер кабым икмәк таба алмыйм.*

[1] Тәгам – ашамлык.
[2] Арзыкны – ризыкны.

*Улым, ачларын күреб, балам, сине китердем мин,*
*Авыр фәкыйрь вакытларда, балам, сине үстердем мин,*
*Суыкларда туңмасын диб, өстегезгә чара итдем,*
*Балам ачка үлмәсен диб, ризыкларын таба идем,*
*Авыр сырхау вакытларда хәлемне сорамады бер дә,*
*Бала бәгъре каты икән, бәхиллек бирмәде бер дә,*
*Бала дидем, бала дидем, башымдан акылым китде,*
*Баланың шәфкатьсезлеге анага катылык итде.*
*Тәмам.*

*Жаркова Сафура Али кызы (1945 елгы)* Урта Әләзәндә туып, Югары Әләзәнгә кияүгә чыккан, өч елдан соң тол калып, ике баласын каенанасы белән тәрбияләп үстергән. Аның сөйләвенчә, каенанасы Жаркова Әсма Әбүшаһман кызы (1908–2002) укымышлы булган. Сафура апа аннан калган кулъязма дәфтәрләрен хәзерге көнгә кадәр кадерләп саклый. Үзе кулдан күчереп язганнар арасында түбәндәгеләр барланды: мөнәҗәтләр, Мигъраҗ кичәсендә намаз-ураза фарыз булу, Мигъраҗга иман китерү, салават, һавадан аваз ишетелү, Хуҗа Бәһаветдин теләк кәрамәтләре, Хәсән вә Хөсәен разый Аллаһу ганһу, Коръән багышлау догасы. Бик пөхтә, матур язу белән күчергән, гарәп телен белүе ачык сизелә. Басма китаплар арасында: «Ислам дине нигезләре», «Кырык хәдис», «Рәднамә» (Казан: Типография В.Л. Домбровского,1908), «Исме әгъзам», «Шәраит әл-иман» (Казан: Типография Бр. Каримовых, 1914), «Дәва китабы».

«Дәва китабы» Мирасханәгә тапшырылды: басма китап, башы-ахыры юк, сакланышы яхшы. Китап түбәндәге баббүлекләргә бүленгән: *Кул агырган*[1] *өчен; Сул колак өчен; Кендек өчен; Бизгәктән; Тамак шешкәнгә; Кара сары догасы; Уң ян – сул ян өчен; Уң тез – сул тез өчен; Уң аяк – сул аяк өчен; Арка авыруы өчен.*

*Исляев Рифат Искәндәр улында (1948 елгы)* әтисеннән калган гарәп графикасындагы язмалар һәм китаплар саклана. Кулдан язылганнар арасында – «Васыятьнамә» (дидактик

[1] Агырган – авырган.

характерда), төрле догалар, Коръән багышлау догасы. Басма китаплар да бик кадерле сакланышта: «Фән тәҗвид» (Казан: Электро-типография «Мааариф»), 1915; «Исме әгъзам» (Казан: Типография Бр. Каримовых, 1909), «Грамматика китабы», «Ислам нигезләре», «Әдәбият мәҗмугасы» сериясеннән «Чиркәс кызы» хикәясе (мөхәррире Лермонтов, мөтәрҗиме Г. Кәрам. Казан: Типография Бр. Каримовых, 1907).

*Ханбекова Хәдичә Хәмзә кызы (1936–2021)* әтисе Ханбеков Хәмзә Айнулла улының 1932 елгы кулъязма Коръәне булганлыгы хакында сөйләде. Кызы аны кадерләп саклап, оныгы Слашкина Дамира Моталләб кызына тапшырган.

*Агишева Нясиха Искәндәр кызында (1937 елгы)* әнисеннән калган дәва, өшкерү догалары, Коръән аятьләре күчереп язылган дәфтәрләр саклана, каллиграфиясе матур, гарәп телен белгәнлеге язуларыннан сизелә.

## 30 июнь – 1 июль, 2021 ел
## Пенза өлкәсе Городище районы Урта Әләзән авылы

Урта Әләзән Россиядә иң зур татар авылларыннан санала. Авылда мәчетләр беркайчан да ябылып тормаган, хәзерге вакытта да унике мәчет эшләп килә. Халкының бик тә дини булуы күзгә бәрелеп тора: хатын-кызлары яшьтән үк яулык япкан, олы кешеләргә хөрмәт нык сизелә, каената-каенана белән яшәү һәр гаиләдә диярлек күзәтелә. Халыкта кулдан күчереп язылган сүрәләр, догалар саклана. Гадәттә алар дәфтәрдә, аерым кәгазьдә язылган.

Сөйләшү барышында диалекталь сүзләргә игътибар иттек. Мәсәлән: *касталанды* – авырды, *өмер буе* – гомер буе, *давыт* – әйе бит (рус. да ведь), *да мы* – әйеме, *аңгарам* – аңлыйм, *мәтәм* – мин әйтәм, *атям бит* – әйтәм бит, *чорналган* – яулык япкан, *әт* – әйт, *тенә* – кичә, *ару* – чиста, *эструка* –төзелеш (рус. стройка), *тиха гына* – әкрен генә, *здрук* – кискен рәвештә (рус. вдруг), *ызба* – өй, *эрәну* – өйрәнү, *тегел* – түгел, *өстәл кругы* – өстәл тирәли, *онукам* – внук, *игәч* – апа, *квас* – элек туйларда куелган эчемлек, *сәнкә* – чана (рус. санки), *вожҗа* – вожжи. Күрүебезчә, рус алынмаларының татарчалаштырылган вариантлары шактый.

Халык Урта Әләзән авылын да берничә очка бүлеп йөрткән: Гурдо очы (Гурдин фамилиялеләр күп яшәгәннәр), Каш очы (биек җирлектә урнашуы аркасында), Куринка очы (утрау сыман булганга), Сыяу очы (чабата ясаучылар яшәгән, сыяу – чабата үрү коралы, шөшле), Тугай очы, Курмыш очы (уртада, төптәрәк урнашканга) һ. б.

Авылда гаиләләрне кушамат белән атау гадәте сакланган. Әйтик, Куян, Козгын, Бүре һ. б.

Халык арасында Урта Әләзән – Әләзән, Югары Әләзән – Аембура, Түбән Әләзән – Иске Әләзән дип тә йөртелә.

*Бикмаев Әбүбәкер Али улы (1946 елгы)* тумышы белән Урта Әләзән авылыннан, дини гыйлем эстәү теләге белән Бохарага китеп, анда җиде ел Мир араб мәдрәсәсендә белем ала, биредә дин һәм җәмәгать эшлеклесе Тәлгать Таҗетдин белән бергә укый. Хәзер дә тыгыз элемтәдә торулары хакында горурланып сөйләде. Әбүбәкер хәзрәтнең шәкертләре дә Россиянең төрле өлкәләрендә урнашкан мәчетләрдә эшлиләр. Пенза өлкәсендә мәчетләр төзетү, устав, мөһер эшләтү, рәсми рәвештә теркәү кебек эшләрен байтак гамәлләр башкарган шәхес буларак билгеле. Бөтен эшләрендә хатыны Бикмаева Рәйсә Имам кызы, балалары Әюб, Аббас, Илһам, Ислям, Василянең ярдәм итүен ассызыклап әйтте. Әбүбәкер хәзрәтнең бик бай китапханәсе бар, аның күп өлешен гарәп, фарсы телендәге хезмәтләр тәшкил итә. Балалары барысы да дини белемле. Китапка зур хөрмәт белән карый. 100–200 еллык китаплары да бар, «Китап хезмәт итәргә тиеш», «Бар китапханәмне балаларыма тапшырам», ди. Әтисеннән калган кулъязма Коръәнне аеруча кадерләп саклый. Хәзерге вакытта Коръән тәфсире яза. Хәдис-тәфсир хакында бик акыллы фикерләр җиткерде.

Китапханәсенең бер өлеше белән без дә таныштык:

• Мөхәммәд Чәләби. Мөхәммәдия китабы. Басма китап, 1878.

• Галәмә әл-кари әл-фәвахәрат». Басма китап, татар телендә.

• Коръән Кәрим. Казан басмасы, 1882.

• Әхмәд Биҗан. Әнвар әл-гашикыйн. Казан: Типография Бр. Каримовых, 1913. Гарәп телендәге бу китап – дөнья барлыкка килү тарихы турында.

• Амали тәрҗемәсе. Казан: Типография Бр. Каримовых, 1903.

• Китаб әл-мизан әл-көбра (Үлчәмнең иң югары ноктасы). Басма китап, һиҗри белән 1306 елда.

• Рәһбәр сыйбьян (беренче сыйныф шәкертләренә әлифба бәгъдендә укытылсын өчен тәртиб иделде). Казан: Типо-литография Императорского университета, 1904. Басма китап, гарәп графикасында, татар телендә.

• Мөгаллим әл-гыйбадәт. Казан: Типо-литография Императорского университета, 1905. Басма китап, гарәп графикасында, татар телендә.

• Гакаиде төркия (ибтидаи дүртенче сыйныф яки рөшдия беренче сыйныфлар өчен). Казан: Типо-литография Императорского университета, 1906. Басма китап, гарәп графикасында, татар телендә.

*Тугушев Искәндәр Фәттах улы (1937 елгы)* әнисе Тугушева Халидә Сөләйман кызыннан (1912–1989) калган китапларны кадерләп саклый.

• Коръән. Казан басмасы.

• Ислам нигезләре. Сакланышы – фрагментар характерда. Басма китап, гарәп графикасында, татар телендә.

• Хәдисләр китабы. Басма китап, гарәп графикасында, татар телендә.

*Бикмаев Мияссәр Сөләйман улы (1938 елгы)* хәзерге вакытта уникенче мәчеттә имам вазифасын башкара. Өч улы да дини белемле. Бикмаев Фидаил Мияссәр улы (1976) – Төркиядә белем алып, хәзерге вакытта Югары Әләзәндә имам булып тора. Мияссәр хәзрәтнең бабасы Умәр Зиннур улы гарәп телен яхшы белгән, укымышлылардан саналган. Өендә бик бай китапханәсе бар. Кайбер китапларын атап китик:

• Мөхәммәд Чәләби. Мөхәммәдия. Казан, 1905. Төрек дини-шигъри әдәбияты ядкәре. Китап ике өлештән тора: беренче өлешендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышы, икенчесендә Кыямәт көне, аның алдыннан буласы вакыйгалар, ахирәт тормышы һ. б. тасвирлы итеп сурәтләнә. Китап татарлар арасында киң таралган; кадими мәдрәсәләрдә дәреслек итеп файдаланылган, гарәп графикасында. 1845 елдан Казанда берничә тапкыр нәшер ителгән.

• Насретдин Рабгузи. Кыйссас әл-әнбия (Пәйгамбәрләр турында кыйссалар). Төрки язма әдәбият ядкәре (1310–1311). Әсәр шул чордагы «пәйгамбәрләр турында риваятьләр» жанрында иҗат ителгән. 1859 елдан Казанда берничә тапкыр нәшер ителгән.

• Коръән тәфсире.

• Җамиг әр-рөмуз. Фикъһ китабы. Басма китап, гарәп телендә.

• Шәрхе әл-фәраиз әс-Сираҗия, 1885. Басма китап, гарәп телендә.

• Кавагыйд әл-әгъраб (Әл-гавамил әл-маэи). Казан: Типография Бр. Каримовых, 1905. Гарәп графикасында, татар телендә.

• Коръән. Казан басмасы. Һиҗри белән 1238 елгы. Мияссәр хәзрәтнең бабасы кызына бүләк итеп калдырган (бабасы – Бикмаев Умәр Зиннур улы, кызы – Бикмаева Мөстәзә Умәр кызы).

*Курмашева Фатыма Каюм кызының (1939 елгы)* ире Курмашев Тәминдар Бәкяр улы (1935–2000) мәчеттә имам булып, иртәнге намаз вакытында кинәт вафат була. Китап укырга яраткан. Яшьлекләрендә китаплар аз булу сәбәпле, чиратлап укыганнар. *«“Кыйссас әл-әнбия” китабы кулыма эләккәч, шатлыгымнан нишләргә белмәдем, күкрәгемә кысып кына алып кайтып, берничә кат укып чыктым»,* – дип искә ала. Гарәпчә укырга, тәҗвидне башта үзлектән, аннары Әбүбәкер хәзрәттән өйрәнгән. Бөтен балалары да дин юлында булулары белән горурлана.

Әңгәмә вакытында Фатыма апа шундый йола турында сөйләде: кемнең баласы булмаса, «су кичеп, ызба куйгач, балагыз булыр» дигәннәр, ягъни суның, елганың ары ягына чыгып, яңа йорт төзеп яши башларга кирәклеген аңлата.

## 2 июль, 2021 ел
## Пенза өлкәсе Городище районы Түбән Әләзән авылы

Авылда кушаматлар киң таралган. Мәсәлән: Ишүк (бабалары Ишмөхәммәд булган), Кучат (эшче нәсел), Хайраннар (булдыклы, оста нәсел), Алмакайлар (Алмакаев фамилиялеләр) һ. б.

Авыл өч очка бүленгән: Татар очы, Рус очы, Мукшы очы. Элек-электән өч милләт вәкилләре бик дус, тату яшәп киләләр.

Катнаш гаиләләр күп. Рус һәм мукшы балалары да татар балалары белән бергә мәктәптә татар телен өйрәнәләр, татарча аралашалар. Тагын шунысы сизелә: халык бөтиләргә нык ышана, мендәр астына куелган дога китаплары (хәтта әбибабаларыннан калганнары да) саклана. Аларның өчпочмак, турыпочмак рәвешендәгеләре дә очрый. Сөйләшләрендә диалекталь формаларга игътибар ителде. Мәсәлән: *сувыта* – суыта, *тудыка* – икетуган абый / сеңел (рус. двоюродный брат / сестра), *түтеш* (түти) – апа, *җенкай* (җанкай) – карт килен, *вата шунда* – вот шунда, *каста* – хаста, *ишкән* – ишеткән, *пясүк* – сахарный песок, *бусә* – бусинка, *тетелде* – сүтелде, *пугрәп* – баз өсте, *шома гына* – тиз генә.

Мәктәптәге «Туган якны өйрәнү музее» бик тә бай. Анда «Сельский вестник» газетасының 1917 елдагы 7, 8 октябрь саннары, «Русское слово» газетасының 1912 елдагы 31 октябрь саны, 1916 елдагы 3 апрель, 4 июль саннары саклана. Шулай ук «Правда» газетасының 1945 елда Бөек Ватан сугышы тәмамлану һәм Җиңү көне уңаеннан чыккан 10 май саны да бар.

*Давыдова (Бахтеева) Октябрина Шиһап кызының* өендә каенатасы *Давыдов Ихсян Хасян улының (1898–1967)* кулдан язган язмалары («Гыйльме хәл»), Казанда 1895 елда нәшер ителгән «Әл-мохтасар әш-шафи» китабы саклана. Алар яшәгән йорт азанчы йорты булган, 81 ел элек төзелгән.

*Бармакова Накия Ибраһим кызы (1946 елгы)* сөйләвенчә, әтисе *Бармаков Ибраһим Кәлимулла улы (1918–2004)* тарих укытучысы булган, аннан күпсанлы китаплар калган:

• Тарих мөкаддәс бүләге (Пәйгамбәрләр тарихы). Башы, ахыры юк. Казанда басылган. Китап түбәндәге бүлекләргә бүленгән: *Дөнья яратылу, Адәм белән Хәүва, Адәм пәйгамбәр вә балалары, Пәйгамбәрнең гаиләсе, Пәйгамбәрнең вафаты.*

• Ана теле сарыфы. Беренче басма. Нашире: Корылтай ширкәте. Казан: Электро-типография «Милләт», 1918.

• Намаз уку кагыйдәләре. Башы, ахыры юк. Казанда басылган. Эчтәлеге: *Намазның ваҗиблары, Намаз бозгучы эшләр, Азан бу рәвештә укылыр, Азан догасы, Намазның сөннәтләре, Җәмәгать намазы, Тәравих намазы, Мохтасәр вә җеназа намазы, Мосафир намазы, Зәгыйфь кешенең намазы.*

• Нәмүнәи әхляк (Әхляк үрнәкләре). Казан: Электро-типография «Үрнәк», 1910.

Китапның эчтәлеге әхлак буенча 32 дәресне үз эченә алган: *Китаб вә сөннәткә иярмәк; Игътикад бәяны; Гомер-вакыт; Юмартлык вә саранлык; Исламият-мөселманлык; Әмер бил-мәгъруф; Нәһи ган әл-Мөнкир; Хәлем-шәфкатьле булмак; Дин вә шәригать эшләрендә таҗә булмак; Алладан курыкмак; Нәзафәт-пакьлек; Бидгать бәянында; Хөсед бәянында; Шомланмак бәянында; Рия бәянында; Исраф бәянында; Гайбәт бәянында; Яман гөман*[1] *бәянында; Алланы сөю; Пәйгамбәрләрне сөймәк; Ата-анага ихтирам; Мөгаллим вә кардәшләргә ихтирам; Күршеләрне вә дустларны сөю вә ихтирам итмәк; Өлеләмер*[2] *итагать; Туган-үскән йирне сөю; Әманәт бәянында; Хәяэ*[3]*-оятлы булмак бәянында; Дин вә шәригать бәянында; Хайваннарга шәфкать бәянында; Мал һәм аны сарыф кылмак; Күркәм холык бәянында; Сөйләшмәк әдәбе.*

• Тыйб китабы (гавамларга ангарырлык лисанында[4]). Казан: Типо-литография Бр. Каримовых, 1905.

Китапның эчтәлеге:

Тәрәккеб бәдәни инсан[5]: *Башдагы ми; Йөрәк; Үпкә рия; Хасталарны, сырхауларны тәрбия тарикы; Хасталарны ашату-эчерү (питание); Тамыр тибүне белү кәйфияте; Имрад сария ягъни йогышлы сырхауларны бәяны; Аркылы бака тамак сырхавы – дифтерит; Бумалы йөткерек зәхмәте, русча коклюш; Бума йөткереге зәхмәте дәва вә гыйлаҗ тарикы; Кызамык зәхмәте, русча корь; Кызамык сырхавыннан дәва гыйлаҗ тарикы; Чәчәк зәхмәте, русча оспа; Кире кайту тир зәхмәте, русча возвратный тиф; Тир зәхмәтеннән дәва вә гыйлаҗ; Кызылча зәхмәте, русча скарлатина; Кызылча зәхмәте – скарлатиннан дәва вә гыйлаҗ тарикы; Йөзгә кызыл тап зоһуры – рожа; Рожа маризыннан дәва вә гыйлаҗ тарикы; Йиңел кызылча, русча краснуха; Ваба зәхмәте, русча холера; Күзен*

---

[1] Гөман – уй, фикер.

[2] Өлеләмер – әмер ияләре, зур түрәләр.

[3] Хәяэ – оят, оятлылык.

[4] Гавамларга ангарырлык лисанында – кешеләргә аңлаешлы телдә.

[5] Тәрәккеб бәдәни инсан – кеше гәүдәсе җыелмасы.

*чаралары; Ваба белән вафат булган кешеләрне дәфен кылу; Канлы эч боруы, русча кровавый понос; Бу сырхаудан дәва вә гыйлаҗ кылу тарикы; Бизгәк зәхмәте, русча лихорадка; Күкрәк ютәле зәхмәте, русча чахотка.*

Китапта титул битендә түбәндәге язма бар:

*«Татар мөселманнары өчен рус лөгатенчә*[1] *мәдрәсә мөгаллимин гаидендә мәктәпнең мөгаллим һәм мәншурлы имам мулла Фәсыйхетдин ибне мулла Мохитдин Алапакы».*

*«Бу рисалә шәһәр Казанның вилаятендә губерна өчен улан маризханәнең*[2] *рәисе табиб Хасадов вә профессор булдылар. Иганәсе илән тәхрир кылынып һәм табиб Хасадов, профессорлар Разумовский, Гуднев, Домбров вә Рожанскийның назирлары илән тәфтиш*[3] *вә тасхих*[4] *кылынды.»*

Тыйб китабыннан шул чорда киң таралган авырулар, авыру атамаларының татарча һәм русча бирелеше, дәвалары хакында тарихи яктан кыйммәтле мәгълүмат алып була. Шул замандагы атаклы профессорларның исемнәре дә телгә алына.

• Татарча уку китабы. Икенче җөзьә. Басма китап, башыахыры юк, гарәп графикасында, татар телендә.

Мәктәп яшендәге балалар өчен хикәятләр, шигырьләр мәҗмугасы. Барлыгы 117 әсәр кертелгән. Мәсәлән, «Кояшның нурлары», «Эшчән аю», «Эшләп тапкан акча», «Язгы эш», «Бакчачы белән угыллары», «Туган авылны сагыну», «Туган йиргә» (шигырь) һ. б.

• Кисекбаш китабы. Казан: Типография Б.Л. Домбровского, 1897.

Авторы билгесез, 270 шигъри юллы әсәр. Поэманың сюжеты әкияти-маҗаралы: Мөхәммәд пәйгамбәргә киселгән кеше башы, ярдәм сорап, үтенеч белән мөрәҗәгать итә. Ул аңа Диюнең шәһәрне җимерүе, улын йотуы, чибәр хатынын урлавы, ә үзен Кисекбашка әверелдерүе турында сөйли. Мөхәммәд пәйгамбәр кушуы буенча, аның тугрылыклы сәхабәсе Гали Дию биләмәсенә бара һәм әсирләрне коткара. Нәтиҗәдә, явыз-

---

[1] Лөгатенчә – тел белән.
[2] Маризханәнең – сырхауханәнең.
[3] Тәфтиш –тикшерү, эзләү.
[4] Тасхих – төзәтү, редакцияләү.

лык җиңелә, гаделлек җиңә. 1846 елдан поэма, күп тапкырлар нәшер ителеп, Идел-Урал төрки халыклары арасында киң таралган, мәдрәсәләрдә өйрәнелгән.

• Хәдисләр җыентыгы. Басма китап, башы-ахыры юк.

• Балаларга әхляк дәресләре. Басма китап, башы-ахыры юк, гарәп графикасында, татар телендә, дидактик характерда.

• Астрономия китабы. Басма китап, рәсемнәр белән, гарәп графикасында, татар телендә. Бары 4 бите сакланган.

• Коръән. Казан басмасы. Башы-ахыры юк.

• С. Бикбулат. Дин дәресләре. Дүртенче җөзьә. Тарихе мокаддәс, сияреннәби[1] вә гыйбадәт. Өченче мәртәбә басылуы. Нашире: «Сабах» ширкәте. Казан, 1918.

*Карькаева Җәмилә Кәрим кызы (1961 елгы)* каенанасы Бармакова Наимә Кәлимулла кызыннан (1916–2004) калган китапларны саклый:

• Гыйльме хәл. 5 нче мөгамәлят кыйсеме. Рөшди[2] сыйныфлар өчен. Басма китап, башы юк, гарәп графикасында, татар телендә.

• Ана теле сарыфы. Басма китап, башы юк, гарәп графикасында, татар телендә.

• Синтаксис китабы. Басма китап, башы-ахыры юк, гарәп графикасында, татар телендә.

• Коръән багышлау догалары. Басма китап, башы-ахыры юк, гарәп телендә.

• Гарәп әлифбасы. Гавам[3] мәктәбе өчен. (Татар әлифбасы тәмамында балаларны кыйраәт гарәбигә[4] вә Коръән укырга төшендермәк йиңел ысулда тәртип ителде.) Бишенче басма. Казан: Типография Бр. Каримовых, 1917.

• Шәраит әл-иман. Казан, 1901. Басма китап. 1917 елга кадәр мәдрәсәләрдә кулланылган иң беренче дәреслек.

• Татарча уку мәҗмугасы. Басма китап, башы-ахыры юк, гарәп графикасында, татар телендә. Хикәятләр җыентыгы.

---

[1] Сияреннәби – Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) холыклары, гадәтләре, тормышы турында язылган китап.

[2] Рөшди – башлангычтан югары (урта) мәктәп.

[3] Гавам – халык.

[4] Кыйраәт гарәбигә – гарәпчә укуга.

• Балалар өчен уку китабы. Беренче уку китабы. Башлангыч сыйныфлар өчен. «Мөгаллим әл-әүвәл», «Мөгаллим әс-сани» үрнәгендәге басма китап, гарәп графикасында, татар телендә.

**3 июль, 2021 ел**
**Пенза өлкәсе Лопатино районы Селәү авылы**

Селәү авылында 1912 елда төзелгән мәчет бинасы сакланган. Хәзерге вакытта ике мәчет эшләп килә, өлкән буын вәкилләре сөйләве буенча, авылда элек биш мәчет булган. Мәчетләренең төзелеше үзенчәлекле, манаралары биек түгел. Равил хәзрәт Арсланов билгеләп үткәнчә, манаралар шундый булуның ике версиясе бар: беренчедән, ерактан күренеп тормасын өчен; икенчедән, чыгым күп сорала. Шулай ук йортларның да күбесе болдыр (өй алды баскычы) белән төзелгән, өй түбәләре дә үзенчәлекле (четырехскатный).

2020 елда авыл тарихы турында зур китап чыгарганнар[1].

Бу авылда да бөти тагу, баш астына догалыклар салып йоклау киң таралган. Шул төбәк сөйләшенә хас сүзләр: *шигырьче* – шагыйрь, *элгәреге* – элек, *мелчә* – тегермән, *тике* – тикле, *тудыкам* (түти) – апа, *вата шылай* – вот шулай.

Авыл халкында борынгы китапларга ихтирамлы мөнәсәбәт сизелә. Әйтүләренә караганда, 10 еллар элек китапларның зур өлеше Казаннан килгән галимнәргә бүләк ителгән.

Мәчетләрендә дә шулай ук халык тапшырган гарәп язулы басма китаплар саклана.

• Алты бармак китабы. Казан: Типо-литография Императорского университета, 1899.

Бу дини-дидактик эчтәлекле әсәрнең авторы – төрек галиме Мөхәммәд ибне Мөхәммәд Чыкрыкчызадә (1623 елда вафат), авторның кушаматы Алты Бармак белән бәйле һәм әсәр шул исем белән киң таралган да, автор биргән исеме – «Дәлаил әл-нөбүвәт Мөхәммәди вә шәмаил әл-фөтүвәт Әхмәди» («Мөхәммәднең пәйгамбәрлегенә вә Әхмәднең затлы сыйфатларына дәлилләр») әкренләп онытылган. Китап фарсы галиме Мөхәммәд әл-Фәрәхинең (Муин-Мискиннең) «Мөгариж

[1] *Хабибуллин А.А.* Суляевка в краю родников. История татарского села. Саратов: Наука, 2020. 384 с.: ил.

эн-нөбуа» («Пәйгамбәрлек баскычлары») исемле трактаты нигезендә язылган.

Әсәр кереш өлештән, дүрт бабтан һәм хатимәдән (йомгаклау) тора. Керешендә Аллаһка, Мөхәммәд пәйгамбәргә традицион мактау сүзләре әйтелә, Коръәннән аятьләр, хәдисләр китерелә. Төп текстта пәйгамбәрләр тормышыннан вакыйгалар сөйләнә, Мөхәммәд пәйгамбәр, аның кылган гамәлләре хакында уй-фикерләре санап кителә. Китап шулай ук тарихтан, педагогика, фәлсәфә кебек фән тармакларыннан да күп кенә мәгълүматларны үз эченә ала. XVIII–XIX йөзләрдә «Алты бармак китабы»ның кульязма нөсхәләре Идел буе, Урал төбәкләрендә киң таралган була. Беренче типографик басмасы Казанда 1861 елда дөнья күрә, аннан соң күп мәртәбә басылган.

• Дөньяның барлыкка килүе хакында китап. Басма китап, башы юк, ахыры бар, кулдан шигъри юллар өстәлгән.

• Мөхәммәдия китабы. Басма китап, башы юк.

• Коръән тәфсиренең берничә бите. Басма китап.

• Тарика Мөхәммәдия тәрҗемәсе. Басма китап, башы юк.

• Пәйгамбәрләр тарихы. Басма китап, башы-ахыры юк.

• Коръән. Казан басмасы. Фрагментлары гына сакланган.

• Намаз нигезләре. Басма китапның берничә бите, татар телендә.

• Хисаб дәреслеге. Басма китап, башы-ахыры юк.

*Морадымов Рушан Рифат улы (1966 елгы)* бала чактан шәмаилләрдәге язу белән кызыксынып, гарәпчә укырга-язарга өйрәнә. Әтисе Морадымов Рифат Садри улы (1924–1990) гарәп язулы китапларны укый белгән, Бөек Ватан сугышында катнашып, 1946 елда туган ягына кайткан.

Хәзерге вакытта Рушан әфәндегә бөтен авыл кешеләре, тирә-яктагы танышлары гарәп язулы китапларны тапшыра. Шулай итеп, гарәп графикасындагы китаплардан саллы китапханә тупланган, Рушан Рифат улы аларны үзе дә өйрәнә. Үзенең көндәлеген гарәп язуында алып бара. «Барлык китапларымны балаларыма тапшырам», диде. Аларга да гарәп язуын өйрәткән.

Морадымов Рушан абый шәхси китапханәсендә 30 га якын китап саклана.

• Кыйссас әл-әнбия (Пәйгамбәрләр турында кыйссалар). Басма китап, сакланышы яхшы. Китапның башында кулдан язылган язуы бар: *«Ошбу китаб иясе – Селәү карьясендә*[1] *ватан идеп торгучы Әхмәди бине Ибраһим Бакаев. Ошбу китаб бик күп кулда булган. Ходага бин хәмед иттем. Рәсүленә дә итдем. Җыярга шөруг итдем*[2] *Насыйбулла бине Әхмәдҗан Әбүзәров».*

• Рисаләи Нурнамә (ягъни хәзрәти рәсүл галәйһи әс-сәлам нурының яратылуны вә хасиятләрене бәяныдыр). Казан: Типография Бр. Каримовых, 1901. Басма китап, гарәп графикасында.

• Салават китабы. Басма китап, башы юк, гарәп телендә.

• Дәкаик әл-әхйар тәрҗемәсе. Ходаин әл-әфкяр. (Габдуллаһ Мөхәммәд бине сәламәт әл-казагы һиҗрәтдән дүрт йөз илле дүрттә (454) вафат ошбу 1324 нче сәнә мосаннифнең[3] вафатына сикез йөз алтмыш тукызынчы (869) елдыр). Казан: Лито-типография Бр. Каримовых, 1911.

• Дин нигезләре. Намаз кылу тәртибе хакында кулдан язып өйрәнелгән китапчык.

• Догаи мәрҗан. Казан: Типография Бр. Каримовых 1905.

• Мәүлид эн-нәби галәйһи-с-сәлам. Казан: Типография Бр. Каримовых, 1915. Гарәп графикасында, татар телендә.

• Намаз нигезләре. Башы-ахыры юк, гарәп графикасында, татар телендә.

Намаз төрләре, намаз уку тәртипләре, намаз кагыйдәләре һ. б. бүлекчәләре белән тәкъдим ителгән китап.

• Кыйссас әл-әнбия (Пәйгамбәрләр турында кыйссалар). Казан: Типография И.Н. Харитонова, 1904. Гарәп графикасында, татар телендә.

• Төхфәт әл-мөлүк тәрҗемәсе (китабе-с-салават һәм эс-сум). Кулдан язылган язуы бар: *«ошбу китаб бүләк ителгән Баликъ бабай тарафыннан Саратудан китердем».*

• Мохтасар әл-викаять тәрҗемәсе (дамелла Мөхәммәди әс-Салихин әл-мөтәвәффа[4]). Казан: Типо-литография Бр. Каримовых, 1910. Гарәп графикасында, татар телендә.

---

[1] Карьясендә – авылында.
[2] Шөруг итдем – керештем.
[3] Мосаннифнең – китап төзүченең.
[4] Мөтәвәффа – вафат булган.

• Әхадисе Кодсия («Кодси хәдисләр»). Тәрҗемәсе илән. Нашире вә мөрәттибе: имам Зариф әл-Әмирхани[1]. Казан: «Үрнәк» матбагасы, 1909.

• Гыймад әл-ислам. Казан: Типография Бр. Каримовых, 1900. Гарәп графикасында, татар телендә.

• Намаз уку китабы. Басма китап, татар телендә.

• Әхадисе мөнтәхәбат[2] (сыйбьян сыйныфларның[3] 3, 4 нчеләре өчен тәртиб улынды). Казан: Типо-литография Бр. Каримовых, 1912.

• Маһфирузә Солтан илә Разынһан. Хикәя. (Бик хуш вә мәргуб[4] кызык вә гыйбрәтле ике гашыйкның хәлене бәян кылынган бер гүзәл хикәядер. Үземезнең татар телендә мондан әүвәл басылдыгы улмаеб әүвәл мәртәбә басылуыдыр.) Казан: Типография Бр. Каримовых, 1904.

• Дини эчтәлекле кульязма фрагмент. 1 бит.

• Китаб әл-мөгамәлят китабының бер бүлеге «Фасыл вә-л-әкәл вә-ш-шәраб» («Ашау-эчү бүлегендә»). Басма китап, башы юк, татар теленә тәрҗемә, гарәп графикасында.

• Хөласаи фи әл-әхбар. Басма китап, башы юк, гарәп графикасында, татар телендә.

• Тәфсире фәваид. Җөзә-и салис мин сурәт әл-Каһф» («Кәһф» сүрәсенең тәфсире). Басма китап, елы күрсәтелмәгән, татар телендә.

• Хәдисләр җыентыгы.

• Коръән тәфсире. Басма китап, башы-ахыры юк, татар телендә.

• Тәсһил әл-бәян фи тәфсир әл-Коръән. Казан: «Үрнәк» матбагасы, 1910.

• Мөхәммәд Чәләби. Мөхәммәдия. Казан, 1890. (2 китап)

• Кулдан язылган «Нурнамә» – шигъри текстлар, гарәп графикасында, татар телендә. Әлеге әсәр – авылда әбиләр җыелып укырга яраткан әсәрләрнең берсе булган, шуңа күрә күчереп язып та ала торган булганнар.

---

[1] Имам Зариф әл-Әмирхани – Әмирханов Мөхәммәтзариф Хөсәен улы (1853–1921), дин эшлеклесе, Фатих Әмирханның атасы.

[2] Әхадисе мөнтәхәбат – сайлап алынган хәдисләр.

[3] Сыйбьян сыйныфларның – башлангыч сыйныфларның.

[4] Мәргуб – теләнгән, кызыгылган.

**4 июль, 2021 ел**
**Пенза өлкәсе Лопатино районы Иске Вершаут авылы**

Бу авылда да гарәп язулы язма һәм басма китаплар саклан-ган. Авылда Мәүлид, ифтар ашлары күркәм итеп оештырыла. Без килгән көнне бер авылдашларын соңгы юлга озаттылар, шунысы мөһим: мәрасимдә бөтен авыл халкы катнашты.

*Алеева Дания Рәис кызы (1979 елгы)* каенатасы Алеев Миргали Юсуф улыннан (1900–1994, мулла булган) калган китапларны өйләрендә хөрмәтләп саклый.

• Имам Касыйм Бикколов. Тарих әнбия (атабыз Адәм галәйһи әс-сәламдән пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһи әс-сәламгәчә). 1 нче кыйсем. Казан: «Мәгариф» матбагасы, 1917. Ахыры юк, гарәп графикасында, татар телендә.

• Дини характердагы китап. Башы-ахыры юк, гарәп графикасында, татар телендә.

Китапта намаз, зәкят, ураза, мосафир, хаҗ, кеше күмү, вәгазь-нәсыйхәт, ярдәмчеллек турында сөйләнә, структур яктан бәяннарга бүленгән, дини хрестоматия рәвешендә басылган.

Эчтәлеге: *Намаз ваҗиблары бәянында; Намаз әдәпләре; Намаз фарызлары; Намаз сөннәтләре; Намаз каза калса гөнаһы бәянында; Каза намазга идәнә уку намаз бәянында; Алтын вә көмеш зәкяте бәянында; Тивә зәкяте бәянында; Сыгыр зәкяте бәянында; Куй зәкяте бәянында; Ат зәкяте бәянында; Зәкавәт сарыф улынанлар бәянында; Рузә бәянында, Сәдака фитра бәянында; Хаҗ бәянында; Хәез бәянында; Нифас бәянында; Госел бәянында; Җәнүб коега төшсә – аның хөкеме бәянында; Сыгыр хөкмене бәяныдыр; Мосафирга ни нәрсәләр мөбах булыр; Мосафир кунак булса фазыйләте бәянында; Йокламак әдәбе бәянында; Йити нәрсәне йиргә күммәк сөннәтедер; Биш нәрсәне кисмәк сөннәтедер; Биш нәрсәне кылмак сөннәтедер; Тәгам йийү әхкямене бәяныдыр; Һөббә әхкяме бәянында; Хәйванатка ничә нәрсәне ашамак харамдыр; Ат итенең кәраһәте бәянында; Берничә эшләр эшләсә фәкыйрьлек китерер; Ун нәрсә күңелгә кайгы килтерер; Хатынлар сохбәтендә әдәб бәяны; Җәмгъ кайсы төнләрдә мөстәхәб бәяны; Вәгазь-нәсыйхәт бәянында; Фөрьяд бил-фәтх ярдәм мәгънәсендә; Иҗмагъның сыйфатлары бәянында.*

• Догаи гаҗаиб әл-истигъфар. Кулдан күчерелгән, гарәп графикасында.

• Кыйссаи Йосыф. Кулъязма. Язма традиция дәвам иткән дип әйтеп була. Хәтта 1970 елларда да күчерелгән.

**5 июль, 2021 ел**
**Пенза өлкәсе Лопатино районы Иске Карлыган авылы**

Элек 3 мәчет эшләп килгән, 750 якын йорт булган, хәзерге вакытта 180 йорт, 700 кеше яши. Авылда китап культурасы көчле.

*Ялагина Нәфисә Рәүф кызы (1970 елгы)* һәм *Рамазанова Мәрьям Тяфик кызының (1977 елгы)* бабалары Мортазин Зариф Әхмәдша улы (1875–1979) авыл мулласы булган, өшкерү, никах, балага исем кушу, мәет озату, бәйрәм намазлары үткәргән, гарәп язуын яхшы белгән. Зариф карт хатыны Мортазина Фатүк (Фатыма) белән 15 бала үстергәннәр, аларның берсе асрау булган. Уллары Бөек Ватан сугышына алынган, аларга туган якларына әйләнеп кайту насыйп булмаган. Онықчыклары Зариф бабай язган хатларны кадерләп саклыйлар. Хатлар бик матур язулы: сагынычлы сәлам сүзләре белән башлана, хәлә-хвал сорашу, хәбәрләр алышу, саубуллашканда да «кайнар сагынычлы йөрәк сәламнәремне җибәрәм» дип яза. Эпистоляр жанр остасы булган дип тә әйтә алабыз. Хатларга күз салсак, Әхмәт исеме (Зариф бабайның төпчеге; 1925–2020), Ахзят абыстай үлеме хакында кайгы уртаклашкан юллар, Надирә (Әхмәт бабайның хатыны) исемнәре очрый. Зариф бабайдан калган китаплар:

• Коръән. Казан басмасы. Башы юк.

• Фрагментар шигъри юллар. 8 бит. Татар телендә.

• Хифзы әс-сыйххәт мәҗмугасы (Дәвалау мәҗмугасы). Фрагментар, 6 бит, басма, татар телендә. Бүлекләргә бүленгән, бүлекләр бүлекчәләргә бүленгән. Кайберләрен тәкъдим итәбез:

*Скарлатина ничек була бүлеге:*

*– скарлатина яки кызылча хасталыгы,*

*– авыруны ничек карарга кирәк,*

*– скарлатина куркынычмы һәм аның илә авыру кешене дару итәргә кирәкме?*

• Язма дәфтәр. «Дини тәкъвим». Кулдан язылган: «1958–1959 г. Советлар җөмһүриятенең Аурупа бүлеге һәм Себер мөселманларының Диния нәзарәте тарафыннан тәртиб ителгән. 1378 сәнә һижри, 1958–1959 ел Милади өчен (дини тәкъвим).

• Әхляк китабы. Басма китап, башы-ахыры юк, татар телендә. Гарәп графикасында кулдан язу өстәлгән: *ошбу китаб Сәйфелмөлек мөәззин улы Мөхәммәдхарисның дәйү беленәдер. Китапның эчтәлегендә түбәндәге мәсьәләләр яктыртыла: гомернең фани улмакының бәяны, вәгъдә төзеклегенең бәяны, яхшы юлдашның бәяны, Габдуллаһ Әнсариның бәяны, гөнаһдин ерак булмакның бәяны һ. б. ш.*

• Грамматика. Фрагмент.

• Коръән тәфсире. Басма китап.

• Татарча уку китабы. Басма китап, гарәп графикасында, татар телендә. Дидактик характерда, ата-ана, өлкән кешеләргә мөнәсәбәт, ел фасыллары белән бәйле хикәятләр.

Эчтәлеге: *Безнең өй эче; Иң яхшы ана; Анасын карый; Бишек җыры; Анага бар да бертигез; Авыру ана; Атасын кызганды; Ата; Атасына булышырга тели; Бабай; Бабасына булыша; Әби; Анасыз өйдә ямь юк; Ятимләр; Яхшы кардәш; Туганнар арасында; Ике туган; Өйдә кечке эшләр; Кала өе; Безнең йорт; Авыл өе; Адәмнең көче; Адәмнең байлыгы; Йир байлыгы; Кышкы эшләр* һ. б.

• Галимҗан әл-Баруди. Әс-саляс әл-гаскуд. (никах, талак, иман). Хадим әл-голүм. Казан: Электро-типография «Милләт», 1911. Басма китап, гарәп графикасында, татар телендә.

*Свергузова Гөлкәй Сафа кызы (1938 елгы)* каенатасы Свергузов Адельша Хәбибулла улы (1892–1983) хакында истәлекләре белән бүлеште һәм китаплары, язулары белән таныштырды. Адельша бабай мәчеттә мулла вазифаларын башкарган, мәдрәсәдә укыткан, китап күчергән, шәмаилләр ясаган. Адельша бабайны, өйләнгәч, дүрт елга армиягә алалар, Гөлкәй әби ул армиядә вакытта каенаналары белән яши. 1914–1915 елларда I Бөтендөнья сугышында катнаша, яраланып, туган ягына кайта. Бөек Ватан сугышы чорында тылда хезмәт итә (боеприпаслар заводында эшли). Адельша бабай 1919–1921 елгы корылык, ачлык елларында Мәскәүгә иген озата бара, шунда

аларны В.И. Ленин кабул итә, шул вакыйга аның күңелендә мәңгелеккә уелып кала. Нинди генә җирләрдә булмасын, кемнәр белән генә аралашмасын, Адельша бабай диненә тугры булып кала, намазын калдырмый, балаларына да һәр эшне «Бисмиллаһ» дип башларга кушкан. Адельша бабайдан түбәндәге язмалар һәм китаплар калган:

• Җавапнамә. Берничә данәдә саклана. Барлык сораган кешеләргә ясаган, балаларына, оныкларына язып калдырган. Эшләнеше бик матур, А3 форматта, каллиграфик язу белән пөхтә итеп башкарылган, циркуль белән сызып эшләгәне күренеп тора.

Җавапнамә – гарәпчә догалар язылган түгәрәк формадагы кәгазь. Анда мәрхүмгә биреләчәк сорауларга җаваплар языла. Имештер, мәет шуны укып, Мөнкир белән Нөнкирнең сорауларына җавап бирә. Дөреслектә, мәет ике фәрештәнең сорауларына Аллаһ кушкан гамәлләрне үтәп һәм гөнаһлардан тыелып яшәгән булса гына җавап бирә алачак. Аны мәрхүмнең күкрәк турысына куеп калдырганнар. Бу гамәл исламда тыелган булса да, халык арасында кулланылу очраклары бар.

• Мөхәммәдия китабы. Казан: Центральная типография, 1909.

• Мөнәвәрә. Басма китап. Башы юк.

• Коръән. Кәлям шәриф. Тәфсир фәваиденең икенче җилде. Казан, 1889.

• Гыйбадәт сәляс. Зәкят, саум, һаҗ, әхкям әҗмалиясене мәгърифәтдә мөфид улмак үзрә сыйбьян тәгълиме өчен тәртиб иделмеш вә гаммә, әһле ислам эчендә нафигъ вә диянәт мөһим бер рисаләдер. Галимҗан Баруди дәст тәртибендә улан мәгариф исламиядин. Җөзьә сабигъдыр. Казан: Типография В.Л. Домбровского, 1903.

• Коръән. Кәлям шәриф. Казан, 1911.

• Фәүзен-нәҗат. Казан, 1895, башы юк. Басма китап, гарәп графикасында, татар телендә.

• Туган тел. 4 нче җөзьә. Казан: Типо-литография Бр. Каримовых, 1918. Сәркатипләре: Г. Гафуров, Ш. Әхмәдиев, З. Нуркин. Китап башында Г. Тукайның «Туган тел» шигыреннән ике юл бирелгән:

*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле,*
*Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.*

Китап хрестоматия рәвешендә төзелгән: хикәяләр, шигырьләр, тарихи хикәяләр, барлыгы – 97 хикәят. Эчтәлеге: *Тәңремә; Чыңгызның яшь вакыты; Авыл; Чыңгыз хан; Омтыла күңелем; Һиҗрәткә сәбәп; Ак Иделдә көймәдә; Яңгыр соңында; Көймәдән ярдәм эзләргә; Безнең тормыш хакында борынгылар; Йир түгәрәк; Хуҗи хан; Шүрәле; Әби падишаһ; Ислам диненең тәэсире; Пәйгамбәребезнең гүзәл сыйфатлары; Бер арыш бөртегенең тарихы* һ. б.

*Рамазанова Шамилә Якуб кызы (1953 елгы)* каенатасы Рамазанов Сафа Рәхим улының (1907–1982) әтисе Рәхим бабайдан калган китапларны кадерләп саклый.

• Дәкаик әл-әхбар тәрҗемәсе. Басма китап, башы-ахыры юк, бабларга бүленгән.

Ислам дөньясында шактый мәшһүр дин галимнәреннән Әбү Габдулла Мөхәммәд бин Сәламәнең «Дәкаик әл-әхбәр» («Һәр мөселман өчен кирәкле мөһим хәбәрләр») хезмәтен гарәп теленнән татарчага Галиәсгар Камал тәрҗемә иткән булган.

• Ислам дине нигезләре. Башы-ахыры юк.

• Гыйбадәт сәляс. Казан: Типография Б.Л. Домбровского, 1903.

• Шәраит әл-иман (Иман шартлары).

• Хикәят. Егет кешегә йитмеш төрле һөнәр аз. Бу сүз – раст сүз. Казан: Типография Бр. Каримовых, 1909.

• Исме Аллаһу Тәгалә әл-хөсни (Аллаһы Тәгаләнең күркәм исемнәре). Казан, 1879 (1297 һижри). Басма китап.

• Гасыр сәгадәт. Басма китап. Башы юк. Әлеге китап түбәндәге хикәятләргә бүленгән: *Корәишләрнең иттифакы; Рәсүллуллаһның һиҗрәте; Мәдинә халкының истикъбале; Мәдинә халкының ихтирамы вә кардәшлек; Һиҗрәтнең соңгы вакыйгалары; Бәдәр сугышы; Өхед сугышы; Хандык сугышы; Хибыр сугышы.*

• Бидаять җәгърафия. Казан, 1918. Басма китап.

• Әл-гукуд әс-сәляс.

• Дога исме әгъзам вә һәм башка шәриф догалар. Казан, 1909.

• Фән тәҗвид.

• Мөнәҗәт. Догалар. Блокнотта кулдан язылган.

Алардан мисаллар китереп китик.

*Мөнәҗәт йа Раббанә*

*Бисмиллаһи әр-рахман әр-рахим.*

*Әүвәл хакны яд идәлем, улдыр рәхман, улдыр рәхман, улдыр борһан, улдыр солтан.*

*Колларына нәкыльмешдер*[1] *телим иман, бихисаб, биниһаять рәхмәте бар Аллаһыдин, пәйгамбәргә йөз мең сәлам, вәгъдә кылыб, өммәтенә шәфкать кыла, салаватны әйтәдер, гыйз*[2] *догам нәкыйләремезенә гаҗиб көнләре бар. И мөэминләр, гафил улыб гомерегезне үткәрмәгез, ярдәм кылыб ятимләргә һәм асрауларга.*

*Бу малыгыз мәңгү калыр дийү сөенмәң,*
*Елан-хәян чолгаб алыр көнләре бар,*
*Бу үлем һәркемгә килми калмас,*
*Азраил шунда ирер, шәфкать кылмас,*
*Шул заманда шайтан алдар көнләре бар,*
*Бу үлем һәркемгә киләседер.*
*Җыйган малың йир ашының каласыдыр,*
*Андыйн артык такый гаҗәб таңнары бар.*
*Шундук хакның каһәре бар,*
*Кыямәтнең һәйбәтендән йир терәге,*
*Бишектәге яшь угланның сачы агаргай.*
*Шул вакытда кан яшь аглар күзләре бар,*
*Йа Раббәнә, син кичергел мин гасыйның*[3] *гөнаһын.*
*Ярлыкайу биргел миңа ахирәтнең пәнаһын*[4]*.*

*Тәммәт.*

**6 июль, 2021 ел**

**Пенза өлкәсе Шемышейка районы Оз авылы**

Авылда элек 11 мәчет булган, хәзерге вакытта 2 мәхәлләгә 1 мәчет эшли.

*Кормашев Исмаил Хәсян улы (1958 елгы)* – 1 нче мәхәллә имамы.

---

[1] Нәкыль – сөйләү.

[2] Гыйз – бөек, хөрмәт.

[3] Гасыйның – гөнаһлының.

[4] Пәнаһын – сыену урынын, саклаучы.

Мәчеттә халык китереп тапшырган китаплар саклана. Алар арасында:

• Дини эчтәлекле кульязма фрагмент

• Кыйссас әл-әнбия. Башы-ахыры юк.

• Уку китабы. Балалар өчен хрестоматия.

• Гыйльме хәл. Фрагмент.

• Төрки кыйраәт (ибтидаи мәктәпләрнең беренче вә икенче сыйныфлары өчен тәртиб иделде). Өченче басылуы. Казан: Типография Бр. Каримовых, 1914.

• Коръән. Кәлям шәриф.

• Хикмәтләр китабы.

• Китаб әд-дәгъва.

• Мөхәммәд Чәләби. Мөхәммәдия. Казан, 1908. Гарәп графикасында.

*Бәхтиев Рушан Шамил улы (1985 елгы)* – 2 нче мәхәллә имамы. Рушан хәзрәтнең әнисе һәм этисе ягыннан әбибабалары укымышлы булганнар. Гаиләсендә сакланган китаплар әнисе ягыннан бабасы Нурулла хәзрәт (1929–2009) һәм әбисе Фатыйма Усман кызы Курамшиннардан калган һәм алар бик кадерләп саклана:

• «Мохтасар әл-кодури» тәрҗемәсе. Мөтәрҗиме[1]: Әбү Габделәхәд шәйх әс-сәлям бине Әсадулла әл-Хәмиди. Казан: Типография Бр. Каримовых, 1911. Басма китап, гарәп графикасында, татар телендә.

• «Алты бармак» китабы. Басма китап, гарәп графикасында, татар телендә.

• Кисекбаш. Казан, 1899.

• Коръән. Кәлям шәриф.

• Дар әл-гаҗаиб.

• Рисаләи Нурнамә. Казан, 1917.

• Кабердән тавышлар. Халид Зыя. Мөтәрҗиме: Габдрахман Сәгъди. Уфа: «Шәрык» матбагасы, 1912. Фрагмент.

• «Мәшкүввәт әл-мосабих». (Әш-шәйх Вәлиддин Мөхәммәд бине Габдулла әл-хатыб әл-гомри Табризи әл-мәвасәвихәр). Китап бабларга бүленгән. Басма китап, 1898.

• Кыйссас әл-әнбия (Пәйгамбәрләр турында кыйссалар). Казан: Типография И.Н. Харитонова, 1904.

---

[1] Мөтәрҗиме – тәрҗемәчесе.

## 7 июль, 2021 ел
## Пенза өлкәсе Исса районы Югары Салмука авылы

***Кугушева Мәрзыя Муся кызы (1931)*** каенанасы Кугушева Наимә Шакирҗан кызыннан (1903–1999) калган кульязма мөнәҗәт һәм хәтем багышлау догалары язуларын кадерләп саклый.

Мәрзыя апаның кызы Шабаева Румия Исхак кызында (1969) Наимә әбисеннән калган китаплар саклана:

• Нәсыйхәт әс-салихин. Казан: Типо-литография М.А. Чирковой, 1908.

• Гаттар. Пәнднамә. Казан, 1884. Китапта «имам-мулла Ягъкуб бине мулла Муса» язулы мөһер сугылган.

• Ислам шәриф. Казан, 1912.

• Китабе Илдарнамә. Казан: Типография Б.Л. Домбровского, 1907.

• Бакырган китабы. Казан: Типо-литография М.А. Чирковой, 1907.

• Аллаһы Тәгаләнең мең дә бер исемләре хасыятьләре берлә. Казан: Типо-литография Бр. Каримовых, 1900.

• Кыйссас әл-әнбия. Казан, 1904.

• Рисаләи фарыз гайне һәм дәгъват. Казан: Центральная типография, 1914.

• Сурә мин әл-Коръән. Казан,1916.

• Намаз кагыйдәләре. Сорау-җавап рәвешендә язылган.

Эчтәлеге: *Рәсүлләргә иман рәвеше; Фәрештәләргә иман килтермәк рәвеше; Тәкъдиргә иман килтермәк ошбу рәвешле булыр; Гөнаһлы бәндә нә илә җәза-ән-нур; Гөнаһ тәүбәсез гафу булырмы?; Имамның ничә мәгънәсе вар; Монда кайсы мәгънәсе морад; Әманәтнең ничә шарты бар; Намазның фаразлыгына дәлил нәдер; Нә илән фараз булган; Биш вакыт намазның фарызлыгына дәлил нәдер; Вакыт фаразлыгына дәлил нәдер; Тәһарәтнең фарызлыгына дәлил нәдер; Хәез кемләргә фарыздыр; Хаҗның фарызы ничәдер; Гыйддәт ничәдер* һ. б.

## 7 июль, 2021 ел
## Пенза өлкәсе Исса районы Каменка авылы

Авылда 9 йорт бар, 21 кеше яши.

*Бикмаева Рауза Исмаил кызы (1950 елгы)* этисе *Невлютов Исмаил Ризван улыннан* (1904–1988) калган китапларны өендә

хөрмәт белән саклый. Әтисе укымышлы кеше булган, гарәп графикасында укыган, Бөек Ватан сугышында катнашкан.

• Коръән тәфсире. Казан: Типо-литография Императорского университета, 1900.

• Шәраит әл-иман. Казан, 1903.

• Дини эчтәлекле китап (*азан, намаз* һ. б. бүлекләргә бүленгән).

**8 июль, 2021 ел.**
**Пенза өлкәсе Лунино районы Шыкша авылы**

Лунино районында бу авылда бердәнбер мәчет эшләп килә. 1947 елга кадәр 3 мәхәллә булган.

*Курмашева Динә Хәмзә кызы (1970 елгы)* белән *Курмашев Ислям Фаттях улында (1965 елгы)* Үзбәкстан якларыннан килеп яшәгән күршеләре Аннинков Искәндәрдән (укымышлы булган) калган язулар һәм китаплар белән танышырга туры килде.

• Ясин. Кулдан язылган. Хәтем. Сүрәләр. Каллиграфиясе матур.

• Газават китабы. Басма китап, башы юк, татар телендә, «Пәйгамбәрләр кыйссасы»на охшаш).

• Кыйссас әл-әнбия. Басма китап, башы-ахыры юк.

• Фәзаиле-ш-шөһүр (бу рисаләдә рәҗәб вә шәгъбан вә рамазан һәркаюсының фазыл вә савабыны идәр). Казан, 1866.

• Дини хрестоматия рәвешендәге басма китап. Тәһарәт, намаз, һ. б. дини мәсьәләләргә багышлана.

• Исме әгъзам. Басма китап. Китапның форзацында кулдан *«Бу китаб Бибихәдичә бинт Йосыф[1]»* дип язылган.

• Дини характерда китап. Кулдан язу өстәлгән: *«Хаҗ кылырга тиешле эшләр язгандыр».*

• Рисаләи Газизә. Басма китап, башы юк.

• Ходай Тәгаләнең мең дә бер исемләре хасыятьләре берлән. Казан, 1892.

• Мәгъшукнамә (бер карьядә бер егет илән бер кызның шигырьләр илән сүзләшкән сүзләредер).

• Балалар өчен уку китабы (хрестоматия). Өченче җөзьә.

• Шәрхе Ниязи. Басма китап, татар телендә.

• Тәфсире Ногмани. Басма китап, татар телендә.

---

[1] Бинт Йосыф – Йосыф кызы.

• Җәгърафия укымакны нәфгы (География укуның кирәклеге).

• Гайн әл-галләм. Казан: Типография Императорского университета, 1806. Бабларга бүленгән.

• Мөхәммәдия. Казан. Башы юк.

*Шаипова Кадрия Мөдәррис кызында (1973 елгы)* каенанасы Шаипова Сания Хәйрулла кызыннан (1934–1992) калган китаплар:

• Догаи исме әгъзам вә һәм башка шәриф догалар. Казан, 1909. Фотокүчермә.

• Коръәннән сүрәләр.

*Деникаева Рәйсә Бари кызында (1945 елгы)* каенанасы *Базетова Алимә Мөхәммәтша кызыннан (1904–1993)* калган китаплар саклана:

• Мөхәммәдия. Казан.

• Коръән. Кәлям шәриф. Казан басмасы.

• 1898 нче сәнә тәэсис кылынмыш Казан җәмгыяте хәйрия исламия уставының тәрҗемәсе. Казан: Электро-типография «Милләт», 1912. 28 б.

Эчтәлеге: *Җәмгыяте хәйрия исламиянең максуды, әгъзалары, попечительство вә башка правление шөгъбәләре; Гомуми мәҗлесләр; Гомуми кагыйдәләр*. Китап ахырында рус телендә язылган примечание бар: «*Учреждение О-ва пособия бедным мусульманам г. Казани, на основании утвержденного Г. Министром Внутренних дел 10 июня 1897 года примерного Устава обществ пособия бедным разрешается. Декабря 24-го дня 1897-го года. Подлинный подписал: Губернатор тайный советник Полоторацкий. Скрепил: управляющий канцелярией Д. Малов*».

Пенза өлкәсендә татар халкының китап традициясе сакланган. Һәр авылда гарәп язулы китаплар барланды. Узган гасырларда яшәгән эби-бабайларыннан истәлек буларак калган язмаларның, китапларның кадерләп саклануы күрсәтелде. Халкыбыз белемле булган, гыйлемгә омтылган, китапка хөрмәт белән яшәгән, киләчәк буыннарга да үзләреннән мирас, ядкәр булып калсын өчен, аны олылап саклаган. Бүген исә балалары аларның өметен аклап, эшләрен дәвам итеп яши.

## ЯЗМА ЯДКӘРЛӘРДӘ – ХАЛЫК ХӘТЕРЕ

*Фәния Фәйзуллина*

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган комплекслы экспедицияләрнең чираттагысы Пенза өлкәсенең Каменка, Белинский, Пачелма, Вадинск һәм Спасск районнарындагы татар авылларына юнәлтелгән иде. Россия куенындагы Пенза өлкәсендә гомер кичерүче милләттәшләребез, татар дигән исемгә тугры калып, горур гына яшәп яталар. Алар, олысы да, кечесе дә, рәхәтләнеп, авыз тутырып, үзләренә хас татар телендә сөйләшәләр. Һәм шушы сыйфатлары белән үзләренә җәлеп итеп торалар.

Сәяхәтебез Каменка районының Кикин авылыннан башланды. Риваятьләр буенча, 1690 елда Арслан Акҗигитов тарафыннан нигез салынган әлеге авыл – тарихи «Алты авыл»ның иң зурысы («Алты авыл» – Пенза өлкәсенең алты татар авылын берләштергән атама). Үз эшләренең белгечләре булган – мәктәпнең Тарихи-туган якны өйрәнү музее директоры Равилә Билал кызы Девлекамова һәм татар теле укытучысы Равилә Фәрит кызы Баткаеваның Кикин һәм «Алты авыл» тарихы турындагы этрафлы чыгышлары, мәктәп кысаларына гына сыймыйча, урман уртасында искиткеч матур табигать кочагындагы милли герой Акҗигитов Арслан Палкай улы кабере янында да дәвам итте. Эзләнүләребезнең нәкъ шушы тарихи авылдан башланып китүе бездә алда барачак авылларга карата зур кызыксыну уятты.

Халык үзенең тарихы белән кызыксына, өйрәнә, мәгълүмат туплый. Ә тарихыбыз тирәнрәк ачылсын, мәдәни мирасыбыз

баесын өчен, галимнәр һәрвакыт халык ярдәменә мөрәҗәгать итә.

Борынгы кулъязмалар, иске китаплар белән кызыксынучы буларак, мин эшемне авылның өлкән буын кешеләре белән аралашудан башладым.

Татар халкы элек-электән китапка хөрмәт белән караган. Аларның һәркайсы саклык белән генә кадерләп тотылган. Халкыбызның тарихын саклаган язма ядкәрләр буыннан буынга тапшырылып килгән. Шуңа күрә халык кулында сакланып калган әлеге рухи мирасны өйрәнү аеруча зур әһәмияткә ия. Комплекслы экспедицияләрнең төп максатларыннан берсе дә – нәкъ менә борынгы басма китапларны, кулъязмаларны барлау, туплау.

Миңа авыл имамы Илдус Шамил улы Такташев ярдәмгә килде. Заманында дүрт мәчет булган авыл уртасында бүген дә заманча төзелгән (2009 елда) ике катлы зур «Айшә, Маһирә» үзәк мәчете нурлар чәчеп утыра. Әлеге мәчеттә бик күп иске китаплар саклана булып чыкты. Имамның сүзләренә караганда, авылда иске китапларны укучы кешеләр инде калмаган. Ләкин авыл халкы, электән үк гарәп язулы китапларга бик игътибарлы һәм хөрмәт белән караучы буларак, үзләре укый белмәгәнлектән, кулларында булган истәлекләрне мәчеткә саклауга тапшырганнар.

Күп сандагы Коръән китапларын исәпкә алмаганда, мәчеттә гарәп язуында 30 га якын төрле эчтәлектәге басма китаплар барлыгы ачыкланды. Аларның күпчелеген дини-дидактик китаплар тәшкил итә. «Мөхәммәдия», «Һәза китаб әт-тәҗвид» (Казан, 1876), «Һәфтияк шәриф» (Казан, 1889), «Алты бармак» (Казан, 1902), «Вакты сәхәр китабы» (Казан, 1908), «Әзкяр әс-салят» (Казан, 1917), «Бәдәвам» һ. б. шушы исемлектән. Алар арасында дөньяви белем бирә торганнары да очрады. Мәсәлән, Тыйб китабы, Физика китабы, Фикъһ китабы, «Балаларга кыйраәт», «Ана теле», «Гөл бакчасы» (шигырьләр китабы) һ. б. шундыйлардан. Кызганычка, күбесенең я башы, я ахыры юк, яки шундый китап булганлыгын дәлилли торган аерым битләре генә калган. Мәчеттәге китаплар авыл халкыннан җыелган. Ләкин аларның кем тарафыннан тапшырылган-

лыклары билгеле түгел. Бары бер китап тышында гына («Вакты сәхәр китабы») «Куйбышевтан. Исмәгыйль кызы Рауза» дигән язу очрады. Мәчеттәге әлеге байлыкның һәрбер битенә игътибарлы булып, кулдан кичереп чыгарга тырыштым. Авылдагы кешеләрнең гарәпчә язмаларга бик сакчыл караганлыклары күренеп тора. Араларында аерым битләрдә язылган үле өстендә укыла торган «Балага ананың васыяте», 40 көнендә рухларга Коръән багышлау һәм шулай ук аерым кулъязма догалар да очрады. Китаплар арасыннан килеп чыккан тагын бер кәгазь аеруча игътибарга лаек. Ул – 1896 елда булган никахлар язылган Метрикә кенәгәсенең аерым бите. Әлеге биттә, 3 нче сан белән, 28 февральдә Пенза губернасы Чембар өязенең Кикин авылының Хөсни Рәхмәтулла углының 24 яшьлек кызы Шәрифә белән шул ук өязнең Кабылкин авылының солдаты 25 яшьлек Шәрифҗан Мөхәммәдгали углының никахы һәм, 5 нче сан белән, 29 мартта Пенза губернасы Чембар өязе Кикин авылының Әхмәдҗан Габделхаликъ углының 20 яшьлек кызы Таһирә белән шул ук авылның солдаты 26 яшьлек Муса Мөхәммәдрәхим улының никахлары теркәлгән.

Авыл халкы башта бик үк ачылып китәргә теләмәсә дә, кадерләп саклаган ядкәрләрне соңыннан үзләре үк «болар нинди китаплар икән?» дип кызыксындылар. Алар, нигездә, басма Коръән китаплары иде. Конеева Гүзәл Исхак кызында (1948 елгы) сакланган «Гарәп әлифбасы», «Дин нигезләре» (намаз тәртипләре), «Мәүгазә дәрел нәсыйхин» (вәгазьләр) китаплары тагын бер кат авыл халкының укымышлы һәм дингә омтылышы булганлыгына дәлил булып торалар. Бу авылда башкача булырга мөмкин дә түгел, чөнки Кикин – атаклы Бигиевләрне биргән авыл. Татар әдәбиятының күренекле вәкиле Заһир Бигиев (1870–1902), әтисе ахун булып билгеләнеп, гаиләсе белән Ростов-Донга күченергә җыенып йөргән вакытта Кикиндә дөньяга килгән. Авыл кешеләре сүзенә караганда, бүгенге көндә алар нигезендә шул нәселнең дәвамчылары яши.

«Алты авыл»ның иң кечкенәсе Тәләтен авылы (Каменка районы) безне бик тыйнак кына каршы алды. Мәзин Фәрит Исмәгыйль улы Дасаевтан (1938 елгы) авылның күрке булып балкып

торган мәчеттә китаплар юклыгын белдем. Кешеләр белән аралашканда, авылда әби-бабаларыннан калган иске китапларны, язмаларны кабергә илтеп күмү кебек аяныч хәлләр дә булганлыгы турында ишетергә туры килде. Шушы 35 хуҗалыклы авылда да ярдәмгә килүчеләр табылды. Үзлегеннән гарәпчә өйрәнгән, заманында абыстай булган Рушания Сабирҗан кызы Такташева (1939 елгы) өендә «Кыйссаи Сәйфелмөлек» (Казан, 1807), «Ике үксез» (Казан, 1904), «Кырык вәзир кыйссасы» кебек басма китаплар һәм «Догаи мәрҗан», «Исме әгъзам» кебек догаларның аерым кәгазьгә язган күчермәләре, шулай ук мөнәҗәтләр язылган аерым битләр сакланып калган. Каты авырудан тернәкләнеп килүче Рушания апаның кызы Флера Назгар кызы (1969 елгы) Тахтарова әбиләре Әбидә Әхмәтҗан кызы Иртугановадан (Кушкин әби) калган әлеге мирасның өйләрендә бик кадерләп саклanулары турында җиткерде.

Пенза өлкәсендәге татар авыллары үзләре тәрбияләгән атаклы шәхесләре аша да билгеле. Алдагы Мачали авылында (Каменка районы) без язучы, мөгаллим Муса Акъегетзадә (1864–1923), 1939–1941 елларда институтыбызның директоры булып эшләгән Хәсән Габдрахман улы Шабанов (1901–1956) эзләре буйлап йөрдек. Һәр авыл үзенең укымышлы нәсел вәкилләрен яхшы белә. Мине Мачали авылында 25 ел мулла булып торган Лотфулла хәзрәтнең (1902 елгы) улы белән килене яшәгән йортка озаттылар. Муса Лотфулла улы (1939 елгы) һәм Сания Абдул кызы (1948) Макуевларда «Алты бармак китабы» (Казан, 1899), «Рисаләи фарзы гайн һәм дәгъвәт» (Казан, 1903), «Рисаләи Тәүхид» (Казан, 1904), «Бәдәвам» (Казан, 1906), Һ. Максудиның «Гакаид»ы (Казан, 1915), «Шәраит әлиман» (Казан, 1917), «Догаи исме Әгъзам вә һәм башка шәриф догалар» (Казан, 1917) кебек 13 исемдәге дини эчтәлекле китап теркәлде. Шулай ук кулъязма хәлендә сакланган «Никах уку тәртибе» һәм «Манара бәете» язып алынды. Муса абый белән Сания апа үзләрендә гарәп язуындагы китапларның тагын да күбрәк булганлыклары һәм, истәлеккә дип, оныкларына таратулары турында сөйләделәр.

Авылда күп еллар математика укытучысы булып эшләгән Рәшит Ибраһим улы Уразгильдеев (1960 елгы) та үзенә әби-

бабасы Арифә (1900–1984) һәм Арифулладан (1896–1963) калган мирас белән таныштырды. «Кәлам шәриф тәфсире» (1899), «Кыйссас әл-әнбия», «Мохтәсар тарих ислам» кебек дини китаплар арасында «Гарәп теле дәреслеге», «Сарфы гарәби» (Казан, 1898), «Мөгаллиме нәхү лисане әл-гарәб» (Казан, 1903) кебек гарәп теле нигезләрен өйрәтүче чыганаклар да барланды. Әлеге мирасның иң кадерлесе, хуҗасы өчен дә, минем өчен дә, әлбәттә, «Мөнәҗәтләр» язылган дәфтәр иде. Рәшит абый, Мирасханәдә урынлырак булыр, дип, гарәп язулы кулъязманы миңа тапшырды. Сания Сабир кызы Тинчуринада (1941 елгы), Фәридә Сабирҗан кызы Акҗигитовада барланган басма «Мөхәммәдия» китаплары, бик начар сыйфатлы «Мәүлид эн-нәби галәйһиссәлам» кулъязмасы, Сафия Мөхәммәт кызы (1934 елгы) Погодинада сакланган «Һәза догаи Мәрҗан» китапларының аерым битләре дә Мачали авылында электә нинди китаплар укылганлыкны раслаучы дәлилләр иде.

Гарәп язуындагы кәгазьләргә халыкта изге итеп карау сизелеп тора. Аларның илаһи көченә ышанып, хәтта елаган баланың мендәр астына да гарәп язулы китап битләре тыга идек, дип сөйләделәр Мачалидә. Бу ышану, үз чиратында, китапларның таушалуына китергән.

«Алты авыл»ның чираттагысы Кобылкин (Каменка районы) авылы үзенең төзеклелеге, зурлыгы белән аерылып тора. Авыл имамы Руслан Хәмзә улы Тинчурин мине турыдан-туры мәчеттә саклаучы китапларны күрсәтергә алып китте. Аның сүзләренә караганда, авылда 1942 елда бик каты янгын булган. Шул вакытта бик күп китаплар янып беткән. Кайбер кешеләр үзләрендә калган иске китапларны саклау өчен мәчеткә тапшырганнар, ә кайберләре яңа өйләргә күченгәндә, үзләре белән алып чыкмаганнар, шулай итеп китаплар юкка чыккан. Мәчеттә сакланган басма китаплар арасында да «Кәлам шәриф тәфсире» (1889), Һ.Максудиның «Шәригать исламиянең әхкям гамәлиясе»нән (С.-Петербург, 1899) башкалары «Мөхәммәдия», «Рисаләи Газизә», «Тәгълим әс-салят тәрҗемәсе», «Мәҗмәгъ әд-дәгъвәт», «Нәвадир тәрҗемәсе» китапларыннан калган башы-ахыры булмаган тарихи истәлекләр генә иде. Араларында «Китабы Устуани» кебек янгын шаһитләре дә очрады.

Элеккеге мулланың өендә китаплар саклангандыр бәлки, дип, мине Кудряковлар белән таныштырдылар. Авылда 1896 еллардан мулла булып торган Гыйниятулла хәзрәт, 1906 елдан мулла булган аның улы Ибраһим хәзрәтнең китаплары, чыннан да, бик ышанычлы кулларга калган булып чыкты. Рамил Камил улы (1979 елгы) белән Әлфия Заһидулла кызы (1978 елгы) бабаларыннан калган иске китапларны, аларның кулы белән язылган һәр кәгазьне кадерләп саклыйлар. Әлеге язма ядкәрләр «Китабы Бакырган», «Тәгъбирнамәи йәнабигъ тәрҗемәсе» (С.-Петербург, 1896), «Рисалә әш-Шафия» (Казан, 1901), «Рәднамә» (Казан, 1908), Шәһид Гаунинең «Фән әт-тәҗвид»е (Казан, 1912), «Көйле иман» (мәктәп балаларына) (Казан, 1915) «Мәҗмәгъ әд-дәгъвәт», «Мәвакыйф» кебек, нигездә, дини эчтәлектәге басма китаплардан гыйбарәт. Арада сакланган «Эш һәм белем» китабының аерым битләре бу мирас хуҗаларының дөньяви белемнәргә дә омтылганлыклары турында сөйли. Кайда гына булсак та, иң кызыксындырганы, әлбәттә, кулъязмалар була. Кудряковларда да, борынгы чорларга караган булмаса да, кулъязма дәфтәр табылу үзенә күрә бер табыш иде. Анда шулай ук мөнәҗәтләр, дини эчтәлектәге шигырьләр язылган.

Белинский районына керүче Кутеевка (Качкару) авылы да – «Алты авыл»ның берсе. Анда безне «Закир мулла» мәчете имамы Рафикъ Ибраһим улы Акмаев якты йөз белән каршы алды һәм без Фируша Абделкадыйр улы (1950 елгы) белән Сафия Әхмәтҗан кызы (1953 елгы) Яваевлар яшәгән йортка юл тоттык. Тарихта Төрек армиясе генералы булып танылган Шакир пашаның туган авылы белән танышуым нәкъ менә Яваевлардан башланды. Биредә Мөхәммәдшакир Шәриф улы Яваев нәселеннән булган Абделкадыйр мулладан калган иске китаплар барлыгы ачыкланды. Басма «Кәлам шәриф тәфсире» (Петербург, 1898), «Тәсһил әл-бәян фи тәфсир әл-Коръән» (Казан, 1910), Габдулла Мөхәммәдфәезнең «Мохтәсар гыйльме халь» (Казан, 1908), «Шөрут әс-салят» (Казан, 1911), Һ. Максудиның «Тәһарәт (Гыйбадәте исламия мәҗмугасының икенче сыйныф шәкертләре өчен)» (Казан, 1911) китаплары теркәлде. Араларында сакланган кулъязма дәфтәр игътибарны җәлеп итте.

Анда язылган «Манара бәете», «Суга барган ана бәете» һ. б. безнең фондларыбызда урын алды.

Шушы авылда туып, бүгенге көндә Пенза шәһәрендә яшәүче, Шакир пашаның турыдан-туры нәсел дәвамчысы Тумеркина Фирдәүс Казыйм кызы (1961 елгы) белән танышу аеруча кызыклы булды. Ул, күп еллар буе мәгълүмат туплап, Шакир паша турында аерым китап та әзерләп бастырган («По следам Шакир-паши», 2021). Бик кызыксынучан Фирдәүс ханым әтисенең әнисе Мөхлисә әбидән (1898 –1980) калган иске китапларны үзендә бик кадерләп саклый. Алар – «Кыйссас әл-әнбия» (Казан, 1899), «Кырык хәдис» (Казан, 1889), «Һәза китаб дәкаикыль әхбар» (Казан, 1900), «Әнварелгашыйкыйн» (Казан, 1904), «Кырык вәзир кыйссасы» (Казан, 1907), Гәрәй Арслановның «Табышмаклар»ы (Казан, 1910), «Тәгъбирнамә» (Казан, 1886, 1917) кебек басма китаплар. Шулай ук үләннәр белән дәвалау турындагы аерым кульязмалар да бар.

Авыл кешеләре Багдалова Нәҗия Кәрибулла кызында (1956 елгы) сакланган «Рәднамә» (Казан, 1909), «Мәҗмәгъ әд-дәгъвәт», «Хизбел бәхер», Фәрит Идрис улы (1957 елгы) белән Әлфия Абдулла кызы (1961 елгы) Дубиннарда сакланган «Дәкаикыль әхбар тәрҗемәсе», «Нәвадир тәрҗемәсе», шулай ук «Закир мулла» мәчетенә Ишкин Идрис тарафыннан тапшырылган «Кәлам шәриф тәфсире» (С.-Петербург, 1899), «Кыйссас әл-әнбия» (Казан, 1903), «Һәфтияк тәфсире» китапларының исемнәре генә дә бу төбәктәге татарларның никадәр динбелемгә омтылышлары турында сөйли.

Тарихи «Алты авыл»ның соңгысы Решетин авылы (Пачелма районы) иде. Биредә мине авылның имамы Ирфан Әнвар улы Тепаев каршы алды. Имам мәчеттә бик күп китаплар саклануын әйткәннән соң, беренче чиратта, мәчеттәге китаплар белән кызыксындым. Анда элеккеге имам Хансиверов Нязиф Исхак улыннан калган, шулай ук шушы авыл кешеләре Казиев Айнулла Мәүледбирде улы, Бариев Сәлимҗан Фәтхулла улы, Максутов Әхмәтҗан, хәзерге имамның әбисе Тепаева Факия Әхмәтҗан кызы тарафыннан тапшырылган шактый гына китаплар булуы ачыкланды.

Биредә ислам дөньясында билгеле булган «Мөхәммәдия», «Мең дә бер хәдис», «Ходай Тәгаләнең мең дә бер исемнәре хасиятләре берлән» (Казан, 1883), «Җәннәтел әсма» (С.-Петербург, 1903), «Китабе хәзрәт Йосыф галәйһиссәлам» (Казан, 1909), «Шөрут әс-салят тәрҗемәсе» (Казан, 1910), «Мөнбиһат тәрҗемәсе» (Казан, 1915) кебек дини китаплар белән бергә дөньяви белем бирә торганнары да бар. Мәсәлән, «Татарча уку» китабы халыкның әдәбиятка омтылышы турында сөйләсә, «Умарталар турында китап» авылда бал кортлары белән кызыксынулар булган, дигән фикерләр уята. Татар халкының бөек шагыйре «Габдулла Тукаевның мәҗмугаи асаре» китабы аеруча игътибарга лаек. Кызганычка, китапның башындагы һәм ахыргы берничә бите ертылган, бер карау белән генә китапның ничәнче елгы икәнен әйтеп булмый. Әлеге китап 1914 һәм 1918 елларда басылган. Китапта рәсемнәр булмауны исәпкә алып, аны 1918 елгы басма дип фаразларга мөмкин.

Китаплар барысы да басма. Шулай да әлеге материаллар арасында безнең өчен әһәмиятле булган кульязмалар да очрады. Алар – васыятьнамә һәм ике дәфтәрдә язылган мөнәҗәтләр (берсен 2014 елның декабрендә Нурҗиһан апа бүләк иткән).

Мәчеттә саклана торган китаплардан чыгып, авыл халкы элек-электән бик дини булган дияргә кирәк. Күп сандагы Коръән китапларын исәпкә алмаганда, анда 30 дан артык төрле эчтәлектәге китап барланды. Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» (5 нөсхә), Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» (2 нөсхә), «Тәфсире һәфтияк» (5 нөсхә) китапларының берничә нөсхәдә булулары электә аларның халык арасында еш укылганлыгы турында сөйли. «Ислам мәҗәлләсе» («Ислам җыентыгы», елы билгесез, 9–10 нчы саннар) журналының битләре дә бу җирлектәге халыкның бик кызыксынучан һәм дин-белемгә омтылучан булганлыгын күрсәтә.

Авылда яшәүче Казеева Сания Әхмәтҗан кызы (1936 елгы) әтисе Бариев Әхмәтҗан Фәтхулла улыннан калган «Әнварелгашыйкын», «Тәрҗемәи мохтәсарел викая» китапларын кадерләп саклаган. Сания апаның сүзләренә караганда, әтисе бу китапларны бик яратып укыган һәм үзенең улларының берсенә Әнвәр, ягъни «Нурлы» дип, исем дә кушкан.

«Алты авыл» боҗрасыннан чыгып, Пенза өлкәсендәге татар авылларын барлауны дәвам иттек. Чираттагы Ятмис (Кочалейка, Каменка районы) авылында да башлап танышкан кешеләремнең берсе авылның имам хатыйбы Хәмзә Юныс улы Еникеев булды. Хәзрәтнең өендә саклана торган китапларны («Мөхәммәдия», «Тәфсире һәфтияк» (1897), «Тәрҗемә әл-мәсаил вә җаваб әс-саил» (С.-Петербург, 1897), «Мохтәсар иман» (С.-Петербург, 1904) караганнан соң, гадәттәгечә, мәчеткә юл тоттык. Анда авыл халкы тарафыннан тупланган тулы «Мөхәммәдия» (Казан, 1903) һәм «Рисаләтел сигез җәннәт», «Рисаләи Газизә», «Һәфтияк тәфсире», «Алты бармак», «Гакаид исламия» (Казан, 1899), «Фәзаилеш шөһүр» китапларының аерым фрагментлары бар.

Абүбикарова Разия Шакир кызында (1948 елгы) авылда абыстай булып йөргән әнисе Еникеева Зәйнәп Хөсәен кызыннан (1911–1996) калган «Мәҗмәгъ әд-дәгъвәт», «Тәкый гаҗәб», Еникеева Разыя Ибраһим кызында (1933 елгы) С. Бикбулатның «Дин дәресләре» (Казан, 1918) китабы, «Әнварел гашыйкыйн» китабының аерым битләре сакланганлыгы билгеле булды.

Пачелма районы Татар Никольское авылы без үткән авыллар белән чагыштырганда күпкә кечкенә булса да, сакланып калган китаплар саны буенча бер дә башкалардан калышмый. Авылда яшәүче 150 ләп кешенең яртысыннан кимрәге генә татарлар булып чыкты. Мин турыдан-туры мәчеткә юл тоттым. Ибраһим Сөләйман улы Мамин (1937 елгы) муллалык иткән Аллаһ йортында иске китаплар табылмады. Биредә без генә түгел, авыл кешеләре үзләре дә кызыксынучанлык белдерделәр. Мөнәвәрә Али кызы Мамина (1946 елгы) каенатасы Усман Йосыф улы (1916–1972) белән каенанасы Латыйфа Идиятулла кызыннан (1908–1973) калган китапларны күтәреп, үзе үк мәчеткә килеп керде. Кадерләп төрелгән төргәктән кайчандыр болар «Мөхәммәдия», «Әхлак рисаләсе», «Һәфтияк шәриф», «Китабел-лөбаб», «Рисаләи нурнамә» (Казан, 1901), «Кыйраәте җәдидә», «Бәдел-мәгариф», «Китаб мөстәтаб. Рәүнәкыль ислам», «Абдәст вә намаз рисаләсе» (Казан, 1899), «Сөбател-гаҗизин», «Татарча уку», «Тәзкия әт-табигать» китаплары булганлыгын дәлилли торган бик күпне күргән аерым

басма китап битләре чыкты. Араларында «Әдәбле улмак»ка өйрәтә торган бер кулъязма да бар иде.

Мәрьям Зиннур кызы Мамина (1949 елгы) да авылда мулла булып торган каенатасы Гомәр хәзрәттән калган мирас белән таныштырды. «Корбан рисаләсе» (С.-Петербург, 1899), «Тәфсире һәфтияк» (Казан, 1900), «Гыйбадәте исламия»нең дүртенче җөзьэ (Казан, 1904), «Гасры сәгадәт», Г. Барудиның «Сөаль вә җаваплы бәдел мәгариф»е (Казан, 1908, 1911), «Китабы Устуани», «Китабы гыйльме халь» (тәһарәт кыйсьме, 3 нче җөзьэ) (Казан, 1915), Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия»се, «Фәзаилеш шөһүр», «Намаз нигезләре», «Кыйссас әл-әнбия тәрҗемәсе», «Мөгаллимел-гыйбадәт», «Мөгаллиме әүвәл», «Мөгаллиме сани яки әлифбаи гарәби» (Казан, 1914), «Дөнья» (гомуми география дәресләре) (Казан, 1918), «Гокуд саляс», «Хәвас әсма Аллаһ әл-хөснә» (С.-Петербург, 1895), «Тәрҗемәтел әнисел җәлис», «Сөбател гаҗизин» китапларын туплаган исемлек шактый зур булды. Ләкин аларның саклаunion сыйфатлары бик түбән иде.

Аралашкан кешеләремнең барысы да Мамин фамилияле булуы игътибарны җәлеп итте. Тарихи чыганакларга караганда, рус дәүләтенең татарларны чукындыруыннан качып, бу якларга Рязань өлкәсеннән татар морзалары килгәннәр. Татар Никольское авылында татар кенәзләре Маминнар яшәгән. 1917 елда биредә 177 хуҗалыкның 127 сендә Маминнар торган. Шулай итеп, мондагы татарлар әле дә үзләренең кенәз-морза бабаларының тамырларын саклыйлар.

Спасск районына керүче Шалдавыч авылы мәчетендә электкеге мулла Хәсән Әбүбәкар улы Курамшиннан калган дини китапларга тап булдык. «Коръән» китапларыннан тыш биредә «Мөхәммәдия» (Казан, 1902), «Китабе сөлләмел голүм» (Казан, 1887), «Догаи мөстәҗаб» (Казан, 1913), «Җәмигъ әл-хөтеб» (Казан, 1910), «Мәҗалисеш шөһүр», «Һәфтияк шәриф», «Шәраит әл-иман» (Казан, 1903), «Бинаи ислам», «Хәләби тәрҗемәсе» китаплары барланды. Шундый кечкенә авылда да борынгы ядкәрләрне саклаучы кешеләрнең булуы күңелгә рухи ләззәт бирә. Рәйсә Нәҗип кызы Курамшина (1938 елгы) үзендә сакланучы китапларны аңа базарда очраклы бер кеше

тапшырганын сөйләде. Әлеге «Алты бармак», «Мөхәммәдия», «Китабел әнмүзәҗ» китапларының ышанычлы кулларга эләгүе шатландыра. Рәйсә апаның балаларының бу ядкәрләрне әниләреннән соң да үзләрендә саклауларында шик юк. Заһидулла Каюм улы Юлгушев та (1939 елгы) үзендә «Догаи исме Әгъзам вә һәм башка шәриф догалар» (Казан, 1909) китабы барлыгын белдерде.

Пенза өлкәсендә алып барылган фәнни эзләнүләр нәтиҗәсендә гарәп хәрефендә татар һәм гарәп телләрендәге барлыгы 140 исемдәге басма китап теркәлде. Яңалыклар булмаганлыктан, нигездә, башсыз-ахырсыз, тулы булмаган китапларга күрә, без андыйларны җыймадык. Киресенчә, Решетин авылы мәчетендә тап булган «Габдулла Тукаевның мәҗмугаи асаре» кебек китаплар мәктәп музейларына куелып, укучыларга күрсәтмә әсбап итеп кулланылса, күпкә файдалырак булыр иде дигән теләкләрне җиткердек.

Кызганычка, бүгенге көндә гарәп хәрефле кульязма китап табу шактый авыр. Без йөргән татар авылларында да аларның булмавы гаҗәп түгел.

Әлеге төбәктә бик еш очраган Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия»се, Насретдин Рабгузиның «Кыйссас әл-әнбия»се («Пәйгамбәрләр тарихлары»), Әхмәт Биҗанның «Әнварелгашыйкыйн» («Гашыйклар нуры»), Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи-Газизә»се, «Бакырган китабы» кебек әдәби ядкәрләр күп еллар буена мәдрәсәләрдә дәреслекләр сыйфатында файдаланылып килгәннәр. Алар, әдәбилек белән бергә дини-дөньяви гыйлемне дә үзләренә сыйдырганнар. Һәм шуның аркасында гасырлар буена практик әһәмиятләрен югалтмыйча, халык арасында киң кулланылышта йөргәннәр. Һәр авылда бу китапларның очравы тагын бер кат аларның яратылып укылулары һәм бик популяр булганлыклары турында сөйли.

Әлбәттә, иске китапларга сакчыл карашлы кешеләрнең күп булуы куанычлы хәл. Әби-бабалардан калган рухи мирасны шулай кадерләп саклау үзенә күрә бер тәрбия чарасы да булып тора. Киләчәктә бу авылларда гарәп язулы китапларны укучылар булырына ышанасы килә. Халык кызыксына, өйрәнә. Кочалейка авылы мәчетендә җәйге каникул вакытында

оештырылган гарәп теленә өйрәтү дәресләре дә үзенең нәтиҗәләрен бирүендә шик юк, шулай ук Мачали авылында мәктәп ябылу сәбәпле эшсез калган Рәшит әфәнде дә үзендә сакланган мирас белән чын-чынлап кызыксынмас дип, кистереп әйтеп булмый.

Гомумән, хөрмәткә лаек халык яши Пенза өлкәсендә. Алар үзләренең бик гади, ачык йөзле һәм кунакчыл булулары белән күңелгә кереп калдылар. Вакытларын кызганмыйча, безгә чын күңелләреннән ярдәм итәргә тырышкан һәр кешегә үземнең олы рәхмәтләремне җиткерәм.

Кулъязма табышларның кайберләре түбәндә тәкъдим ителә:

**Манара бәете**

И манара, синең аең бик эрактан ялтырый,
И манара, син ауганда җөмлә[1] адәм калтырый.

Манара әйтә: «Әлвидагым, бүген мине кисәләр,
Әлвидагым, бәхил бул» – дип, кыйбладан җилләр исәләр.

Манараны кисәләр, дип, күп халыклар килделәр,
Җир йөзенә фәрештәләр саф-саф булып иңделәр.

Манара әйтә: «Кисәләр бит, авам, авам, тотыгыз!
Өммәтләрем, һәрберегез "Вәл гасрый укыгыз"».

Манара да, ай да, комган алынабыз дип дулкынлый,
Һаваларда ай да кояш, йолдызлар – бар да егълый.

Манараның тәрәзәсе бар да җиргә коелды,
Фәрештәләр, канат җәеп, саф-саф булып җыелды.

Борма-борма баскычларын алып-алып куйдылар,
Борма саен фәрештәләр саф-саф булып кундылар.

И манара, син булмагач, барча кошлар таралды,
И манара, син булмагач, ислам дине каралды.

Кайсы көлә, кайсы егълый, кыямәт көнгә охшый,
И манара, син булмагач, бетте азан тавышы,
Кунарга урын булмагач, моңлы кошлар тавышы.

---

[1] Җөмлә – барлык.

И манара, күп вакытлар әйтелгән иде азан,
Ходаның вәгъдәсе шулдыр, җитәдер ахыры заман.

Һавада болыт булмаса, җилләр дә исмәс иде,
Хакдин вәгъдә булмаса, алар да кисмәс иде.

Манараны кисү белән кояшның нуры бетте,
Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун дип, манара авып китте.

Манаралар ауган чакта йир-күк фәрештә егълашты,
Алланың әмере белән Җәбраил канат җәйде.

И манара, син киселгәч, егълашырбыз, әлфирак.
И манара, син куелгач, бөтен дөнья тулды нур,
Инде безгә рәнҗеп китмә, шәһре рәхмәт, шәһре нур.

Әлвидагым, и манара, бүген актык көннәрең,
Инде сине кисәбез дип, бар да килделәр бүген.

Мәсҗедкә әйтә манара: «Хәзер мине кисәләр»,
Җилләр бүген төн ягыннан ямьсез булып исәләр.

Мәсҗед әйтә: «Юк гөнаһым, кисәбез дип киләсез,
Кыяматтә минем өчен нинди җавап бирәсез?»

Мәсҗед әйтә: «И манара, и минем михрабларым,
Әлвидагым, исәнләшик, актыкка минутларым».

Мәсҗед әйтә: «Михрабым, и минем мөнбәрләрем»,
Күгәрчен әйтә: «Калдык ятим, кайда гына кунармын?»

Ничә еллар бу урында ялгыз утырды башым,
Биш вакыт намаз һәм тәравих, салават иде эшем.

Бар халыклар җыелганнар, бар да мәчет сүтәләр,
Мәсҗедтәге фәрештәләр тәкбир әйтеп китәләр.

Фәрештәләр җыелганнар, бар да тәкбир әйтик, дип,
Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр вә лилләхил-хәмд, дип.

Мәсҗед әйтә: «Актык минут, бик ашыгып кисмәгез,
Минем турдан узган чакта дога кылмый китмәгез».

Мәсҗед әйтә: «Ходай мине бу дөньяда зурлады,
Манарамны кисәр өчен ахирәттә хурлады».

Биек-биек манарамны монафикълар кисәләр,
Ахирәттә кисүчеләр тәмугына төшәрләр.

Манара да, ай да, комган каршы иде кыйблага,
Ничә еллар зикер-тәсбих әйткән идең Аллага.

И манара, ничә еллар син утырдың зур булып,
Сине сүтеп төшергәннәр йөрсен иде хур булып.

И манара, исемеңне бигрәк матур кушканнар,
Бәлки телгә килгән булсаң, куркыр иде дошманнар.

И манара, үзеңне кем кискәннәрен белмәдең,
Бер Ходайдан әмер булып, нигә телгә килмәдең?

И манара, син утырдың мөэминнәргә билгегә,
Сине кисеп төшергәннәр хур булсыннар мәңгегә.

И манара, сине кискәч, яңгыр яуды күкерәп,
Сине кисеп төшергәндә җирләр торды тетерәп.

И манара, таң туганда азан тавышын көтәбез,
Инде хәзер син булмагач, әрнеп гомер итәбез.

И манара, мескенкәем, аең белән ямьле идең,
Бик ерактан күренә идең, ялтыраган нур идең.

И манара, Мәсҗедкәем, сагына сине мөэминнәр,
Азан да юк, намаз да юк, зәгыйфьләнде бит диннәр.

И манара, күп вакытлар яшәдең бу калада,
Инде килде сиңа вакыт ошбу фани дөньяда.

Кая синең башларың дәгъвәт иткән[1] чакларың,
Хуш аваз белән мөәзиннең азан әйткән чаклары.

**Суга барган ана бәете**

Тугыз ай ун көн күтәрдем,
Тугач та ак сөтем бирдем.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Баламнан катылык күрдем.

Аналар утыра түрдә,
Вакытсыз кермиләр гүргә.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Ананы сөймиләр бер дә.

[1] Дәгъвәт иткән – чакырган.

Балакаем, ике күзем,
Асырап картайдым үзем.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Бары ялган минем сүзем.

Иртә торсам ике аягым
Кая басарга урын тапмый.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Ана гаебен бала япмый.

Тау булса да ана каплый
Балаларның гаепләрен.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Ана гаебен бала япмый.

Ананың күңеле балада,
Баланың күңеле далада.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Миһербан юк һич балада.

Балам мине алдап әйтте,
Диңгез төбенә барырга.
Ходаем язмаган тәкъдир
Су төбендә җан бирергә.

Ходаемнан әмер булгач,
Тал тамырына тотындым.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Ничек үлмәенчә котылдым.

Карт анасын суга барып,
Асыраудан котылдылар.
Газиз җаным һаман әрни,
Кяфер кулына тотылдылар.

Балаларым уйламыйча,
Тоткын зинданга кердегез.
Ата-ана гомере тормый,
Үлмәсме диеп белдегез.

Диңгез эченнән чыгарганда
Бөтен әгъзам калтырый.
Үземнән допрос алганда,
Җавап бирәлмим, аптырыйм.

Хөкемчегә ялварамын,
Бәхиллим балаларымны, яптырма.
Балаларымны яптырып,
Гомер буема егълатма.

Минем хәлем язып бетми,
Кәгазь илә җитми кара.
Балаларга авыр була,
Мескен гарип ата-ана.

Балалар үстерәбез дә
Намазларны калдыра-калдыра.
Балаларымыз шулай әйтә:
«Ник үлми бу ата-ана?»

Моряклар судан алдылар,
Тотып минем беләгемнән.
Суга барган куркуларым
Һич китмидер йөрәгемнән.

*Яваев Фируша Абделкадыйр улында (1950 елгы) сакланган кулъязмадан эшләнде (Белинский районы Кутеевка авылы)*

**Мөнәҗәт**

Әҗәл ширбәтен бер көн эчәрмен,
Якты дөньядан бер көн китәрмен.
Якты дөньяны күреп туймадым,
Күреп туйсам да мәңге тормамын.

Әҗәлләр җитәр, хәлләрем бетәр,
Ясин укырга вакытлар җитәр.
Укый алмамын, бетәр сулышым,
Булмас артымнан дога кылучым.
Килер Газраил, җанымны алыр,
Кызыл йөзләрем саргаеп калыр.
Якты дөньяны ташлап китәрмен,
Караңгы гүрләрдә ни хәл итәрмен.
Караңгы гүрдә калыр бу башым,
Газиз иманым булсын юлдашым,
Авыр хәл икән җанны бирүе,
Мөшкел хәл икән гүргә керүе.
Шатланыр идем атна кич үлсәм,
Җомгага кадәр гүремә керсәм.
Җанымны алсын атна кичендә,
Газап кылдырма каберем эчендә.
Газиз туганнар, якын иптәшләр,
Дога кылыгыз, мөэмин кардәшләр.
Үтенәм сездән дога кылуны,
Җәннәт эчендә бергә булуны.
Озак тормамын, мин бер үләрмен,
Калган сүземне кемгә сөйләрмен.
Килер дусларым, юа башларлар,
Киемнәремне алып ташларлар.
Тактага салып, тәнем юарлар,
Юып пакьләгәч, кәфен сорарлар.
Минем буемны үлчәп алырлар,
Караңгы гүргә илтеп салырлар.
Зәгыйфь тәнемне каты тотмагыз,
Озак тормыймын, ашыктырмагыз.
Ерак җирләрдән күргән-белгәннәр,
Дога кылыгыз, мөэмин кардәшләр.
Тордым дөньяда бераз вакытлар,
Салкын туфраклар безгә ястыклар.
Караңгы гүргә кемнәр китергән,
Салкын туфракта чери бу тәннәр.
Каберем өстенә чардак корыгыз,
Агач утыртып, нурландырыгыз.

Яфраклар ярса, кошлар сайраса,
Рухым шатланыр, догалар барса.
Үләннәр үсәр каберем өстенә,
Иман нур булсын каберем эчендә.
Нурлы иманым бирсен юлдашка,
Авыр хәл килә, дуслар, бу башка.

*Тахтарова Флера Назгар кызында (1969 елгы)*
*саклана торган кулъязманың күчермәсеннән эшләнде*
*(Каменка районы Тәләтен авылы)*

**Әйтик салават**

Әйтик салават, Ходайны берләп,
Йөрмәсен безне иблис җәберләп.
Әйтик салават, калеб пакь булсын,
Ярым мәхшәрдә йөземез ак булсын.
Әүвәл Аллаһка, Рәсүлуллаһка,
Янә Рәсүлнең әсхабларына.
Рәсүлуллаһның чыкмыйк юлыннан,
Күтәр шәрабен, эчтер кулыннан.
Рәсүлуллаһка әйтик салават,
Кыямәт көнендә кылыр шәфәгать.
Рәсүлуллаһның өммәте булыйк,
Өммәте булыйк, сөннәтен тотыйк.
Рәсүлуллаһны күрсәм төшемдә,
Һич булмас идем дөнья эшендә.
Я туганнар, дога кылыйк,
Кыямәт көнендә бергә булыйк.
Догаларыбыз кабул булса иде,
Рәсүлуллаһыбыз каршы алса иде.
Җаным морадым шул иде, Илаһым,
Күрсәт безгә җәннәт дидарың.
Хәсән-Хөсәен дә Рәсүл янында,
Фатыйма торыр мизан алдында.
Фатыйма үзе Рәсүл кызы бит,
Кыямәт көнендә оялырбыз бит.
Рәсүлнең кабере өстендә чәчәкле гөлләрне күрсәм,
Шәфәгать өмет итеп, үзем шул юлларда йөрсәм.

Рәсүлнең кабере өстендә зекерләр әйтәләр кошлар,
Зекер әйткән кошлар кебек салават укыйк, дуслар.
«Әс-саләтү вә-с-сәләмү галәйкә йә расүлуллаһ,
Әс-саләтү вә-с-сәләмү галәйкә йә расүлуллаһ,
Әс-саләтү вә-с-сәләмү галәйкә йә расүлуллаһ,
Әс-саләтү вә-с-сәләмү галәйкә йә расүлуллаһ».
Салават әйтсә бер бәндә тәмугъ утына ул пәрдә,
Салават әйткән кешенең йөзе ак булыр мәхшәрдә.

*Тумеркина Фирдәүс Казыйм кызында (1961 елгы)*
*саклана торган кульязманың күчермәсеннән эшләнде*
*(Белинский районы Кутеевка авылы)*

**Мөнәҗәт**

Бу дөнья фикерен ташлап, ахирәт фикерен башлап,
Менә бит яза башладым, дәфтәр сызыклары буйлап.
Язам-язам да егълыймын, кыямәт хәлләрен уйлап.
Гафил булмыйк, тәүбә кылыйк, үткән гомер кайтып килмәс,
Кыямәт көне үкенсәк тә, үкенечләр файда бирмәс.
Гафил булмыйк, тәүбә кылыйк, кичен йокыга ятканда,
Куркынычлы хәлләр булыр кыямәт таңы атканда.
Кыямәт таңы атканда кабер өстенә чыгабыз,
Сулар кибәр, күк кызар, ничек, туганнар, чыдарбыз.
Мәхшәр йиренә куарлар, һәрбер гамәлдән сорарлар,
Авыр булыр шунда хәлләр, ни хәл итәбез, туганнар.
Сират күперенә менгәнче һәрбер гамәлдән сорарлар,
Кылдан нечкә сиратны тәмуг өстенә сузарлар.
Я Илаһым, кадир Мәүлам, зәгыйфь кылма иманымны,
Сират күперен кичкәндә тайдырмагыл аягымны.
Аллаһ теләгән бәндәләр дөньядан иманлы үткәй,
Иманлы булган бәндәләр сиратдин яшин тик күчкәй.
Кыямәт көне агыр хәлләр, пәйгамбәрләр дә үзен теләр,
Тәмуглы булган бәндәләр, энҗе тик яшьләрен түгәр.
Гөнаһларым хәддин ашты, дәрья кебек тулды, ташды,
Күңел күземә күренә биек-биек таулар хәтле.
Кыямәт көне булганда Ходай үзе җавап алыр,
Җавап бирә алмаган бәндә гаҗиз булып хәйран калыр.
Без фәкыйрьләрне ярлыка Рәсүлуллаһ хөрмәтенә,
Әй рәхимле падишаһым, таянамын рәхмәтеңә.

Дуслар безгә зур сөенеч, Ходай биргән мөэмин атын,
Мөэмин булган бәндәләргә хәрәм кылган тәмуг утын.
Мөэминлекнең кадерен белик, иблиснең артыннан йөрмик,
Үземезнең тәнемезгә тәмуг утын дәва күрмик.
Я Раббем, кадир Мәүла, ки сәндин гайре юк Аллаһ,
Иманымны зәгыйфь кылма, җәһәннәм утына салма.
Бер Аллаһдин әмер булгач, Газраил җаныңны алыр,
Балаларың, кардәшләрең илтеп кабергә салыр.
Тәрәзе булмас багарга, ишеге булмас чыгарга,
Еланнар килсә чагарга, ничек, туганнар, чыдарга.
Сөекле дустым Газраил, күркәм сыйфатың берлән кил,
Йомшаклык берлән ал җанымны, нурлы кыл, Раббем, каберемне.
Әй Илаһым, кадир Мәүла, камил кылгыл иманымны,
Мөнкир-Нәнкир фәрештәгә җиңел әйлә сөалемне.
Азыгыңны күп хәзерлә, сәфәрең ерак килмәсен,
Кыямәт хәлләрен уйласаң, агызың ачып, һич көлмәссең.
Я гафил, ни ятарсың, болай ятып ни көтәрсең,
Килер сиңа гаҗәп бер көн, дөньяны ташлап китәрсең.
Я гафил, ни уйлыйсың, хәтереңдә үлем бармы,
Кабер дигән караңгы өй, итәргә нурларың бармы.
Кыямәт хәлләрен уйлап, егълаган яшьләрең бармы,
Кабер дигән караңгы өй, итәргә иптәшең бармы.
Йитәр безгә бу нәсыйхәт, Аллаһ калебләргә салсын,
Тыңлаганнар, ишеткәннәр кыямәтдин гыйбрәт алсын.
Ахирәт бәетен язам, дәфтәр сызыклары буйлап,
Күңелең таш булса да, эрер кыямәт хәлләрен уйлап.
Уйлыймын да хәйран калам,ниләр килер бу башыма,
Ничек җавабымны бирим яраткан Аллаһ каршында.

*Кудряков Рамил Камил улында (1979 елгы)*
*саклана торган кульъязманың күчермәсеннән эшләнде*
*(Каменка районы Кабылкин авылы)*

# ТАТАР ТЕЛЕ КӨНБАТЫШ ДИАЛЕКТЫНЫҢ КУЗНЕЦК СӨЙЛӘШЕ ҺӘМ ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

*Миңнира Булатова*

2019 елның 27 маеннан алып 7 июненә кадәр Пенза өлкәсенең Неверкино, Кузнецк һәм Сосновоборск районнарындагы 18 татар авылына Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан комплекслы экспедиция уздырылды: Неверкино районының Али (Алеево), Сарбай (Сулеймановка), Кырнавар, Мансур, Биги (Бигеево), Бикмосеевка, Исәкәй, Җәлил, Мазарлы (Октябрьское), Дөмавыл (Дёмино); Кузнецк районының Бистән (Бестянка), Пәлдәнге (Татарская Пенделка), Ялгаш (Большой Труев), Татар Кынадысы, Дәхтәрни (Малый Труев); Сосновоборск районының Индерка, Әлмәш (Альмяшевка), Сәләмәс (Татарский Сыромяс) авыллары. Бу авыллардагы сөйләш татар теле көнбатыш (мишәр) диалектының кузнецк сөйләше дип атала.

Тарихка килгәндә, татар теленең көнбатыш (мишәр) диалекты вәкилләренең иң борынгы яшәгән җире булып Цна һәм Мокша елгалары бассейннары санала. XVI–XIX гасырларда Рус дәүләте тарафыннан аларны бу урыннардан башта көнчыгышка, аннан соң көньяк һәм көньяк-көнчыгыш юнәлешләрендә күчереп утырту сәясәте алып барыла. Бу күчеш Рус дәүләте чикләрен күрше күчмә халыклар һөҗүменнән саклау өчен, хөкүмәт тарафыннан ныгытмалы саклану

сызыклары, яңа крепостьлар төзү белән бәйле. Рус дәүләтенең чикләре киңәя барган саен, әлеге саклану сызыкларының урыннары да күчә барган. Пенза төбәгенә мишәр татарлары 300–400 еллар элек Төмәннән (хәзерге Мордовиядә Темников шәһәре һәм районы) һәм Сембер губернасыннан күченеп килеп утырганнар.

Татар теленең көнбатыш диалекты вәкилләренең күп өлеше Пенза, Түбән Новгород, Саратов, Самара, Ульяновск өлкәләрендә һәм Башкортстан, Татарстан, Мордовия, Чувашстан республикаларында яши. Бер өлеше Әстерхан, Волгоград, Оренбург, Рязань, Ставрополь, Тамбов өлкәләрендә; шулай ук Себер, Урта Азия, Балтыйк Буе республикаларында, Мәскәү, Санкт-Петербург һ. б. территорияләрдә дә көн күрә.

Россиянең төрле губерналарыннан чыккан татар-мишәрләр, шул исәптән, Пенза татарлары, Казан татарлары белән берлектә, төрле сөйләш формалашуда зур роль уйнаганнар. Мәсәлән, хәзерге Башкортстан территориясенә мишәрләр XVI гасыр ахырында (1586 елда) Уфа шәһәре төзелә башлауга бәйле рәвештә күчереләләр, төбәкнең көньяк-көнбатыш районнары территориясенә XVI–XVIII гасырларда Пенза, Сембер, Тамбов губерналарыннан үз ирекләре яки хөкүмәт рөхсәте белән дә күчеп утыралар: шулай итеп, байкыбаш[1], стәрлетамак[2] сөйләшләре формалаша. Алар, авыллар булып, төркем-төркем урнашалар һәм көнбатыш (мишәр) диалектның специфик үзенчәлекләрен төрле дәрәҗәдә саклап киләләр; кайбер авыл, районнарда алар шактый нык сакланган.

Көнбатыш диалект вәкилләренең тарихы, теле галимнәрне күптән кызыксындыра башлый. XIX гасыр ахыры XX гасыр башларында А.Г. Бессонов, Г.Н. Әхмәров, Н.И. Золотницкий, В.А. Казаринов, Н.Ф. Катанов, Е.А. Малов, С.Е. Малов һ. б.

---

[1] *Булатова М.Р.* Татарские говоры Башкортостана: ареальный аспект. Казань: ИЯЛИ, 2021. 136 с.

[2] *Булатова М.Р.* Татар теле көнбатыш диалектының стәрлетамак сөйләше // Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш. 1 кис. 2 бас. Казан, 2021. Б. 87–130.

галимнәрнең әлеге татарларның сөйләм теленә азмы-күпме кагылышлы хезмәтләре дөнья күрә[1].

Мәсәлән, Башкортстанның көнбатыш районнарындагы татар сөйләшләрен беренче булып өйрәнүче рус галиме А.Г. Бессоновның 1881 елда зур күләмле фәнни мәкаләсе басылып чыга. Анда ул бу төбәктәге татар сөйләшләренең «Казан татар сөйләшенә якын булу дәрәҗәсен» карый. Типтәрләр (билгеле булганча, татар теленең минзәлә сөйләше вәкилләренең зур өлеше «типтәр» катламы (сословие) дип йөртелгән) сөйләшен ул Казан татарлары теленә иң якын торган сөйләш дип билгели һәм «типтәрләр сөйләшенең оешуында билгеле бер дәрәҗәдә мишәрләр сөйләшенең йогынтысы булган» дигән фикергә килә[2]. Бу фикернең гадел булуы абруйлы татар диалектологы Д.Б. Рамазанова материаллары белән дә раслана. Ул, Башкортстан сөйләшләрен өйрәнүче галим буларак, Башкортстанның көньяк-көнбатышындагы татар сөйләшләренең күпмедер дәрәҗәдә мишәр сөйләшләре йогынтысында формалашканлыгын дәлилли[3]. А.Г. Бессонов тел арты [к] тартыгы, аннан соң килгән авазларның «йомшаруы», *-сы*/*-се* икеләтелгән

---

[1] *Ахмаров Г.Н.* О языке и народности мишарей // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Имп. Казан. ун-те. Т. XIX, вып. 2. Казань, 1903. С. 92–160; *Бессонов А.Г.* О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам // Журнал Министерства народного просвещения. Ч. CCXVI. СПб., 1881. С. 200–242; *Казаринов В.А.* О мишарях в Чистопольском уезде Казанской губернии // Известия общества археологии, истории и этнографии при Имп. Казан. ун-те. Т. IV. Казань, 1884. С. 9–10; *Катанов Н.Ф.* Отчет о поездке, совершенной с 20 мая по 20 августа 1898 года в Белебеевский уезд Уфимской губернии // Уч. зап. Имп. Казан. ун-та. Кн. 7–8. Казань, 1900. С. 1–32; *Малов С.Е.* Из поездки к мишарям (о наречии мишарей Чистопольского уезда). Казань: Тип. Импер. ун-та, 1904; *Малов Е.А.* Сведения о мишарях (этнографический очерк) // Изв. общества археологии, истории и этнографии при Имп. Казан. ун-те. Т. IV. Казань, 1884. С. 13–91; *Малов С.Е.* Из поездки к мишарям (о наречии мишарей Чистопольского уезда) // Приложение к учёным запискам Казанского университета, 1904.

[2] *Бессонов А.Г.* О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам // Журнал Министерства народного просвещения. Ч. CCXVI. СПб., 1881. С. 231.

[3] *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западного Башкортостана. 2-е изд. Казань: ИЯЛИ, 2021. С. 10.

тартым кушымчасы кулланылуга (мәсәлән, *урнысы* һ. б.) һ. б. тел үзенчәлекләренә игътибар итә[1].

Октябрь инкыйлабыннан соң күренекле тел галиме Җ. Вәлиди дә татар диалектологиясе белән кызыксына башлый һәм бу өлкәдә шактый эш башкара. Ул үзенең хезмәтендә[2] «казан-татар телен» өч диалектка бүлеп карый: казан, мишәр һәм урал-уфа сөйләшләренә. Көнбатыш (мишәр) диалект турында мәгълүмат бирә. Эстафета Җ. Вәлиди кулыннан Л. Җәләйгә күчә һәм шуннан соң татар диалектлары эзлекле рәвештә бөтен киңлеге һәм тирәнлегендә өйрәнелә башлый. Татарлар күпләп яшәгән Идел буе һәм Урал төбәкләренә җирле сөйләшләрне тикшерү-өйрәнү өчен күпсанлы экспедицияләр турыдан-туры Л. Җәләй катнашында һәм җитәкчелегендә оештырыла. Шуның нәтиҗәсе буларак, галимнең «Татар диалектологиясе» (1947) дигән монографиясе[3] басылып чыга. Галим бу хезмәтендә татар диалектларының өйрәнелү тарихын, классификациясен бирә һәм аларның төп үзенчәлекләрен билгели. Көнбатыш диалектның фонетик, морфологик һәм лексик үзенчәлекләреннән тыш синтаксик күренешләргә дә кыскача гына күзәтү тәкьдим итә.

XX гасырның икенче яртысыннан башлап СССР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер – сәнгать) институты тел белгечләре татар диалектларын, шул исәптән көнбатыш диалектны, өйрәнүгә ныклап керешә. Диалектологлар Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова, Г.К. Якупова, Д.Б. Рамазанова, Л.Ш. Арсланов, Ф.С. Баязитова, Ф.Ю. Юсупов, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова татарлар гомер иткән төрле төбәкләрдә уздырылган экспедицияләрдә катнашалар һәм милләттәшләребезнең тарихына, тел үзенчәлекләренә, матди-рухи мәдәниятенә кагылышлы фәнни мәкаләләр, җыентыклар, китаплар бастырып чыгаралар.

---

[1] *Бессонов А.Г.* О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам // Журнал Министерства народного просвещения. Ч. CCXVI. СПб., 1881. С. 238–240.

[2] *Валиди Дж.* О диалектах казанского татарского языка // Вестник научного общества татароведения. 1927. 36. С. 50–65.

[3] *Җәләй Л.* Татар диалектологиясе. Казан, 1947. Б. 136.

Хәзерге көндә татар диалектологиясендә көнбатыш диалектка караган 19 сөйләш билгеләнгән. Һәр сөйләш махсус экспедицияләр оештырылып, татар теленең диалектологик атласын төзү программасы нигезендә лингвистик география методы белән өйрәнелә: беренчеләрдән булып, мәсәлән, ләмбрә, темников сөйләшләрен – Н.Б. Борһанова[1], хвалын, байкыбаш сөйләшләрен – Л.Т. Мәхмүтова[2], стәрлетамак сөйләшен – Д.Б. Рамазанова[3], чүпрәле, волгоград сөйләшләрен – Л.Ш. Арсланов[4], шарлык сөйләшен З.Р. Садыйкова[5] ача һәм тасвирлый.

Диалектологлар тарафыннан татар халкының бөтен сөйләшләрен колачлаган, аларның фонетик, грамматик һәм өлешчә лексик үзенчәлекләрен тасвирлаган ике томлы «Татар халык сөйләшләре» (2008) дип аталган зур хезмәт басылып чыга. Татар теленең көнбатыш диалектына караган сөйләшләр китапның икенче томында урын ала[6].

XXI гасыр башында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты милләттәшләребез көн күргән төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештыра башлый. Эшне мондый юл белән алып барганда, татарларның тел үзенчәлекләреннән тыш, халык авыз иҗаты үрнәкләре, йола-гадәтләре, музыкасы, йорт-каралты бизәкләре, эпиграфик һәм археографик мирасы да өйрәнелә. Көнбатыш диалект вәкилләре яшәгән өлкәләргә

---

[1] *Борһанова Н.Б.* Татар теленең Мордва АССР территориясендә таралган сөйләшләре турында // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962. С. 93–124.

[2] *Махмутова Л.Т.* Краткие заметки о хвалынском говоре мишарского диалекта татарского языка // Вопросы диалектологии тюркских языков. Баку, 1966. С. 80–83; *Махмутова Л.Т.* О татарских говорах северо-западных районов Башкирской АССР (по материалам экспедиций 1954–1957 гг.) // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962. С. 57–85.

[3] *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западного Башкортостана. Казань, 1984. С. 113–164.

[4] *Арсланов Л.Ш.* Татарские говоры правобережных районов Татарской и Чувашской АССР: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1966. 29 с.; *Арсланов Л.Ш.* Татары Нижнего Поволжья и Ставрополья (язык, фольклор, словарь). Набережные Челны, 1995. 195 с.

[5] *Садыкова З.Р.* Говоры оренбургских татар. Казань, 1985. 160 с.

[6] Татар халык сөйләшләре: ике китапта / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ. б. Казан: Мәгариф, 2008. II китап. 463 б.

дә фәнни сәфәр уздырыла һәм аларның нәтиҗәләре «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә дөнья күргән «Милли-мәдәни мирасыбыз» дигән коллектив китапта яктыртыла. Татарстан Республикасының Чүпрәле районы, Башкортстан Республикасының Стәрлебаш районы, Түбән Новгород, Оренбург, Ульяновск өлкәләре татарларына багышланган китапларда диалектологлар Д.Б. Рамазанова[1], Ф.С. Баязитова[2], М.Р. Булатованың[3] мәкаләләре дә урын алган. Галимнәр анда көнбатыш диалектның чүпрәле, стәрлетамак, сергач, шарлык, хвалын, карсун, мәләкәс сөйләшләренең өйрәнелү тарихын, тулы фонетик, морфологик, өлешчә лексик характеристика, халык традицияләрен яктырткан сөйләү үрнәкләрен бирәләр.

XVI гасырда ук көнбатыш диалект сөйләшләре ике типка – чылаштыручыларга һәм цылаштыручыларга аерылган булган. Соңга таба, төрле тарихи сәбәпләр аркасында, бер-берсенә якын торган яңа сөйләшләр барлыкка килә. Алар фәндә кабул ителгән территориаль-лингвистик билгеләр нигезендә бүленеп чыгалар.

---

[1] *Рамазанова Д.Б.* Телен белгән – тарихын да белер // Милли-мәдәни мирасыбыз: Оренбург өлкәсе татарлары. Казан, 2016. Б. 75–94; *Рамазанова Д.Б.* Кардәшемә якын итеп дәшәм: туганлык атамалары үзенчәлекләре // Милли-мәдәни мирасыбыз: Түбән Новгород. Казан – Түбән Новгород – Мәскәү, 2011. Б. 97–109; *Рамазанова Д.Б.* Карсун сөйләше турында кайбер күзәтүләр // Милли-мәдәни мирасыбыз: Ульяновск өлкәсе татарлары. 2 нче басма. Казан, 2021. Б. 208–234.

[2] *Баязитова Ф.С.* Сүләмә келим, тыңлауцы булса... // Милли-мәдәни мирасыбыз: Чүпрәле. Казан, 2016. Б. 137–160; *Баязитова Ф.С.* Йомшак телле мишәрләрем // Милли-мәдәни мирасыбыз: Түбән Новгород. Казан – Түбән Новгород – Мәскәү, 2011. 2 нче китап. Б. 45–96; *Баязитова Ф.С.* Җирле сөйләшләр һәм халык традицияләре // Милли-мәдәни мирасыбыз: Самара өлкәсе татарлары. 2 нче басма. Казан, 2021. Б. 63–99; *Баязитова Ф.С.* Еллар үткән халык йоласы // Милли-мәдәни мирасыбыз: Оренбург өлкәсе татарлары. 13 нче китап. Казан, 2016. Б. 104–138.

[3] *Булатова М.Р.* Татар теле көнбатыш диалектының стәрлетамак сөйләше // Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш. 1 нче кисәк. Казан, 2019. Б. 87–130; *Булатова М.Р.* Татар теленең көнбатыш диалектының Ульяновск өлкәсендәге сөйләшләре һәм халык традицияләре // Милли-мәдәни мирасыбыз: Ульяновск өлкәсе татарлары. 2 нче басма. Казан, 2021. Б. 146–207; *Рамазанова Д.Б., Булатова М.Р.* Татар теленнән таныр // Милли-мәдәни мирасыбыз: Чүпрәле. Казан, 2016. Б. 85–136.

Кузнецк сөйләше татар теле көнбатыш диалектының чылаштыручы төркеменә карый һәм ул, гомумән, Пенза өлкәсенең Сосновоборск, Городище, Шемышейка, Кузнецк, Беднодемьянск, Пачелма, Белинский, Каменка, Неверкино һәм Лопатино районнарында таралган.

Кузнецк сөйләше беренче тапкыр тел белгече Л.Т. Мәхмүтова тарафыннан өйрәнелә[1]. 1978 елда галимәнең кузнецк һәм башка мишәр сөйләшләре турындагы зур күләмле «Опыт исследования тюркских диалектов (мишарский диалект татарского языка)» исемле китабы басылып чыга[2]. Китапта көнбатыш диалектның фонетикасы, морфологиясе татар әдәби теле һәм башка төрки телләр белән чагыштырып тасвирлана.

1985 елда Ф.С. Баязитова тарафыннан да Пенза өлкәсенә махсус диалектологик экспедиция уздырылып, шактый күләмле материал туплана[3]. Бу төбәк татарларының тарихы, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, этнографиясе, аларга хас сөйләш-тел үзенчәлекләре галимнәрнең фәнни, фәнни-популяр мәкалә һәм китапларында чагылыш таба. Мәсәлән, алар татар диалектологиясенең җитди казанышларын тәшкил иткән «Урта Идел һәм Урал төбәге татар халык сөйләшләре атласы» (1989), «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге» (2009), «Татар халык сөйләшләре» (ике китапта, 2008), тулыландырылган һәм эшкәртелгән «Татар халык сөйләшләре атласы» (2015); шулай ук «Татар диалектларыннан сөйләү үрнәкләре» (Рамазанова Д.Б., 2011), «Татар-мишәр рухи мирасы: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор» (Баязитова Ф.С., 2003), «Мордовия Республикасы һәм Пенза өлкәсе татарлары: диалектология һәм халык иҗаты материаллары» (Кадирова Э.Х.,

---

[1] *Махмутова Л.Т.* Основные характерные черты мишарских говоров на территории Пензенской области (по материалам экспедиций 1958–1960 гг.) // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962. С. 125–162.

[2] *Махмутова Л.Т.* Опыт исследования тюркских диалектов (мишарский диалект татарского языка). М., 1978. 271 с.

[3] *Баязитова Ф.С.* Кузнецк сөйләше // Татар халык сөйләшләре: ике китапта / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ. б. / Казан: Мәгариф, 2008. II китап. Б. 42–53.

Галиуллина Г.Р., Сәйфуллина Ф.С., Юсупова Ә.Ш., 2016) кебек хезмәтләрдә дә урын алган.

Югарыда әйтеп узуыбызча, безнең тарафтан да, ягъни 2019 елда Пенза өлкәсенең Неверкино, Кузнецк һәм Сосновоборск районнарындагы татар авыллары өйрәнелде. Җыелган материалларыбыз фонетик, грамматик һәм лексик яктан тикшерелде.

Гомумән, татар әдәби теле үсешендә көнбатыш (мишәр) диалекты мөһим урын тота. Әдәби тел үзенең фонетик һәм лексик төзелеше белән урта диалектка якын торса, аның морфологик төзелеше күбрәк мишәр диалектына нигезләнә. Көнбатыш диалектның башка сөйләшләрендәге кебек, кузнецк сөйләшендә дә сүз төркемнәре һәм аларның төп грамматик категорияләре, нигездә, татар әдәби телендәгечә. Үзенчәлекле саналган морфологик билгеләрнең күпчелеге теге яки бу морфологик категориянең яки күренешнең төрле фонетик вариантлары булудан гыйбарәт. Әдәби телдә очрамаган, сөйләшләрнең спецификасын тәшкил итә торган сүзләр шактый булса да, көнбатыш диалектның төп лексик составын татар әдәби теле белән уртак сүзләр тәшкил итә. Фонетик һәм грамматик үзенчәлекләрдә дә шундый ук күренеш саклана.

Түбәндә кузнецк сөйләшенә кыскача анализ һәм халыкның рухи-матди мәдәниятен яктырткан сөйләү үрнәкләре тәкъдим ителә.

## Фонетик үзенчәлекләр

Кузнецк сөйләше фонетик үзенчәлекләре ягыннан татар теле көнбатыш (мишәр) диалектының башка сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә, бигрәк тә күрше Ульяновск өлкәсендә таралган хвалын, карсун һәм мәләкәс сөйләшләре белән[1]. Шуның белән бергә, сөйләшне билгели торган аерымлыклар да бар. Алар, башлыча, кайбер авазларның әйтелешендә, аваз тәңгәллекләрендә һ. б. да чагыла.

---

[1]*Булатова М.Р.* Татар теленең көнбатыш диалектының Ульяновск өлкәсендәге сөйләшләре һәм халык традицияләре // Милли-мәдәни мирасыбыз: Ульяновск өлкәсе татарлары. 2 нче басма. Казан, 2021. Б. 146–207.

**Сузыклар.** Кузнецк сөйләше [а] авазын, көнбатыш диалектка хас булганча, ачык итеп, иренсезләштереп әйтү белән характерлана: *алма* – әдәби әйтелеш *а$^{о}$лма$^{о}$*, язылышта *алма*; *бала* – әд. әйтелеш *ба$^{о}$ла$^{о}$*, язылышта *бала* һ. б. Авазның ачык әйтелүе барлык позицияләрдә дә саклана.

[у], [ү] ирен сузыклары, әдәби телдәге [у], [ү] авазларына караганда, таррак әйтелә, сүзләрнең беренче иҗегендә килгәндә, алар дифтонгоид [у$^{о}$], [ү$^{ө}$] булып та әйтеләләр: *кү$^{ө}$з* – әд. күз, *йу$^{о}$к* – йук, граф. юк, *бү$^{ө}$рке* – бүрек, *кү$^{ө}$лмәк* – күлмәк, *кү$^{ө}$ңел* – күңел һ. б.

[у (у$^{о}$)]~[о], [ү (ү$^{ө}$)]~[ө]: *бутка* – әд. ботка, *ту$^{о}$з* – тоз, *үмер* – гомер, *үмә* / *ү$^{ө}$мә* – өмә, *ү$^{ө}$чөн* – өчен һ. б.

Әдәби телдәге [у], [ү] авазлары урынына [о], [ө] яки [ы$^{о}$], [э(е)/е$^{о}$] куллану очраклары да бар: *орлау* – әд. урлау, *ол* – ул; *көңөл* – әд. күңел, *мөх* – мүк, *төбә* – түбә, *көп* – күп, *тегел* / *те$^{о}$гел* – түгел, *че$^{ө}$прәк* – чүпрәк һ. б.

Аерым авылларда [о]~[ы/ы$^{о}$], [е/э]~[ө] тәңгәллеге дә очрый: *йымырка* – әд. йомырка, *тешле* – төшле, *ке$^{ө}$н* – көн һ. б.

Кайбер сүзләрдә [ә]~[и]: *мәләш* – әд. миләш, *дәңгез* – диңгез, *нәк* – ник; киресенчә [и]~[ә] тәңгәллеге дә очрый: *тирәс(з)* – әд. тәрәзә, *пике* – пәке һ. б.

Алгы рәт сузыкларының арткы рәт сузыклары урынында кулланылуы: [ә]~[а]: *сәлену* – әд. салыну, *берәз* – бераз, *әз* – аз, *бәлчек* – балчык һ. б.

Һәм киресенчә, арткы рәт сузыклары алгы рәт авазларына тәңгәлләшә: [а]~[ә]: *чыган* – әд. чегән, *йанаша* – йәнәшә (янәшә), *хазырлаганнар* – хәзерләгәннәр, *бар'ам* < байрам – бәйрәм, *корка* – күркә һ. б.

Рус сүзләрендәге [о] авазына сөйләштә [у] авазы туры килә: *часнук* – чеснок, *мәшук* – мешок, *пәсук* – песок, *пул асты* <рус. *пол асты* – баз, *бучка* – бочка, *кину* – кино, *рагужа* – рогожа, *пымадур* – помидор, *пугар'ап* – погреб, *путалак* – потолок, *насук* – носок һ. б.

[ы]~[у]: *фартык* – фартук, *капыста* – капуста һ. б.

**Дифтонглар.** Кузнецк сөйләшендә, татар теленең башка мишәр сөйләшләрендәге кебек үк, дифтонглар монофтонглаша.

Әдәби телдәге *ай/әй, уй* дифтонгларына сөйләштә [а], [ә] авазлары туры килә, бу вакытта дифтонгтан соң килә торган тел очы тартыклары йомшара, ягъни палатальләшә: *ат'ә* / *ат'а* – әд. әйтә, *кан'ана* – кайынана (каенана), *әләндерү* – әйләндерү, *бәләү* – бәйләү, *мун'* – муйын (муен), *ун'ау* – уйнау, *кат'* – кайт, *кач'ан* – кайчан, *кан'ар* – кайнар, *кас'ы* – кайсы, *кан'* – каян (*Кан' белә?* – Каян белә?), *ад'а* – әд. әйдә (*Ад'а, күчәбез квартирага, ди. Ад'агыз, чәйлибез* – Әйдәгез, чәй эчәбез) һ. б.

*өй* дифтонгы монофтонглашып, [ү] гә күчә: *ү* – әд. өй, *кү* – көй, *сүли* – сөйли, *түгеч* – төйгеч, *үнә* – өенә, *ө$^{ү}$рәтү* – өйрәтү, *үләнгенче* – өйләнгәнче, *сү* – сөй һ. б.

Монофтонглашканда, күтәрелешләре төрле булган сузыклар арасында ирен-ирен [w], ирен-теш [в] тартыклары барлыкка килә, ягъни *ев* / *үw*: *сүwә* / *севә* – әд. сөйә (сөя), *тевә* – төйә (төя), *севәк* – сөйәк (сөяк), *тевен* / *түwен* – төйен (төен), *севен* / *сүвен* – сөйен (сөен), *эвендә* – өендә, *эвә* – өйә (өя), *күwен* – көен: *Малайлар кискән, кызлар үгән утынны – үмә булган. Элгәре алып баралар кийәү эвенә кызны.*

*у$^{w}$е / ү$^{w}$е, ывы/еве ~ уы/үе: йевеш / йү$^{w}$еш* – әд. йүеш (юеш), *кывыру* – куыру, *суwык* / *сывык* – суык һ. б.

*у$^{w}$а / ү$^{w}$ә, ыва / евә ~ уwа / үwә: ту$^{w}$ар / тывар* – әд. туwар (туар), *шу$^{w}$а / шыва* – шуа, *ку$^{w}$ак / кывак* – куwак (куак), *йыва* – йуwа (юа) һ. б.

*өй, ый* дифтонглары *ий* дифтонгына күчә: *сийыр* – әд. сыйыр (сыер), *кийаш* – койаш (кояш), *кийар* – кыйар (кыяр), *ки(й)мә* – көймә, *укий* – укый һ. б.

**Тартыклар.** Кузнецк сөйләшендә әдәби телдәге тирән тел тартыклары бөтенләй юк. Алар урынына, көнбатыш (мишәр) диалектның башка сөйләшләрендәге кебек үк, тел арты [к], [г], [х] авазлары кулланыла. Мәсәлән: *карга, агач.* Чагыштыр: әдәби телдә *қарға, ағач* дип әйтелә һ. б.

[к] авазы, ике сузык арасында килгәндә, күп кенә сүзләрдә яңгыраулаша, ягъни [г]~[к]: *туг(ы)зан* – әд. туксан, *тыгырык* – тыкрык һ. б.

[к]~[х]: *катын* – әд. хатын, *касталанган* – хасталанган; [х]~[к]: *мөх* – мү*к, тухта* – тукта, *тахта* – такта һ. б.

[ғ] авазы гарәп теленнән кергән сүзләрдә төшеп кала: *айыт* – гает, *умер* – гомер, *адәт* – гадәт, *айыплау* – гаепләү, *Али* – Гали, *Айнулла* – Гайнулла, *Айша* – Гайшә һ. б.

Сүз уртасында [ғ] тартыгы урынына кайбер очракта [й] яисә [w], [в] әйтелә: *сәәт* / *с'аат* / *сәйәт* – әд. сәгать, *дива* / *дыва* – дога, *Сәйет* / *Саит* – Сәгыйт һ. б.

[н]~[ң]: иялек килеш кушымчасында *(-ның/-нең),* 2 нче зат берлек сандагы хәбәрлек кушымчасында *(-сың/-сең)* күзәтелә: *безнен* – әд. безнең, *сезнен* – сезнең, *анарга* – аңа. *Бижж йомыркапын сарысына бер йомырканын агын салам, берәз писүк, тоз. Анарга сливочный май. Безнен кырда киндераш чәчелә иде. Сондыкнын эчендә кан'ана өчөн намазлык иде. Анын йанында ниндидер материалдан падаркасы. Закваскасын йаңадан ачытасын, ул әмән кү$^{о}$тәрелә. Айу камыр чәчәген дә эчәбез, парлыйсын да, йыштырасын, киптерәсен.*

[й]~[җ]: көнбатыш (мишәр) диалектның башка сөйләшләрендәге кебек үк, кузнецк сөйләшендә дә әдәби телдәге [җ] тартыгы урынына тел уртасы [й] тартыгы әйтелә: *йәймә* – әд. җәймә, *йәйеп* – җәеп (*йәймә йәйдек, аны йәйрәтәсең*), *йырлый* – җырлый, *йыштыру* – җыю (*паңгы йыштырабыз*), *йан* – җан, *йеп* – җеп, *йебету* – җебетү, *йыйыла* – җыйыла (җыела) һ. б.

Сүз башында әдәби телдәге [җ] янәшәсендә [и] сузыгы (ягъни *җи-*) булса, сөйләштә *йе-* яки *э(е)-* туры килә: *йер эләге* – әд. җир җиләге, *йэдэ* – җиде, *йеңәм* – җиңгәм, *йетешсезлек* – җитешсезлек, *йэр* – җир, *йегеп* – җигеп, *йеңле* – җиңле һ. б.

[җ] тартыгы – кушык аваз. Кузнецк сөйләшендә аның төрле вариантлары очрый: *дж, $^{д}$җ, җ.*

[җ] тартыгы гарәп теленнән кергән сүзләрдә һәм кеше исемнәрендә сүз башында кулланыла: *Җәлил, җәмийәт* һ. б.

Сүз уртасында шулай ук [җ] тартыгы саклана: *оҗмах, мөрҗә, мөнәҗәт, мәҗлес, Хаҗия, Наҗия* һ. б. Искәрмә: *кәҗә, баҗа, уҗым* сүзләрендә *җ>з* күзәтелә, ягъни сөйләштә *кәзә, баз'а, уз'ым.*

Пенза өлкәсендә мишәр диалектының чылаштыручы сөйләше таралган. Ләкин биредә [ч] тартыгы төрле артикуляциядә килә: *тч,* $^{т}$*ч, ч*.

Рус теленнән кергән алынма сүзләрдә [ц] авазына сөйләштә [ч] тартыгының төрле вариантлары туры килә: *крил'ча* – крыльцо (өйалды баскычы), *бал'нича* – больница, *гүрничә* – горница, *мил'нича* – мельница һ. б.

Кайбер сүзләрдә шундый тәңгәллекләр күзәтелә: [п]~[б]: *потак* – әд. ботак, *пот* – бот, *петте* – бетте, *пытл(н)ек* – бөтнек; [б]~[м]: *бун'* – муйын (муен); [м]~[б]: *малан* – балан, *корман* – корбан; [н]~[м]: *нөгөз* – мөгез, [р]~[л]: *шурба* – шулпа; [к]~[т]: *келәү* – теләү; [т]~[к]: *читлаwык* – чикләвек; [д]~[л]: *мунча төндеге* – мунча төнлеге; [н]~[д]: *алын* – алды, *ишек алны* – ишегалды; [п]~[ф]: *тупрак* – туфрак, *йапрак* – йафрак (яфрак), *керпек* – керфек; [т]~[ч]: *тишү* – чишү, *тишенү* – чишенү, *тишмә* – чишмә (искәрмә: *төче* сүзе кересенчә – *чөчө* / *че*$^{о}$*че* / *чече*).

*Тычкан* сүзе *тыс'кан* формасында әйтелә – [с]~[ч].

**Ассимиляция** (авазлар охшашлану). Кайбер сүзләрдә [л] авазы үзеннән соң килгән [г] авазына өлешчә охшашлана: *йаңгыз* – йалгыз (ялгыз), *йаңгал* – йалган (ялган), *аңгару* – аңлау, *соңгару* – соңлау.

Сүз ахырындагы [ч], [ш] тартыклары тел уртасы [й] һәм яңгырау тартыклар алдында килгәндә яңгыраулаша: *бижйез* – әд. биш йөз, *пиҗ башты* – мич башы. Мәсәлән: *Бер бәлешкә сытам иң әзендә унбиж йымырка. Утыз биж йыл эшләдем шулай. Мин фактически фел'дшерскины бетердем, но эж йукка күрә акушеркой урнашырга туры килде. Иртән өҗ йартыдан тора идем, биж йартыга пичкә эштиләрне куйа идем. Элке малайлар өҗ йыл служит итте. Кыж буйы шул эләкләрне балаларга һәр көн компот итеп бирә идек. Пиҗа шул пиҗ башты инде әйтийем. Пулат – пиҗ башына менә торганы, бу йагыннан керә торганы, такта тезгән, анда йоклыйлар элгәре.*

Башка тартыклар артикуляцион яктан әдәби телдәге шул ук авазлардан аерылмыйлар.

**Аваз өстәлү:** [ә]/[а]/[ы]/[ү]: *пәрәмәчә* – әд. пәрәмәч *(Пәрәмәчә айыт көннәрендә обизателны), макы* – мәк, *оныка* –

оныk, *берсеү* – берсе, *алныда* – алда; [т]: *тутыртма* – тутырма, *каптыртма* – каптырма, *пиҗ башты* – мич башы; [р]: *кечерткән* – кычыткан, *кортлау* – котлау; [д]: *кузгалдак* – кузгалак һ. б.

**Аваз төшү**: [л]: *итү* – әд. илтү, *йугат'у* – югалту; [т]: *ишми* – ишетми; [г]: *айыт* – гает, *адәт* – гадәт; [а]: *лабута* – алабута, *чабатлар* – чабаталар, *аwырады* – авырды, *алашлар* – алашалар; [й]: *тирәз* – тәрәзә, *иләшү* – ийәләшү (ияләшү) һ. б.

Сингармонизм законы тәэсирендә алгы рәт авазлары арткы рәткә күчә, ә алар арасындагы тартыклар нечкәртеп әйтеләләр: *ахыр'ы* – ахры, ахрысы, *кад'ыр* – кадер, *Хас'ан* – Хәсән һ. б.

Гарәп теленнән кергән алынма сүзләрдә сүз башында һәм ике сузык арасында килгән *с-з, т-д, р, л, х* авазлары нечкәртеп әйтелә: *йугат'у* – йугалту (югалту), *Пин'з'а* – Пенза, *Мус'а* – Муса, *кит'ап* – китап һ. б.

**Метатеза** күренеше: *эскәймә* <рус. скамейка, *тирә-күрше* – күрше-тирә, *бүрке* – бүрек, *борны* – борын, *урны* – урын, *кабак* – капка, *азбар* – абзар, *мурта* – умарта, *руза* – ураза, *элке* – элек, *кымрыска* – кырмыска һ. б.

## Морфологик үзенчәлекләр

**Исемнәр.** Төшем килешендә 1 нче һәм 2 нче затлардагы тартым белән төрләнгән исемнәр һәм алмашлыклар әдәби телдәге *-ны*/*-не* урынына *-ы*/*-е* кушымчалары алалар: *дусларымы* – әд. дусларымны, *үземе* – үземне, *үзеңе* – үзеңне һ. б. *Утынымы киссәгез, арендага бирәм ызбаны, бер кичкә вичер уздырырга. Камырымы алам, йәйәм табага. Инеш буйына барасын да, битеңе йуасын да, култасмалыңа себерәсең* (сөртәсең).

3 нче затта икеләтелгән тартым кушымчасы куллану очраклары билгеле: *Безнен татар халкысы озын йеңле күлмәк кийәләр иде. Сөннәт туйысын уздыралар. Йорт алдысы. Ишек алнысы читән иде.*

**Саннар.** Аларның төркемнәре, грамматик категорияләре әдәби телдән аерылмый. Шуның белән бергә, микъдар саны урынына җыю саны формасын куллану очраклары бар*: Без сигезәү олан* (сигез бала) *үстек. Үзе генә тегел, тугызаумы* (тугызмы), *унберәүме* (унберме) *анда.*

Бу күренеш көнбатыш диалект сөйләшләрендә *күп* рәвешенә дә хас: *күбәү* / *көбәү*. Кузнецк сөйләшендә, темников, карсун сөйләшләрендәге кебек, ‘күпләп, күп-күп итеп’ мәгънәсендәге *күбәр* формасында күзәтелә: *Кызыл йомырка бар'амендә күбәр-күбәр йомырка пешерәсен дә, оланнарга бирәсен.*

Вакытны белдереп сөйләгәндә, тәртип саны урынына микъдар саны кулланыла, ягъни *-нчы* кушымчасы төшеп кала: *Сәхар'ны ашый төннә ике йартыда* (икенче яртыда). *Иртән өҗ* (өченче) *йартыдан тора идем, бижс* (бишенче) *йартыга пичкә эштиләрне куйа идем.*

**Рәвешләр.** Әдәби телдәге *көн буе, төн буе* тибындагы рәвешләр урынына кузнецк сөйләшендә, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек, *көн ката, төн ката* формалары актив кулланыла: *Төн ката молотилкада суга идек. Көн ката урамда йөреде.*

*Тапкыр, мәртәбә* сүзләре белән беррәттән *тынап* (рус. раз) сүзе очрый: *Кырда көненә ике тынап* (ике тапкыр) *ашаталар. Татар теле ике тынап атнасына укытыла иде.*

Диалекталь характердагы лексик рәвешләрдән түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: *жар* – эссе (әд. эссе сүзен кулланмыйлар), *элке* – элекке (элгәре, элек), *йаз башын* – язын, *йазын* – җәен (*Язын учутщик идем*), *үңгә* – башка, *тенә* – кичә, *үңгәчә* – башкача, *тынасыз* – хәл алмыйча (хәл җыймыйча), *койты* – начар (*Бик койты булган вакыт, Сталин үлгәч. Койты ишетеләме телефоннан?*), *карсак* – түбән, *йаңгыз* – ялгыз, *кыңгырырак чыгу* – кәкре (туры чыкмау, кыешрак булу), *төнә* – кичә (*Газлар төнә йу°к* – Газ кичәдән бирле юк), *йурап* – юри, *мәңге* / *мәңгедән* – электән, күптән (*Пичләр мәңге* (күптән) *йу°к, кәбәм. Урыс халкы мәңгедән* (электән) *паңгы йыйа)*, *сирәк-сайак* – сирәк-мирәк (редко), *иртәгәдән соңга* – берсекөнгә һ. б.

**Алмашлыклар.** *Берче* алмашлыгы, ләмбрә, темников, хвалын, мәләкәс, карсун, әстерхан сөйләшләрендәге кебек үк, түбәндәге мәгънәләрне белдерә: 1. ‘һәрвакыт’: *Кулында китабы, берче укый гына*; 2. ‘рәттән, тулысынча’: *Бу урын берче урман булган*; 3. ‘бөтенләй’: *Кулым арыды берче*; 4. ‘барын, барысын’: *Берче биреп бетерде*; 5. ‘барлык, барча, барысы,

бөтенесе’: *Килегез берчегез* (барыгыз да), *килегез бире. Берчебез* (барыбыз да) *керә мәктәпкә, килгән кунаклар. Берчесе халык урамда, оланнар үзләренә сикерешә. Берчесе йат авылныкылар.*

Күрсәтү алмашлыклары: *выты* / *вата* / *вытыка* / *вытыкай* – < рус. вот – менә, әнә. Мәсәлән: *Выты* (менә) *безнең историйебыз. Анын выты йеп бәли торган нийесе бар иде. Вата мәчетебез безнеке бар, вот өч. Вытыка ызба куд'ык. Вытыкай* (анда) *картлар йәши. Вытыкай эшчеләр кырларга чыга иде.* Сирәк: *вcase* / *мыни.*

*Нәрсә* сорау алмашлыгы белән беррәттән *нәстә* алмашлыгы да кулланыла: *Өлгереш ун'аганда наказ бирәләр нәстә, нишләргә – бийергәме, йырларгамы инде анда. Бер куй алалар или кәзәме – шунда нәстә очрый, шуны чалалар. Дөге буткасы булса, анын өстенә йөземэләк, кур'ага, нәстә бар салалар.*

**Фигыльләр. Затланышлы фигыль формалары.** Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең 3 нче зат берлек санында әдәби форма белән беррәттән *-дыр*/*-дер* хәбәрлек кушымчалары ялгану очраклары күзәтелә: *киләдер* – әд. килә, *-дыр*/*-дер* кушымчалары этимологик яктан *тор* фигыленә кайтып кала дип аңлатыла. Мәсәлән: *Урман кису бар иде, әле инде йу$^{о}$ктыр* (юк). *Ке$^{ө}$ндез жар, йаңгыр йаумыйдыр. Мин килгәндә су йу$^{о}$ктыр, йу$^{о}$ллар йу$^{о}$ктыр. Су буйларында бернәрсә дә йу$^{о}$ктыр иде. Элкеге вакыттагы черек картук ашау йу$^{о}$ктыр хаз'ыр.*

1 нче һәм 2 нче затларда тамыр яки нигезе *-ыр*/*-ер*/*-р* га беткән берлек һәм күплек сандагы киләчәк заман хикәя фигыльләрдә, инфинитивта *р* авазы төшеп кала: *чакырыга* – әд. чакырырга, *пешерегә* – пешерергә, чакырымын – чакырырмын, *чакырысын* – чакырырсың, *чакырысыз* – чакырырсыз һ. б. Мәсәлән: *Эчәгеннән суган, картук кушып, бик тәмне генә берәз кыздырыга* (кыздырырга) *кирәк аны. Кызларга вичер уздырыга* (уздырырга) *урны кирәк. Кызныкы кесәсендә култасмал* (кулъяулык), *аларга бирегә* (бирергә), *штоб чиләкне түкмәскә. Тирәсне* (тәрәзәне) *үзем себеремен* (сөртермен). *Мөшкә бәлеш пешересен* (пешерерсең). *Пен'зыга барысыз* (барырсыз).

*-ган*/*-гән* формалы фигыльләр еш кына *бар, йук* сүзләре белән килеп, зат кушымчаларыннан башка гына кулланылалар:

*Шуны әби-бабайдан сүләгәннәрен ишкән* (ишеткәнем) *бар. Ул авылга барган* (барганыбыз) *йуоκ. Элке йыштырган, хаз'ыр пангыларны бәг йыштырган* (җыйганыбыз) *йук.*

Бу сөйләштә билгеле киләчәк заманның *-ачак/-әчәк* (барачак, киләчәк) формасы, *-малы/-мәле* (бармалы, килмәле) һәм *-асы/-әсе* (барасы, киләсе) формалы фигыльләр кулланылмыйлар.

Сөйләштә дәвамлы үткән заманның көнбатыш диалект сөйләшләренә хас *-а/-ә, -ый/и + булган* (әд. *-а/-ә* торган булган) төзелмәсе дә күзәтелә: *Тчәчләренә талир тәңкә тага булганнар* (тага торган булганнар). *Шол вакытта клубка йыйылып йырлый булганнар* (җырлый торган булганнар) *өч көн рәддән. Бишекләрен дә кырга тага булганнар. Сир* (сыйыр) *тота булганнар, картук тчәчә булганнар. Йәш киленнән кан'ана йәймә йәйдерә булган. Безнен бабайлар нарат теөпләрен дҗийа булганнар, итә* (илтә) *булганнар, сата булганнар. Хайбулла бабакай братлары белән дегетне алып бара булганнар Заволгага.*

1 нче зат берлек һәм күплек сандагы теләк фигыльләре *-ыйым/-ийем, -ыйык/-ийек* кушымчалары белән ясала: *барыйым* – әд. барыйм, *барыйык* – барыйк, *килийем* – килим, *килийек* – килик һ. б. Мәсәлән: *Анарга әйтийем. Безнен заманда, ат'ийем* (әйтим), *йегетне армийәгә озатканда, йегетнен эвендә малайларны гына йыштыралар* (малайларны гына җыялар), *кызлар йуоκ. Давай барыйык, йакшы.*

Эчке теләк, ният, барлык мишәр сөйләшләрендәгечә*, -кы/ -ке (-гы/-ге) +кели / тели* (әд. *-асы/-әсе, -ыйсы/-әсе + килә*), *-ырга/-ергә + кели / тели* төзелмәсе белән белдерелә: *барырга кели* – әд. барырга тели, *баргысы кели* – барасы килә. Мәсәлән: *Минем һич киткем келәми* (китәсем килми) *аннан. Торгысы да, киткесе дә келәми. Вичерда ул кели йырларга.*

**Фигыль юнәлешләре.** Йөкләтү юнәлеше. Бер төркем фигыльләрнең йөкләтү юнәлеше формасы *-кыз/-кез, -гыз/-гез* архаик кушымчалары ярдәмендә ясала (*-гыр/-гер, -кыр/-кер*): *Зурлап никах мәҗлесе үткәзәләр* (үткәрәләр) *кафеда хаз'ыр. Раштуа бар'амендә йәшләр кызык өчен башн'ага тчана менгезеп*

*куйганнар. Потом тытып кергезә иделәр кур'ат'никтан табык. Урны-йерне кигезгәндә йырлыйлар.*

**Затланышсыз фигыль формалары. Хәл фигыльләрнең** әдәби телдәге *-ганчы/-гәнче* кушымчасы урынына сөйләштә *-гынчы/-генче, -гинча/-гинчә, -гынчык/-генчек* кушымчалы формалары кулланыла: *килгенче / килгенчек* – әд. килгәнче, *үләнгенче* – өйләнгәнче. *Китмә, оулым, братың үләнгенче* (өйләнгәнче) *тор, дим. Күмәч ишек башында, уолым килгенче* (армиядән кайтканчы) *йа тора, йа тормый, йа тыскан ашый. Урам беткенчек* (беткәнче) *туры барасын.*

Сөйләштә *-а/-ә/-ый/-и* кушымчалы хәл фигыльләр *-ып/-еп* формалы фигыльләр урынына да кулланыла: *Ат кузгылдагы йыйа* (җыеп) *кılә. Рыштуада ыланнарны куркыта* (куркытып) *йөри иделәр. Йакшы кешене тчакыра* (чакырып) *китердем. Үгә йырлый* (җырлап) *килде. Тарас бабам утын кисә* (кисеп) *йерде, такталар йара* (йарып) *йерде.*

**Ярдәмлек сүз төркемнәре.** Кайбер **бәйлекләр** сөйләшнең үзенчәлеген тәшкил итәләр: *тике / тәкле / тәке, чике / чәке* (тикле, кадәр). Мәсәлән, *Камзул тезгә тике иде, кыска төгөл иде. Йаз башы чәчүләргә тике халык барчасы йыйыла шунда. Йыл тавыгы корка тике була инде, тутыргач. Ул тәкле ашлар уздыралар. Аны артыннан кычкыралар: шул тәке бик күеп безнен йерләр. Йома вакытында беренче йартыдан ике тулгынчыга чәке бернишләргә дә йарамый. Абкәләренә чәке барган. Чәчен үерә иделәр дә шунын чике.*

*Өчен* бәйлеге: *Башняга чана менгезеп куйганнар кызык өтчөн. Сондыкнын эчендә кан'ана өтчөн намазлык иде. Безнен, ди, кырлар келәүле, шунын өчөн кирәк корбан чалып, йамгыр сырарга чыгарга. Күзекмәсен өтчөн дыва куйалар, бетү куйалар тайкасына* (бала башлыгына). *Ат* (исем) *куштырыр өчөн чакыралар мулланы.*

Сөйләштә *әмән* сүзе **теркәгеч** (гүя, әйтерсең дә) һәм охшату-чагыштыру бәйлеге (шикелле, кебек, бугай) буларак актив кулланыла: *Шулай әмән сүз булган. Капыста бәлеше тансыкка әмән. Джҫома кен берни эшләмә, берни йума да әмән. Элке әмән пәсуклар йуктыр иде. Бик чөчө* (төче) *була иде әмән.*

*Әмән йәш киленнәр килә, төшә машинадан. Әпәй пешергәндә калдырасын әмән закваскасын кара әпәйнен.*

Сорау **кисәкчәсе** *-мы/-ме* кузнецк сөйләшендә, көнбатыш диалектның башка сөйләшләрендәгечә, логик басым төшкән теләсә нинди җөмлә кисәгенә ялганып килә: *Безгәме килдегез?* (Безгә килдегезме?). *Син Казанның үзендәме торасын?* (Син Казанның үзендә торасыңмы?). *Онгамы эшли идегез? Соңгамы туйыгыз булды?*

Җөмләдә сорау мәгънәсе интонация ярдәмендә белдерелергә мөмкин: *Син Алиларга бардың? Киләләр?*

## Синтаксик үзенчәлекләр

Исем-исем сүзтезмәләрдә тартым кушымчасын кулланмау очраклары бар: *карту белен* – әд. бәрәңге белене, *мөшке бәлеш* – мөшке бәлеше, *эчәк бәлеш* – эчәк бәлеше, *йастык тыш* – йастык тышы, *тирәс төп* – тәрәзә төбе, *кыз кичә* – кыз кичәсе, *айу камыр* – айу камыры – гөлҗимеш, *куй тчага* – куй чагасы – сарык бәрәне һ. б. *Тарас бабам утын кисә йөреде, тәрәз төпләр* (тәрәзә төпләре) *йасады.*

*-ныкы/-неке* кушымчалы алмашлыклар һәм исемнәр еш кына аергыч функциясен үтиләр һәм аерылмышның алдында да, артында да килә алалар: *Баласы туды анықы. Чебешләр ᵀчыга тавыкныкы: кас'ы әнәч, кас'ы кучат ат'абез инде. Безнеке Алеевка да чисты татар. Йорт анасы чәчләрен өᵞрә йалын атныкын. Урманыбыз пангыга* (гөмбәгә) *бай безнеке, йыштырабыз. Бабам минеке бригадир иде. Безнеке мәчет ачылгач, йыштырып* (җыеп) *йөрделәр китапларны. Калхузыбыз таркалса да, халкыбыз безнеке эшсез калмады.*

Бу сөйләшкә дә, көнбатыш диалектның башка сөйләшләрендәге кебек, җөмләдә сүзләрне кире тәртиптә куллану хас: *Үдәме әллә син?* – Син өйдәме әллә? *Алар инде материалны йебәреп тора иделәр әниемә* – Алар материалны (тукыманы) әниемә җибәреп торалар иде. *Ашадык коймак и әпәй пешкән үдә* – Өйдә пешкән коймак һәм ипине ашадык. *Анын өчен чакыралар мулланы* – Аның өчен мулланы чакыралар. *Кан'ана пристин'а йәйә аларга* – Каенана аларга простыня җәя. *Олан*

*чагымда шуны эшләгәнен беләм әниемнен* – Бала чагымда әниемнең шуны эшләгәнен беләм.

Неверкино районы Бикмосеевка авылында басым җөмлә ахырына төшә. (Ахырын сузып әйтәләр, көйләгән сыман.)

### Лексик үзенчәлекләр

Кузнецк сөйләшенең төп лексик составы, нигездә, татар әдәби телендәгечә. Диалекталь лексиканың шактый зур өлеше көнбатыш (мишәр) диалектның башка сөйләшләре белән уртак, берникадәр үзенчәлекләр дә табыла. Сөйләш өчен характерлы диалекталь лексиканың кайбер тематик төркемнәрен күрсәтеп үтик.

Туганлык атамалары: *атай* – әд. эти, *анай* – әни, *олан* – бала, *оныка* – онык, *кан'ата* – каената, *кан'ана* – каенана, *йәңәм* – җиңгәм, *кан'сеңел* – каенсеңел, *игәч* – бертуган апа (*Игәчләр дип сүләгәндә генә ат'аәбез, ә дәшкәндә апам дип*), *ага / абзий* – абый (олы абый), *быратым / туганым* – үзеннән кече ир туганы, *әбекам / әбкай* – дәү әни, *бабакам / бабакай* – дәү әти, *тудыйым / тудыка(й)* – ике туган; *тумачи* – өченче буын туган, *кәбәм* – < гар. кәгъбә – *бәбкәм, җаным, яратканым* (эндәшү сүзе) һ. б.;

Аш-су атамалары: *әпәй* – әд. ипи, *мөшке / мешке* – эремчек, *пәрәмәчә / пәрәмәче* – пәрәмәч, *картук* – бәрәңге, *чигелдәк* – бавырсак, *кыйыкча* – кош теле, *эшти* – 1) рус. ‘щи’, 2) аш, *салма / эләкшә* – токмач, *йезәңге* – кабартма, *пышки* – кабартма, *казы* – казылык, *рузалар* – роза чәчәге сыман уратылып, камыры кош теленеке (хворост) кебек, көнбагыш маенда пешерелә торган ризык, *катлама* – тар юка камырны урап, майда пешерелә торган ризык, *сеңәл* – сыек, *куры* – ипи ачыткысы, *шурба* – шулпа һ. б.

Үсемлек атамалары һәм хайваннар дөньясы белән бәйле сүзләр: *паңгы* – әд. гөмбә, *каw(в)ын* – кабак, *картук* – бәрәңге, *кечеркән / кечерткән / кесерткән* – кычыткан, *кагыт* – как, *макы* – мәк, *кузгылдык / кузгалдак* – кузгалак, *таwык күз* – кызыл бөрлегән, *айу камыр(ы)* – гөлҗимеш, *айбагар* – көнбагыш, *дүңгелди* – песи борчагы, *орлык яру* – көнбагыш чирту, *йеземәләк* – йөзем җимеше (изюм),

*читлаwык* – чикләвек, *мәләш* – миләш, *муйыл* – шомырт; *мачы* – мәче, *кочок* / *кочук* – эт, *алаш*а – ат, *нөгөз* – мөгез, *корка* – күркә, *кукук* – күке, *куй* – сарык, *куй тчагасы* – сарык бәрәне, *кучат* – әтәч, *әнәч* – яшь тавык һ. б.

Каралты-кура, хуҗалык эшләре һ. б. белән бәйле лексика: *кабак* – әд. капка, *у* / *ызба* – өй, йорт, *аран* – абзар, сарай, *азбар* – двор, йорт хуҗалыгы (*Бу урамда ун азбар), зәмәт* – койма, *винек* – мунча себеркесе (миллек), *өстәл төзибез* – табын хәзерлибез, *кур'ка* – чүмеч; *чокыр* – чашка, *чәй тәлинкәсе* / *чәй асты* – чынаяк тәлинкәсе, *пулат* – сәндерә, *түр* / *агач түр* / *кынапый* – кәнәфи (тактадан гына эшләнгән диван), *идән асты* – өйдәге баз, *йастык* – мендәр, *кимә* – көймә, *мошко* – киндер, киндер сүсе, *лаука* < лавка – кибет, *пижай* / *пижбашты* – мич башы, *рагужа* – калын, тупас тукыма (юкәдән тукылган тукыма һәм капчык), *саласка* – чана, *пәсүк* – песок, *пул асты* – баз, *пугар'ап* < рус. погреб – кар базы, *путалак* < рус. потолок, *прагал* – тыкрык (переулок), *тигәнә* – он савыты, җилпуч, *л'ар* – лар, *пул'* – мунча ләүкәсе һ. б.

Йола, гореф-гадәт белән бәйле сүзләр: *сүз бетерү* – туй алдыннан сөйләшү, *бәбәй буткасы* / *бәбәй мае* – балага исем кушу мәҗлесе, *безелек* – язын, кар киткәч, җир ачылгач уйнала торган беренче уеннар, *мамык* / *мамык мәҗлесе* / *корбан мәҗлесе* – туйның икенче көнендә килен төшкән йортта үткәрелә торган хатыннар мәҗлесе һ. б.

Табигать күренешләре белән бәйле сүзләр: *кизләү* – чишмә, *йаз башы* – яз, *йаз* – җәй, *төнәген* – кичә һ. б.

Кеше һәм аның эш-хәрәкәте белән бәйле сүзләр: *куңгылдак* – әд. яланаяк; *бун'* – муен; *койты* – начар; *зәләмә* – алама-сәләмә, иске-москы, тузган, начар; *багу* – карау; *фотога сугу* / *карточкага сугу* – фотога төшү; *пыт'ыр* – кечкенә (*пыт'ыр ылан* – кечкенә балам, төпчек балам, *пыт'ырыбыз* – кечкенә балабыз); *йадау* – ябык; *күркле* / *йәмле* – матур, чибәр; *теги* – парлы (парный, четный); *теᵒгиле-теᵒгисез* – парлы-парсыз; *тирес* – тискәре (як), кире (як) (*тирескә таба бару* – кире якка бару); *усал* – начар, әйбәт түгел; *карсак* – тәбәнәк; *йаңгалау* – ялганлау; *аңгару* – аңлау; *күзектерү* – күз тидерү; *тыну* – хәл җыю, ял итү; *тетү* – тарату, сүтү, сүтеп ташлау;

*тезү* – төзү, кору, урнашу, ясау; *тетелү* – таралу, таралышу (разойтись), сүтелү, таралу; *туу* – тудыру (*Өчесен дә авылда тудым* (тудырдым) *мин. Йәдэ бала тудым* (тудырдым). *Кайта* сүзе урынына *килә* фигылен куллану (*Олум армедән килә* (әд. кайта) *отпускага)* һ. б.

Кием-салымнар: *тастымал* / *тасмал* – баш яулыгы (платок), *култасмал* / *култастымал* / *борын яулыгы* / *күз йаулыгы* – кулъяулык, *француз тасмал* – француз яулык; *пухситка*/*ситка* – кәҗә йоныннан шәл; *йөслек* – сөлге; *вал'ник* – < рус. валенки – киез итек; *вар'ик*/*варига* < рус. варежки – бияләй; *батин* – ботинка; *тайка* – бала башлыгы; *кийенчекләр* – яхшы киемнәр; *сәнәбәт* – җиңсез өс киеме, камзул; *насук* – йон оекбаш; *касник* – чулпы; *чолка* – оек (чулки); *кашма* – сарык йоныннан басылган киез, палас (кошма, войлок); *пристин'а* – < рус. простыня; *фартык* / *запун* – алъяпкыч, *руминка* – йонлы аяк киеме һ. б.

Пенза төбәгендәге татарларның кузнецк сөйләшенә хас (әйтеп узылган) фонетик, грамматик, лексик үзенчәлекләр һәм гореф-гадәт, йола һ. б. сөйләү үрнәкләрендә дә күренә. Текстларда сүзләрнең әйтелеше транскрипциядә биреләчәк. *Я, ю, е* хәрефләре урынына [йа], [йә], [йу], [йы], [йы], [йе] авазлары, өстәмә билгеләрдән [w] – ирен-ирен өрелмәле тартык аваз кулланылды.

## ЭКСПЕДИЦИЯ ВАКЫТЫНДА (НЕВЕРКИНО, КУЗНЕЦК ҺӘМ СОСНОВОБОРСК РАЙОННАРЫ) КУЗНЕЦК СӨЙЛӘШЕ ВӘКИЛЛӘРЕННӘН ЯЗЫП АЛЫНГАН, ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕН ҺӘМ ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕН ЧАГЫЛДЫРГАН МАТЕРИАЛЛАР (СӨЙЛӘҮ ҮРНӘКЛӘРЕ)

### Авыллар тарихы, тормыш-көнкүреш турында

Монда сазлык булган, күᵒл ат'әләр. Килә-килә төзелгәннәр *(урнашканнар)*. Күᵒлләр булган. Авыл уртасында күл. Йындырка булган аты *(исеме)*. Йегерме беренче йылда пожар булып, буралар йанган. Ашлык чәчкәннәр – ашлык чыкмаган. Бег ачлык булган. Койты *(начар)* йыл булган. Алаша йегеп чәчкәннәр. Урак урып, көлтә бәләдем. Вата чыбагачлар бар, шунын белән

сугарга көлтәне. Алаша белән чәчеп, урып. Бишекләрен дә кырга тага булганнар. Черегән картукны йыйарга бардым мин дә Никул′скийга. Картукны пешерәсен дә оны чыга.

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Баишева Вәсилә Гайнулла кызыннан (1926 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Али *(Гали)* бездә иң абруйлы кеше булган. Кырлар бү$^{о}$ләләр. Ул ат өстендә китә, атка атлана да китә. Али бабай шул тәке йер ала. Аны артыннан кычкыралар: шул тәке бик кү$^{ө}$п безнен йерләр. Шул Саратов, Ул′йан белән граничит безнен авылыбыз. И шунда кычкыралар: «Тукта, Али, тукта Али, тукта Али». Йере дә анда калган. Шуны әби-бабайдан сүләгәннәрен ишкән *(ишеткәнем)* бар. Ул исемнән калган. Али авылы әтелә дә.

Калхузыбыз таркалса да, халкыбыз безнеке эшсез калмады. Берчесе үзе ниндидер эш табып, шөгелләнәләр. Кем ит белән, кем терлек асырый, кем кош-корт асырый, кем сөт, мөшке *(эремчек)* сата, май сата. Калхузнын йерләрен бүлделәр, безгә пайлар бирделәр.

Сийыр тота булганнар. Картук чәчә булганнар. Картуклыклардан черегән картуклар йыштыра идек, ди. Шуларны әнийем хаз′ыр дә сүләп тора.

Куй ке$^{ө}$тү$^{w}$е *(сарык көтүе)* айырым йе$^{е}$ри. Кетүчеләребез бар. Катыгын да йасыйбыз, мөшке дә бар, каймак та – ни бар затлар бар.

Сигезәү үстек. Әнием йегерме йеденче йылгы. Безнен кырда киндераш чәчелә иде. Әнием безнеке үзе сигез оланга үзе төн буйы тегә иде. Даже пал′толар үзебезгә тегә иде. Малайларга бү$^{е}$рекләр тегә иде. Ташкенда абыйлары тырды. Алар инде материалны йебәреп тора иделәр әниемә.

*Неверкино районы Али авылында*
*Биктимерова Гайшә Әюп кызыннан (1950 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Хаз′ыр лаука *(кибет)* урнында мәчет булган. Земл′анкада урманда тырганнар, потом авылны тезегәннәр. Каандыр дү$^{е}$рт бабай килгән, мәләшлек булган.

Ураза бар'амы була, корбан. Шол вакытта клубка йыйылып йырлый булганнар өч кен рәддән. Тәкбир кене йарамый эшләргә. Шул вакытта тынганнар, йырлап бийегәннәр.

Йаз башын *(язын)* тау башына йөрә иделәр. Ут куйа иделәр, анын аша сикерә иделәр. Су вакытында, кар вакытында. Пичәнчәсен дә пешерә идек картуктан. Ут йана, шунын ке$^{е}$ленә пешерәләр картукны. Әпәйеңе, то$^{у}$з анда аласын. Нәстә барыңны. Элке монда зур су була иде.

*Сосновоборск районы Әлмәш авылында*
*Ягудина Гүзәл Сәит кызыннан (1967елгы),*
*Сәйфуллина Румия Кәлимулла кызыннан (1951елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Безнен бабалар дегетчеләр булганнар. Без Дәхтәрни дип ат'абез иде. Безнен бабакай, Хайбулла бабакай, братлары белән чыгара булганнар да алып бара булганнар Заволгага. Анда сата булганнар аны. Дегеткә алыштырганнар, то$^{у}$змы, нәрсәләр алганнар. Безнен бабайлар килеп утырганнар урман эченә. Йасый булганнар дегет базы. Атлары бар и дегет чыгарганнар шунда. Нарат те$^{е}$пләрен джийа булганнар, итә булганнар. Шондый заводиклар йасаганнар. Шонда китереп йандырып, дегет чыгара булганнар.

Малан *(балан),* паңгы, чиклавык сата иделәр урманнан джийып. Элке карту пирогы да эшләгәннәр, ачка ү$^{е}$лмәстән.

*Кузнецк районы Дәхтәрни авылында*
*Салихова Фатыйма Зыятдин кызыннан (1938 елгы),*
*Яфасова Әминә Мохам кызыннан (1926 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Төн ката *(төн буе)* молотилкада суга идек. Кыз $^{т}$чак шы$^{о}$лай узды. Безнен тырмышларны йакшы ко$^{т}$чокка *(эткә)* да күрсәтмәсен. Шы$^{о}$лай үтте безнен ү$^{е}$мерләр. Ке$^{е}$ттек берче йакшылык булыр дийеп.

Ишек алнысы читән иде. Йеде бала тудым *(тудырдым)* үдә. Алты йыл алашада эшләдем, ирем ү$^{е}$лгәч, балаларым ө$^{ү}$чен. Аннан инде о$^{у}$лларым армийәдән кат'ты *(кайтты)* да, берем шуфер эшли башлады, ыстаршийым трактарист эшли

башлады. Зур о$^{у}$лым үләнде дә китте. «Китмә, о$^{у}$лым, братың үләнгенче *(өйләнгәнче)* тыр», дим. «Иләшә *(ияләшә)* алмасан, кат′ырсың».

Зур йылгада ташу ага иде. Йаз башын (*язын*) ташу багарга бара идек. Шу$^{о}$нда былыннарга чыга идек, кызлар да, йегетләр дә килә иде. Йәш катыннар да бара иде. Картлары да кас′ы кызыксынганнар бара иде. Йыйылыша идек, ун′ый идек. «Мә сиңа йаулык, кана миңа саулык», дип әтеп, ташлый идек күөз йаулыкларын.

*Неверкино районы Али авылында*
*Баранова Гөлгенә Билал кызыннан (1927 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Бездә йылгадан өстәрәк $^{т}$чишмә бар. Ул $^{т}$чишмә йанында топол ү$^{ө}$сә иде. Бер тапкыр ке$^{ө}$чле су агымы беләнмедер тупылны йуwып те$^{ө}$шерә дә, ул аумый, те$^{ө}$шә дә утыра. Тупыл утыргач, халык тарата, чынмы йу$^{о}$кмыдыр, вроде аның файдасы бар. Ул те$^{ө}$шкәч аумаган, утырып калган. Аллаһы Тәгаләдән ул и аның эзендә чыккан чыгымнан халык төрле йаклардан, төрле өлкәләрдән килеп су ала иделәр. Ул вроде инде терелтә: кемдер кү$^{ө}$зләрен йыва, кү$^{ө}$зе атчыла, кемнең тагын нидер. Вот шулайга берничә йыл шылай йе$^{ө}$ределәр дә и артык бетте инде. Алтмышынчы йыллар булгандыр. Бер йегерме-утыз йыллар йе$^{ө}$ределәр, озак йе$^{ө}$ределәр. Тополне кискәләп, урманга итеп, каадыр йугаттылар аны. Халык тытынды, кисеп, ниләрен алырга, ул биг файдалы дийеп. Әл дә сүләделәр бер трактарист ул тополне алып китеп, каадыр кискәли. Соңыннан ул тракторист йу$^{о}$к булды. Шу$^{о}$ндый изге агачны кискән өчөн.

*Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында*
*Хәбибуллина Талия Рөстәм кызыннан (1952 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Безгә, матәм *(мин әйтәм),* ник Казан дийеп кушмаганнар, ник Пәлдәнке? Ник Татарийага кушканнар. Без точны казанда тырабыз. Безгә хут дү$^{ө}$рт йактан кил, и абезател′не авылнын өстенә йетмичә, авылыбыз кү$^{ө}$ренми. Дү$^{ө}$рт йактан урман, чокырда. Без вет урыс халкы белән тырганга күрә, безнен

бик көп сүзләребез урысча. Безнеке йартысы урыс, йартысы татар.

Рыштуада оланнарны *(балаларны)* куркыта йе$^{ө}$ри иделәр. Тирес туннар кийеп керәләр. Кызыл йымырка кен, ничек этийем, әмән шундый традицийа, урыс празнигы инде. Шу$^{о}$л ке$^{ө}$н шикләнәбез: кем керә – айагы йеңелме булыр, авырмы булыр; тырмышыбыз алгамы китәр, арткамы китәр.

Киндер эскәтерләр, киндер йөслекләр *(сөлгеләр)* булган. Киндерашны ашый идек. Аны майга чыгарта иделәр барып. Аларны ниндидер суларга сала иделәр, черетәләр, тевәләр, мошко чыга. Мошко этелә иде. Мошкодан киндерләрне йасый иделәр. Черетәләр, тукмаклыйлар и аннан йеп чыга. Эрли тырган станокларга йебәрәләр киндер йепләрне.

*Кузнецк районы Пәлдәнге авылында*
*Еникеева Рауза Исхак кызыннан (1940 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Чыwашлар килгән булган торыга дийеп. Йу$^{о}$к урманнар, ниләр. Алар Карновар исеме ат′еп киткәннәр. Үзләре киткәннәр моннан.

Бик зур аwыл булган бездә. Беркаа да халык китмәгән әмән, ретелмәгәннәр *(таралмаганнар)*, эж *(эш)* булган. Койты *(начар)* булмаган безнен авыл, тату торганнар. Без татарча укыдык.

Йаз башы бик күрекле *(матур)* уза иде – бийүләр, гармуннар. Су буйларында зур су ага иде бик. Ташу этәбез. Мустлар йуг иде элгәре. Бозлар ага. Халык кичен китә су багарга. Гармуннар, бийүләр, йырлаулар. Култасмал (*кульяулык*) ыргыта иделәр суга. Теләкләр теләп.

Кырда пешерү бар иде. Буткалар. Зур казаннар элгәре. Кизләүдә йахшы су агып тора иде.

**Те$^{ө}$гели, те$^{ө}$гисез.** Пижага *(мич башына)* джыйылып, ун′ыйлар иде. Бер кулына куйа чигелдәк *(бавырсак)* өчнемедүртнеме. Бусы угадат′ должен те$^{ө}$гилеме-те$^{ө}$гисезме *(парлымы-парсызмы)*. Угадат′ итсә, чигелдәкләрне ала, итмәсә – үзенекен бирә. Йанварда. Шу$^{о}$ндый йола. Оланнар азбар *(йорт)* сайын йе$^{ө}$ри иделәр. Пасха да эшли иделәр. Бездә дә йымырка

пешерү бар иде суган кабыгына буйап. Элгәрегедән үк бар иде. Урысларнын адәте.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Мансуров Вильдан Касыйм улыннан (1945 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

## Гореф-гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр, ырымнар

Йаз башы чәчү беттеме – **Сабантуй**. Вис авыл тына иде: карты, йәше, ыланнар – берчесе шунда барып, анда көрәшләр, узышулар, теөрле уйыннар. Карты, йәше – элгәре берсе тигез иде.

**Яңгыр яумаганда**. Болынга чыгып, намазлар укыйлар, йамгыр сорыйлар. Оланнар су сибешәләр, йамгыр сорыйлар. Машинаны да, кешеләрне дә койалар, берсен койондыралар. Чыгып йамгыр сорый иделәр дә, Алла бирә иде. Әлхамделлиһи шөкер. Әле дә әнийем әтә, безнен кырлар, ди, өрәнде иләшкән, ди, үмере йаңгыр сорыйлар, корбан чалалар. Безнен, ди, кырлар келәүле, шунын өчен кирәк корбан чалып, йамгыр сорарга чыгарга. Мин помнит итәм: әниләр, чыгарып, кучаркалар бәрә иделәр. Нинди йола булгандыр. Каты боз йауганда, нәрсәдер укып, чыгып бәрә иделәр. Олан чагымда шуны эшләгәнен беләм әниемнен.

Азбар сайын гармонистларыбыз иде йәшләр. Хәмзә күөршем дә ун′ый иде. Кичен эшләрне, йазын ашыгып-ашыгып бетерәбез дә, берчебез урамга. Берчесе халык урамда, оланнар үзләренә сикерешә. Элек бик шат иде тырмышлар. Халык шат иде әмән авыр йыллар булса да.

**Боз китү.** Йаз башы уйын ун′ау иде йәшләрнеке кар, боз киткәндә. Вата хаз′ер анда мәчет тезелде. Шул урында. Йаз башы ике атна шул чәчүләргә тике ике атна бетерү халык барчасы йыйыла шунда. Безелек уйыны ун′адык.

**Каз йолку** үмәләре иде. Йәшләр йыйыла идек. Кеөнызын йолкабыз казларны, арчыйбыз, өтәбез, сыйырабыз каwырсынын, йуwабыз. Кичен вечер ун′ибыз. Обизател′но кайа каз

үмәсе булдымы, анда вичер. Аннан былай да вичерләр йыйа иделәр. Элгәре бик кызыклы иде безнен замана.

*Неверкино районы Али авылында*
*Биктимерова Гайшә Әюп кызыннан (1950 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

**Рамазан** айы бар'амы пәрәмәчәләр, бәлешләр пешерәбез. Эчәк бәлешләре, мөшке бәлеше, кур'ага бәлешләре. Килгән кешеләргә, кунакларга өстәл төзибез *(табын әзерлибез).* Элке катлама пешерәләр иде. Хәзер аны пешермиләр. Йезәңге атә идек. Май эчендә аны пешерәләр.

Степка чыга идек оланнар белән. Йомырка кыдылатып ун'ий идек. **Кызыл йомырка кене** ателә иде. Йаз башын була ул. Апрел 25 ләрендә була иде. Үдән пешерәбез. Суган кабыгына буйыйбыз кызылга, төрле краскага.

**Йегетне армийәгә** озатканда элке йегетнен эвендә йыштыралар. Безнен заманда, атийем, малайлар гына йыштыра *(җыелыша),* кызлар йук. Урам буйында кабак өстенә *(капка төбенә)* без чыга идек кызлар. Ызбаң алнысына чыгасын да, ул узып китә. Саубуллашып, култасмал селкеп китә. Култасмалны икене бәреп йебәрә, суга. Ул тасмаллар су белән агып китә. Йегет култасмалны селкә. Инешне күчкәндә бәрә дә, сунын уртасыннан узып киткәндә, машина белән. Агып китә су белән. Сухари каба да арты белән чыга үдән. Сау катырга дип инде. Аны сындырып калдыра, аны йыштырып куйалар.

Мулланы чакырып, балага ат куштыра. Мәйлет йыштыра. Бәбәй буткасы ателә. Анда бү$^{ө}$ләкләр белән киләләр. Бер ай торгач, мәйлет җийа. Шунда дус-ишләрен, карендашләрен чакыра.

*Неверкино районы Мансур авылында*
*Ямлиханова Мәхфүзә Исмаил кызыннан (1941 елгы),*
*Биктимерова Рәмзия Идрис кызыннан (1941елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Үземнен о$^{у}$лымны озатканда йыйдым кызлар, малайлар – вичер булды. Тасмалларны йу$^{о}$лда бәреп баралар иде. Берне генә дә төгәл. Кесәсенә култасмаллар ала иде и бәрә бара. Берне, тагы бара, тагы берне шылай. Үгә кат'сын өчөн. Арты

белән чыгаралар эвеннән китә торган солдатны. Чыгып китә. Мөрҗәгә кычкырасын: «О$^{у}$лым, кайт», дип, өч мәртәбә. Күмәч пешерә идек. Шуны кыстырып куйа идек ишек башына. Ул килгенче *(кайтканчы)* йа тора, йа тормый, йа тыскан ашый.

*Неверкино районы Биги авылында*
*Акчурина Сәгадәт Абдулла кызыннан (1941 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

**Вичерда** тугәрәк ун′нар, кыругта йырлау, бийеп йе$^{ө}$рү иде. Өлгереш дип атә идек. Сине суга да ремен′ белән, йә йөслөк белән, ыстулга куйа да, син өлгер алып. Өлгермәден, сине суга, аннан наказ бирәләр нәстә, нишләргә – бийергәме, йырларгамы инде анда. Миңа туры килде күөрсәтергә ‘кулыңнан кан чыгар’. Ни$^{т}$чек мин кан $^{т}$чыгарим кулымнан. Ул икән лампага каршы куйарга да, кызыл күренә. Шул кан чыгу була икән ул. Икенче берәүгә ‘йыласын, йәшен себерсен’. Ул икән кулйаулык белән – тирәсе тирләгән – тирәсне себерегә *(тәрәзәне сөртергә)* кирәк. Шундый хал′ләр була иде. Йе$^{ө}$зек йәшерү дә бар иде. Сикереп чыгарга, ике йактан тыталар ү$^{ө}$зеңне, наказ бирәләр чыгалмыйсын да: йырлау, бийеү, ни дә булса сүләү.

**Яңгыр яумаганда. Таwык корбаны** дип атәләр бездә. Бала-тчага чиләкләр алып, урамда узып барган кешеләр өстенә су сибә. Оланнар таwык корбаны ун′ап бетергәч, «Йаңгыр, йау, йау, иләктән, чиләктән, пәрәмәчә коймактан, арыштан бодайдан, без сорыйбыз Ходайдан», дип йе$^{ө}$риләр. Бала-$^{т}$чага җийыла. Аларга нәстә ни булганны чыгарып бирәсен. Кас′ы йымырка, кас′ы конфит, кас′ы акча, кас′ы он. Аннан инде бер кеше су йанына барып, оннарыннан-ниләреннән әләкшә кебекме пешерә, йымыркамы пешерә. Вот шылайга. Су те$^{ө}$бенә җийылалар, утыралар, оланнар ашый.

Бездә сабантуй төгел, фестивал ателә иде.

*Кузнецк районы Ялгаш авылында*
*Ишкулова Рауза Нургали кызыннан (1940 елгы),*
*Ибраева Рәфия Исхак кызыннан (1966 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

**Вичер** да булган. Бер-бересенә утын кисешкәннәр. Кызларга вичер уздырыга урын кирәк. «Утынымы киссәгез, арендага

бирәм ызбаны бер кичкә вичер унарга». Бер лампочка. Ленин бабайныкы. Авылда бер генератыр эшләгән. Шу$^{о}$нда кызлар йыйыла, малайларга да әтәләр. Малайлар кискән, кызлар үгән утынны – ү$^{ө}$мә булган. Ызбалар кечкенә булган. Кышын да, йазын да йыйылышканнар. Эшләгәч кенә вичер уздырганнар, ун′аганнар.

Кызлар **чигү** чигәргә айырым йыйылышканнар. Бер атна күрше кызда, бишәүме, дүртәүме, приданныйга чиккәннәр. Икенче кенне икенче ахирәтенә барганнар. Дҗийылышып чиккәннәр. Йе$^{ө}$решеп торганнар, бер үдә генә төгел.

**Боз киткәндә** йаулык ыргытабыз кү$^{ө}$пергә барып. Саулык сорыйбыз, кызлар кийәү сорыйлар. Кагызга теләк йазабыз да, ул агып китә.

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Сәйфетдинов Рафаэль Касыйм улыннан (1962 елгы),*
*Рәхимов Салих Али улыннан (1954 елгы),*
*Рәхимова Галия Касыйм кызыннан (1957 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

**Рыштуада** бәрәләр иде кабак (*капка*) аша чабаталар, вал′ник, калуш. Тчыгасын да инде, те$^{ө}$нге унике сәәттә и кабак аша бәрәсен. Иртән чыгып багасын инде каа таба башы тора. Башы Кынадыга *(авыл исеме)* таба булса, Кынадыга чыгабыз кийәүгә, Пәндәлигә *(авыл исеме)* таба булса, Пәндәлигә. Чигелдәкне *(бавырсакны)* терлекләргә чыгаралар, каптыралар. Байга барасын инде.

Бырынгы кызлар дҗийыла булганнар. Тавыкны кертәләр унике сәәттә Рыштувада. Су, аракы куйалар. Сунымы эчә, аракымы эчә тавык. Әгәр аракыны эчсә инде, кийәүгә исереккә барасын. Суны эчсә, йакшыга барасын.

Оннан чигелдәк йасыйсын да ун′исын.

**Кызыл йомырка** – ул урысларныкы Пасха. Йортта терлекләр кө$^{ү}$п булсын, кош-ко$^{у}$рт кө$^{ү}$п булсын ө$^{т}$чөн. Безнеке шундый йола белән кызыл йомырка ателә. Шул те$^{ө}$нне йомырканы кызылдан буйыйлар, өстәлгә куйалар. Кем керә, шуңа абизател′ны шул йомырканы бирергә кирәк. Айак сыныйлар, әл дә кем керә беренче. «Кыт-кыт» дип кытыклап керә. Айагы дҗиңел булса, шул кешенеке, кешенен йылы удайотся. Ко$^{у}$ш-курты кө$^{ү}$п

булса, чебешләре чыгарса, терлеге бозауласа анда, куйлары чагаласа *(бәрәнләсә),* менә без шунарга бәлибез аны, кызыл йомырканы.

*Кузнецк районы Дәхтәрни авылында*
*Ельмеева Мәрҗәм Исхак кызыннан (1936 елгы),*
*Мусякаева Равилә Йосыф кызыннан (1938 елгы),*
*Аитова Наилә Таһир кызыннан (1963 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Бик йакшы йе$^{ө}$решеп кушылдык. Алашада туйлар ун′адык. Унике алаша иде туйыбызда. Миндә плүш пал′тә иде. Бер атна буйына туй. Сыйда катык, анын артыннан ит, анын артыннан салма, аннан бәлеш, анын артыннан өстәлне йыштырып алып, аннан соңга чәй. Чәй астына катлама, бәлеш, конфит, бал куйалар иде.

**Ат куштыра** иделәр. Бәбәй мунчасы йага иделәр. Аннан суңга бутка йыйа иделәр. Ыру-кардәшләр бәбәйгә подарка итә.

**Раштуа**. Чигелдәк пешерәләр. Кийенешеп азбар сайын йе$^{ө}$риләр, бииләр, йырлыйлар. Аларга чигелдәк бирәсен, акча, конфит бирәсен. Зәләмә дә кийенә, иске туннар да кийенә. Касылары курка, кабакны чыга выни, йебәрми. Орлыйлар. Чананы алалар да азбардан алып китәләр. Итәләр дә куйалар йырак кына. Әле выны йар астына йебәрәләр. Башн′а бар иде. Башн′ага чана менгезеп куйганнар. Ну кызык өчөн. Чигелдәк йасаган йомыркалап йахшы гына. Камырны катуклаган да, кискәләгән дә табада пешергән, майлап. Йе$^{ө}$рүчеләргә бирәләр. Әгәр имеш аны пешермәсән, ку(й)ларын *(сарыкларың)* булмый. Аны пешерегә кирәк.

Кызыл йомырка ке$^{ө}$нендә бармакларны бөкләп ат′абез, ун′исын: шылай тотасын да әмән, ‘те$^{ө}$гилеме, те$^{ө}$гисезме’ *(парлымы, парсызмы)* дисез. Бер кеше атә ‘те$^{ө}$гиле’. Те$^{ө}$гиле булса, нибар чигелдәгеңе ала.

Пасха урысларныкы. Но все равно красим. Йомырка пешерәсен, кызылга буисын. Оланнар йе$^{ө}$ри. Оланнарга конфит, йомырка, акча бирәсен.

Кем керә үгә **кызыл йомыркада**, пасхада и сыныйлар айагын. Йакшымы, койтымы дип. Вәт әмән мин бире кердем, сыный хоз′айка йыл буйында йакшымы булыр. Әнийемне кичен үк

чакыра иделәр: ‘Син инде безгә кер’. Әнийем караңгыдан тора. Утын йыйа-йыйа кочагына барып керә. Укый, «кыты-кыта» кычкыра. Аннан соңга анарга бирәләр ни бар затын. Әнийем азбар *(йорт)* сайын йеᵉри иде. Аннан братым тытынды. Йакшы кешене чакыра иделәр, чтоб самый первый ул гына керсен.

Саласка *(чана)* белән кышын да ташый булганнар. Писләр йагарга. Суны кизләүдән, мыный инештән, ташый идек. Кеᵉн буйы су ташый идек. Йыварга да кирәк, эчергә дә кирәк. Урман кисү бар иде, әле инде йуктыр.

*Неверкино районы Бикмосеевка авылында*
*Абделманова Хаҗия Муси кызыннан (1937 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Чабата бәрә – кас′ы йакка, шул йакка кийәүгә китәсен. Азбардан бәрәләр выт *(менә шушы)* кабак *(капка)* аша урамга. Чабата каа таба бага. Әле калуш бәрәләр. Потом тытып кергезә иделәр кур′ат′никтан тавык. Салалар су, бодай. Если тавык бодайга китсә, байга чыгасын. Суга китсә, значит йарлыга. Чутмы-чатмы ун′адык. Өстәл кыругына тезеләләр малайлар-кызлар. Парлымы-парсызмы – угадай инде. Оланнар ун′ий иделәр аны ызбада.

*Неверкино районы Җәлил авылында*
*Абдекеева Мәрфуга Сәлахетдин кызыннан (1929 елгы),*
*Фейзикова Дания Гомәр кызыннан (1970 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

**Хатыйм** булса, бездә пәрәмәчә куйалар, коймак и әпәй, үдә пешкән. Йабалар йөслөкләр белән. Аннан дыва укыгач, чыгаралар катыкны. Катык артыннан ит чыгаралар. Аннан салма. Салма артыннан бутка. Аннан сон чәй, бәлешләр. Сал′ник атәләр – рисовый бутка булса, анын өстенә йеземәләк (*йөзем җимеше*), кур′ага. Нәстә бар салалар. Карабдай булса, үзе генә.

**Балага бәйле йола.** Исем куштыру. Анын өчөн чакыралар мулланы. Ул укий дывасын. Колагына кычкыра өч тапкыр нинди ат куштыралар. Өстәлгә куйып, йастык өстендә. Аннан бәбәй чәйе эшлиләр. Кызга укыталар бәбәй чәйе генә, малайга сөннәт келәве, сөннәткә бирәләр. Аныкы ике мәҗлесе була: бәбәй чәйе дә и сөннәте. Сөннәт туйысын уздыралар. Хаз′ер

корбан чалалар йәшләр. Малай тугач, икене, кыз тугач – берне куйны *(сарыкны),* терлекне. Бырын берне генә чала иделәр.

Акча маңгай куйалар бала йанына бәби үстерегә килгәндә. Күзекмәсен өчен дыва куйалар, бетү куйалар. Күркле *(матур)* брушкамы куйган тайкасына *(башлыгына).* Кү$^{ө}$зең те$^{ө}$шә бетүгә. Бишектә тирбәтәләр оланны. Специал′ны урнысы булган бишекнеке маткада *(матчада).*

*Сосновоборск районы Әлмәш авылында*
*Ягудина Гүзәл Сәит кызыннан (1967 елгы),*
*Сәйфуллина Румия Кәлимулла кызыннан (1951 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Мин **кендек әбисе** булдым. Алтмыш өченче йылны йегерменче аwгустта сигез кеше туды бер суткада. Төнге уникедә башладым, тудырып *(тудыртып)* киләм, тагын – сигез кеше бер суткада. Кынадыда рождаемост′ кү$^{ө}$п иде – первое место.

Үземнен зарплатама лаукадан *(кибеттән)* алдым ике метр палатна, бер митыр клийунка. Шу$^{о}$л клийонканы йәйәм, пристин′аны йәйәм, анан тудырам *(тудыртам).* Искеләр йу$^{о}$к. Элкеге вахытларда йастык тышны салдырып, шунда чорный идек. Пристин′аны калдырам. Шу$^{о}$л катын соңыннан йывып, үземә итәләр. Анда ү$^{ө}$түклисын гына. Утыз биҗ йыл эшләдем шулай. Мин фактически фел′дшерскины бетердем, но эж йукка күрә акушеркой урнашырга туры килде.

Олан *(бала)* тугач, маңгайына кором се$^{ө}$ртәләр. Кем килсә дә, кем бакса да, кү$^{ө}$зе шунда те$^{ө}$шсен. **Корку койу** бар. Олан ко$^{у}$рка. Выты аны кирәк ишек те$^{ө}$бендә оланны аласың кулыңа, кургашын эретәсен. Консерва савытына саласын и су саласын да ул сүнә. Олан бусагага утыра, мин укийым дыва баланын башына. Укийым да атәм: ни койам, ко$^{у}$рку койам. Ко$^{у}$ркувын койам: өч мәртәбә башыннан шолай әләндерәм-әләндерәм. Шуны итеп, ишекнен тупсасы дип әтәбез, ишек атына уголга тупсага бәрегә тийеш. «Ко$^{у}$ркувын кой», дип, оланнарын китерәләр иде. «Кан′ар кургашын башына тамызмагыз», дип атәм. Шондый йолалар бар иде.

Өстәлнен дү$^{ө}$рт почмагын итәләр, родничокка, кендекка, авызга и тоже ишек тупсасына се$^{ө}$ртеп чыга. Эчерергә кирәкми, тол′кы се$^{ө}$ртергә. **Кү$^{ө}$з тимәсен өчөн.**

Безнен абийебез атә иде:

– Йакшы тай атка ийәреп йеᵒри.

– Артыңа бәрсәң, алдыңа төшә.

– Запаслы ат арымый кач′ан да.

– Байда долг җугалмый. Ул түли.

– Теᵒкермә иске койыга, әләнеп сывын эчәрсен.

Мин синен белән әмән орыштым, мин синен белән тийеш дусланырга. Дамы?

*Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында*
*Йосыпова Кадрия Ризаэтдин кызыннан (1928 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Понедел′ник – баш кен, вторник – буш кен. Джома кен берни эшләмә, берни йума да әмән. Идәннәр, керләр йума – гон′аһ. Тәмлеләр пешер дә аша. Мөнәҗәт атәсенме, әбиләр җыйасынмы. Мунча кене – кечатна кен читверг. Элкедән шолай булган. Атнараз кен – суббота, урыс атна кен/базар көн.

*Кузнецк районы Ялгаш авылында*
*Вайселева Суфия Таһир кызыннан (1937 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

## Туйлар

Без башта **сүз бетердек**. Рамазан айы иде. Киләсен, кызга башкода. Кем белән булса да йегет килә, сүләшәсен. Кызны сорыйсын эти-әнисеннән, ризалыгын. Кыз әмән риза, сүләшәсен кач′ан никах, туй. Бүләкләр алышу: кан′анам бирде миңа пухситка *(кәҗә шәле),* туйга көмеш йөзек бирде бабайым. Әл дә дә бар каадыр ул йөзегем. Алтын теᵒгел. Агач түр *(кәнәфи)* иде, аңа йәйгеч бар иде. Әнийем бик хазырлаган иде бирнәләр. Тамбур белән бәли идек коргычлар, эскәтерләр.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Мансурова Мәрьям Габдрахман кызыннан (1947 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

**Йәш килен корбаны** атәләр безнен авылларда, ә Кырнаварда *(авыл исеме)* йәш **килен мамыгы** атәләр. Ул выты *(менә шушы)* туй уза, бер атна уза. Мәҗлес уздыралар. Әбиләрне

чакыралар, туйда булмаган ыруларны, кү$^{ө}$ршеләрне. Йәш киленгә дыва кылдыралар. Анда да бирнә бирешәләр. Әнисе китерә кызнын, малай әнисе дә бирә. Кара-каршы. Хал′еннән килгенчә әмән. Элгәре заманда самый ценный булган отрез. Материал инде. Күлмәклек өч метр әмән.

*Неверкино районы Исәкәй авылында*
*Бибарсова Равилә Гайнулла кызыннан (1936 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

**Урлап алу.** Кызнын торгысы да, киткесе дә келәми. Орлап китерделәр. «Каласынмы?», «Калам», ди. Никах укыталар. Шол ук кен булмаса да. Кыз йагыннан килә эти-әнисе, йакын кардәшләре. Мулла килеп, никах укый. Бу урлап алуны сүләдек.

**Ризалашып бару.** Беренче инде качан кызны йәрәшәләр, анда беренче кызнын бү$^{ө}$ләген йебәрәләр. Ул күремдек этелә. Күремдек – ул ризалашу кыз йагыннан. Сөлгесен куйалар, әбигә тастымал *(баш яулыгы),* бабайга йөслеген куйалар, чәйен куйалар. Кызнын күремдеген алып баралар кийәү эвенә. Күремдек килде – согласие бар. Тытыналар туйга әзерләнергә. Беренчедән, ник′ах. Аннан сон йазылу, аннан туй. Элгәре туйны атналап уйный иделәр. Элгәре алып баралар малай эвенә кызны. Малай эвендә ике кен туй була. Өченче көнендә хәл белү килә. Аннан кыз йанында тытына. Бер өч кен анда. Туганнарында йе$^{ө}$рү. Безнен вакытта азбар сайын ала иделәр бар йакыннары. Биш-алты үгә бара иделәр. Иң суңында йәшләрнеке вичер. Атларны бизәп, калакуллар белән, йе$^{ө}$ри иделәр гармушка тартып, йырлап. Урам буйы йе$^{ө}$риләр дә барып керәләр йегет эвенә. Анда барып кергәндә ке$^{ө}$зге тыту. Ике йаклап ке$^{ө}$зге тыталар йәшләргә, ширбәт, бал каптыралар. Духи сибәләр киленгә. Кан′ана пристин′амы йәйә аларга. Акны. Акка бастырып йәшләрне кертәләр. Элгәре йастыкка *(мендәргә)* бастыру йуг иде. Крылчасына йәйә дә пристин′а, икесе генә шулай керә инде. (...) Тимер акчалар, конфетлар сибәләр. Эти-әнисенә китерә бү$^{ө}$ләкләр. Этигә кү$^{ө}$лмәк, әнигә кү$^{ө}$лмәк-шәл, намазлык. Килен үзенеке дә намазлыклар белән килә булганнар.

*Неверкино районы Али авылында*
*Биктимерова Гайшә Әюп кызыннан (1950 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Туйда уникешәр-унөчәр алаша була иде. Бизи иделәр алашаларны. Йөслекләр, эскәтерләр йабалар атлар өстенә, дугаларга. Шутник бабайлар катын-кыз күлмәге кийәләр. Алар баскан, йырлап баралар.

Сондыкка те$^{е}$шерәләр йәш киленне, ак пристин′а йәйгән. Йастыгын куйа сондык өстенә. Йастык астына акча куйа. Кем ала ала шул акчаны. Башка кеше. Акчалы булсыннар, дип куйалар. Йәш киленне алып киткәндә оланнар утыртып чыгаралар. Ике олан. Конфит сибә иделәр. Йәш киленне чыгарганда йырлый иделәр бик. Туйда элке өстәл артында ирләр генә, катын-кызлар йу$^{о}$к, утыртмыйлар. Никах кыз эвендә була. Йәш килен йагы туй күтәрә. Атна буйы кодаларны йе$^{е}$ртәләр әмән: кардәшенә барам, икенче кардәшенә. Аннан йәш киленнәрне чакырып йе$^{е}$ретәләр. Чәйгә. Шишмәдән су алу иде элгәре. Килен барган суга, карамысла тагып. Йәш киленнән кан′ана йәймә йәйдерә булган төшкәч, камыр бастыра инде. Кан′ана багып тора. Йәйеп күрсәтә килен. Кыңгырырак та чыга инде берәз, кыйыграк.

Әнийем өрәтте. Ыстулга басып, йәймәне тапый идек.

Пилминнәр да бар иде йасау, бөгмәләр. Аны да кан′ана өрәтә иде. Анда без йәш идек. Унсигезенче йәш. Нәрсә беләсен – бер зат та белмисен.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Мансурова Мәрьям Габдрахман кызыннан (1947 елгы),*
*Мозаффарова Рауза Габдрахман кызыннан (1945 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Туй бездә дү$^{е}$рт ке$^{е}$н барган. Туйда икенче кенендә булган сый. Кызны китерәләр дә беренче кен малай эвендә булалар. Аннан була кыз эвендә сый. Аннан поклонный булган тагын малай эвендә. Аннан кыз эвендә тагын поклонный. Вичер сынны була анда дү$^{е}$рт кен. Әбиләре белән как раз бер атна. Шул ук үдә кардәшләрен чакырганнар. Родител′ский ү *(өй)*. Башка үләрдә төгел. Бизеп бетәләр ничә кен туйда булып.

Икенче кен килен суга барган. Малайлар урамда ке$^{е}$теп тора йәш киленнен судан килгәнен, чиләген түгәргә коромысло белән. Кызныкы кесәсендә култастымал, аларга бирегә, ыштуб чиләкне түкмәскә. Вичерда чигеп утырган култастымаллары.

Бү$^{е}$ләкне бирегә өлгөрмәсә, чиләкне түгәләр. Түгелсә, кире бара суга. Анда өчәү-дү$^{е}$ртәү малай басып тора. Йаулыкларны ыныклап апчыга.

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Сәйфетдинов Рафаэль Касыйм улыннан (1962 елгы),*
*Рәхимова Галия Касыйм кызыннан (1957 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Сондыкка сала бардык. Бирнә йыштырасың. Туйдан алныда *(туй алдыннан)* китерә сондыкны, аны бизи. Туй кенендә китерделәр йәш киленне. Ачтылар сондыкны. Сондыкнын эчендә кан'ана ө$^{т}$чен намазлык иде. Анын йанында ниндидер материалдан падаркасы. Сондыкны бушатып, шул йөслөкләрне *(сөлгеләрне)* тага иделәр туй кенендә. Йәш киленне китергәч. Бөтен ниләрне тагып бетерәләр. Туй халкы багып торган таккаННарын.

Салма тапаттырган *(токмач кистергән)*. Камыр биргән, салма тапый алса йахшы гына, вак кына.

Йәш килен акча сипкән килгәндә. Кийәү чыкканда йәш килен йортына сибеп китә. Оланнар йыштыра (*җыя*) иделәр. Урны-йерне кигезгәндә йырлыйлар.

Акмы йастык тышлары,
Күкме йастык тышлары?
Севеп алган, севеп барган –
Шолар оҗмах кошлары, –

дип йырлыйлар.

Кийәү йегетләрен кергезә баралар, йырлыйлар. Зурлап никаһ мәҗлесе үткәзәләр кафеда хаз'ыр.

*Кузнецк районы Бистән (Гөлбестан) авылында*
*Бикмурзина Наҗия Исмаил кызыннан (1955елгы),*
*Хөсәенова Рәисә Абдулла кызыннан (1941 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Ирең, кийәү йантыгыннан куйалар киленгә күлмәк, аннан шәлме куйалар. Әмән йәш киленнәр килә, төшә машинадан. Ак пристин'а йәйәләр. Беләзекләр булса, икене беләзекләр куйалар. Беләзекләр булмаса, бишәр сумлык акчаларны куйалар. Әле шулай. Элкеләрнең йуг иде. Бал каптыралар, көзге тота-

лар. Ширбәт сывы өстеңә «фуу» дийеп өрәләр. Чөчө су, бал сывы йасыйлар стаканнарга.

Элке туйда парлап тегел, ирләр генә иде. Аннан инде парлар чыкты, катыннар белән чакыралар. Икенче кен пахмел′йага киләләр, кийәүнең эвенә. Кийәүнең йантыгын кызның йантыгы (*кыз ягы*) күтәрә, кунакка чакыра. Шында унмы, йегермеме пар чакыра йакыннарын.

Корбан мәж$^3$лесе йыйалар кийәү эвендә. Бер атна, ике атна узгач, корбан мәҗлесе, мамык мәҗлесе ателә инде. Мамыкка чакырам атә иделәр. Кызның токымы килә дә инде, үзенең токымын да йыйа. Йегет эвендә була. Хатемнәр укилар, дыва кылалар, аш-су өстәлләрдә инде. Хатем укий – саулык сорап китә. Киченгә кызларны чакыралар – кызлар вичеры. Круг ун′ибыз, биибез, йырлыйбыз. Суга иделәр солдатский прәжкә белән идәнгә. Артка – степка – чыгып ун′и идек. Кызлар уйыны. Култасмаллар бәрә идек. Инеш буйына барасын да, битеңе йуасын да, култасмалыңа себерәсең *(сөртәсең)*. Култасмалны бәрәсен суга, су анасына, дийеп. Су анасына сәлам. Ул алып китә.

*Неверкино районы Мансур авылында*
*Ямлиханова Мәхфүзә Исмаил кызыннан (1941 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

## Кием-салым, бизәнү әйберләре

Безнен татар халкысы ызын йеңле күлмәк кийәләр иде. Кыска йеңлене кимәде. Намаз укыганда да, былай да катын-кызлар берче *(барсы)* тастымалдан *(баш яулыгы)* иде. Тастымалны алдан *(алгы яклап)* бәләделәр. Култасмал – кулйаулык кечкенә. Руминкалар кигән кызлар. Бийек табанлы әниемдә бар иде. Йонлылар иде. Вал′ник *(киез итек)* басканнар. Урыс авылы бар. Анда итәләр иде йонны. Вал′ник бастыра идек ке$^{е}$зге йоннан. Йаз башы *(язгы)* йоннан йерли идек үзебез йоннарны. Насук, варик бәли идек. Кашма йәйә идек, йасый иде бик сирәк кеше. Мишкавина өстенә йумаган йоныңны бик рәтләп кенә тезәсен. Аннан ары аны йебетәсен, кучалыйсын. Мишкавина белән ук. Берәз матат′ итәсен, әләндерәсен. Ке$^{е}$згө йон гына кирәк. Аннан аны тетәсен и кипетук саласын. Аннан

тагын чорныйсын. Кү$^{ө}$п мәртәбә аны чорнарга кирәк. Түрләргә *(кәнәфиләргә)* йәйә идек кашманы.

*Неверкино районы Биги авылында*
*Акчурина Сәгадәт Абдулла кызыннан (1941 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Талир тәңкә тага булганнар. Чәчләренә касниклар ү$^{ө}$рә иделәр. Камзул тезгә тике иде, кыска төгел иде. Итәге киңрәк иде. Мында каптыртма белән. Башка тастымал йабынганнар. Боронгы әбиләр ике чикеннән тотып йабына иделәр.

Мошко *(киндер)* үстерәләр иде. Аны изгәли идек, селкә идек. Бәл′әмнәргә бәләп ташый идек. Йерләтә шул мошкыдан. Мәшүкләр, полыхлар йасый булганнар. Полыхларны йәйеп, иген бушата идек. Киндераш анарга әтә идек.

*Неверкино районы Җәлил авылында*
*Абдекеева Мәрфуга Сәлахетдин кызыннан (1929 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Ике шәл бәләдем үмеремдә, кийәүгә чыкканда. Йөслекләр чиктек, йастык йапкычлары бәләдем. Эскәтер бәләдем ышпулкадан. Элке лампалар да йуг иде. Бер савытка сол′аркамы, керосинмы сала да анайлар инде. Шуны берәз йагабыз. Кө$^{ү}$п йагарга да бирмиләр. Әнийем әтә: «Йатыгыз, булды, керосинымны бетерәсез!» – ди. Анан сон лампалар чыкты.

Эшли идек тә, чигә идек тә, ун′адык та. Тытына идек тә йегетләр, кызлар бергә, бер малай, бер кыз биисен уртада. Бер кыз чыга, ул үңгә *(башка)* кыз ала да бии тагы. Малай китә, үңгә тагын малай кереп бии. Әләнеп ун′ый идек. Элке үдә ун′ый идек. Чабата белән бармадык вичерга, чабата белән ышкулга гына йери идек.

*Неверкино районы Бикмосеевка авылында*
*Куряева Хаҗия Гайсә кызыннан (1937 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Румаллар – шәлләр кебегрәк алар. Камзул, элке «сәнәбәт» тә атәләр иде. Түгәрәк тәңкә, ке$^{ө}$меш тагалар иде. Апам тага иде артка, $^{т}$чаңгол-$^{т}$чоңгол, чәч о$^{т}$чына ү$^{ө}$рә иде дә. Бабайлар

кәпәч кигән. Кәзәләр тотканнар. Эрлиләр. Шәлләр бәли булганнар борын, хәзер йук. Ку$^{ө}$з тимәсен дийеп, брушкалар тагалар оланнарга. Биҗ дога йазып салына, кү$^{ө}$з тимәсен дийеп.

*Кузнецк районы Ялгаш авылында*
*Вайселева Суфия Таһир кызыннан (1937елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Без чигү чиктек: эскәтерләр, йөслекләр чигә идек. Йәш киленнәр запун кигән. Бырынгы заманда акчалар булган – тәңкәләр. Кызыл, күк ленталар ү$^{ө}$реп йебәрәйдек артка, чәчкә. Тасмал – ул йаулык. Без әтәбез тасмалыңны ниндине йабынасың башыңа? Тамбур белән бәли идек коргычлар, эскәтерләр. Куйны кырка идек тә, йерли идем. Орчык белән йерлисен, катасын, йывасын, бәлисен. Оланнарга да бәләп кигезәм. Насуклар, вариклар бәли идем. Кышын сывык була иде. Бездә вот шундый хал′.

*Неверкино районы Дёмино авылында*
*Хәлимова Разия Шагияз кызыннан (1937 елгы),*
*Әбүзәрова Рауза Гомәр кызыннан (1935 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Мәрхүм әтием чабата тугыта иде. Агач башмагы размерын куйа да, йү$^{ө}$кә белән ишкәкли. Һәрбер чабатадан йе$^{ө}$риләр иде. Мин кимәдем.

Мамык кебектән өскә казаки *(пальто)* кийә идем. Җиңнәре дә ызын. Кышын сывык, ә бу йылы. Казакины базардан алалар иде. Элгәре Кузнецкида саталар иде. Шуннан ала идек. Үтте үмер, әле ки, йаның ни тели. Вал′ник кийә идем айакка. Румал шәл китереп саталар иде. Куwаклы ү$^{ө}$зе, тигез төгел, күтәрелеп эшләнгән. Күркле *(матур итеп)* йасаганнар. Кәзә пухыннан шәл бәлиләр иде.

*Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында*
*Мостафина Мәсүдә Кәрим кызыннан (1941 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

## Аш-сулар

Туйда кийәүләргә, кәләш артыннан килгәч, анарга **тавык тутырып** куйалар, пешереп. Аны кийәү турый. Тавыкны чалабыз. Э$^{т}$чен аласын, зубын йыртмыйча. Э$^{т}$чен ар$^{т}$чыйсын. Йывып чистартасын, өтәсен. Ары тутырабыз йымырканы. Гурласыннан салабыз әз генә йымырканы, берәз йелдерәбез. Биг сеңәл *(сыек)* булмасын дийеп. Йакшы гына йамыйбыз. Гурла йагыннан тирене айырабыз тәненнән. Тутыра барабыз, өрә барасын, ыштуп кү$^{ө}$п сыйсын. Йыл тавыгы корка тике була инде, тутыргач. Йымырканы тутырып бетергәч, бәлисен и әкрен генә пешерәсен. Йегерме бишләр дә йымырка сыйа. Борын өчайакларда пешергәннәр.

**Мөшке (эремчек) бәлеше** пешердем. Чөчө *(төче)* сездә пешерәләр, безнеңчә түгел. Камырын анын нәзек *(юка итеп)* йасарга кирәк. Дрожа салам мин. Анын ни$^{т}$чек эчлеген хаз′ырларга? Эремчек, анарга әз генә пешерәсен дөгө. Бер бәлешкә сытам и(н) әзендә унбиш йымырка. Анарга сливочный май. Әгәр дөгөсез йасасам, каймак кушмыйм. Дөгө белән йасасам, каймак кушам. Пәсук, то$^{у}$зын берәз саласын. Бу эчлеге инде, эремчеге. Йәйәсен инде камырны и мөшкене йәйәсен, каплыйсын. Уртасын тишәргә кирәк. Анын майы ага башлый. Майны ул севә. Анда күп сары май салырга кирәк. Сары май да, эремчек тә, каймагын да, катыгын да йасыйбыз.

Чийәнен тешен *(төшен)* алып, чийә бәлеше йасыйбыз. Рузалар, лилия, катлама пешерәбез.

Мәҗлесләрдә **кывас** бездә. Квасны үзен кан′атабыз закваска белән. Кавын *(кабак)* белән булмаса, тәме йу$^{о}$к. Кавын көп чәчәбез. Кавыннан бәлешләр пешерәбез. Квасны обизател′но заправл′айым. Кавын пешереп турыйбыз. Кийар, памидур, зеленнарны вак кына. Мин лично үзем йәшел суганны да турыйм. Тозын, писугын салам да, тукмак белән изәм аны йакшы гына. Ул вис суклары $^{т}$чыга. Ни бар заты изери. Соңга гына памидурын, кыйарын турыйбыз. Алма салалар, но мин салмыйм, ул а$^{т}$чыта. Кывас ашап туйгысыз иде.

Первый мәҗ(з)лесләрдә бездә кывас куйалар. Тәлинкәләргә салып, аны һәрберсе ашый. Икенчегә ит белән бәрәңге,

өченче – салма *(токмач).* Аннан инде мөшке бәлеше, аннан бутка: йә карабдай, йә деге, йе$^{\text{ө}}$зем, эләкләр белән инде. Алардан сун чәй. Ка(й)берләре мантыйын да йасый.

Борын **беленнәр** пешерәләр, **ту коймаклары**. Ту коймакларына тары йармасын тевәләр түгеч *(төйгеч)* белән. Кабартып шунардан ту коймаклары йасыйлар. Бу беленнәрдән калынрак була. Бик тәмне кан′арлатый *(җылы көе).* Аны обизател′ны кан′арлатый мәҗлесләрдә куйалар. Пешереп бетерә дә йылыга куйа. Өстәлгә йылылатый куйалар.

Айытларда бездә обизател′ны **пәрәмәчә**. Ит белән. Ит күзле пәрәмәчә пешү. Айыт көннәр обизател′ны таба исе $^{\text{т}}$чыгару. Һәр үгә каа кермә – ул, кан′ар пәрәмәчә эстәлдә. Дрожжевой камыр, сөткәме анда, кефиргамы эшлисен камырын. Ка$^{\text{т}}$ч′ан инде ул э$^{\text{ө}}$лгерә, пәрәмәчәне йасыйсын, итләрен куйасын. Аннан газ э$^{\text{ө}}$стендә пешерәсен. Ыланнарыма духовкада пешерәм – май эчендә булмасын.

*Неверкино районы Али авылында*
*Биктимерова Гайшә Әюп кызыннан (1950 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

**Закуска** – **пәрәмәчәләр** пешерәләр вит. Анын уртасын шолай тишәләр дә, пич каршында төгел, учакта пешерәләр. Табага май салалар да, бер йагын куйа бара. Ул өрелә, аннан икенче йагын әләндерәләр. Чимайда *(ак май)* төгел, гөләндергеч майында пешерәләр. **Белене** нәзегерәк, **коймак** калынрак. Кывас белән кабарга чыгара коймак. Әпәй алныда. Аны йыштыралар да инде **кывас** ку$^{\text{о}}$йалар, кас′ы катык ойыта. Аннан йыштыра да итне чыгара. Аннан салма, аннан шол бутка. Дөгенеке, карабдайныкымы или тү йармысыныкымы. Өч төрле була иде.

**Кывас.** Куры *(ипи ачыткысы)* бездә ателә. Квснын нийесе, ачытырга ул. Суны кан′ата. Аннан кызарткысына әпәйләр, арыш ононмы бутый да кыздыра. Узган пичтәме. Аны кан′ата йанынан, сөзә ачытып. Ул кывас була.

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Әхмәрова Сания Якуп кызыннан (1940 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Кызыл **йомырка** атәбез. Йыл да була. Күбәр-күбәр *(күп итеп)* йомырка пешерәсен дә, оланнарга бирәсен. Раштуада борын **чигелдәк** пешерәләр иде.

**Кыwас.** Әпәй пешергәндә калдырасын әмән закваскасын кара әпәйнен. Арыш оныннан. Аны йанадан ачытасын, ул әмән күтәреләә, калка өскә. Кан′аган, суwынган су саласын, сухофрукты саласын. Әпәй кыздырасын – бик йакшы теᵒс бирә. Сеᵒзеп аласын аны. Сеᵒзеп алгач, салалар кур′агасын, черносливын, сухофруктасын. Салган кыйарын да сала. По сезону инде. Арбуз вакыты булса, арбузын да сала. Крошка *(окрошка)* түwел, именне кыwас безнен йантыкларда *(якларда)*. Пен′з′ада кыwас та кан′ар бәлеш. Иттән бәлеш һәр кеᵒн дигәндәй. Мөшкенеке бар′әмнәрдә генә. Мәҗлескә.

*Неверкино районы Исәкәй авылында*
*Бибарсова Равилә Гайнулла кызыннан (1936 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

**Кырахмал кисмәсе.** Урыс җирендә картук кала. Черегәч крахмал була. Апамнар шуны карамыслаларда китерәләр иде. Йывалар, киптерәләр иде. Тирмәндә, ике таш йомры инде, әләндерә идек. Шунардан, табага салып, кисмә йасисын. Аты кисмә иде аныкы, бер зат та түwел. Или беленнәр пешерә идек шуны беләән. Миңа йеде-сигез йәж булганда, нормага эшләүчегә айытка *(гаеткә)* бер стакан он бирәләр иде.

Кавыннын *(кабак)* үᵒрәсен пешерәләр. Картук урынына. Картук йук. Зур пич бар иде, әпәй пешерә торган, казаны бар. Шунда бер казан каwын үᵒрәсе пешерәләр.

**Башак** йыйа идек кырда. Игеннеке койыла иде борын заманнарда. Башакны ывасын, игене чыга. Йывасын, пешерәсен, киптерәсен дә, тирмәннән тартып, хет үрәлек берә шул крахмалга кушарга.

**Киндер** чәчәләр иде. Аны йыштыра иделәр. Көлтәләргә бәлиләр. Көлтәләрне суга салалар. Ул анда йомшара. Анын йепләре чыга. Инеш йанында, күпердәме, кыйныйсын. Тайак, анын очына йеп бәләнгән. Аннан йеп чыга иде. Шул **киндер йебе** була иде.

*Неверкино районы Исәкәй авылында*
*Хәсәнова Маиза Мөхәммәтҗан кызыннан (1940 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

**Сондык** туй белән килә. Никахка килгәндә. Аш сондыгы. Анда ывагач, катлама, кыз күмәчләре. Өстенә тастымалымы, йе$^{ө}$слегеме. Бирнә кебек бирелә. Бал инде ир йагы итә, кыз йагы китерми бал. Никʹахтан соң йәшләр эчкелек туйы.

Канʹанам **тутыртма** йасый иде пичтә. Алашанын туры эчәге кирәк. Аны йывасын. Бик ару йыварга кирәк аны. Вак кына тапыйсын чиснугын да, суганын да, ни бар, бы$^{о}$рычын нисен. Бутыйсын аны йахшы гына да. Эчәк буйына тутырасын. Бик тыгыз тутырмыйсын. Воздух әмән кергән шикелле итеп, шартламасын өчөн ыштоб эчәк. Аннан аны куйасын чуйыннар белән пичкә. Ул пешә анда су эчендә. Аны алып табаларга куйасын волʹный пичкә. Ул анда колбасага әләнә. Тутыртма була ул. Алашаны чалсаң, терлек чалсаң, эчәге булса, тутыртма йасый иделәр. Минем канʹанам бик оста йасый иде тутыртманы. Мин кошлар итеннән дә йасый идем, кошларны чалгач. Эчәген пешерәсен, бәлеш йасыйсын. Кывырдак йасыйсын. Бавырларыннан. Хәзер салʹанка атәләр. Эчәгеннән, суган, картук кушып, бик тәмне генә берәз кыздырыга кирәк аны. Эчәкне, пешкәч, табага салырга кирәк, кыздырыга кирәк аны. Аннан соң бәлеш эченә кушасын картугын, суганын.

Рамазан айында бездә балык ашамыйлар. Канʹатам атә иде ул бугаз кылмаган дип. Башка вакытны балыкны табада кывыра *(куыра)* идек. Балан да йыштырабыз, чиклавыгын да. Йүкә чәчәкләре, матрушкасын, эләк йапрагын, карлыган йапрагын да. Бе$^{ө}$тенесен йыштырып элке дә эчәк идек.

Зывыт башында (рус. свод, *мич башы аралыгы*) **кагыт** та киптерә идек. Алманы пешереп сөзәсен дә иләк аша, шоны тактага йәйәсен. Башта чыгарасын азбарга. Йамгыр тамгалый башлый, кертәсен дә зывыт башына. Йамгырлар китсә, зывыт башында кибә иде. Аннан муда чыкты – табага салабыз да пичкә куйабыз. Алай йеңел. Калынрак та саласың, йамгырдан да куркмыйсын. Мәләштән йасамадым, карлыганнан йасыйлар.

*Неверкино районы Биги авылында*
*Сатаева Равилә Закир кызыннан (1943 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Бездә чәчәләр иде киндераш. Ыва идек тә ашый идек. Майлы бит ул.

Черегән бәрәңгене киптереп, он кушып, пәрәмәчә пешерәбез, кузгылдактан – шурба. Ат кузгылдагы йыйып килә идек йылга буйларыннан. Аны тапый идек тә, йәшелен сыга идек. Аннан шурбага.

**Кыйыкча.** Сигез йомырканы алам, сарысын гына ватам. Ике йомырканы агы белән ук. Басам. Берәз каймак салам бер кашык. Айбагар *(көнбагыш)* майында пешерәм. Нечкә генә йасыйсын.

**Катлама** да шылай. Но анда агын берәз күберәк саласын. Йәймәңне йәйәсен, киңерәк, озынрак кисәсен. Мин катламаны икегә бүләм. Уклауга чорныйм и майга саласын да, айбагар майы эчендә әләндерәсен дә, ул катлама була.

**Чигелдәк** *(бавырсак)* йасыйлар шул ук камырдан. Чөче камырдан. Wак кына кискәли дә май эченә сала да, сөзеп ала. Чигелдәкне Раштуа кенне пешерәбез. Чигелдәк эченә ни булса да тыга: күмер, акча куйа идек. Хазыр мудадан чыкты әйбер салу.

*Неверкино районы Биги авылында*
*Акчурина Сәгадәт Абдулла кызыннан (1941 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Бар′әмнәрдә пәрәмәчә, йе$^{ө}$зәңгеләр өстәлдә булсын. Бер палитр сөт саламын и йомырка саламын. Дрожжа саламын эченә. Камырны басып куйамын каструлга. Ул калка да йөзәңгеләрне йасыйбыз. Айбагар майында пешерәбез. Бар′әмнәргә пешерәбез обизател′ны пәрәмәчә, йе$^{ө}$зәңге, кыйыкча, чәкчәкләр, мөшке бәлешләре.

**Мөшке бәлеше.** Камырын сөткә басабыз. Бер паллитр сөт, дү$^{о}$рт кашык каймак салабыз әмән. Бер чынайак айбагар майы саламын камырына. Берәз сода, бераз то$^{у}$з. Басам да, каплап куйамын табак астына. Мин икешәр бәлешләп йасыйм. Ике бәлешкә ике кила мөшке кирәк, мөшке эченә саламын каймак бер паллитр. Аннан соң бер паллитр сливочный май мөшке эченә. Бер бәлешкә ун йомырка саламын, берәз писук, то$^{у}$з и

бутыймын. Камырымны алам, йәйәм табага. Мөшке эченә рис саламын. Бер стакан бер бәлешкә рис. Бик тәмле бәлеш чыга. Иртәгә оланнарыма йасармын, Алла кушса. Духовкага куйамын. Багамын, кызара бәлешем. Кан'ар бәлешләр кү$^{ө}$п те$^{ө}$рлө. Мөшке бәлеш тә кан'ар бәлеш ателә. Пешерәбез аны, сывына. Мәҗлескә чыгарабыз кан'арлый.

**Рузалар** йомырканын сарысыннан. Биж йомырканын сарысына бер йомырканын агын салам, берәз писук, то$^{у}$з. Камыр басасын, йәйәсен. Кискәләргә гризиж белән – чибәрлерәк була, розачка кебек итеп. Палка белән пешерәбез, палканы тыгабыз май эченә.

**Катлама.** Шылай йәйәләр йәймәне. Уклауга чорнап, майга сала баралар. Ике кеше кирәк анда пешерегә. Берсе әләндерә бара. Уклаwын йебәрә дә, и катламаны бастырып куйалар шылай. Патнуска. Тетәргә. Әнийем атә берәз тетә төшегез катламаны.

Элгәре **каwын (*кабак*) бәлеше**. **Кипкән алма бәлеше** йасый иделәр. Әнийем бер мәшүк киптерә иде. Аны пичкә чуйынга тыга иде. Ул пешә. Берәз пәсүк сала. Кү$^{ө}$п тегел. **Капыста бәлеше** тансыкка әмән.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Мансурова Мәрьям Габдрахман кызыннан (1947 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

**Кыйыкча.** Камырны йәйәсен, кискәлисен. Трехуголкага. Май эченә саласын. Май кан'ап тора, бу пешә. Айбагар майына салып пешерәләр. Айбагар майын халык элгәре ү$^{ө}$зе суктыра иде. Кырдан айбагар джиалар иде. Уборка беткәч, и барып маслабойкаларда суктыралар иде.

**Белен** – ачытасын да пич каршында пешерәсен. Келә (*теләсәң*) карту пәрәмәчәсе пешер. Олан чакта элгәре. Кичен изеп салма (*токмач*). Камырны баса иде. Су каный, сала и катык. Әпәй кывасы этелә ул.

*Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында*
*Мостафина Мәсүдә Кәрим кызыннан (1941 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Кан′ар бәлеш төре. Кузгылдак турыйсын, йымырка белән бутыйсын, өстен йабасын, духовкага куйасын. Ул другой бәлеш булып чыга.

**Куʷас.** Анарга кирәк ржаной мука. Аны кабартасын, кан′атасын суны. Йабып куйасын. Через сутка кыwас. Эченә саласын йымыркасын, йемешләр пешереп салырга да була, из′умын, курагасын и кыйар берәз гына турыйсын. Тозын, писугын саласын. Шуны бутыйсын. Бик йакшы була.

Сугыштан соң кечерткән ашадык, ат кузгылдагын ашый идек. Турыйсын, сөзәсен дә ашыйсын, каймак, сөт салып.

**Черегән картуктан.** Кайыра идек картукны, аны һәйбәт йывасын, суйасын да и аны тукмак белән изәсен. Ит тарткычлар йуктыр (юк) иде. Изәсен, тоз саласын, йомырка сытасын, табада пешерәсен. Онгамы эшли идегез? Он йуг иде, онсыз. Йымырканы бутыйсын да. Ул изрәми, не оттаивает, йакшы. Шуны ашый идек. Черегән картук булса, кинәнә идек.

*Неверкино районы Сарбай авылында*
*Рахманкулова Тәнзилә Шаһи кызыннан (1935 елгы)*
*һәм Ханикеева Әлфия Мөнир кызыннан (1962 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Пол′анка кырларына алмага да бара идек. Элке әмән пәсуклар йуктыр *(юк)* иде. Алманы турый идек тә, койашка каршы или пичтә киптерә идек. Аны кышынга һәйбәт. Пешерә идек тә бәлеш эшли идек. Кагыт йасыйлар иде анардан. Карлыганнан да кагыт йасыйлар идек. Пизел *(кызыл миләш)* дә, балан да бар. Баланны, давленйадан да йакшы ул, бәлешкә сибәм. Элке пизелдән кагыт да йасыйлар иде, әле бырылып та бакмыйлар. Кара пизел *(кара миләш)* бар. Шымыртны оланым белән йыштыра идек тә, пешерә идек тә пируг эшли идек. Бик чөчө була иде әмән. Компот та йасый булганнар, киптерә булганнар. Берчесен *(барысын)* йыштырганнар. Матрушкасын йыштырганнар. Урманнарга бара идек, чамбырны йыштыра идек. Эләкнен йапыракларын йыштыра идек тә, аны киптерә идек тә әлә дә, чәйгә парлап эчәбез. Тәмне була. Әле дә кучан йапракларын йыштырабыз да, билем сызласа, йабыштырам. Дару да кирәкми. Бака йапрагын да киптерәм. Йүкә чәчәге ни

бар заттан йакшы. Йыйып киптерәм. Айу камыр *(гөлҗимеш)* чәчәген дә эчәбез, парлыйсын да. Йыштырасын, киптерәсен. Урманда барсы бар. Йый гына.

*Неверкино районы Мазарлы авылында*
*Кутаева Рафика Абдулла кызыннан (1933 елгы)*
*М. Булатова язып алды*

Сугыштан сон халык лабута *(алабута)* ашады. Лабута күмәче пешердек. Лабутаны суга иделәр, мил′ничага бара-лар, онга әләндерәләр. То картуп, то йапрак, йүкә йапрагы и күмәчләр йабалар. Картук йапрагы, кечеркән йапрагыннан да эшти ашы була.

*Сосновоборск районы Сәләмәс авылында*
*Яхина Банат Йосып кызыннан (1937елгы)*
*М. Булатова язып алды*

# ПЕНЗА ӨЛКӘСЕНЕҢ ГОРОДИЩЕ, ЛОПАТИНО, ШЕМЫШЕЙКА, ИССА, ЛУНИНО РАЙОННАРЫНДА ЯШӘҮЧЕ ТАТАРЛАР СӨЙЛӘШЛӘРЕНЕҢ АВАЗ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Алсу Бәдртдинова*

2021 елда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган комплекслы фәнни экспедиция вакытында Пенза өлкәсендәге татарлар яши торган Городище районының Югары Әлзән (Аембура), Урта Әлзән, Түбән Әлзән; Лопатино районының Селәү, Иске Вершаут, Иске Карлыган, Берлек; Шемышейка районының Оз; Исса районының Югары Салмука, Каменка (Плетневка), Шеркәвич (Кильмаевка); Лунино районының Шыкша (Синорово) авылларында тел, халык иҗаты, сәнгать, борынгы кулъязмалар һ. б. өлкәсендә фәнни тикшеренүләр үткәрелде.

Бу мәкаләдә фәнни экспедиция вакытында җыелган сөйләм үрнәкләренә фонетик анализ нәтиҗәләре бирелә.

Әлеге территорияләрдә татар теленең көнбатыш диалектына караган кузнецк сөйләше таралган. Мәгълүм булганча, бу диалект сөйләшләре үзләренең тел үзенчәлекләре буенча ике зур төркемгә бүленәләр: чылаштыручы һәм цылаштыручы сөйләшләргә. Пенза өлкәсендә, нигездә, чылаштыручы сөйләшләр очрый [Баязитова, 2008, б. 42].

Татар теленең көнбатыш диалекты XIX гасырда ук В.А. Казаринов (1885), Е.А. Малов (1885), Г.Н. Әхмәров (1903), С.Е. Маловлар (1904) тарафыннан өйрәнелә башлый.

Без фәнни эзләнүләр үткәргән авылларда таралган сөйләшләрнең аваз үзенчәлекләре турында мәгълүмат «Татар халык сөйләшләренең электрон атласы»нда, «Татар халык сөйләшләре» (2008) җыентыкларының икенче томында чагылыш таба. Сөйләшнең авазлар системасы Ф.С. Баязитова (2008), Л.Т. Мәхмүтова (1962), Э.Х. Кадировалар (2015) тарафыннан тикшерелгән.

Бу территорияләрнең фонетик изоглассалары «Татар халык сөйләшләренең электрон атласы» һәм «Татар халык сөйләшләре атласы» (2015) басмаларында күрсәтелгән.

Сөйләшнең авазлар системасына анализ белән бу якларга оештырылган экспедицияләрдә катнашкан татар галимнәре Ф.С. Баязитова (2008), Л.Т. Мәхмүтова (1962, 1978), Э.Х. Кадирова (2015) хезмәтләре аша танышырга мөмкин.

Фәнни яктан бу як сөйләшләрен Л.Т. Мәхмүтова 1958–1960 елларда Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһТИ тарафыннан оештырылган экспедицияләр вакытында диалектологик атлас төзү өчен әзерләнгән сораулыклар ярдәмендә һәм монографик планда тикшерә. Ул бу якларга татарларның 300–400 еллар элек Төмән, Сембер губерналарыннан, соңрак Сары Тау якларыннан күченеп килүе турында яза [Махмутова, 2015, с. 204].

«Татар халык сөйләшләре» (2008) җыентыгының икенче томында Ф.С. Баязитованың «Кузнецк сөйләше» мәкаләсе авторның 1985 елгы экспедиция вакытында Пенза өлкәсе татар авылларында җыелган материалларына һәм Л.Т. Мәхмүтова хезмәтләренә таянып язылган.

Сөйләштәге лексик-фонетик диалектизмнар «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә бирелә (төзүчеләре: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова).

Экспедиция барышында сөйләш вәкилләре сөйләмендә чагылыш тапкан фонетик үзенчәлекләр махсус төзелгән сораулыклар ярдәмендә өйрәнелде. Фәнни тикшеренүләр үткәргәндә махсус төзелгән сораулыкларда фразалар, лексемалар русча бирелә, җавап бирүче (сөйләшне кулланучы, информант) аларны татарчага тәрҗемә итә, җаваплар диктофонга языла. Шулай ук авторның шәхси күзәтүләре, тере сөйләмдәге үзенчәлекләр дә теркәп барылды.

Сөйләштә рус теленнән яки рус теле аша башка телләрдән кергән сүзләрне туган телгә яраклаштырып сөйләү күренеше күзәтелә. Без өйрәнгән җирлекләрдә ул түбәндәге сүзләрдә чагылыш таба: *балнис* – рус. больница, *вись* – рус. весь, *пинзә* // *пинза* – рус. пенза, *ысба* // *ызба* – рус. изба, *пуп* – рус. поп, *вәт* // *вот* – рус. вот, *капыста* – рус. капуста, *мор'а* – рус. море, *ләпәләре* – рус. лапа, лапки, *картук* // *карту* – рус. картофель, *ләщә* – рус. лещь һ. б.

Галимнәр фикеренчә, әлеге территорияләрдә әдәби телдәге тирән тел арты [к], [ғ] авазлары таралмаган [Баязитова, 2008, б. 43; Электронный атлас татарских народных говоров], ләкин без бу авазларның да әйтелешен күзәттек. Димәк, сөйләш әдәби тел, күрше сөйләшләр һәм башка телләр тәэсирендә үзгәрешләр дә кичерә. Кайбер мисаллар: тирән тел арты [к] авазы очраган сүзләр – *қая, юқ, йомырқа, бақый, қызыл, ақча, қаз, йолқалар, қоега, қызын, қадый, қалды, қайда, қуеныңда, қырларым, ерақ, қайсы;* тирән тел арты [ғ] авазы очраган сүзләр – *барырға, юк иде (йуғиде), булғаннар, соңға, ғына, сағынып, алғач, барғач, туған, ғомерең.* Шушы ук сүзләр [к], [г] авазлары белән дә әйтелә.

Әлеге авылларда күбрәк әдәби телдә [ж] авазы белән әйтелгән сүзләр урынына [й] белән сөйләү таралган. Мисаллар: *җыела – йыйыла, җибәрәләр – йебәрәләр, җеп – йеп;* [ж] һәм [й] авазларын параллель куллану очраклары да бар: *йыр* // *җыр, йырладылар* // *җырладылар, йеде* // *җиде* һ. б. Л.Т. Мәхмүтова бу яклардагы [ж] авазын аффрикат дип билгеле [Махмутова, 2015, с. 208]. Авазның [$^{д}$ж] варианты да очрый: *җимеш –$^{д}$җимеш, җыештыру – $^{д}$җыештыру* (Шымешейка районы Оз авылында *искә төшерү* мәгънәсендә кулланыла).

Татар әдәби теленнән аермалы буларак, сөйләштә [ч] авазы урынына күпчелек вакытта [$^{т}$ч] аффрикаты кулланыла: *ө$^{т}$чен$^{т}$че – өченче, үлгән$^{т}$че – үлгәнче, ке$^{т}$чкенә – кечкенә, ауга$^{т}$ч – аугач, кө$^{т}$чсез – көчсез, аерган$^{т}$чы – аерганчы, $^{т}$чабышып – чабышып, о$^{т}$чырдым – очырдым* һ. б. Шулай ук сөйләштә [тч], [ч] вариантлары да бар дип яза галимнәр [Баязитова, 2008, б. 45].

Кайбер сүзләрдә палатальләшкән [д'] һәм [т'] авазлары әйтелә: *инд'е, айырд'ылар, саламд'ыр, am'ылды.* Л.Т. Мәхмүтова да тартыклар кайвакыт үзгәреш кичерәләр, палатальләшәләр дип яза: *Хәсән – Хас'ан, кадер – кад'ыр, йад'ым – ядем, кардәш – хар'д'аш* [Махмутова, 1962, с. 130]. Автор фикеренчә, әлеге үзгәрешләр сузыклар тәэсирендә барлыкка килгән, арткы рәт сузыклары алгы рәт сузыклары белән чиратлашып, тартыклар нечкәрәк әйтелә [шунда ук, б. 130].

Кайбер сирәк очрый торган үзенчәлекләр: 1) [з] авазын саңгыраулатып, [с] авазына якын китереп әйтү: *көз – көс, яз – яс, баз – бас;* [т] авазын [ч] авазы белән алмаштыру очрагы: *чишмә – тишмә;* [х] авазын [к] авазы белән чиратлаштырып әйтү очраклары: *яхшы – йакши, хатыны – катны, хаста – каста* (Ф. С. Баязитова мисалларында: *махтау – мактау, хаза – каза, мәхтеп – мәктәп* һ. б. [Баязитова, 2008, б. 44]); [п] һәм [ф] авазларының чиратлашуы: *йапрақ – яфрак.*

[у] һәм [а] авазлары бер-бер артлы килгәндә, аларның арасына [в] авазы өстәлә: *йуварга – юарга (йуарга), тувар – туар, тавык – тавык (тауык), быва – буа, сувык – суык, сөвәк – сөяк (сөйәк), йүвеш – юеш (йүеш).* Л.Т. Мәхмүтова *уа,-үә* дифтонгларының *ywа, үwә,* ешрак *ыва, евә кебек әйтелүен* билгели*: куак – куwак // кывак, куала – куwала // кывала* һ. б. [Махмутова, 1962, с. 155].

Сүзләрдә еш кына [а], [ә], [ө], [ү] авазларыннан соң килгән [й] тартыгы төшеп кала: *катчан – кайчан, әдә – әйдә, әләндерәсең – әйләндерәсең, әтәлмим – әйтә алмыйм, әтелә – әйтелә, әләнә – әйләнә, әтәбез – әйтәбез, әберләр – әйберләр, сүли – сөйли, сүләми – сөйләми, ү – өй, үдә – өйдә, үләнергә – өйләнергә, кимә – көймә.*

Җанлы сөйләмне күзәтү вакытында [и] һәм [е] авазларын чиратлаштыру күренеше дә теркәлде: *мескин – мескен, кише – кеше, йеде – җиде.*

Без йөргән авылларда күбрәк иренләшмәгән [а] авазы кулланыла. Шул ук вакытта кайбер сүзләрдә ул көчле олаштыруга дучар була: *а°тасы, мулла°, ча°кта, а°ны.* Бу яктан кузнецк сөйләше урта диалект белән уртаклык күрсәтә [Бәдртдинова, 2017, б. 31].

Көчле олаштыру [у] авазын әйткәндә дә сизелә. Аерым очракларда ул [о] авазы белән алыштырыла*: шондый – шундый, шолай – шулай.* Әлеге күренешкә мисаллар башка галимнәрнең хезмәтләрендә дә китерелә: *урлау – орлау, курчак – корчак, ул – ол, усак – осак* [Баязитова, 2008, б. 42].

Сөйләш өчен шулай ук [ү] авазын да [ө] авазына охшатып әйтү хас: *үөстер – үстер, күөп – күп.* Шуның белән бергә [ү] авазын [у] авазына охшатып, калынайтып сөйләү очраклары да билгеләнде: *куп – күп, бурәнә – бүрәнә, кук – күк.*

Сөйләштәге әлеге күренешләрне, күбрәк материал җыеп, махсус эксперименталь методлар белән тикшерү сорала, чөнки авазларны иренләштереп әйтү – урта диалектка һәм Урта Идел Буе халыкларына да (удмурт, чуваш, мари телләренең кайбер сөйләшләренә) хас күренеш.

Диалектизмнарда да шактый аваз үзенчәлекләре күренә, мәсәлән, ассимиляция һәм диссимиляция очраклары: *әҗдуган* әдәби телдәге *аждаһа* сүзенең диалекталь формасы; *йанғыш – ялгыш; искиләр – иснеләр; шурба – шулпа; төннә – төнлә, йангыр – яңгыр.*

Авылларда калын кушымчаларны нечкәртеп әйтү күренеше дә киң таралган, ягъни арткы рәт (калын) сузыкларыннан торган сүзләргә алгы рәт (нечкә) сузыклы кушымчалар ялгап сөйләү очрый: *кодагий – кодагый, булгалий – булгалый, урнең – урының, булсен – булсын, башымне – башымны, авылымне – авылымны, бормале – бормалы, юле – юлы, азаге – азагы, алыгез – алыгыз, ярларне – ярларны, туйганче – туйганчы.*

Ирен гармониясе саклану очраклары да бар: *кар төштө, төкөр, бөтөн, өшөдөм, коро, төтөлде* (бетте мәгънәсендә), *йорто.*

Тере сөйләмдә теркәлгән үзенчәлекләрнең берсе: *Вот ызбага кергезәм үзегезне* репликасында сөйләшкә хас фигыль кушымчасы да, фонетик диалектизм да күренә. *Ә аннан бетә инде, курбан чалабыз бетә* җөмләсендә *бетә* сүзе ымлык ролендә, ярдәмче сүз, *и вот* мәгънәсендә кулланыла, дип нәтиҗә ясадык. *Аты йуктыр (исеме юктыр), сукканыбыз юктыр, ул затлар болай бетә бездә бар* дигәндә, фотога төшерү турында сүз бара.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Пенза өлкәсе авылларында таралган сөйләш үзенең фонетик үзенчәлекләре ягыннан татар теленең көнбатыш диалекты белән тыгыз бердәмлек күрсәтә. Шул ук вакытта анда урта диалект өчен хас күренешләр дә урын ала. Моннан тыш, ул билгеле бер дәрәҗәдә әдәби тел йогынтысын да кичерә. Мәсәлән: сөйләшләрдә тирән тел арты [к] һәм [ғ] авазлары очрый, иренләшкән [а°] авазы да теркәлде. Башка үзенчәлекләргә килгәндә, сөйләштә рәт гармониясе бозылу күренеше: арткы рәт сузыклары белән әйтелүче сүзләргә алгы рәт сузыклы кушымчалар ялгану, кайбер очракларда тартыкларны палатальләштерү, [ж] авазы белән әйтелүче сүзләрне күбрәк [й] авазы белән әйтү, [у] һәм [а] авазлары бергә килгәндә аларның арасына [в] авазы өстәү һ. б. үзенчәлекләр билгеләнде.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**


Атлас татарских народных говоров [Электронный ресурс]. URL: https://atlas.antat.ru/. (мөрәҗәгать итү вакыты: 05.03.2024).

Атлас татарских народных говоров / отв. ред.: Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хайрутдинова. Изд. 2-е, доп. и перераб. Казань: ИЯЛИ, 2015. 632 с.

*Ахмаров Г.Н.* О языке и народности мишарей // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Имп. Казан. ун-те. Т. XIX. Вып. 2. Казань, 1903. С. 92–160.

*Баязитова Ф.С.* Кузнецк сөйләше // Татар халык сөйләшләре: ике китапта. II китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ. б. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 42–53.

*Бәдртдинова А.Ә.* Татар теленең кузнецк сөйләше аваз үзенчәлекләре (Пенза өлкәсендә булган 2021 елгы экспедиция нәтиҗәләре) [Электрон ресурс] // VIII Международная научно-практическая конференция «Занкиевские чтения» на тему: «Интеграция науки и практики в современном образовательном пространстве: традиции и инновации», посвященной Году семьи. URL: https://mcito.ru/publishing/teleconf/tpi_5/submitted.html (Мөрәҗәгать итү көне: 14.03.2024).

*Бәдртдинова А.Ә.* Татар теленең урта диалекты вокализм системасына күзәтү // Фәнни Татарстан. 2017. № 4. Б. 28–34.

*Кадирова Э.Х.* Пенза өлкәсе һәм Мордва Республикасы татарларының сөйләм үзенчәлекләре (экспедиция материаллары нигезендә) // Türkoloji Üzermde Araştırmalah (Исследования по тюркологии). Kazan-Afyonkarahisar, 2021. S. 17–29.

*Кадирова Э.Х., Галиуллина Г.Р., Сайфулина Ф.С., Юсупова Ә.Ш.* Мордовия Республикасы һәм Пенза өлкәсе татарлары: диалектология һәм халык авыз иҗаты материаллары. Казан, 2015. 313 б.

*Кадирова Э.Х., Девликамова В.Н.* Пенза өлкәсе Кикин авылы татарларында туй // Сборник статей Международного тюркологического симпозиума, посвященного памяти выдающегося тюрколога доктора филологических наук, профессора, академика РАН Эдгема Рахимовича Тенишева (16–19 октября 1913 года). Казань: ГБУ «Республиканский центр мониторинга качества образования», 2013. С. 216–219.

*Казаринов В.А.* О мишарях в Чистопольском уезде Казанской губернии // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университетете. Т. IV. Казань, 1884. С. 9–10.

*Малов Е.А.* Сведения о мишарях: Этногр. очерк / [Соч.] Прот. Е.А. Малова. Казань: Тип. Казан. ун-та, 1885. 79 с.

*Малов С.Е.* Из поездки к мишарям: (О наречии мишарей Чистопол. уезда) / С.Е. Малов. Казань: Типо-литогр. Казан. Имп. ун-та, 1904. 24 с.

*Махмутова Л.Т.* Основные характерные черты мишарских говоров на территории Пензенской области (по материалам экспедиций 1958–1960 гг.) // Материалы по татарской диалектологии, Вып. 2. Казань, 1962. –С. 125–162.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

Экспедиция в Пензенскую область 2021 [Электрон ресурс] // Официальный сайт Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ. URL: Экспедиция в Пензенскую область 2021 (antat.ru) (Мөрәҗәгать итү көне: 09.02.2024).

## Информантлар исемлеге

**Городище районы Югары Әләзән авылыннан:**

Айсина (Мухутьева) Зиәдә Шәхмәрзян кызы (1943 елгы);
Бигишева (Назирова) Гөлсинә Ядкәр кызы (1981 елгы);
Кадиркаева (Копьёва) Равилә Мөкаддәс кызы (1970 елгы);
Клатов Руслан Җәүдәт улы (Югары Әләзәндә туган, анда яшәми; 1973 елгы);
Клатова (Исляева) Халидә Риатулла кызы (1941 елгы);
Назирова Зәкия Хәмзә кызы (1953 елгы);
Пономарева (Назирова) Наҗия Искәндәр кызы (1965 елгы);
Слашкина (Ханбекова) Дамира Моталлап кызы (1963 елгы);
Ханбекова Гөлсинә Ядкәр кызы (1986 елгы).

**Городище районы Урта Әләзән авылыннан:**

Бибарсов Адельша Ибраһим улы;
Бибарсов Әхмәтша Абдулхак улы (1936 елгы);
Бибарсов Шокери Литфулла улы (1935 елгы);
Бибарсова (Аблянскина) Сания Таһир кызы;
Бибарсова (Кирасирова) Румия Хәмзә кызы (1937 елгы);
Бибарсова Хәбирә Мортаза кызы (1918 елгы);
Бикмаев Мияссәр Сөләйман улы (1938 елгы);

Бикмаева (Бәхтиярова) Равза Мөхәммәтҗан кызы (1940 елгы);
Бикмаева (Исянова) Фирүзә Мияссар кызы (1966 елгы);
Бикмаева Рәйсә Имам кызы (1949 елгы);
Бикмаева Хава Рәшид кызы (1977 елгы);
Бухменов Гали Габбас улы (1975 елгы);
Дмбердеев Исмаил Муса улы (1942 елгы);
Клинкова Асия Равил кызы (татар теле укытучысы);
Кожевникова Рәмзия Җәффәр кызы (1952 елгы);
Кормашев Тәминдяр Бәкәр улы (1935 елгы);
Кормашева Фатыйма Каюм кызы (1939 елгы);
Кормашев Хәйдәр Тәминдар улы;
Куряев Габбас Ибраһим улы (1940 елгы);
Куряева-Таһирова Кәримә Искәндәр кызы;
Нәкыя Хафиз кызы;
Сукорева (Кожевникова) Сәра Җәффәр кызы (1957 елгы);
Сукорева Нурия Мазаффар кызы (1985 елгы);
Тугушев Искәндәр Фәттах улы (1937 елгы);
Тугушева (Дашкина) Сания Хәмзә кызы (1941 елгы);
Янгуразов Фатих Хәнәф улы (1943 елгы).

**Городище районы Түбән Әләзән авылыннан:**
Бармаков Ибраһим Кәлимулла улы (тарих укытучысы) (1918–2004);
Бикмаева Румия Әсәдулла кызы (1956 елгы);
Бикмаева Хава Шәмдулла кызы (1937 елгы);
Бичурина Рәмзия Җиһанша улы (1947 елгы);
Давыдова (Бәхтиева) Октябрина Шиһап кызы (1932 елгы);
Долошина Маһинур Кәлимулла кызы (1929 елгы);
Җаббарова Фәүзия Мидхәт кызы (1956 елгы);
Морозова Рәйсә Сөләйман кызы (1942 елгы);
Пятаева Сания Асидулла кызы (1959 елгы);
Севастополева Нажия Касыйм кызы (1943 елгы);
Шарипова (Бәширова) Сафия Шакир кызы (1951 елгы);
Юняев Мозаффар Каюм улы (1929 елгы).

**Лопатино районы Иске Вершаут авылыннан:**
Алиева Дания Рәис кызы (1979 елгы).

**Лопатино районы Иске Карлыган авылыннан:**
Мусякаева Мөнәвәрә Хәсән кызы (1946 елгы);
Мусякаева Рәйсә Зөфәр кызы;
Саләмова (Дусаева) Зәйтүнә Әлләм кызы (1949 елгы);
Саләмов Зөфәр Ибраһим улы (1944 елгы).

**Лопатино районы Берлек авылыннан:**
Мортазин Сәмәт Гаяз улы (1968 елгы).

**Шемышейка районы Оз авылыннан:**
Апкаева Румия Җафар кызы (1948 елгы);

Кәримов Рафик Хөсәен улы (1950 елгы);
Нугаева Рәшидә Йосып кызы(1943 елгы);
Якупова Алия Мөхәммәтҗан кызы (1954 елгы).

**Исса районы Югары Салмука авылыннан:**
Хәлмәева Саҗидә Хәмзә кызы (1934 елгы).

**Каменка (Плетневка) авылыннан:**
Абдрашитова Алия Аит кызы (1941 елгы);
Алмаметов Айса Абдр-ч
Бикбаева Сания Абдулла кызы (1956 елгы);
Бикмаева Рауза Исмәгыйль кызы (1950 елгы);
Исмәгыйлов Хөсәен Мөхәммәтҗан улы (мич ясаучы, тимерче);
Исмәгыйлова Халидә Исмәгыйль кызы (1946 елгы);
Курмаев Хафиз Үрмәр улы;
Мәүлүтов Исмәгыйль Ризван улы;
Мусякаева Сания Хәмзә кызы (1940 елгы);
Йосыпов Фәрит Ибраһим улы (1921 елгы);
Йосыпова Халидә Ибраһим кызы (1954 елгы).

**Лунино районының Шыкша (Синорово) авылыннан:**
Абдуллова Карина Ринат кызы (2007 елгы);
Бараева Зөлфия Равил кызы (1966 елгы);
Ерзина Рәшидә Ибраһим кызы (1952 елгы);
Калашникова Фәридә (Фаридя) Руфаил кызы (1969 елгы);
Санкина Сания Фәттах кызы (1949 елгы);
Умярова Сания Шиһап кызы (1938 елгы).

# ПЕНЗА ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ ФОЛЬКЛОРЫ
## (Халык иҗаты үрнәкләре)

*Ильмир Ямалтдинов*

Пенза өлкәсе территориясе татарларның традицион яшәү урыны булып тора. Безнең ата-бабаларыбыз элек-электән Идел Болгары һәм Алтын Урда составына кергән Сура елгасы үзәнендә урнашкан Урта Идел Буе төбәгендә яшәгән. Рус дәүләте составына кертелгәннән соң, XVII гасырда чик сызыкларын төзү сәбәпле, Пенза өлкәсе территориясенә Алатырь, Арзамас, Темников шәһәрләреннән йомышлы татарлар актив рәвештә күченә башлаган. Төбәк тарихында татар кенәзләре һәм морзалары Акчуриннар, Алышевлар, Бигловлар, Дашкиннар, Енгалычевлар, Еникеевлар, Кугушевлар, Кушаевлар, Макуловлар, Маматовлар, Моратовлар, Сакаевлар, Тенишевлар, Терегуловлар, Утяшевлар, Чанышевлар һ. б. вәкилләре тирән эз калдырганнар[1].

Пенза төбәгендә яшәгән милләттәшләребезнең фольклоры, авыз иҗаты белән кызыксыну чама белән ике йөз еллар элек башланган, дисәк, һич тә ялгыш булмас.

Россия Фәннәр академиясе ачылганнан соң (1725), аның эшчәнлегенең аерылгысыз бер юнәлеше буларак, күпмилләтле илдә яшәүче халыкларның тарихын, этнографиясен өйрәнү максатыннан экспедицияләр оештырыла башлый. XIX гасырның беренче яртысында Казан университеты галимнәренең

---

[1] Пензенская область // Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации: справочник / АН РТ, Институт татарской энциклопедии и регионоведения. Казань, 2016. С. 111.

хезмәтләрендә дә татар халкының тарихына, рухи мирасына һәм фольклорына караган кыр тикшеренүләре нәтиҗәләре яисә башка чыганаклардан алынган материаллар бар[1]. Аннан соң да Пенза өлкәсе җирлегендә яшәүче милләттәшләребезнең халык иҗатын өйрәнү эше татар галимнәре һәм әдипләре тарафыннан дәвам иттерелә.

Пенза татарларының сөйләшләрен өйрәнү өчен, телче-диалектологлар да әлеге төбәккә берничә тапкыр экспедициягә чыгалар. Бу өлкәдә төрле елларда галимнәр Л. Мәхмүтова, Ф. Баязитова күп эш башкаралар, тел материалы буларак, халык иҗаты үрнәкләрен дә туплыйлар.

Пенза төбәгенең татарлар яшәгән районнарына Институтның иң беренче фольклор экспедициясе 1958 елның август аенда танылган фольклорчы галим, филология фәннәре докторы Хәмит Ярми җитәкчелегендә оештырыла. Экспедиция эшендә алты фольклорчы катнаша. Алар өч төркемгә бүленеп эшлиләр. Беренче төркем (Х. Ярми (җитәкче) һәм Х. Гатина) Сосновоборск районы Индерка, Кузнецк районы Ялгаш, Дәхтәрни, Татар Кынадысы, Неверкино районы Мазарлы (Октябрьское), Дөмавыл һәм Колчура авылларын өйрәнәләр. Икенче төркем (Э. Касыймов (отряд җитәкчесе) һәм Ә. Рәшитов) Лопатино районы Карлыган, Берлек, Иске Вершаут, Селәү, Шемышейка районы Оз (Усть-Уза), Городище районы Урта Әләзән, Югары Әләзән (Аембура) һәм Иске Әләзән авылларында эшлиләр. Өченче төркем (И. Надиров (отряд җитәкчесе) һәм Р. Кәримов) Белинский районы Качкару (Кутеевка), Каменка районы Мачали, Кикин (Кикын), Кобылкин, Беднодемьяновск (хәзерге Спасск) районы Шалдавыч авылларында тикшеренүләр уздыра. Барлыгы 9 райондагы 20 татар авылында булалар. Нәтиҗәдә, 58 әкият, 35 бәет, 3042 җыр (кыска, сюжетлы, йола һәм уен җырлары), 15 авыл тарихы, 11 мәкаль-әйтем һәм табышмак үрнәкләре язып алып кайталар. Алар Институт архивында

---

[1] *Ямалтдинов И.И.* Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века. Собирание, публикация и научное изучение фольклора / И.И. Ямалтдинов. Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 35–36.

саклана[1]. Әлеге материалларның бер өлеше Институт әзерләгән унике томлык «Татар халык иҗаты» җыелмасында (1976–1988) басылган яисә җыентыкларның искәрмәләрендә вариант буларак күрсәтелгән.

2007 елның июнендә Пенза төбәгенең татарлар яшәгән авылларына Институтның икенче фольклор экспедициясе оештырыла. Экспедициядә дүрт фольклорчы катнаша. Барлыгы 2 районның 4 татар авылында булалар. Фольклорчылар И. Закирова, А. Садыйкова, А. Фәхретдинова, Р. Сафиуллина Городище районы Урта Әләзән, Югары Әләзән һәм Кузнецк районы Татар Кынадысы, Пәлдәнге авылларында тикшеренүләр уздыралар. Алар йола фольклоры, бәетләр, мөнәҗәтләр, табышмаклар, халык уеннары, мәкаль-әйтемнәр, мифологик хикәятләр, сөйләкләр кебек халык иҗаты жанрларына караган һ. б. үрнәкләр язып алып кайталар.

Һәм, ниһаять 2019, 2021, 2022 елларда әлеге төбәккә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының берничә өлкәгә кагылышлы тикшеренүләрне максат итеп куйган комплекслы фәнни экспедициясе оештырылды.

Пенза өлкәсендә татарлар яшәгән 13 районның 40 тан артык авылында *(Неверкино районының Али, Кырнавар, Мансур, Биги, Бикбулат (Бикмосеевка), Сарбай, Исәкәй, Җәлил, Мазарлы, Дөмавыл, Кунчерово; Кузнецк районының Бистән, Пәлдәнге, Татар Кынадысы, Ялгаш, Дәхтәрни; Сосновоборск районының Индерка, Әлмәш, Сәләмәс; Городище районының Югары Әләзән (Аембура), Урта Әләзән, Түбән Әләзән; Лопатино районының Селәү, Иске Вершаут, Иске Карлыган, Берлек; Шемышейка районының Оз авылы; Исса районының Югары Салмука, Каменка (Плетневка), Шеркәвич (Кильмаевка); Лунино районының Шыкша (Синорово); Каменка районының Кикин (Кикын), Тәләтен, Мачали, Кобылкин, Кочалейка (Ятмис); Белинский районының Кутеевка (Качкару); Пачелма районының Решетин, Татар Никольское; Вадинск районының Татар*

[1] Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Колл. 64, п. 1, сакл. бер. 2.

*Шуриновкасы (Шуринка), Мучали, Татар Лакасы, Вадинск, Чудовка (Чудилка); Спасск районының Шалдавыч, Белоозерка авыллары)* булып, шәхсән минем тарафтан 1000 берәмлектән артык халык авыз иҗаты үрнәкләре һәм татар халкының традицион мәдәниятенә караган материаллар язып алып кайтылды.

Пенза өлкәсендә яшәүче татарлар арасында, сан ягыннан караганда, иң киң таралган авыз иҗаты жанрларыннан җырларны һәм мөнәҗәтләрне аерып чыгарырга була. Беренчесенә килгәндә, берничә йөз *җыр* язып алынды. Аларның күбесе – кыска җырлар һәм такмаклар. Мәсәлән, Неверкино районы Кырнавар авылында Мусина Алия Габдрахман кызы (1943 елгы Кырнавар авылында Абдульмянова Фәридә Каюм кызы (1949 елгы), Неверкино районы Мансур авылында Салюкова Хәлифә Илач кызы (1926 елгы), Емлиханова Мөнирә Абдул кызы (1947 елгы), Неверкино районы Биги авылында Сатаева Равиля Исхак кызы (1948), Неверкино районы Бикбулат (Бикмосеевка) авылында Фәхретдинова Маһруй Үмәр кызы (1934 елгы), Неверкино районы Исәкәй авылында Бахтиева Румия Ибраһим кызы (1962 елгы), Неверкино районы Мазарлы авылында Комякова Миясса Әмин кызы (1939 елгы), Гульмиярова Мәрьям Җиһанша кызы (1959 елгы), Кузнецк районы Бистән авылында Хайрова Фатыйма Исмаил кызы (1952 елгы), Кузнецк районы Дәхтәрни авылында Мусякаева Рәисә Шакир кызы (1945 елгы), Сосновоборск районы Индерка авылында Бакаева Сания Али кызы (1949 елгы), Вагапова Гүзәл Равил кызы (1968 елгы), Сосновоборск районы Бистән авылында Шабакаев Ринат Мәхмүд улы (1962 елгы), Лопатино районы Селәү авылында Мусилева Наилә Исхак кызы (1980 елгы), Лопатино районы Иске Вершаут авылында Сейдгазова Алимә Мохтар кызы (1940), Тимербулатова Нәркәс Җәфәр кызы (1967 елгы), Давыдова Фирдәүс Ришат кызы (1964 елгы), Шемышейка районы Оз авылында Ногаева Рәшидә Йосып кызы (1943), Пачелма районы Решетин авылында Таишева Нәгыймә Яфкуб кызы (1960 елгы), Сендикаева Лия Абдулмәннән кызы (1961 елгы), Таишев Заһидулла Кәлимулла улы (1956 елгы), Агишев Кәрибулла Абдулла улы (1957 елгы), Спасск районы Шалдавыч авылында Курамшина Рәисә Нәҗип кызы (1938 елгы), Девли-

камова Адиля Әхмәт кызы (1959 елгы) безгә берничә дистә халык җырларын махсус җырлап күрсәттеләр. Аларның әйтүенә караганда, мондый җырлар халыкта бик күп.

Пенза төбәге татарларында озын көйләр дә саклана. «Наласа авылы көе», «Су буйлап», «Герман көе», «Шомыртым», «Сарман буйларында», «Рәйхан», «Олы юлның тузаны» һ. б. җырларны һәр авылда диярлек башкарып күрсәттеләр.

Пенза өлкәсендә «Көймә» җыры да бик популяр. Әлеге җырлы-биюле уен җыры берничә вариантта язып алынды[1]. Түгәрәк уен җыры «Ай-ли, гөлкәем» дә киң таралган.

«Беренче мәхәббәт», «Ак чәчәкләр», «Сусау», «Әниемә» кебек автор җырлары да халык тарафыннан бик яратып башкарыла. Алар арасында халыклашкан җырлар да бар. Мәсәлән, Неверкино районы Җәлил авылында Исянова Мәфруза Хәлилулла кызыннан (1940 елгы) «Туган авылыма» (Сара Садыйкова көе, Мостафа Ногман сүзләре) һәм «Әниемә хат» (Әкрәм Даутов көе һәм сүзләре) җырларыннан өзек яздырып алынды. «Туган авылыма» җырының кайбер сүзләре үзгәртелгән, беренче һәм икенче куплетларның урыннары алыштырып башкарылды.

Тарихи җырларга килгәндә, Кузнецк районы Бистән авылында Айзатуллина Һава Исхак кызыннан (1937 елгы), Сосноворск районы Индерка авылында Бакаева Сания Али кызыннан (1949 елгы), Спасск районы Шалдавыч авылында Курамшина Рәисә Нәҗип кызыннан (1938 елгы) «Әбделмән купич» җырының ике варианты язып алынды.

Пенза өлкәсе татарларында иң киң таралган халык иҗаты жанрларының икенчесе – *мөнәҗәтләр*. Аллаһы Тәгаләгә, пәйгамбәрләргә, ислам диненә, Коръәнгә мәдхияләр, шигъри нәсыйхәтләр, бәйрәм, аерым алганда, мәҗлес мөнәҗәтләре киң таралган. Бу аңлашыла да, чөнки Пенза өлкәсе татарларында дин көчле. Мәсәлән, Неверкино районы Сарбай авылында

[1] Неверкино районы Кырнавар авылында Абдульмянова Фәридә Каюм кызыннан (1949 елгы), Сосновоборск районы Индерка авылында Бакаева Сания Али кызыннан (1949 елгы), Сосновоборск районы Бистән авылында Шабакаев Ринат Мәхмүд улыннан (1962 елгы), Неверкино районы Мансур авылында Салюкова Хәлифә Илач кызыннан (1926 елгы), Емлиханова Мөнирә Абдул кызыннан (1947 елгы) һ. б. язып алынды.

Рахманкулова Тәнзилә Шаһи кызыннан (1935 елгы) «Лә иләһә илләә Аллаһы», «Юлдашым булсын иманым, «Килеп кердем өегезгә», «Рәхмәт мөнәҗәте»; Неверкино районы Кырнавар авылында Мусина Алия Габдрхман кызыннан (1943 елгы) «Мәрхабә мөнәҗәте», «Пыйгамбәрләр кыйссасы», «Йосыф мөнәҗәте»; Неверкино районы Бикбулат (Бикмосеевка) авылында Асейдуллина Сания Вахит кызыннан (1939 елгы) «Юсеф аләйһиссәләм мөнәҗәте», «Бәхетле кыл Тәгал Алла» һ. б. мөнәҗәтләрне теркәдек. Иң киң таралган мөнәҗәтләрдән «Әлвидаг», «Рамазан ае мөнәҗәте», «Мәрхабә», «Рәсүлулла», «Йосыф мөнәҗәте», «Газиз ана», «Раббым Алла, диде Муса» мөнәҗәтләрен күрсәтергә була.

Кулаткы районы Зимичә авылына ишан бабайга, соңрак каберенә йөрү гадәте булган. Безнең тарафтан ишан бабайга багышланган «Хәзрәт мөнәҗәте» теркәлде.

Ияләр, җеннәр турындагы *мифологик сөйләкләр, хикәятләр һәм әкиятләр* халыкта борынгыдан сөйләнеп килгән, кешеләр аларга ышанган, буыннан буынга тапшыра килгән. Бигрәк тә, татар халкында киң таралганнары – атның ялын үрә торган абзар иясе (йорт анасы), төрле кыяфәткә (песи, эт, бабай, матур кыз һ. б.) керә ала торган, яисә бала елаган тавышка ияртеп адаштыручы җен-пәри-шайтан-мәлгунь, атны тугарып, дугасын (сбруен) кире якка җиккән очракта гына, яисә аяк киемен алыштырып киеп кенә котылып була торган адаштыручы җенле урыннар, яратмаганга күрә күзенә күренүче яисә табак-савыт шалтыратучы, яисә сыер бозаулаганда тәрәзә шакып уятучы өй иясе (йорт анасы), морҗадан чыгучы-төшүче аздякы, берәрсе үлгәннән соң шул кеше булып ияләшүче җен, адашкан кешегә юл күрсәтүче Хозыр Ильяс, чәчен тарап утыручы су анасыннан башлап, Пенза төбәгендә генә була торган, аерым алганда, Дыбруда йокы бирмәүче, төнлә урманга чакыручы шайтаннар, яки адаштыра торган Мәҗәй, яисә Каенсардагы җен урынысы[1], ялгыз мунчага кергән бер әбине мичкә тарткан җен[2], җәннәт юлын күрсәтүче Кораеш еланга укыла торган

[1] Неверкино районы Али авылында (Алявылда) Кузяхметов Усман Аглиулла улыннан (1963 елгы) язып алынды.

[2] Неверкино районы Али авылында (Алявылда) Аитов Зәкәрия Хасян улыннан (1966 елгы) язып алынды.

дога[1], инеш буенда юыныргa чакыручы җен, яисә Казлукада яшәүче колдун[2], яисә Чирүдәге колдун әби[3], грань яисә казарма шайтаннары[4], Бикмосеевка күпере шайтаннары[5], җен эзенә басып, өенә кайталмыйча йөргән апа[6], берсе үлсә, тумаган балаларны алучы, яисә сөннәткә утыртучы гайбирәннәр[7], пир хатынын тудыртучы кендек әби[8], баласын буып үтерә язган мич башындагы йонлы зат[9], төнлә кагыла торган шайтан җиле яисә өйгә кереп кинәт юк булучы Хозыр Ильяс[10], кендек әбигә кунарга кереп ул тудырткан балаларның язмышын күрсәтүче, яисә Мәчтүрәнең хасталанган улын дәвалаучы Хозыр Ильяс[11], ире-хатыны начармы-әйбәтме булачагын әйтеп бирүче Хозыр Ильяс[12], ияләргә укыла торган йорт-җир догасы[13] һ. б. турындагы мифологик сөйләкләр, хикәятләр һәм әкиятләр бар.

**Тарихи һәм топонимик риваятьләр** язып алынды, авыл тарихларына (Али авылы, Сарбай, Биги, Бикбулат, Али, Чыршым,

---

[1] Неверкино районы Али авылында (Алявылда) Шабурова Хәнифә Мөхәммәтҗан кызыннан (1926 елгы) язып алынды.

[2] Неверкино районы Мансур авылында Рәхимов Равиль Җиһанша улыннан (1963 елгы) язып алынды.

[3] Неверкино районы Мансур (элек Чербулат) авылында Емлиханова Мөнирә Абдул кызыннан (1947 елгы) язып алынды.

[4] Неверкино районы Биги авылында Юнусова Фәридә Абдулла кызыннан (1940 елгы) язып алынды.

[5] Неверкино районы Исәкәй авылында Бахтиева Румия Ибраһим кызыннан (1962 елгы) язып алынды.

[6] Неверкино районы Исәкәй авылында Хасянова Майзә Мөхәммәдҗан кызыннан (1940 елгы) язып алынды.

[7] Неверкино районы Мазарлы авылында Комякова Миясса Әмин кызыннан (1939 елгы) язып алынды.

[8] Кузнецк районы Бистән авылында Хайрова Фатыйма Исмаил кызыннан (1952 елгы) язып алынды.

[9] Кузнецк районы Ялгаш авылында Алькаева Сабира Сәет кызыннан (1946 елгы) язып алынды.

[10] Кузнецк районы Ялгаш авылында Хальметова Гөлия Таһир кызыннан (1934 елгы) язып алынды.

[11] Кузнецк районы Ялгаш авылында Усманова Әминә Хәнәфи кызыннан (1950 елгы) язып алынды.

[12] Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында Курмаева Хатимә Хусяин кызыннан (1930 елгы), Мендаева Халидә Хусяин кызыннан (1939 елгы) язып алынды.

[13] Кузнецк районы Дәхтәрни авылында Мусякаева Рәисә Шакир кызыннан (1945 елгы) язып алынды.

Янган авыл, Җәлил, Мазарлы, Пәлдәнге, Татар Кынадысы, Әлмәш һ. б.) бәйлеләре – шул авылларда яшәүче милләттәшләребезнең үз тарихларына битараф булмавына ачык мисал.

Неверкино районы Мазарлы авылында Кагарев Аббяс Хасян улыннан (1941 елгы) Рамай җырының барлыкка килү тарихы турында риваять язып алынды.

Татар халкында «Әүлия зираты» дип аталган яисә «изге урын» белән бәйле риваятьләр киң таралган. Алар Пенза өлкәсе татарларында да бар. Мәсәлән, Каенсарга барганда Әүлия зирәтләре[1], Әминә әүлия зәрәте[2], Ишан бабакай зәрәтләре[3], Изгеләр өсте[4], Әлмәш бабай өсте[5] һ. б. очрый.

Пенза төбәгендә татар халкына хас *уеннарның* тасвирламалары сакланган. «Түгәрәк»[6] уеннан башлап, аулак өйләрдә, кичке уеннарда[7], соңрак мәдәният йортларында традицион уйналып килгән «Көймәдән», «Йөзектән» («Йөзек салыш», «Фантюк»), «Прәшкәдән», «Шишадан», «Күпердән»[8] һ. б. белән беррәттән, яз башында чәчүгә чыкканчы «Безелек» уйнау да булган, ә балалар «Дәңгездән» («Акули», «Черта»), «Чижик», «Клюк», «Гузна» «Ашык», «Чука» «Әлчи» «Мәрә», «Мәчтән», «Шага» һ. б. уеннарны аеруча яратып уйнаган.

*Әкиятләргә* килгәндә, Пенза өлкәсе Кузнецк районы Бистән авылында Айзатуллина Һава Исхак кызыннан (1937 елгы) «Кулсыз кыз» әкиятенең бер варианты язып алынды. Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында Курмаева Хатимә Хусяин

---

[1] Неверкино районы Али авылында (Алявылда) Аитов Хасян Исхак улыннан (1939 елгы), Кузяхметов Усман Аглиулла улыннан (1963 елгы), Аитов Зәкәрия Хасян улыннан (1966 елгы) язып алынды.

[2] Неверкино районы Кырнавар авылында Мусина Алия Габдрахман кызыннан (1943 елгы) язып алынды.

[3] Неверкино районы Мазарлы авылында Гульмиярова Мәрьям Җиһанша кызыннан (1959 елгы) язып алынды.

[4] Кузнецк районы Пәлдәнге авылында Енгалычева Венера Исмәгыйль кызыннан (1938 елгы) язып алынды.

[5] Сосновоборск районы Әлмәш авылында Сидорова Разия Калим кызыннан (1961 елгы) язып алынды.

[6] Пенза өлкәсе татарлары түгәрәк уеннарны «Круг уены», «Круглы» дип тә сөйлиләр.

[7] Пенза өлкәсе татарлары кичке уеннарны «Вечер» дип тә сөйлиләр.

[8] Пенза өлкәсе татарлары «Мустан» дип атый.

кызыннан (1930 елгы), Мендаева Халидә Хусяин кызыннан (1939 елгы) алдавыч әкият теркәдек.

Сирәк булса да *бәетләр* дә очрады. Татар халкында киң таралган «Сак-Сок» һәм «Суга баткан Гайшә» бәетләре язып алынды. Неверкино районы Кырнавар авылында Абдульмянова Фәридә Каюм кызыннан (1949 елгы) язып алынган «Рафыйк бәете», Кузнецк районы Бистән авылында Айзатуллина Һава Исхак кызыннан (1937 елгы) язып алынган «Усман бәете», «Давыдов Якуп бәете» бу төбәктә бәет чыгару традициясенең дәвам итүен күрсәтә. Лопатино районы Иске Карлыган авылы мәктәп музее бүлмәсендәге кульязма дәфтәрдә (дәфтәрне тапшыручы – Мәһдиева Рәисә Исхак кызы (1939–2013), 64 биттә дәфтәрнең (анда альбом диелгән. – *Авт. иск.*) Никяр апаныкы икәнлеге ачыклана) – кызлар дәфтәрендә истәлеккә бәетләр, җырлар язылган. Анда «Алданган кыз», «Яшь ямщик», «Фатыйма» бәетләре теркәлгән.

*Балалар фольклорының* «Багу поэзиясе» әсәрләреннән берничә бишек җыры, әйтеш, мавыктыргыч, сөйләм такмагы, шулай ук «Күңел ачу» һәм «Уен фольклоры» үрнәкләре язып алынды. Татар халкында традицион рәвештә башкарыла торган «Йокла, балам, йом күзең», «Әлли-бәлли бәү итә», «Аллаһу-Аллаһу», «Куяннар-куяннар», «Гу-гу, күгәрчен» кебек бишек җырлары Пенза төбәгендә киң таралган. Аларның берничә вариантын теркәдек.

*Табышмак* һәм *паремияләр* үрнәкләре дә өлкән буын вәкилләренең хәтерендә генә саклана.

*Дастаннар* кызганыч ки, очрамады.

*Йола фольклорына* килгәндә, йола һәм гореф-гадәтләр турындагы мәгълүматларны җырлары, уеннары, махсус әйтелә торган сүзләре белән бергә бер күренеш буларак язып алырга тырыштык. Мәҗүсилек һәм борынгы чорлардан калган сүз үрнәкләре, ырымнар, келәүләр, имләүләр, йолалар теркәлде.

Пенза өлкәсе татар авылларында гомер итүче милләттәшләребездән язып алынган, халкыбызның буыннан буынга, телдән телгә күчеп килгән кайбер фольклор үрнәкләрен (язылып алыну тәртибендә тематик бүлекчәләргә урнаштырып) тәкъдим итәбез.

# МИФОЛОГИК СӨЙЛӘКЛӘР, ХИКӘЯТЛӘР ҺӘМ ӘКИЯТЛӘР (ияләр, җеннәр турында)

## *Йорт анасы*

Йорт анасы үрә чәчне, кешеләр үрми, сүтәлмисең. Йорт анасы яратмаса, тир эчендә була алаша. Алаша су эчендә була төн эчендә, сүмәсә йорт анасы. Алаша бүген дә бар. Йорт анасы үрә. Яратса – чәчен үрә, әгәр яратмаса, сыерны колодага сала – комушкага сала. Ничек саладыр, Алла белсен. Чыгасың – алаша су эчендә.

## *Йорт анасын күчерү*

Элке әйтә иделәр картлар. Әтиләре китәдер, болар үзе генә китмиләр. Без должен алашада килеп керергә бире, карт йорттан. Ул элгәреге картлардан калган шулай.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Аитов Хасян Исхак улыннан (1939 елгы),*
*Аитов Зәкәрия Хасян улыннан (1966 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Дыбру шайтаны*

Дыбруда стан бар иде бит. Охранникларга бәләнә иде шайтан. Төнне яңгыз гына охранник. Яткан булса төнне, йокы бирми, уята, шакый, чакыра каядыр, төнне, әйдә урманга диеп. Дыбру урманы – полевой стан, анда бригад тора иде. Анда техника тора иде яз буе. Төнне кала охранник. Аны уята шайтан.

## *Мәҗәй*

Мәҗәй – адаштыра торган урын. Төннә атлар белән киләсең, яңгыз булсаң – адяшасың. Якты булгынчы кеше адяшып йөри.

## *Җен урынысы*

Каенсарда яктыда да адяштыра. Җен урынысы дип әйтәләр.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Кузяхметов Усман Аглиулла улыннан (1963 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Җен тарткан*

Мунчада кемнедер пичкә дә керткән иделәр. Бер әби яңгыз кергән мунчага. Башы белән тыкканнар ахры. Җен тарткан дип әйтәләр.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Аитов Зәкәрия Хасян улыннан (1966 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Җен ала*

Таба да – ала оланнарын, белми олан кая киткән. Элке кая эшләгән – шунда тапкан. Вакыты җитә, табалар, җеннәрне кем дә күрми. Таба, кем дә белми олан кая киткән. Олан югала.

Үз балаларын бирә булганнар сиңа, ә синекен үзләренә ала булганнар. Җеннәр алыштыралар, дип сүлиләрие.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Аитова Нәсимә Идрис кызыннан (1963 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Йорт анасы. Йорт атасы*

Йорт анасы, Йорт атасы бар йортта. Кемдер сүлидер иде. Алашаның ялын тарый, ди, ялларын үрә, ди.

Кораеш атлы еланга
Лә илаһе иллаллаһы
Зөлкаләм.
Кораеш атлы еланга
Мең дә бер сәлам!

Үлгәч, имеш, кабреңә куйгач ук, гөнаһың булса, Кораеш атлы елан керә. Шушыны укысаң, җәннәт юлын күрсәтер, ди.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Шабурова Хәнифә Мөхәммәтҗан кызыннан (1926 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Йорт анасы*

Терлекнең төсе килми, үтерә. Алашаны әйтя иделәр ялы үргән була. Үргәнне сүтәлмисең.

### *Хозур Ильяс*

Хозур Ильяс инде бик сирәк күренә булган. Яшен тизлегендә ул күренә булган. Таяктан ул йөри булган.

Хозур Ильяс юлдаш булсын, Зәңки бабай сакчы булып йөресен.

Хозур Ильяс ак киемнән булган.

### *Мәндәк тавында адаштыра*

Төшәсең авылга Неверкиннан тауны. Мәндәк тавы. Шул төштә әйтя иделәр адяштыра. Бер әби чыгып китә терлеген эзләргә и бик озак ул адяшып йөри. Авылны танымый. Әле инде килә бер үгә имеш, пусти ночевать, ди. Аннан инде монда әйтялар, соң син бит инде, Мәликә әби. Ник син инде урысча сүлисең. Син өз авылыңда, бу без, и үенә илтеп ебәрәләр. Шулай сүлиләр. Адяштыра булган.

### *Аздякы*

Аздякы төшә булган бик чулак кешеләргә. Әле бик аруга төшә ул, әле бик чулакка (пычракка). Пычрак торган кешеләргә. Әле выт мичләр юк. Мичтән төшкән.

### *Мунча җене*

Мунчага яңгыз ярамый керергә, җен була диеп. Кемнедер шулай пич эченә кергезгән имеш.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Мусина Алия Габдрахман кызыннан (1943 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Мунчада җен*

Әбиләр әтә иде мунчага яңгыз кермә, җин анда, җин бар. Кайнанам йөрми иде.

Сәрвәр әби әйтә мунчага кердем, әй, ди, арттан җилкәләремә басты, ди. Укырга тотындым, ди, өч раз әйттем, ди. Артымнан төште, китте, ди. Җен, ди, төшеп китте, ди.

*Неверкино районы Мансур (элек Чербулат) авылында*
*Салюкова Хәлифә Илач кызыннан (1926 елгы),*
*Емлиханова Мөнирә Абдул кызыннан (1947 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Җен юынган*

Биредә инеш ага. Анда төне-көне су качать итә иделәр, элекке вакытта. Тәүфик абзыймы сүләгән иде. Ул суны включать итәргә төнне йөри иде. Керәм, ди, утырган. Анда чаннары бар, евына, әтә, ди, кил евынырга бире чакыра, ди. Укырга тотындым да, ди, и бетте, ди, югалды.

### *Аздякы*

Аздякы төшкән чүплегенә, дип сүлиләр иде. Бик аруга да төшә дип.

### *Колдун*

Колдун Казлукада (Козловкада) булган. Безнең кырлар прилегать итә. Тракторист сукалый, каршысына күчекме чыга, бүремедер. Бу кафайкысы белән тота аны, кыни үзен.

Моннан безнеке икенче көннеме, өченче көннеме кемдер бара Казлукага. Керә хозяинга да, теге яткан пижасында. Хәле юк.

– Ни булды, Ваня?

Бу кеше көчеккә әверелгән булган, безнеке тотып кинаган. Шул колдун булган.

*Неверкино районы Мансур (элек Чербулат) авылында*
*Рәхимов Равил Җиһанша улыннан (1963 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Колдун әби*

Чирүдә Разия апа әйтә. Сыерымны кемдер сава, ди. Сөт тама, ди.

Басыласыңмы дип әтәм, ди, бу эшеңнән, суктым, ди, үзен.

Икенче көнне бу бара бер әбинең эвенә, бу кан эчендә, бу киналган, ди. Шундый колдун әби булган.

*Неверкино районы Мансур (элек Чербулат) авылында*
*Емлиханова Мөнирә Абдул кызыннан (1947 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Йорт анасы*

Йорт анасы бар. Җәңки бабай бар. Чулпан бабай бар. Җәңки бабай терлекнеке.

Йорт аналары бар. Сыер бозаулый иде. Әни пешерә иде, этә иде барыгыз, оланнар, ишек башына куегыз йорт анасының күмәчен. Барып карыйбыз, ашамаган әл дә. Әнием: торсын-торсын, ашар, ди.

Аерылып чыкканда йорт анасын алып китәргә кирәк. Хоть машинада, хоть алашада. Керәсең оранга. Кашма тотасың. Кашма – покрывал. Адя кәбәм, безнең белән яхшы торырсың. Адя-адя чакырасың да чанага куясың. Алаша тарталмый, анием атя иде, шул кашманы салгач. Көч белән авыр бара, груз төягән кебек. Аннан кашманы итәсең дә шул йортыңа кертәсең.

*Неверкино районы Биги авылында*
*Юнусова Фәридә Абдулла кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Граньда шайтан*

Бабай сүли. Киләм, имеш, трактр белән, анда салам купнясы, шул салам купнясыннан, имеш, торды да китте. Напарнигыма атям, ди, син салам кучасында ятмаганмы идең?

Атя, имеш: – Юк. Значит теге, ди, шайтан. Ул ерак, граньда. Анда бояр торган, бояр кыры этәләр иде, хәзер грань, диләр. Шунда коесы, суы бар иде. Ызбаларны теттеләр, и кыр ясадылар.

## *Казарма шайтаннары*

Шайтаннар булган. Элгәре канятам аны сүли иде. Ул отрядка, солдатларга эпәй ташый булган, пекарныйдан, алашада. Ул атя казармада яткан солдатлар. Бабай килә дә ята, ә бер шалдыр-шалдырдый, ди, солдатлар йоклый, ди. Ике көн шалдыр-шалдыр шалдырдый, ди, шайтан. Кашыкларны шалдырдата, ди. Канятам әйтә, башымда чыбыркым иде, ди. Алаша кыва торган. Тордым да, ди, шуны шарт-шарт-шарт өч кат шартлаттым да, солдатлар торды, ди:

– Нәстә эшлисең?

Әтәм ди:

– Черт гоняю.

Өч көн шуны саклап тордым, ди. Аннан соң килмәде, ди.

### *Җен иялəшсə*

Җен иялəшсə, ире булып килə. Тəрəзəдəн бага. Ишеген ачамы, мөрҗəдəн төшəме.

Мылтыктан ата почмакка, мылтыктан китə, курка.

*Неверкино районы Биги авылында*
*Юнусова Фəридə Абдулла кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Йорт аналарын күчерү*

Яңа йортка кергəч, күмəч ябалар. «Йорт аналары, йорт аталары, сезгə ризык китердек, шатланыгыз, яңа йорт алдык». Аларны күчерəлəр.

Икенче йортка киткəндə ат җигəлəр, шунда утыралар. Атялар: «Йорт анабыз, йорт атабыз, сезне алырга килдек, давай утырыгыз, – итəлəр, кергезəлəр. – Әйдə, керегез, вата азык сезгə».

### *Йорт анасы*

Йорт анасы чуваш əбие булып чыгып баса да сыерыгыз бозаулады, ди, чыгып багыгыз. Куян, тор, хайваның хайван китерə, ярдəм бирегез, дип.

### *Җен иялəшсə*

Бер хатын бар иде. Җен иялəшə, китми, торырга халь калдырмый. Шулвакыт атялар иде инде, алалар мылтык та аталар үдə. Шул мылтык тавышыннан, имеш, курка.

*Неверкино районы Бикбулат (Бикмосеевка) авылында*
*Асейдуллина Сания Вахит кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Хозыр бабай*

Элек кайняталарым, кайняналарым сүли иде. Хозыр бабай күренə ул, гөняһсыз кешегə генə күренə, чапанлы, күренə, коткара Хозыр нəби.

Кем юлга китə, əтəсең, Хозыр нəби, йа Рабби, пəрдəлəп йөрет баламны. Уң як фирештəм, суң як фирештəм, йа Рабби, шул баламны саклап йөрет. Хозыр бабакай, кəбəм, девамда бул.

*Неверкино районы Бикбулат (Бикмосеевка) авылында*
*Фəхретдинова Маһруй Үмəр кызыннан (1934 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Йорт анасы*

Без алаша тота идек, алашабыз бик яхшы иде. Шулай кайчан чыга идек, яраткан алашасының ялын үрә иде шул. И шул ялны беркем дә тишәлми аны.

Яратмаган тирлеген әйтәләр иде, колодага бәрә диеп. Күтәреп бәрә, ди, яратмаганын. Аяклары югарыга, ди, шулай сүли иделәр.

Йорт анасы саклый үзеңне. Шулай әйтәләр иде. Кем дә күрми.

### *Бикмосеевка күпере шайтаннары*

Әни школда пичләр яга булган. Анда инде килгәндә, күпер узарга кирәк булган. Һәрбер кеше, нужасы бит, кочагына утын алган оланнарына китерергә. И килгәндә күпер астында уянып киткән. И шул Аятелкөрсине укыйм атя, укый алмыйм. Телне богаулый, ди, укый алмыйм. Аннан инде акылына килә, укыгач инде, и бага ул бөтенләй үзгә төштә, күпер астына төшкән. Аны бит төшергәннәр, и шул деваны укыгач, тиха гына чыгып киткән үгә.

*Неверкино районы Исәкәй авылында*
*Бахтиева Румия Ибраһим кызыннан (1962 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Мунча җеннәре*

Унике сәәттә мунчага керергә ярамый.

Җомга көн мунчага керергә ярамый – зарар тия, хасталанасың. Төнге уникедә ярамый. Сүли иделәр. Барган мунчага. Аннан соң мәет тә бар:

Җомга көн баралмадым җомгага.
Ике кыз чакырдылар мунчага.

Җомга көн мунчага кергән дә үлгән ул. Җеннәр булган. Шулай сүлиләрие әниләребез.

*Неверкино районы Исәкәй авылында*
*Бахтиева Сафия Абайдулла кызыннан (1947 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Җен эзенә басу*

Җен эзенә бастым. Әнием шулай адяшкан иде. Әнием мунчада иде бездә. Мунчадан китте. Бездән бер өч йорт. Без мун-

чага да кердек, мунчадан да чыктык. Бераз тордык инде. Чәй эчеп тә яттык. Тәрәзгә кеше шак-шакый. Без юлда тора идек. Безнең аша Октябрьскига йөриләр иде. Кунарга соралалар иде, кыш иде. Баксам тәрәзәдән, әнием анда. Мәтәм, нишлисең?

Атя: Кызым, җен эзенә бастым наверно. Бүген ничә әләндем инде таки үемә баралмыйм. Әләнә дә безгә килә, әләнә дә безгә килә, бу инде соңгы тапкыр. Шакымаган инде. Соңгысында туңам инде, өшим, шакыем, үгә итсеннәр. Вот җен эзе була, җен эзенә баскан булды әнием.

*Неверкино районы Исәкәй авылында*
*Хасянова Майзә Мөхәммәдҗан кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Йорт аналарын күчерү*

Идән уртасына бер дә тотылмаган пристиня йәйегез, и, этегез:

– Йорт аналарыбыз, йорт аталарыбыз, ни бар бала-чагаларыгыз белән әһле әүләкларыгыз белән утырыгыз шунда.

Аннан пристиняны шылайга бөтәрләп тотыгыз да шулайгага чыгарыгыз да машинагызга куегыз. Үгә кергесәсез дә, бисмилляны әйтеп, бүлмәгә йәйрәтәсең. И шылай әйтергә:

– Йорт аналарыбыз, йорт аталарыбыз, үзегезнең кеңелегез теләгән төшләргә урынланыгыз.

Элке алаша белән эшләгәннәр. Бер абзыйлар күченделәр яңы ызбага. Безнең Мөкаддәс бабайның – канягамның атына шулайга сандык куйдылар. Ул сандыкка йорт аналарын тутурганнар да инде, и күчерделәр яңы ызбага. Шыгырдаттырып, ди, арба бара.

*Неверкино районы Җәлил авылында*
*Исянова Мәфруза Хәлилулла кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Йорт анасын күчерү*

Яшьләр яңа ызба куялар иде. Минем әнием шулай сүли иде. Мин чыктым, этә, яңа йортка. Әле пешерәм пәрәмәчләр. Пич яктым. Әтиемне ебәргән анасын-атасын чакырырга. Алар боларны ебәрми булганнар. Болар карышып чыкканнар. Биш

брат үскәннәр бер ызбада, биш килендәш. Килендәшләр мунчада ашый булганнар. Оллары белән ата отдельный ашый ызбада, әниләре-килендәшләр – мунчада. Шобага селкәләр – кайсы брат чыга. Ул шобага әтиемә эләгә. Иң кечкенә ол әтием, биш браттан. Әтиемне бабакам бик ярата булган, әбием дә аны чыгарырга ниятләре юк, әниемне дә. И этиләрем карышып чыгалар.

Әтием әтә: барды алырга, килмәделәр, йөрәкләнгәннәр. Әни барган каньның башын үпкән, кулын үпкән, аннан канясыныкын. Аннан эткән, имеш: эти-әни, чәй алырга килдем үзегезне, и китерә әнием үзләрен чәйгә. Әтием әтә: сиңа килделәр, миңа юк.

Әле йорт анасы өчен. Барып йорт анасын карт йорттан китерергә. И китәләр йорт анасы өчен. Әле аның девасы бар. Бисмиллә әйтеп укыйлар аран каршына, ишек төбенә тарттыралар атны, арбаны куялар аран ишеге түбенә, и шул деваны укыйлар да, и йорт анасы менеп утыра, күзенә күренми. Деваны укыйлар да: йорт анасы, алырга килдек, адя китәбез. Атны кузгата, ат никак кузгалалмый. Йорт анасы авыр була ул. И тагы бер дева укыйлар да, и ат кузгалып, бу яңа йортның аран каршына китереп, девасын укып, йорт анасын йебәрәләр. Күзгә күренми ул. И шулай итеп, яңа йортка аранга йорт анасы керә.

### *Гайбирәннәр*

Әле первуй корсак үземдә, йеткән вакытым. Кайнанам белән тора идек. Әле төшемдә килде ап-ак халатлы бер кеше, ыстул куйды шунда, ыстулга ап-ак тас куйды, шул вакытта гына әни уятты. Тор әтә, тор оланны алалар ведь. Әле сикереп тордым тиз генә, и калды оланым алмыйча. Ул җен түгел, гайбирәннәр. Ул фәрештә була шундый. Ул гайбирәннәр, этә бересе үлсә, обязательный олан алалар үзләренә гайбирәнлеккә өйрәтергә. Җен орласа, артык тапмый кеше. Гайбирән орласа саваплы, гайбирән ясыйлар.

И вот сөннәткә гайбирәннәр төнне бирә. Олан туганда сөннәтле туа. Минем агамның олы, агамны сугышка алдылар, аларның олы туды. Мәрхүм абзием китте сугышка, кайгыртып китте инде. Атя китәм сугышка, оланым да сөннәткә бир-

ми кала. Иртән тордык – олан сөннәтле – сөннәткә биргәннәр төнне гайбирәннәр.

*Неверкино районы Мазарлы авылында*
*Комякова Миясса Әмин кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Җен эзе*

Сулеймановкага барганда шундый урын булган. Җеннең эзенә бастың и чыгалмыйсың. Адяштырып йөретә үзеңне иртәсенә кадәр.

Каеннык, җен эзенә бассаң чыгалмыйсың, кояш иңгәч, әйләнәсең-кайтасың, әйләнәсең-кайтасың шунда.

### *Йорт анасы*

Йорт анасы, пижайга ятсаң, пич янынарак үзеңне төртеп ебәрә.

### *Ак бабай*

Трактарислар кичен сукалый булганнар. Вот аларга шундый затлар чыга булган. Затлар кеше сыйфатында чыга. Килеп, ашарга сорый. Әмән килә, сүли үзең белән, әләнеп багалар – юк. Ак бабаймы, ничектер атя иделәр.

Каним сүләде. Чыктым, имеш, янымда үгә кергесеме келәгәндер инде, бу каа ашыкканмыдыр. Бу бай атя, ебәрмәде мине. Мин, атя, шуннан соң беда күрдем. И атя, уйладым, вот Аллаһ Тәәла миңа кемнедер ебәргән, ә мин ул эшне йеренә йеткезмәдем. Бирмәгәнме, сораганмыдыр нәрсәдер. Азбарда терлекләрме үлгән.

*Неверкино районы Мазарлы авылында*
*Гульмиярова Мәрьям Җиһанша кызыннан (1959 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Шайтан баласын юындырган*

Бездә булган бик яхшы әби. Катыннардан бала тудырта (кендек әби). Кичен айтя, йоклыйм, шакыйлар, әмән бу ни инде?

– Нәзифә әби, әдә тор, хатыным бәбәли.

Шул чыктым атя кабак өскә, шундый тройка алашалар, шундый яхшы карета. Утырттылар да үземне, алып киттеләр, атя,

бала тудыртырга. Бардым, атя, бер хатын бала таба, таптырттым. Берсе атя, берсенә бар әнә Альфияның өстәлендә су капланмаган чиләк белән, шул суны китер оланны евындырырга. Шайтанның баласын тудырткан. Атя, все, оланны евындырдыкниттек, и атя, ачулы сүзем навозлыкта. Альфия суын калдырган. И иртә өстен бардым да аттем шул Альфияга. Альфия бар, шул чиләктә суны түк, бүген шундый-шундый хәл иде, шайтан балалады и синең сывыңда евындырдылар. Вот атя иделәр: су алгач, чиләккәме-нигәме или өстен капларга кирәк, или бисмилля атеп, өч тына сыдырырга кирәк өстен, чтоб шайтан кермәсен.

## *Үмәр бабай девасы*

Бездә күмелгән Арифә олы бәлхи Үмәр бабай. Ул булган мәҗнүн. Әмән тиле дә түгел. Хәер биреп, дога кылса, кабуллыкка ирешә девасы. Үмәр бабайга ниятләп хәер бирсәң, юлың уңар, ниятең кабуллыкка ирешә.

*Неверкино районы Мазарлы авылында*
*Ляпина Әлфия Искәндәр кызыннан (1966 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Йорт аналары*

Чакыралар яңа үгә хәтем укырга. Шунда йорт аталарына, йорт аналарына, йорт бакаларына, йорт еланнарына, су атасы Сөләйман, су анасы Зөләйха, кыр хуҗасы Хозур галәйәссәләмгә укыйбыз, аларга багышлыйбыз.

Элке бабамнар сүли иделәр. Бер йорттан икенче йортка күчкәндә атны йегәләр, атка толып куялар, элкеге зур толып, йон эчле шул толыпны чорныйлар да инде, кереп, карт бабайлар йорт атасын, йорт анасын укып алып чыгалар. Атялар, килдек алырга сезне йорт аналары, йорт аталары, адягыз.

*Неверкино районы Дөмавылда*
*Ямбулатова Мөнирә Хәйрулла кызыннан (1941 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Йорт аналары*

Йорт аналары бар. Зәңки бабайлар. Алар саклыйлар. Тварны да, кешене дә.

Йортка өстәл куясың. Анда аш куясың. И атясең: йорт аналары, йорт аталары, кунакка чакырам сезне.

Йорт аналарын күчерәләр. Балалар киткәндә, йорт анам, йорт атам, сез әле моннан китәсез алар белән, утырыгыз.

### *Биш нарат*

Адяштыра торган урын бар. Биш наратта адяштыра анда. Без бервакыт үземнең халялым белән бардык алаша белән утынга. Утынга бардык и әле әйтә, син шунда тор, хәзер киләмен, и ул әле китте, алаша тотынды, үз урынында тормый, биергә тотынды. Әле ул ебәрелә дә аның янына китте, мин калдым. Инде мәрхүм чабыша-чабыша килде. Син кая, син кая? Мин, мәтәм, монда, селкенмәдем. Килеп алды да, без киттек.

Бервакыт бардык малинага eләккә. Мин, мәтәм, шул төшләрдә генә йыйыштыра йөрим хәзер, аннан, мәтәм, барырмын. Әле мин бара-бара чыктым биш наратка таба. Ул әле мин анда адаштым. Әле ая да чыгалмыйм. Әле чыктым Индерка юлына. Аякларыңны икесен тирескә (кирегә) ки, и әле чыгасың. Чыктым да килдем, караңгы төшкәч, зәрәтләр аша. Адяштым шулай анда. Ни өчен адяштыра? Анда әле Пугачёв узган, сугышканнар, патша солдатларын тагып киткәннәр биш аратка. Пугай сугышы дип әйтәләр. Килгән. Алар мыннан узганнар, и вот шунда звуклар да чыга.

### *Пир хатынын тудырта*

Элке пирләр булганнар. Ул пирләр бер әбине дә алып киткәннәр. Пирнең хатыны тыва, ул тывалмый. Әбине килеп алалар. Тудыртучы әби булган монда. Аны алып китәләр үзен. Ни кирәгеңне бирәбез, сорасаң, бирәбез весь. Адя мине итегез. Әбине утыртып алып киткәннәр. Ул анда барып, пирнең хатынын тудырта. Әби мине кире итегез инде, ди. Итәбез, имеш, бик күп бүләкләр үзенә бирәләр, күп инде бирәләр, алтын бирәләр үзенә. Әле үгә килә, үгә китерәләр. Ада килгәч бакса, алаша баклары төягәннәр. Элке кайнянамнар сүли иде шулай. Пир ул җен самый.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Хайрова Фатыйма Исмаил кызыннан (1952 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Биш нарат*

Пирле уй дип әйткәннәр. Пирләр шунда булган дип әйткәннәр. Ул төшләрдән сөйләүләре буенча сугыш булган. Шунда Пугачёв сугышлары узган, и бик күп кешеләр шул төштә күмелгән. Шунарга күрә пирле төш дип әйтәләр.

Ул төштә минем әнием туры килгән. Каандыр тегеннән килгәндәме, соңга калсаң, икенде – ахшам арасына шул вакытны үзеңне саташтыра-адаштыра. Каршына город килеп басарга может. Домнар. Каада барырга да белмисең. Таки йөрисең бер урында. Каадыр киттең, ә үзең бер урында торасың.

### *Йорт анасы*

Йорт аналарын күчерү бар. Әйберләрме, аш-сумы бирәсең. Машинага төяп китәсең. Укып, аларны дога кылып озатасың.

Әйдәгез, йорт аналарыбыз, безнең белән. Мында яхшы тордык. Әйдәгез безнең белән.

Әнием сүли иде. Әле, имеш, сыерны бозауларга көттеккөттек, юк. Кереп яттым, бер-ике сәәтме йокладым, и үземне кемдер төртә. Кеше үдә юктыр. Сыер бозаулый диеп уята төртеп. Күрмәгән ул аны. Кул белән ничектер тигән дә сыер бозаулый, дигән.

Канянамнар сүли иделәр. Маткага куйдылар, Аятелкөрси дип әйттеләр.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Абубакирова Һава Харис кызыннан (1954 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Йорт анасы*

Улың үләнеп чыкса да, әмән үз эвенә китсә. Алашада килеп, нәрсә барны нитеп атя иделәр инде.

Утыр йорт анасы. Ул күренми дә инде. Итәләр үзен яңы йортка. Безгә хезмәт бирдең яхшы. Хәзер яңы йортка күч инде. Шулай үзгә йортка ат белән аны итәләр. Йорт анасын чакырып, ул атка утыргач, алаша, имеш, авыр тартып китә инде. Какбудто чыгып утырган алашага.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Айзатуллина Һава Исхак кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Җен алыштырган*

Сүлиләр иде без олан чакта җен алыштырган. Аннан әткәннәр, бу сезнең оланыгыз түгел, бу җеннеке. Җеннәр арасында каадыр мунчада алыштырган. Әткәннәр алыгыз да веник белән кинагыз ул оланны, ул олан сезнеке булыр. Кини-кини ул олан кешенекенә әйләнгән.

### *Җен ияләшкән*

Әнисе үлгән дә, бер кыз бик кайгырткан. И җен иләшкән әнисе сыйфатында. Көн дә икән килә, көн дә, и бу кыз югаля шул вакытны. Аннан иртән торалар, өстәлләрендә куй буклары, иләр, шундый затлар. Ул икән җен китерә анарга кәнфитләр-ниләр, кертә дә куя. Аннан бу кыздан сорыйлар: кая барасың. Кая да бармыйм, ди.

Җен әткән, әгәр әтсәң, мин артык килмим, әгәр әтсәң, что мин йөрим.

Монардан әттерә-әттерә, әттерәләр бу кыздан. Әтә дә, шул кичне ул кыз чыга, чыга да, иртән торалар. Кызның башы кабакның теге ягында, бакча ягында, туловищесы сарай ягында. Кысып үтергән әткән өчен. Шуларны ишеткән идек.

### *Пич башында йонны зат*

Әбием краска сатырга йөри булган. Әле бардык, ди, имеш, бер авылга. Беркем кунарга ебәрми, кыш. Аннан бер хатын әтә, ди, ванә авылның читендә бер ызба бар, шунда, әткән, хоть кемне дә ебәрәләр. Анда, ди, киттек, ди, әле, ди, бардык, дөрес, ди, ебәрде. Безне, ди, пич башына яткызды, ди. Ну инде кинәндек, ди, суыктан өшегән, изрәп йокларга безә пич башы йылы төш. Әле төнне, имеш, оланым бер ара гырылдый башлады, ди. Янымда. Шул 11 яшендә булган. Әле гырылдый-гырылдый шулай, ди, кулыма баксам, ди, анда, ди, йонны зат, ди, оланның өстендә. Әле, ди, тотындым укырга. Әле, ди, берара, ди, юшка шап итеп ачылды, ди, шап итеп ябылды да, ди. Ызбаның алнысы, ди, весь ут белән тулды, ди. Девалардан курккан, ди, шуннан, ди, оланымны коткардым. Әгәр, ди, йокыга киткән булсам, оланымны буып үтерә иде җен, ди. Каадыр мукшы авылына барганнар сатарга.

*Кузнецк районы Ялгаш авылында*
*Алькаева Сабира Сәет кызыннан (1946 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Шайтан җиле*

Төнне йөрергә кирәкми – шайтан тия. Качан өч юл чатына тукталып торасын, ват шунда җил көчле күтәрелә, шунда шайтан кузгата, җиле сиңа тия. Хасталанасың. Кирәк аны өшкерергә. Чокырга су аласың да инде, анарга саласың айбагар мае, ярма – тары ярмасы, күмер саласың, шуны әйләндерәсең инде.

Ай катя, көн катя,
Син дә кайт.
Җир анасы – Җирән сакал.
Күк анасы – Күгән сакал.
Су анасы – Суган сакал.
Ай катя, көн катя,
Син дә кайт!

Шулай әйтеп өшкерәсең, суны бәрәсең аннан. Бәрәсең кояш батышына, кеше йөрмәгәч, кеше йөргәндә бәрергә ярамый, кояш байыйым дигәндә бәрәсең:

– Мәгез ашыгызны, бирегез саулыгымны!

### *Хозыр Ильяс*

Төрлечә ул йөри, ди, Хозыр Ильяс. Нидер эшли идем, бер кеше керде, бер абзи. Карт тегел, яшьрәк. Керде дә сәләм бирде дә утырды. Адя, мәйтәм, абзи, хәзер чәем кайни, чәй эчәрсең. Уки тор, хәзер садакамны алырга кердем, и шул чыксам, абзием юк. Хәзер садака бирәм, дигәч, Алланың рәхмәте яусын, ди, кирәкми, балам, ди, берниең дә кирәкми. Мин хәзер тынам да китәм, ди. И ту кердем садакамны алырга. Акчамны алдым, чыктым, бабаем юк. Ишекне ачып чыксам, каршыдагы. Кемдәме чыкмады бездән дим. Кем чыксын, ди, кем дә юк. Выт шул Хозыр Ильяс булган.

*Кузнецк районы Ялгаш авылында*
*Хальметова Гөлия Таһир кызыннан (1934 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Хозыр Ильяс*

Күршемдә әби тора иде янгыз. Ул сүләгән иде моны. Әле, имештер, бер янгыз әби – хатын тора. И анарга килә дә бер бабай әтә инде:

– Балам, мине кунарга бүген ебәр инде.

– Бабай, дигән, мин бит янгыз хатын, ничек инде мин сине кунарга ебәрием. Мин балалар тудырып йөрим, дигән, авыл буенда. Анда китәм, монда китәм.

– Балам, мин бер нәстә дә нитмимен, мыштым да юк инде, бер нәрсә мешать итмимем сиңа. Кунам инде.

Ну, ярый. Кундыра инде бу хатын. И төнне инде моны чакыралар бала тудырырга. Әле китә бала тудырырга. Килә инде, имеш, әле моның ызбасы весь ут эчендә. Алла, бу бабай нишләде курка-курка эвенә керә. Әле үгә керә, бернәрсә юктыр. Бабай пышылдап йоклый.

Әле икенче көнне тагы шулай туры килә. Бу хатын тагын китә тудырырга бала. Әле килә, мының ызбасында кеше тагылганны (буылган) тәрәзәдән үк күрә. Алла, ват нинди бәләгә эләктем бу бабайны ебәреп инде. Әле тагы керә, мыш та юк, бабай пыш-пыш йоклый. Әле тагы өченче мәртәбә тудырырга китә бала. Килә әле, тәрәзәсеннән күрә инде ызба эче весь су моныкы. Весь су каплаган. Әле инде, Алла, каан мондый су була үдә. Курка-курка эвенә керсә, тагы берни юк. Бабай иртә тора да инде әле. Бу хатын сорый инде:

– Бабай, дигән, шундый-шундыйниләр миңа күрсәттең инде, бу сың, дигән, нәстә була?

– Выт дигән, балам. Беренче балаң дигән, тудырган балаң янып үләр, икенче балаң буылып үләр, өченче балаң суга батып үләр.

Выт шыл Хозыр Ильяс була.

* * *

Мәстүрәнең оланы хасталана. Килеп керә бер бабай. Ну, ярый, бу үзенчә каршы ала, чәй дә төзи. Барып бер әйләнә, бабай нидер әйтә, оланны өшкергән була. Бакса, инде бабай юктыр. Оланы терелә. Шул Хозыр Ильяс булган.

*Кузнецк районы Ялгаш авылында*
*Усманова Әминә Хәнәфи кызыннан (1950 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Хозур Ильяс*

Йөри урманнарда-кырларда Хозур Ильяс. Яхшы кеше ул. Пигамбәр. Бер кешегә килгән дә:

– Каны су, кызым?

Су чыгарган. Кружкасында май булган. Майлы суны чиләккә чубырган да. Аның өстендә ведь чабыша йөри майлар. Биргән Хозур Ильяска. Ул алган да суны:

– Балам, дигән, яхшы тормышта яхшы ир биләрсең.

Кружкасы юмаган. Яхшы кеше генә кружканы юа, койты инде юмый. Койты кешенең ире яхшы була. Ә яхшы кешенең ире койты була.

Аннан берсенә килгән дә, бер кисәк әпәй бир, дигән. Юктыр, дигән, әпәем. Бар кит. Ебәргән.

Ну, дигән, яхшылык күрмәссең син, балам. Каны, дигән, су хоть. Биргән, чыгарган су. Су биргән ару стакан белән. Үз кул-көчең белән көн күрерсең, дигән. Ирең койты булыр, син, дигән, яхшы. Ару су биргән. Шулай диеп сүлиләр борынгылар.

## *Йорт аналары*

Йорт аналары, йорт аталары, алар бар. Аларны без белмибез генә. Яңа ызбага киткәндә:

– Утырышыгыз, үзгә төшкә киттек.

Алаша, ди, сыгылып тарта, тарталмый. Әле төшегез, төш. Вот шунда булыр ызбабыз. Селкенеп, ди, китте, ди, алаша. Әти әтә иде, бар алар, бар.

*Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында*
*Курмаева Хатимә Хусяин кызыннан (1930 елгы),*
*Мендаева Халидә Хусяин кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Җен ияләшкән*

Вата безнең каршы кабагыбыз. Җен ияләшкән, ире үлгәч. Эшкә дә барми. Көн дә елый, төн дә елый. Анарга ишектән, ди, вата керә, шыгырт итеп керә, ишекне яба, тишенә и караватка ята. Әхмәт килә, ди. Аннан соң көчәя бара, көчәя бара. Аны дүрт угылга аттыралар. Шайтанны аттыралар. Аннан инде девалар укилар да, ул бетте анарда.

Ул иләшә кеше үлгән, ул кайгырта, көн дә уйлап ят, ват шунарга күрә әтәләр бит ияләштермә, атнакич баш кич кенә укы. Көн дә укыма. Дога кылма. Ул ияләшә. Килмәсен. Ул анда калсын инде.

## ***Йорт-җир девасы***

Йорт анасына, йорт атасына, Чулпан ата, Чулпан ана, Зәңки бабай, Хоббый Хуҗа, Батхый бабай, Чулпан углый, Әнвәр ана, Хәким ата, Ишкильдик баба, Мәшәик Касыйм баба, Дивана хуҗа, исеме ательмаган төкле бабабызга, Хуҗа Насретдин, Хуҗа Баһаветдин, Муся Халимуллага, мәшрикъ белән мәгъриб арасында ике баласы белән без сезне сагындык дева белән, без сезне сагындык, сәламәтлек белән йорт җиремне ак кыл, пакь кыл, ислам динендә сабит кыл, Раббым. Бар дәүләтләребез үзебезгә саулык-шатлык белән, тынычлык белән, бәла-казасыз, хәсрәтсез үзебезгә биләргә насыйп әйлә, бар хайваннарыбызны да, Раббым, вакытлары җиткәнче үзебезгә асрап, файдаларын күрергә насип әйлә, хаерле тынычлыктан алма, килер ризыкларыбызны киң кыл, төрле бәла капукларны ябык кыл. Йа Раббым, төрле, йа Раббым, иләһием, афәтләрдән, бәла-казалардан сакла, йа Раббым, тынычлык белән яшәргә насип әйлә. Ват шыны укыйсың да и Аллаһы Тәгаләдән сорыйсың. Анарга әмән укыйсың, бер Әлхәм, 7 Кылху укыйсың. Касы елына бер укыта, касы хоть көн дә укысын. Элке укыган кешеләр китерә идек. Чегелдәк пешерә идек, чтобы май исе чыксын. Төрле затларын куя идек. Он куя идек, аннан соң яулыгын бәли идек тә и сарайга стул куя идек. Әмән барып, кешене чакыра идек тә, ул керә дә, кабагын ачып калдыра иде, икендедән соң. И керә дә, яшьми-нитми, сараеңда уки да инде и чыгып китә иде. Сиңа күренми иде, ызбага керми иде ул укучылар. Хәзер үзебез укибыз.

*Кузнецк районы Дәхтәрни авылында*
*Мусякаева Рәисә Шакир кызыннан (1945 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## ***Җен иләшкән***

Бер укыган әби бар иде. Шунарга җен иләшкән иде. Сүләнә шулар белән. Нәрсә сүли торгандыр. Артык исе дә юк аныкы.

Девалар белән куалар аны, мылтык ата иделәр. Путалугына ата.

*Кузнецк районы Дәхтәрни авылында*
*Хальметова Сания Хөсәен кызыннан (1929 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Йорт аналары*

Элке вакытта йорт аналары булган. Аларга багышлап, дога да булган. Аларга багышлап, корбан да булган. Йортның тынычлыгы өчен. Хәзер, атялар, юк. Оланымны аерып чыгарды. Алаша сорадым, алашасы бар кешедән. Аларның әйберләрен төядем. Атям: сез чагаладыгыз, иягез белән яңы ызбага барыыз. Арбаны төртеп иттем. Бисмилля итеп, алар йортына кергәнчегә тики.

Йорт аналары чагаласа, кемгәдер аерылып чыгарга кирәк булган. Элке булган шундый гореф-гадәтләр, әле юк, атялар, әлеге имамнар.

Күмәчне тозсыз, өчне беленне пешерәләр. Сарайга берсен, эткә берсен, сарай баганасына берсен.

### *Йорт-җирнең тынычлыгы өчен*

Йорт-җирнең тынычлыгы өчен алардан да сораганнар: Зәңки бабайдан, Зәңки әбидән, ебәк чәчле Сәҗидә анабыз, ебәк сакал йорт атабыз.Шулай диеп тә сораганнар.

### *Җен иялэшә*

Күп елаган кешегә җен килә. Үлгән кеше булып килә. Бер әби сүли. Имеш, ирем үлде, елыйм көне-төне. Оланы да югалды. Икенче оланы үлде. Көне-төне елыйм, имеш. Кич җитте дә, имештер, ишекләр киң ачыла, имеш, керде дә кычкыра арт аяклары өстендә. Бер көн, ике көн, имеш, страхтан үләргә генә. Сакладык, имеш. Мөрҗәгә өч көн рәттән аттырдык, югалды.

Вата күрше әбиемнең бабае үлде. Оланнары үлде. Әби капа янгыз калды. Әле, имеш, пич башында шулай утырып торам, икенде – ахшам арасы. Бабай, как обычно, киарлы кәпәцтән, ак күлмәктән, кара костюмнан, ничек йомага йөри иделәр и шуылый, имеш, килде. Керде. Мин пич башында, имеш, балкып торам.

Тьфу әйттем, имеш, оятсыз. Дөньяда тыныч бирмәдең, киткәч хоть, тыныч бир үземә. Укый-укый, имеш, пир югалды. И тагы бер дә килмәде. Күп еласаң, иләшә.

### *Аздякы*

Анамнарга барам. Кышын, сигезенче ярты. Артымнан Харис хатыны килә. Маряка тау башына еттек. Мөрҗәдән чык-

ты да ут уйга төшеп китте. Телем югалды. Артымнан кеше дә килә.

– Син күрдеңме?

– Күрдем. Син дәме күрдең?

– Мин дә күрдем.

Бу Аздякыны күрдем үз күзем белән. Ике тына. Тагын бер мөрҗәдән чыкты.

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Хәбибуллина Җәүһәр Усман кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Пижайга да ята, янына да ята. Дымавой. Аның урынысы бла иде пижайда. Урны калдырасың. Якын килмәгез янына, дия идек. Лежанка да калдырдык, җәеп тряпка. Югары полкага. Мә, дымавой, сиңа диеп.

*Сосновоборск районы Әлмәш авылында*
*Ягудина Наилә Абдулла кызыннан (1941 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Йорт аналары*

Йорт аналарына әпәй крышкасы кисәбез, ары май ягабыз. Бер сум көмеш акча. Аны тимердәй торсыннар өчен. Пычак белән кырабыз. Үз чүпрәгеңә чормыйсың и йорт анасына керәм: йорт ия, йорт анам, бу сезгә. И укыйсың Әлхәмне, Кылхуалланы и сораласың, мин сезгә ашарга китердем дип, азбар буенча йөретәм, и куям кыстырып аран угылына. Чүпрәкне хатын-кыз күлмәгеннән ертып алырга кирәк, ирең булмаса. Булса, ир кешенекен. Кем белән дә сүләнмисең куйганда. Яшәргә ярамый, йомадан соң елына бер, апрельдә куялар. Йорт анам, йорт атам, бу сезгә. Йортымны саклагыз, хайваннарны саклагыз, сараемны саклагыз. Барчабызга саулык бир, йортыбызга бәрәкәт сал.

Зәңки әби – ефәк чәчәгем.
Зәңки бабай – ефәк сакалым.
Йорт анам – ефәк чәчәгем.
Йорт атам – ефәк сакалым.

Җир анам – ефәк чәчәгем.
Җир атам – ефәк сакалым.
Урман анам – ефәк чәчәгем.
Урман атам – ефәк сакалым.

И шулай сорыйсың.

*Сосновоборск районы Әлмәш авылында*
*Ягудина Наилә Абдулла кызыннан (1941 елгы),*
*Әхмәрова Нажҗия Умәр кызыннан (1940 елгы),*
*Забирова Шафика Кәлимулла кызыннан (1938 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## ЫШАНУЛАР, ЫРЫМНАР, ЙОЛАЛАР, ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР

### *Яңгыр сорау*

Бабайлар йыйыла еде. Аллаһ Тәәләдән сорыйбыз, яңгыр яусын дип. Степта (болында). Чалабыз терлек, и укибыз, Ходай Тәәләдән яңгыр сорыйбыз. Анда балалар да йыйыла, бөтен халык.

Яңгыр яу, яңгыр яу
Иләктән, чиләктән.
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан.
Без сорыйбыз Ходайдан.
Бир Алла, бир Алла,
Биргәнеңне кире алма.

### *Кызыл йомырка*

Кызыл йомырка да бар иде. Йомырка пешерәләр, буйыйлар кызылга. Оланнар йөгерәләр, бирәләр йомырка әбиләр. Аны сораласың. Теләп чакыралар, бара, йомырка бирә, акчасын бирә. И сорыйсың:

Бисмилләһи рахмани рахим,
Йә Рабби, илаһи Кадир,
Безгә биргән шул дәүләтләреңне
Үзегезгә меңләтә бирсен.
Кош-корт булсын, чебешләр булсын,
Казлар булсын, үрдәкләр булсын,
Куркалар булсын, тавыклар булсын!

Икенче вакытны киләләр шулар ук Кызыл йомыркада, картлар чакыралар. Шөкер Аллага. Анікы тавыгы бар, үрдәге бар, куркасы бар, аякка еңел син, сине чакыралар постоянный.

### *Кияү мунчасы*

Кияү мунчасы була. Ул мунчаны саклыйлар. Саклыйлар – нидә булса салмасыннар. Ташкамы. Саклыйлар – кем дә кермәсен. Анда юыналар. И комганга акча тыгасың, коры комганга. Кучаны тыгасың да калдырасың. Аннан кем мунчаны яккан – бара мунчага, ала да кесәсенә сала.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Аитов Хасян Исхак улыннан (1939)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Солдат озату*

Һәр көзен, яз башы егерме-утыз малай озата идек. Весь мәхәллә йыйыла иде. Элгәре яз башын, болын әтәбез, степьта и шуда бар яшь кадрлар чыгалар иде уйнарга. Үдә көндез хәтем укыталар. Дога кылдырабыз, чтоб барып, сау-сәламәт кайтсын. Кичен йәшләр йыйыла, уйныйлар, көләләр, гармун уйныйлар. Озатканда әпәй каптыралар, чыкканда артың белән чыгаралар.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Кузяхметов Усман Аглиулла улыннан (1963 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Армияга озату*

Армияга киткән балага хәтем укыта идек, сау кайтса, корбан да чала идек.

Әпәй каптыра идек, аны ишек башына куя идек, кайткынга торсын. Өйдән арты белән чыгаралар иде.

### *Яңгыр сорау*

Яңгыр яумаса, яңгыр сорый иделәр. Степька – болынга чыгалар иде. Муллалар, бабайлар чыгалар иде. Чәй эчерәләр иде, бераз хәллерәге нәүмәт итә. Сорыйбыз:

Яңгыр яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан.

Без сорыйбыз Ходайдан
Бир, Ходаем, бир, Ходаем,
Биргәнеңне кире алма.
Бар ятимнәр, бар фәкирләр,
Безне ачка калдырма!

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Шабурова Хәнифә Мөхәммәтҗан кызыннан (1926 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Яңгыр сорау*:

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан.
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан.
Бир, Алла, бир, Алла,
Биргәнеңне кире алма!

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Сәйфуллина Кадрия Оваз кызыннан (1964 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Яңгыр келәү*

Куй чалалар зәрәтләр төбендә. Сорыйбыз:

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан.
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан,
Бир, Алла, бир, Алла,
Биргәнеңне кире алма!
Бар ятимнәр, бар сабыйлар,
Аларны ачка калдырма!

*Неверкино районы Сарбай авылында*
*Вагапова Майзә Исхак кызыннан (1938 елгы),*
*Хәбибуллина Наилә Исмаил кызыннан (1950 елгы),*
*Ямбулатова Сәйдә Абдулла кызынан (1952 елгы),*
*Вагапова Равиля Зариф кызыннан (1950 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Кызыл йомырка*

Мине бактылар, аягым йеңел. Күрше килә дә: Исхак абзый, Майзәне иртәгә йебәр безгә.

Кызыл йомырка көнне барам, керәм, миңа 2 йомырка бирәләр. Шундый гадәт бар иде.

*Неверкино районы Сарбай авылында*
*Вагапова Майзә Исхак кызыннан (1938 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Ташу вакытында саулык сорау*

Су анасы – Зөләйха.
Су атасы – Сөләйман.
Мә сиңа яулык,
Каны миңа саулык, –

инешкә бәргәндә, ташу акканда әйтәсең. Кар эченә чүпрәк куясың да бәрәсең. Саулык сорау.

### *Мунчада*

Мунчада ишекне ябасың да:

Су анасы – Зөләйха.
Су атасы – Сөләйман.
Сывы, парысы –
Чабыныгыз!

### *Яңа йортка күчкәндә*

Бала ата-анадан киткәндә. Бала аерылып китә, чыгып әйтәсең:

Йорт анасы, йорт атасы, китәләр.
Утырыгыз сез дә, барыгыз бергә!

*Неверкино районы Сарбай авылында*
*Рафикова Кадрия Хафиз кызыннан (1963 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Раштуада*

Безнең күрше авыллар – рус авыллары. Без аларча алып бармасак та, үзебезчә Рыштва көнне обязательно чәгелдәк пешерәбез. Чәгелдәк пешергәч, ул чәгелдәкне шундый гына түгәрәк-түгәрәк, аны уйныйбыз. Алабыз кулга: четме-чутмы

(четный-нечетный). Рыштвада уйнарга чыгабыз. Киенәбез. Йортларга керәбез. Керәбез «исәнмесез» дип, үзебезне белгебез келәми.

Чертлар кебек киенеп керәбез. Төрлечә-төрлечә. Танытקыбыз келәми үзебезне.

Гадать итә идек.

Тозлы күмәч пешерә идек.

Калуш бәрә идек. Калушның борыны кайсы якка бага – шул яктан киявең була.

Сарык тота идек. Төрлечә була иде. Караңгыда тотасың. Аннан яктыда багасың: картмы? яшьме? Ниндие эләккән. Кучкармы эләккән. Кучкар булса, жених була, бу ел иргә чыгасың. Карт сарык булса – ирең карт була.

Кое ясый идек. Тозлы күмәчне пешерә идек, сүз дәшмичә бер-беребезгә. Төшебездә кем сиңа су бирә – шул женихың булып чыга.

*Неверкино районы Сарбай авылында*
*Паздникова Сәйдә Хафиз кызыннан (1965 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### ***Йорт анасын күчерү***

Алаша егә булганнар. Алашага куя булганнар одеялын, ястыгын. Рәхим итегез, имеш. Утырыгыз, күчәбез үңгә йортка, диеп.

Аннан алар бүленә булган. Чагалый, күрәсең, йорт аталары, йорт аналары. Алаша тарталмый, ди. Сүли иделәр инде. Алаша тарталмагач, йорт анасы чыгып утырган була инде.

Зәңки бабай, Кыдырмач бабайга дога кылганнар.

### ***Ывызга уку. Йорт аналарына уку***

Сыер бозаулагач, ывыз пешерә идек. Ывызга укыйсың инде.

Бисмилләһи рахмани рахим. Ошбу укылмыш кәләми шәрифемне багышлыймын иман газабыбызга, Хуҗа Әхмәт Вәсвигә, Баһабызга Вәсфи Карига, Билял хәзрәткә, Хөбби Хуҗага, Хаким атага, Зәңки бабайга, Чулпан атага, Чәршәмбе әбиләргә, һәркайсысының ирештереп нәби хөрмәтемнең шәфәгатен нәсип ит. Нәсип кылга иден, я Рабби, укылмыш кәләми шәрифләремне

багышлыйм 11 Әхмәтләргә, 7 Султаннарга, бикәләргә, Әхәп Кәрифләргә, Хәнсевар улы ишан бабайга, Абдельман хәзрәткә, Сәбит олы Мөхәммәт, Әҗәм бабакайга. Барчасыны ирештереп, Нәби Мөхәррәмнең шәфәгатен насип әйлә. Бөтен җир йөзендәге җаннар өчен булганда, йорт хуҗаларына укырга кирәк.

### *Курку кою*

Бала куркса, бер әби кургашинны эретә, оланны бастыра, и шуны инде тарелкага коя. Анда инде кеше сүрәтеме чыга, хайван сүрәтеме – шулардан курккан була инде. Укып-укып өшкерәләр.

### *Күзегү*

Өстәл кругларын юып, оланга эчерә иделәр. Эчерәләр дә, бәрә иделәр төнлеккә таба, кояш иңешенә. Күзегү булган.

### *Олан йөремәсә*

Көтүгә каршы чыгаралар. Урамнан еп табалар, аны бәлиләр аягына да, инде көтү кергәндә кисәләр, и шуннан инде бала йөри башлый, диеп әйтя иделәр.

### *Көтү чыгарганда*

Көтү чыгарганда әпәй каптырасың терлегеңә, үгә кайтсын диеп.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Мусина Алия Габдрахман кызыннан (1943 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Яңгыр яумаса сорыйлар:

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән дә чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан.
Без сорыйбыз Ходайдан.
Алла, бир, бир.
Биргәнеңне кире алма.
Бар сабыйлар, бар ятимнәр,
Аларны ач калдырма.

## *Раштуа*

Раштва бар. Элекке чәгелдәктән уйный идек. Вечер йыйа иделәр үзебезгә. Егетләр дә керә. Уйныйбыз: парлымы, парсызмы? Кем инде неправильно әйтә, аны чиертә, кулына.

Киенүче дә бар, кичен йөриләр алар. Утынны икенче төшкә күчерәләр, арбаны алып китәләр.

Башмак бәрәсең кабак аша. Бәрәсең артың белән басып. Кая таба төшә, кая таба барасың.

Кәгазь яндыра идек көзге өстендә. Кемнең ире шофёр була.

Кое да ясый идек, йөзекләрне дә тага идек. Шундый уен бар иде. Әле юк, әле бер дә юк андый эшләр.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Абдульмянова Фәридә Каюм кызыннан (1949 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Бармый да бардым,
Хәйрана калдым.
Хәзрәт кәбәмнең
Нурларын алдың, –

Ишан бабайга баргач, шулай укыйлар. Зимичага (Кулаткы районы) баргач.

*Неверкино районы Мансур (элек Чербулат) авылында*
*Салюкова Хәлифә Илач кызыннан (1926 елгы),*
*Емлиханова Мөнирә Абдул кызыннан (1947 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Раштуа*

Раштва көнне йөриләр оланнар. Чәгелдәк пешерәбез. Әнием әйтә иде: бар куйларыгызга да ашатыгыз. Икешәрне ашата иде. Шундый адәт. Үзебез дә ашибыз, уйнибез. Киенә идек, я разный мусор. Кешегә керәсең. Кайсы куып чыгара, кайсы ни бирә. Әле дә бар. Арбаны күтәреп куялар. Коелар сала идек, калушлар бәрә идек – кая таба бара.

Спичкадан кое ясап, җеп белән йөзек сала идек. Төшеңә кем керә.

* * *

Яңа елны каршы ала идек, иске елны яндыра идек саламнар белән. Ишәсең дә тартып йөрисең саламны. Калын булса, ул озаграк яна.

– Иске ел яна, иске ел яна, иске ел яна, – дип кычкырып йөрисең. Әле балон яндыралар. Машина балоны – колесо.

* * *

Әвен базында адаштыра. Борынгыдан калган.

### *Яңгыр сорау*

Яңгыр яумаса, сорыйлар, кырга чыгалар, инешкә төшәләр. Бер әбиебез ашарга пешерә иде. Безне кырга алып китәләр яңгыр сорарга, сорыйбыз:

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан.
Бир, Алла, бир, Алла,
Биргәнеңне кире алма!
Ач итмә!

Бер-беребезгә су бәрешәбез, евынабыз.

### *Зәм-зәм суы*

Уникенчедә барабыз. Йыйыналар барысы бу очтан, киләләр, чыгам, бисмиллә әйтеп, укып. Укый-укый барабыз, зәм-зәм каян алабыз. Крайныйда бер кое бар, ул кое фантал кебек ташып тора. Барасың, укып аласың. Берәм-берәм оланнар ала, әбиләр ала. Зәм-зәм суы белән чәй куеп эчәбез. Шифа булсын тәнебезгә әтәбез. Зәм-зәм суы бер елга тике тора, бозылмый.

### *Тышау кисү*

Көтү килгәндә тышаулыйсың да йөремәгән оланны, шул тышаун кисәсең, укып. Аннан олан еңеллек белән йөри.

### *Күз тисә*

Күз тисә, өстәл угылын юа, шул помойны эчерә оланга. Кояш иңешенә суны бәрәсең:

Су белән килгән булсаң,
Күз белән килгән булсаң,
Ырымнан килгән булсаң,
Ай катя, көн катя, син дә кайт.
Каян килдең, шунда кит.
Җилдән килсәң, җилгә кит.
Уттан килсәң, утка кит.
Судан килсәң, суга кит.
Күздән килсәң, күзгә кит.
Үзенә кайтсын!

* * *

Аны кара күмер белән, янган күмер белән эшлиләр шул кутыр-путырны.

*Неверкино районы Биги авылында*
*Юнусова Фәридә Абдулла кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### Яңгыр сорау

Яңгыр яумаса, корбан чалалар. Бездә йерибез сораулы. Бабайлар-әбиләр йыйылып. Балаларны йөретә идем кырларга. Яңгыр яу, яу кычкыралар:

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан.
Бир, Алла, бир, Алла,
Биргәнеңне кире алма!
Иляһыем, ярлыка!
Салма безне тарлыкка!
Салсаң безне тарлыкка,
Тартып алып ярлыка!

*Неверкино районы Бикбулат (Бикмосеевка) авылында*
*Асейдуллина Сания Вахит кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### Күз тию

Күз тиюләр бар иде, үтерә торган. Аны инде укырга кирәк иде. Элеккеләр укыйлар иде. Аятелкөрси укып өшкерәләр иде.

Күз тисә, бер савытка су аласың, ишекнең ручкасын, кая тотылып кергән, аннан касякларын ишекнең, өстәлнең кругын, кайсы чашкадан бәлки чәй эчте. Аннан оланны себрәсең дә инде, берәр кашык каптырасың, калганын чыгарып ишектән, забор аша түгәсең.

Киемен кисеп алганын ишеткән бар. Чыгып кына китте, имеш, нидер булды оланыма.

Чыгып киткәч үк, эзеннән тупрагын алалар, шуны суга салып, бер кашык эчерә, калганын түгәргә забор аша.

### *Бала сөйләшмәсә*

Олан сүли белмәсә, мыкылдап йөресә, кәҗә астыннан чыгаралар иде. Өч тапкыр. Моннан берсе биреп тора, тегеннән икенчесе алып тора. Әләндерәләр, өч кат чыгаралар. Уң яктан.

### *Раштуада*

Раштвада азбарга чыга идек, куйлар тота идек. Кем эләгә үзеңә. Яхшырагымы, койтырагымы. Бер елдан чыксаң, яхшырак егет булыр. Мәүлүк булса, бер мәүлүккә китәрсең. Күрмисең, караңгыда тотасың куйларны.

Чабата бәрә идек. Чыгабыз да чабата юк, калуш. Калуш бәрәсең, урам якка, и чыгып багасың кайсы якка калушның башы киткән.

Чегелдәк пешерә идек. Йомыркага су салып, камыр баса идек тә, шундый-шундый чәгелдәкләр пешерә идек. Элеккеге юк иде, без үскән вакытта юклык иде, лавкада зат та юк, май да, зат та юк. Без крахмал ашап үстек. Борынгы заман кешеләре. Картук та юк иде туйганчы ашарга.

*Неверкино районы Исәкәй авылында*
*Хасянова Майзә Мөхәммәдҗан кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Яңгыр сорау*

Яңгыр сорарга сахрага чыгабыз. Корбаннар бугазлап сорыйбыз. Намазлар укыйбыз. Балалар кычкыра:

Яңгыр яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан,

Без сорыйбыз Ходайдан.
Бир, Алла, бир, Алла,
Биргәнеңне кире алма, кире алма.
Бар ятимнәр, бар сабыйлар,
Бар кош-кортлар, бар хайваннар,
Безне ачка калдырма!

Корбаннар бугазларга булмаса, әбиләребез су буена чыгабыз. Инеш буена. Шунда ашлар пешерәбез. Бала-чаганы йыйабыз.

* * *

Яз башы, половодьеда бара идек тә саулык сорый идек:

Су атасы – Сөләйман,
Су анасы– Зөләйха.
Мә сиңа яулык,
Каны миңа саулык.

*Неверкино районы Җәлил авылында*
*Исянова Мәфруза Хәлилулла кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### Яңгыр сорау

Кырларда корбаннар чалалар. Әле дә чалалар, яңгыр сорыйлар. Оланнар:

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан.
Бир, Алла, бир, Алла,
Биргәнеңне кире алма!
Бар ятимнәр, бар фәкирләр,
Безне ачка калдырма!

Аллаһ Тәгаләдән соралу, яңгыр сорау. Аннан су сибешәләр.

### Раштуа

Раштва бар. Веniклар артыңа, комганнар асып йөрисең. Мунча чабынырга дип, Раштвада керәсең.

Чәгелдекләр пешерә идек Раштвада ашарга. Аннан соң буралар бурый идек. Төшеңдә кем килә, ул шул коедан су алып

эчерә. Ват шул малайга кияүгә чыгасың инде. Шулай ышана идек, эшли идек. Аннан соң капка-азбарга чыгып, кабаклар аша чабаталар бәрә идек, әле галушлар, батиннар. Уң яктан кабакның теге янтыгына бәрәсең. Кайсы якка борынысы борыла, шул якка кияүгә чыгасың.

Аннан соң араннарга чыгып, куйлар кочаклый идек. Яшь куй булса – яшькә кияүгә чыгасың, карт куй эләксә – картка кияүгә чыгасың.

Аранга чыгып, буралар саный идек. Шул бура кемнеке күп чыга – байга кияүгә чыгасың. Төнне, күрмичә саныйсың бураны.

Куйларны кочаклаганда мужиклар да ята иделәр куйлар арасына, йонны толып ябыналар да яталар куйлар арасына. Шундый кызыклар була иде.

Бер сәаттә төнне йөри иде шулай халык. Койты киемнәр киенәсең (өстән тирес тун да ябынасың, куй тиресе куясың. Кызык булсын өчен). Башка капрон чулкалар кия идек, кеше сине танымый.

Чаналарны орлый идек. Бик кызык үстек без. Хәзер олан белми бер зат та.

*Неверкино районы Мазарлы авылында*
*Комякова Миясса Әмин кызыннан (1939 елгы),*
*Кагарева Мөнирә Әмин кызыннан (1942 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Саулык сорау*

Елгабыз ага иде, и барып чүпрәкләр бәрә идек:

Су анасы – Зөләйха.
Су атасы – Сөләйман.
Мә сиңа яулык,
Безгә бир саулык.

Чүпрәкләр агып китә, үзебезгә саулык сорыйбыз. Әле елгага бер зат та бәрергә кушмыйлар муллалар.

### *Яңгыр сорау*

Яңгыр яумаса, корбан чалып, ашлар пешереп, кани сахрада, и яңгыр сорый идек, намазлар укып. Шуннан шыгырдап яңгыр ява иде. Әгәр яумаса, икенче көн дә бара идек. Оланнар:

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан
Без сорыйбыз Ходайдан.
Яңгыр яу, яу, яу,
Безне ачка калдырма!
Бир, Алла, бир, Алла,
Бирганеңне кире алма!
Бар ятимнәр, бар фәкыйрьләр,
Аларны ачка калдырма!

*Неверкино районы Дөмавылда*
*Ямбулатова Мөнирә Хәйрулла кызыннан (1941 елгы),*
*Абушаһманова Мәрьям Хөсәен кызыннан (1948 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Зәм-зәм суы

Зәм-зәм сывына киләләр бире. Анардан күчә пешерәләр. Җиде төрле аштан. Борчак, рис, ярма, тоз, май, су. Шул суны алгач пешерәләр. И авыз ачалар. Рузя кешеләр.

## Раштуа

Раштва бар. Чыктык куйлар кочакларга. Бер кызыбыз кочаклады карт куйны – кияүгә чыкты үләнгән мужикка. Мин бардым да кочакладым яшь кенә кәтә чаганы. Минеке миннән ике яшькә яшьрәк булды.

Раштвада күмәчләр ашый идек, пешереп. Көзгегә барасың да, әгәр дә өлгермәсәң, капла, иначе суга үзеңне пир и күгәреп каласың, имеш. Танырга кирәк, кем егете. Озак карап торырга ярамый.

## Күз тисә

Каян килдең, шунда кит,
Үзеңнеке үзеңә.
Оланымның саулыгын бир үзенә.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Хайрова Фатыйма Исмаил кызыннан (1952 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Курку коюю*

Элке кургашин белән коя иделәр. Кургашинны эретәсең анда иләкләр-чиләкләр куясың. Эреткәч, оланның башында тотасың и коясың. Сураты нарсага ошый, шуна айтясың, аласың да күмәсен үзен. Җиргә күмәргә кирәк.

Каан килдең, шунда кит,
Үз юлыңда тор.

### *Яңгыр сорау*

Кырык көн яңгыр яумаса, зәрәтләр башына яңгыр сорарга чыга иделәр. Зәрәтләр башында ирләр азан атялар, намаз укыйлар. Зәрәтләр кругында Алладан сорый йөриләр.

Алла, бир, хаерлы яңгырыңны.
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә-коймактан,
Без сорыйбыз Ходайдан.
Раббым, бир, хаерлы яңгырыңны.
Ашлыкларны киптермә,
Безне ачка үтермә,
Бир хаерлы яңгырыңны.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Абубакирова Һава Харис кызыннан (1954 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Яңгыр сорау*

Яңгыр яумаса, зәрәтләр башына чыгып, яңгыр сорый идек Алладан. Нәрсә барыңны менгезәсең. Шунда өстәл төзисең.

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан.
Без сорыйбыз Ходайдан
Алла, бир хаерлы яңгырыңны!
Корт-кош хакына,
Без сабыйлар хакына
Алла, бир хаерлы яңгырыңны!
Ашлыкларны киптермә,

Безне ачка үтермә,
Алла, бир хаерлы яңгырыңны!

Зәрәтләр кругында йөри идек шулай. Су сибешә идек авылда.

### *Раштуада*

Куйлар эләргә чыга идек. Яхшы гына куй элсәң – бай була.

### *Тимрәү*

Күмер белән тимрәүне сызалар иде.

Каан килдең, анда кит.
Җилдән тигән булсаң – җилгә кит.
Җеннән тигән булсаң – җенгә кит.
Ай белән аралыйм,
Көл белән куралыйм.

### *Судан сорау*

Су янына качан төшәсең су алырга, имнәргә:

Су атасы – Сөләйман.
Су анасы – Севаркай.

Сездән килдем сорарга баламның саулыгы өчен. Су бирегез. Аны тирескә таба алырга кирәк. Суның агышына таба. Чумырып аласың. Баламның саулыгы өчен килдем сездән су алырга. Алдыңа агызып ебәрәсең әпәй-тоз. Әпәй өстенә тоз куеп агызып ебәрәсең. Әйтәсең: икмәк-тозым белән килдем. Аннан сывыңны алып китерәсең. Ул суны оланның куркывы коярга, аны кояш иңгәч алырга.

### *Курку коюю*

Матка турысына куясың банкадамы өстенә инде, элке гәрәбәнкә яба булганнар или тарак ябып инде. Шыны шунда кундырасың матка астында. Икенче көнне баланың куркывын коярга. Баланы кергезәсең, и табак шыл суны кургашин салып. И шыны инде саласың да и нинди төстә шул кургашин нинди устаугa керә инде. Нәрсәдән олан курккан. И куркывы бетә.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Айзатуллина Һава Исхак кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Яңгыр сорау*

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан!
Сыерларның сөтләре
Әз булмасын, күп булсын!
Бодайларның башаклары
Ач булмасын, тук булсын!
Бир, Алла, бир, Алла,
Биргәнеңне кире алма!

### *Оланны мунчада чабу*

Оланны әти-әниләре үзләре чапмый, нинди дә булса кеше чаба мунчада:

Атаң кискән утын түгел.
Анаң яккан мунча түгел.
Атаң кебек көчле бул!
Анаң кебек йомшак бул!

### *Мунчадан чыкканда*

Мунчадан чыкканда соңга керүчеләр веникны куеп, йорт анасы, йорт атасы, кереп юыныгыз, кереп чабыныгыз. Безгә саулык сорагыз, дип әйтә иделәр картлар. Тазларны каплап калдыралар, чүмечне. Веникны калдырып шулай такмаклыйлар.

### *Сөннәт туе*

Элек сөннәт туйлары ясый иделәр. Бишеккә яткызалар сөннәткә биргән малайны, бишек башына янчек тегәләр, шунда акча салалар. Күпме акча җыела балага. Ә хәзер инде больницадан китерәләр. Һаман кардәшләр тәбрикли.

### *Бәбәй мунчасы*

Бәбәйне юалар. Беренче мунчага ике ананы чакыралар. Кайнана и үз ана. Чабалар. Ата-ана белән үс, бәхетле бул, дип. Аннан сыйланасың, мунчадан килгәч.

*Кузнецк районы Пәлдәнге авылында*
*Енгалычева Венера Исмәгыйль кызыннан (1938 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Яңгыр сорау*

Яңгыр яумаса, яланга чыга идек.

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан!
Бир, Алла, бир, Алла
Биргәнеңне кире алма!

Дога кыла идек. Хайваннар хаки хурмәтенә, сабыйлар хаки хурмәтенә, үсемнекләр хаки хурмәтенә, йа Раббым. Шулайга сорыйбыз үз телебез белән.

### *Бүре эзенә басу*

Бүре эзенә баскач, кашына башлыйлар. Бүречә улап чаба булганнар мунчада.

### **Күз тисә**

Су ала, тәрәзәләрне, ишек сапларын, өстәл угылларын, авызы-борынысын-битен себергәннәр дә и суны бәргәннәр бусага аша, йортка.

Кем тиергәнен белсәләр, тоймастан гына кисә булганнар чабуын. Аннан яндырганнар.

*Кузнецк районы Ялгаш авылында*
*Алькаева Сабира Сәет кызыннан (1946 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Яңгыр сорау*

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан.
Бир, Алла, бир, Алла,
Биргәнеңне кире алма!
Бар сабыйлар, бар ятимнәр,
Безне ачка калдырма!

*Кузнецк районы Ялгаш авылында*
*Әбдерәхимова Маһира Әнвәр кызыннан (1951 елгы),*
*Амирова Гөлшат Абдул кызыннан (1954 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Яңгыр сорау*

Яңгыр яумаса балалар чыгалар иде сорарга:

Янгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан
Без сорыйбыз Ходайдан.
Бир, Алла, яңгырыңны.

*Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында*
*Хәбибуллина Талия Рөстәм кызыннан (1952 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Яңгыр сорау*

Яңгыр яумаса, Аллаһ Тәгаләдән сорый идек. Ашлар пешерә идек. Намаз укып сорый идек.

Янгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан!
Арышларның башлары
Ач булмасын, тук булсын!
Сыерларның сөтләре
Аз булмасын, күп булсын!
Бакчаларда алмагач,
Корый яңгыр яумагач!
Бир Алла яңгырыңны!
Бир Алла янгырыңны!

Җинау, бер худтан кычкыра идек. Шыбырдап яңгыр ява иде.

### *Кандалагыз ни ашый?*

Кызыл йомырка кичен йөри идек. Киләбез дә капка төбенә оланнар кычкыра:

– Кандалагыз ни ашый?

Моннан җавап бирәләр:

– Кандала кандаланы ашый!

### ***Күз тисә***

Күзектерү белә сразу кеше үлә. Өч тәрәз күзен, ишек бавын, бишекне, өстәл угылларын ярты чокыр су аласың и кулыңны ебетәсең дә, шуларны чәйкап, шуны губасына сөртәсең оланның. Суны бәрәсең дә чокырны каплап куясың.

Бир минем яхшыны.
Үзеңнеке үзеңә.
Мачи сүсен күзеңә.
Каан килдең, шунда кит!
Каан килдең, шунда кит!
Аллаһ Тәгаләдән шифа сорыйм.

### ***Раштуа***

Раштвада коелар ясый идек. Нинди егет су алыр коебыздан. Спичкадан коелар ясый идек. Ыргак ясап куя идек.

Чабаталар бәрә идек. Кайсы якка таба бара.

Чәгелдәк пешерә идек.

Куйлар тота идек. Чагалаган куй эләксә – толга барасың.

*Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында*
*Курмаева Хатимә Хусяин кызыннан (1930 елгы),*
*Мендаева Халидә Хусяин кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### ***Олан күзексә***

Олан елый. Ул күзеккән була. Аласың су бер тамчы гына. Күмер саласың, өч тамчы гына айбагар мае. Өстәл угылларын, бишек бауларын, ишек тоткаларын... аны ишекнең бусагасына сала идек. Ишекне кыстыра идек, чтобы яман күз кысылсын, яман авыру кысылсын.

Каан килдең, шунда кит,
Җирдән килсәң – җиргә,
Җеннән килсәң – җенгә,
Күктән килсәң – күккә.
Кеше күзе белән,
Яман күз белән килсә –
Үзенең явызлыгы үзенә төшсен!

Яба да куя идек.

### *Курку кою*

Бала куркса, курку койдыра идек. Оланны утыртабыз бусагага. Стулны куябыз. Башына каплыйбыз, аның өстенә табак куябыз, аның өстенә салкын су салабыз. Әле беребез кургаш кайнята. Китерәбез дә и вот шыны салабыз салкын суга. Оланны тотып торасың, селкенмәсен. И шул, нәстәдән булган, шул рәсем төшә. Шул табакка. Төшкән рәсемне өч юл чатына бәрәсе. Өч мәртәбә шулай эшләргә.

Каан килдең, шунда кит.
Җирдән килсәң – җиргә,
Җеннән килсәң – җенгә,
Күктән килсәң – күккә,
Кеше күзе белән килсәң –
Әмән кеше күзенә кит.

Аннан сывыңны аласың да оланыңны евындырасың. Аннан соң вилка аша, вилка кадыйсың җиргә дә, шуның аша шуның суын, оланыңны евындырган суны вилка аша саласың.

Аннан соң:

Су анасы – суган сакал,
Җир анасы – җирән сакал,
Күк анасы – күгән сакал,
Урман анасы – урган сакал, –

этәсең дә, шул вилка аша саласың.

### *Сихер тисә*

Төрле чүпрәкләрне әмән йомырка аласың, йомырка эченә шуларны төйисең, йомырка эчен агызып. И аннан соң яз башын су агышына аны озаталар. Аннан катя авыру.

*Кузнецк районы Дәхтәрни авылында*
*Мусякаева Рәисә Шакир кызыннан (1945 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Җилгә җибәрү*

Девалар белән өшкерәбез, җилгә ебәрәбез.

Бисмилләһи рахмани рахим.
Җил анасы – җирән сакал.

Су анасы – суган сакал.
Күк анасы – күк сакал.
Каян килдең, шунда кит.
Шул кешенең үз саулыгын үзенә бир.
Мәгез сезгә!

Көл бәрәсең дә артыннан ебәрәсең. Аятелкөрси укып кайтып киләсең. Авыруны җилгә җибәрәбез.

Пирдән килсә – пиргә китсен.

### ***Курку кою***

Олан куркса, курку коялар иде. Утырталар матка турысына оланны. Кургашин алалар. Ул кургашинны эретәләр дә табакка су өстенә иләктән шул эрегән кургашинны салалар.

Кургашин нинди сыйфатка төшә инде. Шунардан курккан була ул. Аны буньына (муенына. – *И.Я.*) бәлиләр, межага күмә иделәр.

* * *

Ташлар да кыздырып бәрә иделәр. Борчаклар бәлиләр иде.

Дүрт юл чаты кирәк. Тага (дага. – *И.Я.*) тимере дә булсын, мунча ташы да булсын, борчак та булсын, он да, койты чәчләр булсын, койты төкләр, кирәкмәгән 7 әйбер кирәк:

Мә сезнең азыгыгызны,
Безгә бир саулыгыбызны.
Каан килдең, шунда кит.
Мәгез сезнең азыгыгыз.

Бәрәсең дә китәсең. Кем он куя, кем тоз куя. Кем ни куя, 7 төрле зат булсын.

Өч мунчадан кирәк берәр таш алырга. Өч ташны бергә бәлисең, итеп бәрәсең.

*Кузнецк районы Дәхтәрни авылында*
*Хальметова Сания Хөсәен кызыннан (1929 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### ***Тавык келәве***

Яңгыр яумаса, тавык келәве атялар. Сулар йыштыра идек, качып тора идек каа булса, коймаларның читләрендә. Кешеләр килә башласа, шул суны кечкенә кружкалар белән кешеләрнең

өстенә коя идек. Коя идек тә үзебез качып китә идек. Яңгыр шулай сорый идек:

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан.
Ашлыкларны киптермә,
Безне ачка үтермә.
Сыерлар да тук булсын,
Безгә катык-сөт булсын,
Бир, Алла, бир, Алла,
Хаерлы яңгырыңны!

## *Раштуа*

Раштвада кызлар уйный иделәр, гадать итә иделәр үзләренә.

Кергезә иделәр тавык. Тавыкның каршысына куялар төрле-төрле ашлар. Бодаймы, сумы куялар. Нәрсәне тавык килеп ашый. Кемнең тавыгы нәрсә ашый. Көзгегәме бага. Су эчсә, була эчкече, бодай ашаса – мул булыр, көзгегә бакса – кевәс (модный) булыр. Чыга иделәр дә араннарга, бүрәнәләрне кочаклый иделәр. Аранның эчендә. Атя иделәр: сусик-мешок, сусик-мешок, сусиктамы булыр ашлыгың шул кешенеке, кемгә син кияүгә чыгасың, мешокта гынамы булыр, колхозникмы. Стан башлап бер бүрәнәгә – сусик, икенчесе – мешок нәрсәдә бетә, шунысы синеке булыр. Сусик булса, көп булыр ашлыгы, бай булыр. Мешок булса – рабочий, аныкы әзрәк була.

Спичкадан кое ясый иделәр. Йокларга балыкны ашап ятасың. Кем үзеңә шул коедан чумырып су бирә.

Баш аша кабак аша вальник выргытасың или галуш. Кайсы якка борыла – шунда кияүгә чыгасың.

Караңгыда керәсең дә куйлар кочаклыйсың. Яшь куйнымы кочакладың, карт куйнымы кочакладың. Яшь булса – яшькә чыгасың, карт булса – картка. Арык булса – арыкка.

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Бакаева Сания Али кызыннан (1949 елгы),*
*Вагапова Гүзәл Равил кызыннан (1968 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Саулык сорау*

Яз башы ташулар. Сулар кузгала. Үзеңнең тузган күлмәгеңнең чабуын алып атяла:

Мә сиңа яулык,
Каны миңа саулык!

Агызып ебәрәләр. Нибар агуларың агып китсен черегән чүпрәгең белән. Ташу вакытында.

### *Күз тисә*

Күз тисә – өшкергәннәр. Тозлы су койганнар. Әз генә су алырга, әз генә май тамызырга, әз генә тоз салырга.

Каан килдең шунда кит,
Иртә килгән булсаң, иркеп кит.
Кич килгән булсаң, кичеп кит.
Төш килгән булсаң, төшеп кит.
Айлар катя, көннәр катя,
Шулар кебек син дә кайт.

Битен, башын евалар, ишек бауларын сөртәләр дә и ташлыйлар өч юл чатына. Яшмичә баралар, яшмичә салалар.

### *Ты(р)шау (кисү)*

Йөреми олан. Көтү килгәндә оланны бастыра булганнар. Көтү килә, оланны чыгаралар, олан озак йөреми. Бастыралар оланны, мунчала ебе белән аяклары тышаулаган. Йомырканы каты алып ебәрәсең дә, шуннан олан йөреп китә артыннан. Йомырканы каталатып ебәргәч, астан кисеп ебәрәсең.

* * *

Сигәк оланга керпе ите ашата булганнар.

* * *

Чыра пычакны куялар. Кыздыралар да сидеген тоталмаган кешене песикай иттерәләр. Шуның пары менә.

* * *

Елый белми, сүли белми олан. Аларның тел астын кисә булганнар. Теле ябышып туа олан.

* * *

Тамак шешсә. Баш бармак белән ала көл, көлгә сала тоз. Тьфу басты да, и тамакка баса бер якка, икенче якка.

### *Тимрәү*

Евеш тимрәү бар, коры тимрәү бар. Җиде көннек күмер кирәк, пич ягылган булсын җиде көн. Җиде күмерне алалар и ол күмер белән сызалар тимрәүне.

Әм Амрамун, и ташлый.

### *Курку кою*

Куркуны кояр өчен кичен банкага алырга кирәк су. Суның эченә салырга кирәк зур шып, аны өстенә поперек куярга расческа. Ул матник астында кунсын ул су. Икенче көн ул суны аласың. Әле кирәк кургашин эретергә. Кургашинны кашыкта эретәсең, укыйсың нәрсә кирәк:

460 тамырда, 400 аврып сәвәктә булган шипа (шифа) өчен, йә Рабби, тәҗрибә кылам! Нәссәдән килгән, шунда китсен.

Суга шул кургашинны коясың да, нәстә анда, эт сыйфатымы, эттәнме курккан, кешедәнме курккан, и шуның образы чыга. Өч тына повторять итәргә кирәк. Аны ары төшкә түгәргә кирәк.

* * *

Баканың икрасын йөртергә кирәк щитовидканы бетерсен өчен.

### *Кендек бәйләү*

Яшь туган олан елый. 40 көн булгач, аның балярга кирәк кендеген. Кендеген баляр өчен, өч тынап тәҗрибә кылырга кирәк. Ни белгәнне укып, тевен ясап барырга. Еп булсын липовый, мунчала ебе. Юлда табылган еп кирәк. Балягәч, тизрәк чери торган төшкә күмәсең.

Яшь баланы чапканда:

Әниең яккан мунча түгел,
Әтиең кискән утын түгел.
Айшә Патима кулыдыр.

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Хәбибуллина Җәүһәр Усман кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Яңгыр сорау*

Корбан чалалар иде, әби-бабайларыбыз укый, без яңгыр сорыйбыз.

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан!
Бир, Раббым! Бир, Раббым!
Рәхмәтле яңгырыңны.
Ашлыкларны киптермә,
Безне ачка үтермә.
Бир, Раббым! Бир, Раббым!
Рәхмәтле яңгырыңны!

*Сосновоборск районы Әлмәш авылында*
*Ягудина Наилә Абдулла кызыннан (1941 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Яңгыр сорау*

Яңгыр яумаса, корман (корбан. – *И.Я.*) чалалар. Сулар сибешә иделәр.

Яңгыр яу, яу, яу
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчә, коймактан,
Арыштан, бодайдан,
Без сорыйбыз Ходайдан!
Ятим балалар өчен!
Гөнаһсыз хайваннар хакына
Рәхмәт тамчыңны тамыз инде!

*Сосновоборск районы Сәләмәс авылында*
*Альбекова Алия Исмаил кызыннан (1944 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## РИВАЯТЬ-ЛЕГЕНДАЛАР, АВЫЛ ТАРИХЛАРЫ, СӨЙЛӘКЛӘР

### *Алявыл*

Монда Али торган. Али бабай диеп әйтәләр. Ул каяндыр килгән. Али бабай атлана алашага и бара, и алаша примерно шунда туктала да, аныкы колесо шунда бетте. И шул Али авылы дип атала да.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Аитов Хасян Исхак улыннан (1939)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Али авылы*

Падишада 25 ел служить итә. За хорошую службу йир бирә. Шул йиргә барасыз, алаша бирә үзенә. Алашага утыра да китә. Бара арыганчы. Ул примерно 20–25 километр моннан. Ул шунда туктый. Али авыл территориясе 25 километр булган.

Муратывка – икенче авыл. Аның браты булган. Монда Али, тегендә Мурат. Братын калдыра Муратовкага.

Кайсылары әйтә: Нижний Новгородтан булганнар татарлар.

Суның теге ягы – Али авыл, суның бу ягы – Судачок. Элек икесе ике колхоз булган.

Каенсар бар. Анда каеннар үскән. Монда имәннек, тау башында, хәзер ул имән бетте – нарат утырттылар, сукалап. Орешник бар, анда чиклавык булган.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Кузяхметов Усман Аглиулла улыннан (1963 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Чапай яры. Анда сыеры каталап төште. Кличкосы булган Чапай. Кушаматы.

Бу якта әйтәләр: Сары яры. Анда сары кум (ком) чыга. Сарыкум – сары яр диеп әйтелә.

Чабаклы елгасы. Анда таллар үскән, аннан талларны суйганнар и юкә, и юкәдән чабаклар (лапти) үреп ишәләр.

Бай тавы. Бай торган анда.

Крута, биек тау – Бояр тавы. Анда боярлар торган. Урыс булган. Аларның ызбаларын тетәлмисең. Йомырка сарысыагы белән салган булганнар дип айтяләрие. Аннан ваттылар,

ташын да алдылар. Ул йомырканы растворга кушканнар, чтоб тетелмәсен.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Аитов Зәкәрия Хасян улыннан (1966 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Әүлия зирәтләре

Каенсарга барганда Әүлия зирәтләре әйтәләр. Анда ике мәет күмелгән. Ташлары да бар. Шундый круг белән весь круглаган ташлар. Хәзрәт Сөләйман ситка тоттырды. Ташлары иске, язылмаган. Елга ташлары куйган. Язмаган анда зат та.

Элгәре вакытта акча күп түгел иде, копек кына, вот шул акчаны, барасың да, белгәнеңне укыдың да, акчаны куясың да китәсең. Анда изге кешеләр күмелгән. Аннан ул акчаны беркайчан да кем дә алмый. Теге таш өстенә куясың да бу таш белән каплыйсың акчаны. Әбиләр барып, хәтем укыйлар. Ул изге төшләр, әүлия зирәтләре.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Аитов Хасян Исхак улыннан (1939 елгы),*
*Кузяхметов Усман Аглиулла улыннан (1963 елгы),*
*Аитов Зәкәрия Хасян улыннан (1966 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Сулеймановка

Первый килүче бабай Сөләйман булган. Безнең унике чакрым бер зур авыл – Мазарлы дигән, Октябрьский әле. Аннан аерылып, бер бабай килеп утырган – Сулейман бабай. Авыл Сулеймановка русча, татарча Сарбай.

*Неверкино районы Сарбай авылында*
*Вагапова Майзә Исхак кызыннан (1938 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Әүлияләр

Зәрәтләрдә бар әүлияләр. Атлары белән әйтялар. Алифә кызы Әминә әүлия былган. Укымышлы былган инде күрәсең. Нур чыккан зәрәтеннән. Күргәннәр, картлар күргән. Күмгәннән соң нур чыккан.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Мусина Алия Габдрахман кызыннан (1943 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Биги. Бикбулат. Али*

Ул барлыкка килгән 1547 елны. Иван Грозный указы буенча.

Өч брат булган. Биги, Бикбулат и Али. (Али авылында сез идегез). Берсе Али авылы – шунда киткән, берсе биш чакрым Бикбулат авылы и бу Биги авылы. Бикбулат – Бикмосеевка авылы, безнең районда. Бикмосеевканың элеккеге исеме – Бикбулат. Аннан анда ике авылны куштылар: Бикбулат и Муся авылын. Бер овраг кына аларны аерып торган.

Бу өч братның балалары Мурат – Муратовка авылында.

Алар килгәннәр татар ягыннан.

*Неверкино районы Биги авылында*
*Сатаева Равиля Исхак кызыннан (1948 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Бикмосеевка*

1745–1762 еллар арасында барлыкка килгән. Монда булган Бикбулат. Степановка, Яковлевка авыллары булган. Темниковский уездан килеп нигез салалар Бикмосеевкага.

*Неверкино районы Бикбулат (Бикмосеевка) авылында*
*Асейдуллина Сания Вахит кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Күк капугы*

Күк капугы ачылган гөняһсызга гына ул. Минем бабаем күргән. Ут яга иде элекке светларны артта. Күк капугы ачылды, ди. Сразу яп-яктырып китте, ди. И ябылды да, ди. Анда, өлгерсәң, сора саулык-сәламәтлек үзеңә, балаларыңа. Өлгерәлмисең – сразу ачыла да ябыла.

*Неверкино районы Бикбулат (Бикмосеевка) авылында*
*Фәхретдинова Маһруй Үмәр кызыннан (1934 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Чыршым. Янган авыл. Җәлил*

Ул кайчандыр иске вакытта суның теге ягында иде безнеке. Хәзер анда зәрәтләребез. Бу якта авыл, уң якта. Аннан соң Андреевкага килә авылга бер карт Андрей. Ул ул вакытта

землевладелец булган, бай булган. Ул җирләрне сатыпмы алган, и безнең авыл анарга мешать иткән. Ул вакытта авыл булган Чирчим. Чирчим елгасы агып килә. Югарыда бардыгыз Исикигә, ул әйтелгән – Югары Чыршым, безнеке әтелде – Түбән Чыршым. Ул Чыршым безнеке күчә, качан авылны яндыра башлыйлар. Алар төзелә башлый суның бу ягына – хәзер кая тора безнең авыл. И шунда ул ателя Погорелый Чирчим – Янган авыл. Ул 1950 елларга тике иде. Шул исем белән йөрде.

Минем бабам 1870 елгы иде. Ул миңа сүләде: минем әтием, ди, анда торган. Бабамның атасы. А Погорелый Чирчимны алыштырдылар 1950 елларны. Татарларның шагыйре Муса Җәлил, значит Җәлил авылы дип әттеләр безнекен. Джалилово русча. Әле ул вакытта районда өч авылны алыштыралар. Октябрьский – ул иде Могилки, аннан Кузнецкийдан килгәндә Березовка – Дуңгузи ателя иде.

*Неверкино районы Җәлил авылында*
*Шабанов Хөсәен Ибраһим улыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Чирчим. Джалилово*

Әтиебез туган булган, ул безнең авылның коренной жителе Исянов Хәлилулла Абдулла олы. Йеде яшеннән ул сукыр булган. Безнең авыл булган элкеге вакытта Чирчим. Ул Чирчим ваты күрше авылда Андреевка булган. Шул Андреевканың урыслары безнең авылның мостның теге ягындагы частен яндырганнар. Берни дә калмаган, инешкә тике, янып беткән. Ярты авыл гына калган да, и аны эткәннәр Погорелый Чирчим. Кайсы елныдыр безнең авылга килә казан ягыннан берәү. Ул була Муса Җәлил белән сугышта. Безнең авылга килә инде. Ник Погорелый Чирчим инде? Аңа шулай-шулай сүләгәннәр дә. Ул, даваегыз авылыгызны Муса Җәлил исеменнән Джалилово дип язабыз. И әтәләр безнең авылыбызны Джалилово диеп. Мин беләм, бер 12–13 яшьләремдә идем. Әтекам сүли иде.

*Неверкино районы Җәлил авылында*
*Исянова Мәфруза Хәлилулла кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Октябрьское. Мазарлы*

Безнең авыл элекеге Могилка иде. Аның зәрәтләре күп булган. Зәрәтләр өстенә төзелгән халык. Зәрәтләр чувашныкы да булган монда, татарныкы да, урысныкы да, күп булган зәрәтләр. Халык килә, төзелә барган. Аннан Могилка урысча яхшы түгел, Мазарлыга әйләнде, урысча Октябрьскига әләндерделәр.

*Неверкино районы Мазарлы авылында*
*Комякова Миясса Әмин кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Рамай җыры тарихы риваяте*

Ярлы кызы белә бай егет. Хатының синең шундый дип хурлыйлар. Үтер. И ул рабочиена атя: үтерегез, хатынын, ярлы хатынын. Ул хатын бик милая булган. Рабочие белән вежливый шундый, ашата-нитә. Имеш, без сине үтермибез, ну син кит, бирегә кайтма, и үтермиләр. Китә инде еракка. Бик голосы яхшы була. «Рамай» дигән җыр чыгара.

*Неверкино районы Мазарлы авылында*
*Кагарев Аббяс Хасян улыннан (1941 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Ишан бабакай зәрәтләре*

Зимичамыдыр, ишан бабакай күмелгән. Анда баралар. Ни булса да ниятлиләр, ниятләре кабул була да, баралар. Алла Тәлә ризалыгы өчен анда чалалар корбан. Анда ишан бабакайның зәрәтләре. Зәрәтләргә баралар.

*Неверкино районы Мазарлы авылында*
*Гульмиярова Мәрьям Җиһанша кызыннан (1959 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Изгеләр өсте*

Бездән бер җиде чакрымда Изгеләр өсте әйтәләр. Җиде изге булганнар. Аларның каберләре булган урман уртасында. Хәзер инде анда урман үскән. Авылда белүчеләр бар, кая ул изгеләр. Хаҗгамы бара булганнар, Болгаргамы. Нәрсә булса, сораулары булса, изгеләр өстенә баралар.

### *Пәлдәнге*

Авылыбыз 1674 еллар тирәсендә барлыкка килгән. Аны патша тарафыннан татар морзасына бүләккә, за службу биргәннәр. И ул бу җирләргә килеп утырган. Биредә булган мордвалар. Аларны китәргә мәҗбүр иткәннәр. Алар авылны сатканнар. Символический хак булсын дип, полденьгага сатканнар. Шуның өчен Полденьга булып йөрегән. Авыл әллә ничә төр исемдә йөрегән. Мансуровка да ул булган, Түбән Бикбулат дип тә йөреткәннәр. Шуннан ук ниндидер бер рус кнәзенә күрше авылны биргән. Шуннан Русская Пенделка ул. Ул Покровка дип йөретелгән булган. Ә аннан инде ничектер полденьганы – Пенделка дип алмаштырганнар. Авылда 3 мәчет булган. Ул хәзер кечкенә Русская Пенделка, рус очы өчен чиркәү ясаганнар. Безнең авылны тыкрык кына аерган. Русская Пенделка бик зур авыл иде, хәзер 20 кеше генә. Бездә әл дә 230 кеше.

*Кузнецк районы Пәлдәнге авылында*
*Енгалычева Венера Исмәгыйль кызыннан (1938 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Нидән ул Кынады?*

Иван Грозный заманында кешеләрне анда көчләп чукындырганда, аларны кыйнаганнар, кан аккан. Канядымыдыр, Кынядымыдыр. Шундый сүздән Кынады елгасы, шул елга буенда урнашканга, безнеке Кынады. Өч авыл ул елга буенда Татар Кынадысы, Мукшы Кынадысы, Рус Кынадысы. Безнең авылда башлана ул Канадейка (Кынады) елгасы.

*Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында*
*Хәбибуллина Талия Рөстәм кызыннан (1952 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Әлмәш*

Әлмәш төзелгән вакытта өч мужик килгән.

Безгә Хаким абзи сүләде. Саратывтан килгәннәр, диеп. Хаеровлар килгән, өч брат. Землянка дигән тау бар. Шул тауга землянка ясап, 3 брат яшәгәннәр. Аннан разрешение алып, бире менгәннәр, кырчивать итеп. Мәләш күп булган. Мәләшне кисеп, авылны төзи башлаганнар. Өч мужиктан авылыбыз барлыкка килгән. Альмяшев фамилия Пүтәй бабайны. Альмяшев

Хәким абзиларныкы. Аннан инде киткәннәр дальше. Өч брат Хайров булганга, алыштырганнар фамилияләрен. Берсенең алашасы бик карт булган, берсенеке яшь булган. Агачларны кырчевать итеп ызбалар куя барганнар. 1700 еллар булган.

*Сосновоборск районы Әлмәш авылында*
*Ягудина Наилә Абдулла кызыннан (1941 елгы),*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Әлмәш*

Моннан бер-ике чакрым тау, урманнык булган. Шунда Бистәннән караклар качып килгән. 3 семья. Казыганнар землянка. И шунда торганнар. Монда инде урман була. Китә-китә авылга күчәләр. Өч семья аерыла. Мәләш була күп. И китә Әлмәш.

И шунда ватакай мәчет төзиләр. И азан кычкырырга менә. Монда бер толпа алашалар орлап китерәләр. Азанчы:

– Әссәләй, артыгыздан кугын килә, – дип кычкыра.

Монда бәк зур күл була и күлгә үзләрен, алашаларны батыралар. Зәрәтлә күле дия идек. Кипте ул.

*Сосновоборск районы Әлмәш авылында*
*Шабаева Рәйсә Адельша кызыннан (1941 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Әлмәш*

1843 елны киләләр дүрт семья Бестянкадан. Кем атя алар Хаеровлар, кем атя Альмяшевлар.

Алар дүрт брат була Хайровлар. Землянкага урнашалар. Ике ел торалар анда. Әле дә ул төшкә Землянка әйтәбез. Күп мәләш үскән ул төштә. Мәләштән квас ясыйлар. Бер братлары буян була, орыша үзләре белән. Болар семья советында решили моңардан отказаться. Мәләш Мәләшевка китә, соңрак Әлмәш – Альмяшевка. Өч брат фамилия алалар Альмяшевлар дип. Ә бу котырган кала Хайров булып. Ике елдан соң первый ызба куялар. Малайлар туа баралар, ызбалар куя баралар. Шул вакытларда бик күп малайлар туа. Кызлар юктыр. Тотыналар Сәләмәстән ташырга. Кемдер бара Сәләмәскә, бер хатын очрый, аннан китерә уникене. Төн уртасында шки-шаки хатын кирәкме сиңа.

Садыйк абыйга шкыган. Илгән анда ырулары, сеңелләре озата-озата яшь киленне. Әйдә бүген кун, иртәгә сине кемгә булса да бирермен, ди.

### *Әлмәш бабай өсте*

Сухой год була, ачлык. Котырган бабай (кушамат. – *И.Я.*) китә келәнергә. Ул үлә каадыр Пенза янында. Юсеф абзиныкы сеңле анда тора. Аны күмәләр, ул зәрәт башы анда, аны выдают как за святого. Аның кабренең холмигы утырмый, ә үсә бара. Кемнеке нинди әзере бар, атялар Әлмәш бабай өстенә хәер бирермен диеп.

*Сосновоборск районы Әлмәш авылында*
*Сидорова Разия Калим кызыннан (1961 елгы),*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## УЕННАР, АУЛАК ӨЙЛӘР

Элгәреге вакытта ызбаларда вечер уйный идек клубларда. Элекке уеннар була иде. Уйныйбыз, җырлыйбыз.

Өй артындагы талларны
Яратмасаң – кисәрсез,
Мин сагынсам, тирәз ачам,
Сез җил булып исәрсез.

Йырлыйк әле, дуслар, йырлыйк әле,
Йырлашалар дисеннәр.
Ашыйык, эчийек, уйныйык, колийек,
Бер братлар, дисеннәр.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Аитов Хасян Исхак улыннан (1939)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Уеннар: «Күпердән», «Мәрәдән», «Йөзектән», «Кругтан», «Дәңгездән», «Ашыктан», «Гузнадан».

*Неверкино районы Сарбай авылында*
*Рахманкулова Тәнзилә Шаһи кызыннан (1935 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Ясалма курчаклар иде. Пыяладан уйный идек. Базлар казый иделәр. Бер унны. Анарга пыялаңны күмеп китәсең. Иртә торасың – аны орлаганнар. Тапмаса, үзе дә кала.

«Мәчтән» уйный идек.

«Дәңгездән» уйный идек. 6 шакмак сыза идек.

«Ашыктан» уйный идек. 4 ни и 1 матка. Аны бәрәсең. Йыйыштырасың кулың белән сикертеп-сикертеп.

Вечерларда уйныйсың, биисең. «Круг»тан. Ерлыйсың:

Син дә матур үзеңә,
Мин дә матур үземә.
Йонын койган тавык кебек
Күренәсең күземә.

Аннан «Прәшкәдән»уйный иделәр. Егетләр инде прәшкәне ала да суга кызларны, аркага. Аннан ул кыз торып китә.

«Йөзек салыш»уйный идек. «Фантюк» әтә идек. Кемдә фантюк, ул чыксын.

«Мостан» уйный идек. Ул инде ерлыйсың, яхшы озын ер ерлап чыгасың астан:

Менә сиңа сул кулым,
Менә сиңа уң кулым,
Менә сиңа, якын дустым,
Менә сиңа пар кулым.

Аннан «Көймә» уены. Җырлыйбыз, биибез:

Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә,
Үзе юк.
Хаты гына килә генә,
Сөйләшергә генә, генә
Үзе юк.

«Бутылка» уены. Бутылка әйләндерә иделәр. Кемгә чыга, наказ бирәләр: йә ерларга, йә биергә.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Мусина Алия Габдрахман кызыннан (1943 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Вечер йыйа иделәр кызларны, и уйный идек, сыйлана идек. Кругтан уйный идек, кертә иделәр гармунга каршы үзебезне. Бии идек. Егетләргә бер генә бармак бирә идек, болай бирсәң, кулыңны кысалар, бер бармак кына бирәсең, ояла идек. Уйныйбыз:

Көймә генә килә генә,
Хаты гына килә генә,
Сүләшергә генә, генә
Үзе юк.

*Неверкино районы Мансур (элек Чербулат) авылында*
*Салюкова Хәлифә Илач кызыннан (1926 елгы),*
*Емлиханова Мөнирә Абдул кызыннан (1947 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Яз башы уеннар уйный идек: «Безелектән», «Куыштан», «Мостан».

Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә,
Эзе юк.
Хаты гына килә генә,
Сүзе генә килә генә,
Сөйләшергә генә, генә
Үзе юк.

«Прәшкәдән»уйныйлар иде.

«Чукадан». Утырта идек гузна. Терлекнекен ала идек гузна. Таяк белән бәрә идек. Чука китә очып, шул сүәк китә очып, аны бу барып ала, син өлгерәсең базга килергә.

«Әлчи». Куйның вак сүәкләрен ала идек, бишне ала идек. Дүртне куясың, берне күккә сикертәсең дә моны, берне аласың.

*Неверкино районы Бикбулат (Бикмосеевка) авылында*
*Асейдуллина Сания Вахит кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Уеннарыбыз бик күп иде. Әлеге яшьләр белмиләр. «Лапта»-дан да уйный идек. Мәч бәрү. Бәрәбез дә мәчне, тегеннән тота кара-каршы торган кешеләр.

«Мәрә» уены. Мәрә сыза идек. Түгәрәк мәрә була. Ике кеше баса. Түгәрәкнең уртасында сызык. Кулыбызда кечкенә генә

пәкеләр була иде. И бәрә барабыз. Кая пычагың эләгә, шуннан сызабыз. Аның җирен алырга кирәк. До конца сызып алып бетерәм. Ул минеке мәрә була. Кызлар да, малайлар да уйный.

«Качыштан»да уйный идек. Саный идек: «Эники беники ехали за веники, эники-беники хлоп». Или: «Царь-царевич, король-королевич, сапожник-портной, скажи кто ты такой?» Сиңа эткәндә, царевич эләгә, син чыгасың и качып китәсең.

«Акули» уены. Кызлар уйный идек. Шахмата ясый идек. Шакмаклар сыза идек. Алтынымы, сигезнеме. Шунда куясың бәрә торган ниеңне, и тибә барасың. Бәрә торган түгәрәк авырырак булсын. Тибеп, икенче клеткага. Линияга тимәсен. И шулай китерә барасың. Йөртеп чыксаң, син җиңүче буласың.

«Ашыктан». Сарык сөякләреннән. Биш ашык, берсе сырлаган була, буялган була. Бишесен дә очыртасың. Тоталсаң, син инде җиңәсең. Ике кул белән очыртасың, икесе белән дә тотасың. Бишесен дә тотарга кирәк. Биш ашык була. Берсе сырлаган. Шул ашыкларны күтәртеп бәрәсең өстәлгә, и эләктереп алырга кирәк. Син тотып өлгерсәң, җиңгән буласың. Ә очып китсә кая да булса, ул син еңәлмисең.

«Йөзек салу»дан уйный идек.

«Шишадан»уйныйбыз. Кругка кешеләр тезелә. Вечерда нибары түгәрәккә басасыңи, шишаны уртага куялар. Әләндереп ебәрәләр, кемгә таба ул бара (карый), шуны биетәләр, йә ерлаталар.

Артка кулын куя. Арттан кем булса да килеп суга. Артың белә торасың инде. И килеп сиңа суга ул. Кулга суга кулы белән. Син тойсаң инде ул, ул кешенең кем икәнен белергә кирәк аның.

*Неверкино районы Исәкәй авылында*
*Бахтиева Румия Ибраһим кызыннан (1962 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Вечерлар уздырган вакытта круггагы апаларыбыз ерлый иде. Уртага кемне тели, алалар да, такмак белән бииләр, йырлыйлар:

Эй бормалы, бормалы,
Бормалы су буйлары.

Бормалы су буйларында
Үскән зифа буйларым, –

шундый йырлар йырлый идек.

Круг уртасында парлы-парлылар такмак әйтә.

*Неверкино районы Җәлил авылында*
*Исянова Мәфруза Хәлилулла кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Кичен «Безелек» уйныйлар иде. Яз башы «Безелек» көн дә була чәчүгә чыкканчы. Бөтен авыл «Безелек»кә чыга.

*Неверкино районы Мазарлы авылында*
*Кагарев Аббяс Хасян улыннан (1941 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

«Мәрәдән»уйный идек олан вакытта.

«Чертадан».

Кабак өскә чыгасың, карупка ясыйсың биш төрле. Монда ике коробка, монда уртадан. Дәҗгелдән-дәңгелдән шулай уйный идек. Йөрү – дәңгелдәү. Мәрә – сызык.

«Ашыктан». Биш ашык, берсе матка. Матканы бәрәсең дә боларны аласың, матка шул дүрт ашык өстенә төшсен. Матка – ялтыравык пыяла, таш. Ашык – куй сөякләре.

«Гузнадан». Гузналарны тезәсең. Берсе шунарга ата. Кайсы ава, аны ала барасың. Кемнеке гузнасы күбрәк була. Ашыктан зурысы шул гузна була.

*Неверкино районы Мазарлы авылында*
*Комякова Миясса Әмин кызыннан (1939 елгы),*
*Кагарева Мөнирә Әмин кызыннан (1942 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

«Мәрәдән»уйный идек. Мәрә сыза идек. Питка ата идек. Питка – пыяла читеме. Авыр кирәк, очып китмәсен өчен.

Дум сыза идек. Өчәр шакмак ике якка. Бәрәбез дә аяк белән, бер аяк белән, шул шакмакларны чыгарга. Яхшы гына. Чтобы мәрәгә кермә. Сызыгына керденме, все син чыгасың уеннан. Икенче китә, шул питканы бәрә дә. Шул ярыкларга тигезмә син. Тигезденме, уеннан чыгасың.

*Кузнецк районы Дәхтәрни авылында*
*Мусякаева Рәисә Шакир кызыннан (1945 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## ӘКИЯТЛӘР

### *Кулсыз кыз*

Бер кыз атасы-анасы үлгән дә инде, ике абые аныкы бар. Әле болар үләнгәннәр. Абзилары бу кызны багалар, карилар. И бу хатыннар көнли моны. Тукта, ничек тә булса абыйларыннан аерабыз бу кызны. Бик күп зыян эшлиләр. Вата сеңелегез эшләде, сеңелегез эшләде. Алашаларның, сыерларның бунҗнарын чабалар. И атя: вата сеңлегез шулай эшләде. И бу кызның абзилары ике кулын да чабалар да, и ике кулсыз шул кызны сөреп җибәрәләр. Әле бара, ашагысы кели, куллары юк. Очрый патша сараена. И анда садга керә. Алмалар анда бик күп. Кулы юк, алалмый. Сузылып каба да бер алманы, яртысын аши, калганы кача авызыннан, аши алмый. И шулай йөрегәндә, патшаның малае чыга. Бу кыз бик күртле булган, оста булган, матур кыз инде. И бу егет үләнә, кызның ике кулы да юк. Бу йөккә уза. Бу егет – патша улы сугышка китә, патша үзе карт була. Сугышка китә и бу хатынның малай тыва. Илчеләр абзиларының йортына кунарга керәләр. Вот алар сүли. Мин барам илче булып, патшабызның олы бар. Вроде мин барам сөенче айтырга патшага. Бу малай йоклаганда хатны алалар да язалар:

Хатының туды мында,
Ни малай, ни кыз шунда.
Ни бака, ни тәкәрлек,
Әллә нинди бер җәнлек.

Шулай язалар да җибәрәләр патшага. Әле теге ала хатны, уки и атя иде: ни булса да, ми баргынчы кузгамагыз. Хоть нәрсә генә булсын, баланы яхшы карагыз. Ну тегенәрдән сорыйлар, әле кайтканда да безгә керген. И тагын ул керә аларга, и хатны тагы алыштыралар. Бер минутта тотмагыз, кывыгыз үзен. Шулай алыштыралар да инде хатны тагын. Әле моны жәллиләр. Барыбер кывып ебәрәләр, патша кушкан янәсе. Әле бу киләдер су янына, эчкеси кели, кулы юк, буньына таккан оланы. Эчкесе кели. И бөгелә су эчәргә, оланы суга төшә и бу тотына утырып еларга. Әй, Ходаем, әй, Ходаем... Алланың әмере, куллары үсә шунда. Бала хакына куллары үсә. И ала

инде баланы. И китә инде. Шул абзиларына бара. Туган эвенә китә. Әле керә аларга. Болар багыгыз ничек сеңлебезгә охшаган, но бу куллы, баласы бар. Әле, имеш, кунарга ебәрәбез. Как раз патша кайта сугыштан. Алар алгы ызбада аши-эчә, бу пич башында баласы белән утыра. И баласы сүли торган бала инде. Үскән әле. Имеш, әни, миңа экият сүлә. Улым, минем үз күргәнем дә экият. Үзенең нәрсә узганын весь экияткә сүли баласына. Патша тыңный да бу хәлне, сикереп менә пич башына. Хатынын төшерә тиз генә, оланны ала, и бу абзилар хатыннарын өрәнмәс тай күрыгына бәләп ебәрәләр.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Айзатуллина Һава Исхак кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Алдавыч экият*

Булган бер бай.
Сарай салган таштан.
Иң азак:
Сүлимме баштан?

*Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында*
*Курмаева Хатимә Хусяин кызыннан (1930 елгы),*
*Мендаева Халидә Хусяин кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## БӘЕТЛӘР

### *Рафыйк бәете*

Үдән чыгып мин китәмен,
Олы юлларга салынып.
Миннән калган балаларым
Көтәдер мине сагынып.

Башларымда бик зур яра,
Балаларым ятим кала.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәл,
Нуриям да ялгыз кала.

Үдин чыгып киткән чакта
Карамадым мин көзгегә.
Һич тә инде уйламадым
Үлем килер минем кичкә.

Балаларым, йөрәкләрем,
Мин бер дә туймадым сездән.
Ышанамын, балаларым,
Әтиегезне онытмассыз.

*(Галиев Рафыйк Каюм улы, 1957 елгы иде братым.)*

Каршыбызда җума мәчет,
Картлар җыела җумага.
Ни бәхетсез бала булдым
Яшьли ятам җеназага.

Үдин чыгып мин китәмен,
Больничада җан бирәмен.
Ходай булсын юлдашым.

Егылды автобустан төшеп. И анда катыннарга телефон номерын өлгерде биреп. Алар скорый чакыртып, больничага. Давление күтәрелгәнен тоя, уздыралмады.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Абдульмянова Фәридә Каюм кызыннан (1949 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Суга баткан Гайшә

Чәршәмбе көн кер юарга
Ник җибәрдең , әңкәем?
Барма, Гайшә, дигән булсаң,
Бармас идем, әңкәем.

Баткан чакта итәкләрем
Батадыр да калкадыр,
Муендагы тәңкәләрем
Су төбенә тартадыр.

Кулымдагы көмеш йөзек
Көнгә каршы эридер.
Тал чыбыктан зифа буем
Су төбендә черидер.

Аучы мылтык атадыр,
Төтене җиргә ятадыр.
Матур Гайшә баткан дигәч,
Туе җылап кайтадыр.

Өстемдәге камзулымны
Элеп куйдым казыкка.
Зифа буем үскән икән
Балыкларга азыкка.

Чәршәмбе көн мунча яктым,
Битем-күзем юарга,
Чәршәмбе көн кер чайкадым,
Газиз башым җуарга.

*Неверкино районы Мазарлы авылында*
*Комякова Миясса Әмин кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Усман бәете

Винек алып киттем мин пулга,
Ике буй кыз килеп асылды буньга.
Пычак алып берсе сызды буньыма,
Каным акты мунча идәне буена.

Мунча идәнен кырып-себереп юдылар,
Пул астына ләхет казып куйдылар.
Пул астында мин исләнә башладым,
Аннан алып, агым суга ташланды.

Агым суда акмас усман сөлге,
Бритника эләккән уң беләгем,
Уң кулымда алтын йөзегем иде,
Мин үлгәндә самый көзге көн иде.

Әй мәрхаба, шәкәр-чәемне эчтем,
Жар мунчага газиз җанымны кичтең.
Әй, мәрхаба, кеше чалып котылдың,
Кулаткыда суган урлап тотылдың.

*(Усман сәүдәгәр булган.)*

## *Давыдов Якуп бәете*

Каршыбызда карамада
Кара карга карылдыйдыр.
Вәләк белән башка суккач,
Кара каным шарылдыйдыр.

Башка сугып үлмәгәчтен,
Мине буып үтерделәр.
Шуннан соң минем гәүдәмне
Салкын коега бәрделәр.

Мине коедан алдылар,
Ак пулыкка чормадылар.
Больницаның өстәлендә
Сөягемне турадылар.

Болыннарда печән чаптым,
Кибәннәргә өялмәдем.
Өйдән чыгып киткән чакта
Бәхил булыгыз, диялмәдем.

Бакчадагы җимешләрне
Өлгермичә ашамагыз.
Әти-әни сораламын,
Догагыздан ташламагыз.

Яз башы карлар эрегәч,
Елгаларда бозлар агар.
Хатыным үзенә бала табар,
Ике баламны кем багар.

Каршыдагы алмагачка
Су салыгыз, корытмагыз.
Туганнарым, мин соралам:
Ике баламны онытмагыз.

Кантурлардан кереп алдым
Алга буяган акча.
Әҗәлсез бит үләм инде
Сираҗ агай буенча.

Безнең авылныкы бер бабай утыра булган Кузнецкий артында. Минем дәдәм, этиемнең браты, бригадир булып эшли булган Сөземдә. Бер хатын аннан Сираҗ агасын үзенә алырга сораган. Дәдәм кантурдан акча алган рабочийга. Аны инде, шул акчаны кешедән җибәргән. Бандитлар белгәннәр, акча үзендә диеп, и вроде атькан: барам Сираҗ агай артыннан инде. Адя бездә кун, иртәгә барырсың. Мында инде дәдәмне үтергәннәр, и күршесе багып трмаган моны. Шул башка сук-

кач, тез өстендә йөргән. Буганнар аннан үзенең майкасы белән. Акча юк, итеп коега салганнар. И аннан пастухлар тапкан иде үзен.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Айзатуллина Һава Исхак кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Алданган кыз*

Кайдадыр шунда, гөл бакчасында
Яшь кыз булып йөри идем мин.
Дус кызлар белән, җинавлап бергә,
Әл дә дөнья белми идем мин.

Килде бер егет, тотты кулымнан,
Әйдә, диде, бергә күңелле.
Алып килеп бер җиргә,
Дусларымнан аерып мине.

Диде син матур, яратам сине,
Тыңла әйткән минем сүземне.
Кызганам сине, ялгызлыгыңны,
Диеп суырып үпте.

Егет бик чибәр, килде күңелгә,
Кызындырды мин кыз баланы.
Утырдык бергә, караңгы җиргә,
Шунда өзде ике араны.

Көннәрдән беркөн күрдем җегетне,
Иптәш, сиңа ни булды?
Йөкле калдырып мин кыз баланы өйдә,
Безгә бер бала булды.

Диде: җүләр кыз, сөйләмә юкны,
Мыскыл итмә мин яшь егетне.
Сине күрмәдем, бергә йөрмәдем,
Эзлә хәзер үзең кебекне.

Эй җүләр җегет, белмисеңмени?
Озакламый судка барырсың.
Бала синеке, син туйдырырсың,
Айга йөз сум түләп барырсың.

## *Фатыйма бәете*

Бу бәетне башлаганда
Бисмилласыз башламагыз.
Айша мескин вафат булды,
Девагыздан ташламагыз.

Тарих мең дә сигез елда,
Егерме ел эчендә.
Үз-үземә әҗәл таптым
Фатыйма апам өчен дә.

Кара шәл иде башымда,
Кан яшь иде һәр ашымда.
Солдат кебек служить иттем
Фатыйма апа каршында.

Кара-каршы куш гуринча,
Йөремәдем мин буенча.
Үз-үземә әҗәл таптым
Фатыйма апам буенча.

Әни маем, васиятем –
Көзгеләрне ваттырма.
Йезни абзый, васиятем –
Сөягемне тураттырма.

Йезни абый, васиятем –
Пристиныннан чыкмасын.
Фатыйма судга барганда
Йезни абый борчылмасын.

Миннән калган кара сачны,
Фатыйма, син үрерсең.
Миңа күрсәткән күремне
Балаларыңнан күрерсең.

Кичтә ятып, бер төш күрдем:
Елан капты беләгемне.
Бер стакан су бирегез,
Агу катты йөрәгемне.

Кичә яттым, бер төш күрдем:
Күк күгәрчен оя ясый.
Бер стакан су бирегез,
Агу йөрәгемне ашый.

*Лопатино районы Иске Карлыган авылындагы*
*мәктәп музее бүлмәсендә Мәһдиева Рәисә Исхак кызы*
*(1939–2013) тапшырган кулъязма дәфтәрдән*
*И. Ямалтдинов күчереп алды*

## *Хахул туе – зур туйдыр*

Хахул туе – ни зур туйдыр,
Ике арган, бер гармуньне.
Миңа никях укыганда
Ике дьяк, юк бер мулла.

Хахул туе килә дигәч,
Сикереп төштем такта астына.
Әти кәбәм, иңәләдер,
Оятлы итмә халык каршында.

Хахул биргән йон күлмәкне,
Әни кәбәм, киярсеңме?
Әни кәбәм, киярсеңме?
Кызың – кәфер, беләсеңме.

Әтикайның алма сады,
Алмалары кызарадыр.
Хахул егет мактанадыр
Мөселмандин кыз аладыр.

Бергә укыган тудыкайларым
Сахрадан йөреп киләләр.
Сау булыгыз, ыру-кардәш,
Мине хахулга бирәләр.

Әтикайның самавыры,
Салфетка япкан өстенә.
Әтине муллалар карги,
Минут та ни чәке (күп) өстенә.

Әти мине бигрәк севә,
Сиксән сумга ковёр ала.
Һичбернәрсәм жәл калмидыр,
Ислям дин генәм җәл кала.

Әти мине бигрәк сәвә,
Утыз сумга бер шәл ала.
Һичбернәрсәм жәл калмидыр,
Утыз шәкертем жәл кала.

*Шемышейка районы Оз авылында*
*Ногаева Рәшидә Йосып кызыннан (1943 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## МӨНӘҖӘТЛӘР

### *Лә иләһә иллә Аллаһы*

Лә илаһә иллаллаһы –
Алла гомер бер лә ул.
Лә илаһә иллаллаһы –
Рәсүлебезгә җавап ул.

Лә илаһә иллаллаһы –
Сүзләремнең иң изгесе.
Лә илаһә иллаллаһы –
Мөселманлык билгесе.

Лә илаһә иллаллаһы –
Ялгызларга сердәш ул.
Лә илаһә иллаллаһы –
Каберләрдә юлдаш ул.

Лә илаһә иллаллаһны
Әйтер идем һәрдаим.
Лә илаһә иллаллаһтан
Аермасын Ходаем.

Лә илаһә иллаллаһны
Әйткән – җәннәт хуры ул.
Лә илаһә иллаллаһы –
Каберебезнең нуры ул.

Лә илаһә иллаллаһны
Телдән куймыйм бер заман.
Лә илаһә иллаллаһтан
Аерылган кол яман.

Лә илаһә иллаллаһы
Җирдә ризык сеңдерер.
Лә илаһә иллаллаһы
Күктә урын бирдерер.

Лә илаһә иллаллаһы –
Сүзләрнең иң кирәге.
Лә илаһә иллаллаһы –
Динебезнең терәге.

Лә илаһә иллаллаһы –
Телебезгә җиңел ул.
Лә илаһә иллаллаһы –
Мизаннарда авыр ул.

Лә илаһә иллаллаһы –
Йөзебезнең нуры ул.
Лә илаһә иллаллаһы –
Оҗмахларның нуры ул.

Лә иләһә иллаллаһны
Әйтер иманлы бәндә.
Лә иләһә иллаллаһы –
Тәмуг утына пәрдә.

Лә иләһә иллаллаһы –
Мөселманлык билгесе.
Лә иләһә иллаллаһы –
Гамәлнең иң изгесе.

Лә иләһә иллаллаһы –
Җирдә ризыктыр миңа.
Лә иләһә иллаллаһы,
Нурлы иман бир миңа.

Лә иләһә иллаллаһны
Әйтейек бергә-бергә.
Лә иләһә иллаллаһы
Юлдаш булсын кабердә.

Лә иләһә иллаллаһы –
Рәсүлебез хөрмәтенә.
Лә иләһә иллаллаһы –
Мөхәммәд өммәтенә.

Лә иләһә иллаллаһы –
Арши көрши баскычы.
Лә иләһә иллаллаһы –
Сигез оҗмах ачкычы.

Лә иләһә иллаллаһы –
Газыймүл хәким.
Лә иләһә иллаллаһы –
Раббул вәсил газыйм.

Лә иләһә иллаллаһы –
Раббу сәмәвәти вәррух.
Лә иләһә иллаллаһы –
Раббул гардзи,
Раббул гаршил,
Раббул Кәрим.
Амин, амин, амин.

Рәхмәт мөнәҗәте
Өстәлләрдә төрле нигъмәт,
Төрлесендә төрле ләззәт.
Безне хөрмәт иткән өчен,
Ходай бирсен сезгә җәннәт.

Шушы йортның хуҗасына,
Дәһи ата-анасына.
Дәһи балаларына,
Рәхимең сал, Рәсүлулла.

Дога кылыек бу хуҗага,
Ике җиһанда шат булсын.
Кереп җәннәт сараена,
Җәһәннәмдин азат булсын.

Мәҗлесне тәмам итеп,
Ни бүләкләр бирием сезгә?
Ходай биргән бүләгем бар,
Хәер-дога кылам сезгә!

Мәҗлесләр тәмам булсын!
Бер Ходаем разый булсын!
Фәрештәләр «амин» дигән
Сәгатьләргә туры килсен!

*Неверкино районы Сарбай авылында*
*Рахманкулова Тәнзилә Шаһи кызыннан (1935 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*




Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре
Пенза өлкәсендә. 2019 ел



Экспедиция әгъзалары Неверкино районы Али авылында җирле үзидарә җитәкчеләре
белән. 2019 ел




Экспедиция төркеме Неверкино районы Җәлил авылында. 2019 ел



Неверкино районы Али авылы күренеше. 2019 ел



Музыка белгече Э.М. Галимова
Неверкино районы Исәкәй авылында
Хасьянова Майзия Мөхәмммәтҗан кызы белән
әңгәмә вакытында. 2019 ел



Сәнгать белгече Л.М. Шкляева
Неверкино районы Октябрьское авылында
Дәүләткилдеева Халидә белән. 2019 ел



Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре
Неверкино районы Октябрьское авылында. 2019 ел



Институт галимнәре Э.М. Галимова, И.И. Ямалтдинов Сосновоборск районы Әлмәш авылында информантлар белән әңгәмә вакытында. 2019 ел



Фәнни экспедициядә катнашучы галимнәр (А. Әхмәтова, М.Р. Булатова, И.И. Ямалтдинов, Э.М. Галимова) Сосновоборск районы Әлмәш авылы халкы белән. 2019 ел



Сосновоборск районы Әлмәш авылында информантлар белән очрашу. 2019 ел



Тел белгече М.Р. Булатова Кузнецк районы Дәхтәрни авылы хатын-кызлары белән әңгәмә вакытында. 2019 ел



Экспедиция төркеме Кузнецк районы Бистән авылында информант Бикмурзина Нажия Исмәгыйль кызы яшәгән йортның капка төбендә. 2019 ел



Фольклорчы галим И.И. Ямалтдинов Кузнецк районы Бистән авылында милләттәшләребез арасында. 2019 ел



Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре
Кузнецк районы Ялгаш авылында. 2019 ел



Экспедиция әгъзалары Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында
Янгазовларда кунакта. 2019 ел



Институт галимнәре Городище районы Югары Әләзән авылы клубында информантлар белән очраша. 2021 ел




Экспедиция төркеме Белинский районы Кутеевка авылы халкы арасында. 2022 ел

Пенза татарлары
бик кунакчыл
халык





Эпиграфика белгече
В.М. Усманов мәгълүмат
туплый

Сәнгать белгече
А.Ф. Борһанова информант
белән





Спасск районы халык иҗаты музее директоры Елена Бормашова Казан галимнәрен музей белән таныштыра. 2022 ел




Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ галимнәре Белинский районы Кутеевка (Качкару) авылы янында. 2022 ел






Городище районы Түбән Әләзән авылында татар йортларының тышкы күренеше





Городище районы Түбән Әләзән авылында татар йортларының тышкы күренеше





Городище районы Түбән Әләзән авылында татар йортларының тышкы күренеше





Городище районы Урта Әләзән авылында татар йортларының тышкы күренеше





Городище районы Урта Әләзән авылында бай итеп бизәкләп эшләнгән татар йорты һәм капка төбе





Городище районы Урта Әләзән авылында татар йортларының тышкы күренеше



Татар хатын-кызлары бизәнү әйберләре. И.Н. Ульянов исемендәге музей. Пенза шәһәре



Татар хатын-кызларының баш киеме фрагменты. И.Н. Ульянов исемендәге музей. Пенза шәһәре



Күкрәкчә. Укалап чигү.
И.Н. Ульянов исемендәге музей.
Пенза шәһәре





Чигүле күкрәкчәләр. Городище районы Түбән Әлэзән авылы Мәдәният йорты музее



Тоташ чигү үрнәге. Городище районы Түбән Әлэзән авылы Мәдәният йорты музее



Тоташ чигү үрнәге. Ярullina Нурия Юныс кызы (1929 елгы) эше. Кузнецк районы Дәхтәрни авылы



Чигүле мендәр. Тапкырлап чигү. Рауза Фәттах кызы (1939 елгы) эше. Кузнецк районы Татар Кынадысы авылы



Декоратив салфетка. Фрагмент. Тапкырлап чигү. Неверкино районы Кырнавар авылы



Сөлге. Фрагмент. Тапкырлап чигү. Хамәтова Румия Заһри кызы (1950 елгы) эше. Неверкино районы Кырнавар авылы



Чигү үрнәге.
Мөхәмmәтҗанова Румия
Җәгъфәр кызы эше.
Неверкино районы
Кырнавар авылы



Сөлге. Тоташ чигү.
Шәвәлиева Сайраха
Шиһап кызы эше.
Неверкино районы
Али авылы



Декоратив салфетка.
Тоташ чигү.
Шәвәлиева Сайраха
Шиһап кызы эше.
Неверкино районы
Али авылы





Кулъяулыклар. Тоташ һәм сабаксыман чигү.
Аббасова Фатыйма (1924 елгы) эше.
Кузнецк районы Бистән авылы





Сөлге. Бизәкләп туку.
Каменка районы Кикин
авылындагы мәктәп музее.
Сосновоборск районы
Индерка авылы



Тастымал. Бизәкләп туку һәм тамбурлы чигү үрнәге.
Неверкино районы Октябрьское авылындагы
мәктәп музее



Сөлге. Тамбурлы чигү үрнәге.
Авторы билгесез. Кузнецк районы
Бистән авылындагы мәктәп музее



Сөлге. Тамбурлы чигү үрнәге.
Яхина Фаилә (1927 елгы) эше.
Кузнецк районы Бистән авылы



Сөлге. Тамбурлы чигү. Кузнецк районы
Ялгаш авылындагы мәктәп музее



Сөлге. Тамбурлы чигү. Әмирова (Мәҗитова)
Зәйтүнә Зәйдулла кызы (1942 елгы) эше.
Кузнецк районы Ялгаш авылындагы
мәктәп музее





Сөлгеләр. Тоташ һәм сабаксыман чигү. Сәйфуллина Сәйдә Абуталип кызы (1935 елгы) эше. Сосновоборск районы Әлмәш авылы



Сөлге. Тамбурлы чигү.
Неверкино районы Дөмавыл авылы



Сөлге. Тоташ чигү.
Бибисарова Әдилә Абдулла кызы (1938 елгы) эше.
Неверкино районы
Исәкәй авылы





Күкрәкчә. Укалап чигү.
М.И. Бикбаева эше.
Неверкино районы
Октябрьское авылы




Күкрәкчәләр. Укалап чигү.
Неверкино районы Октябрьское авылындагы мәктәп музее



Күкрәкчә. Укалап чигү.
Сәйфуллина Сәйдә
Абуталип кызы (1935 елгы)
эше.
Сосновоборск районы
Әлмәш авылы




Күкрәкчә. Фрагментлар. Укалап чигү.
Мәктәп музее. Кузнецк районы Ялгаш авылы



Намазлык. Тоташ чигү.
Әмирова Зәйтүнә эше.
Кузнецк районы Ялгаш авылы



Намазлык. Сабаксыман чигү.
Кузнецк районы Ялгаш авылындагы
мәктәп музее



Намазлык. Сабаксыман чигү.
Даутова Нәзирә Фәхретдин кызы (1914 елгы)
эше. Кузнецк районы Дәхтәрни авылы



Намазлык. Сабаксыман чигү.
Фейзикова Дания Умәр кызы (1970 елгы) эше.
Неверкино районы Җәлил авылы




Караваt челтәре. Бибисарова Әдилә Абдулла кызы (1938 елгы) эше.
Неверкино районы Исәкәй авылы



Декоратив салфетка. Челтәр.
Н.М. Кичуткина эше.
Неверкино районы Исәкәй авылы



Караваt челтәре. А. Рәхимова эше.
Неверкино районы Мансур авылы



Чигү остасы Бикмурзина Нәҗимә.
Кузнецк районы Бистән авылы. 2019 ел



Декоратив салфетка. Челтәр.
Әмирова эше.
Кузнецк районы Большой Труёв авылы



Караватчелтәре.
Неверкино районы Кырнавар авылы



Ашъяулык. Фрагмент. Челтәр.
Акчурина Рокыя Даут кызы (1941 елгы) эше.
Неверкино районы Кырнавар авылы



Караватчелтәре.
Неверкино районы Кырнавар авылы



Караватчелтәре.
Шәвәлиева Сайраха Шиһап кызы эше.
Неверкино районы Али авылы



Челтәр ашъяулык.
Шәвәлиева Сайраха Шиһап кызы эше.
Неверкино районы Алеево авылы



Челтәр шәл. Зәбирова Шәфика Кәлимулла кызы (1938 елгы) эше.
Сосновоборск районы Әлмәш авылы



Алъяпкыч. Тоташ һәм сабаксыман чигү.
Н. Бикмурзинада саклана.
Кузнецк районы Бистән авылы



Сырган камзул. Рәхимова Маһруй Хөсәен
кызы (1907 елгы) эше.
Неверкино районы Мансур авылы



Алъяпкыч. Тоташ һәм сабаксыман чигү.
Кузнецк районы Ялгаш авылындагы
мәктәп музее



Хатын-кыз күлмәге.
Кузнецк районы Бистән авылындагы
мәктәп музее



Татар милли хатын-кыз киеме.
Неверкино авылындагы клуб музее



Сырган камзул. Р. Еникеева эше.
Кузнецк районы Пәлдәнге авылы



Камзул.
Сосновоборск
районы
Индерка авылындагы
мәктәп музее.



Бәрхет камзул.
Мянзелина
Мәрхуб эше.
1912 елда тегелгән.
Неверкино районы
Али авылы



Ирләр ыштаны. Сосновоборск районы
Индерка авылындагы мәктәп музее



Калфак. Укалап чигү.
Әбүбәкерова Мөршидә
Али кызы (1906 елгы) эше.
Неверкино районы
Октябрьское авылы



Идән җәймәсе (Р.Я. Айнетдинова эше)
һәм чабата. Сосновоборск районы Индерка
авылындагы мәктәп музее



Калфак. Сәйлән белән чигү.
Сосновоборск районы
Индерка авылындагы
мәктәп музее



Түбәтәй. Тамбурлы чигү.
Кузнецк районы
Татар Кынадысы авылы



Татар йортының эчке күренеше. Кузнецк районы Татар Кынадысы авылы мәктәп музее



Н.Ю. Яруллина йорты. Кузнецк районы Дәхтәрни авылы



Чигүле мендәр тышлары. Сатаева Равилә Исхак кызы (1948 елгы) эше. Неверкино районы Биги авылы



Чигүле карават җәймәсе һәм мендәр тышлыгы. Альбекова Халисә Насыйбулла кызы (1961 елгы) эше. Сосновоборск районы Маркино авылы

## *Рамазан ае мөнәҗәте*
## *Мәрхабә*

Рәҗәп, Шабан ае узгач,
Килде маһи Рамазан.
Рәсүлулла хөрмәтенә,
Килде шәһри Рамазан.

Мәрхабә, йә мәрхабә,
Шәһри Рамазан, шәһри нур,
Лә илаһә иллаллаһы,
Лә илаһә иллаллаһы.

Маһи шәриф килгәчтин
Җиргә күккә нур чәчәр,
Рузя тоткан бәндәләргә
Җәннәт ишеген ачар.

Рузя тоткан бәндәләрнең
Күңелләре шат булыр.
Маһи шәриф хөрмәтенә
Калебләре пакь булыр.

Сәхәр торган бәндәләр,
Алар өлеш алырлар.
Маһи шәһри белән бергә
Хак каршына барырлар.

Маһи шәриф рузясы
Гөнаһларны көйдерер.
Маһи шәриф хөрмәтенә
Тәмуг утын сүндерер.

Май – һәр айдан хөрмәтле,
Барчабыз хөрмәтләнсен.
Хөрмәтләнгән бәндәләрне
Шаһиәт кыл, Рәсүлулла.

Әлхәмделилләһи шөкер,
Килеп җиттек бу айга.
Кемчә булыр, кемчә булмас
Киләсе шәриф айда.

Кабул кылгыл догабызны,
Кабул кыл рузябызны.
Маһи шәриф хөрмәтенә
Ярлыка барчабызны.

*(Әбиләрдән өйрәнгән мөнәҗәтләр.)*

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Мусина Алия Габдрахман кызыннан (1943 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Мәҗлес мөнәҗәте*

Рәхмәт булсын, хөрмәтләдегез
Дөнья нәүмәтләре белән.
Алла сезне хөрмәтләсен
Оҗмах нәүмәтләре белән.

Котлы булсын бу мәҗлесләр,
Бу өй нурлар белән тулсын,
Мәҗлес корган бәндәләргә
Сигез җәннәт насип булсын.

Безнең теләгән теләкләр
Барчабызга да ирешсен.
Без теләгән теләкләргә
Фирештәләр «амин» дисен.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Акчурина Сәгыйдә Мөбәй кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

* * *

Укы дисәгез, укыйм,
Ихляс белән тыңласагыз.
Гөнаһлардан тәүбә кылып,
Гибада кыйлыр булсагыз.

Терек булган вакытыңда
Күрешкән саен бәхилләш.
Терек чакта садакаңны
Үз кулларың белән өләш.

Әгәр Коран укыр булсаң,
Тыңнап торсын калганнарың.
Агач яфрак койган кебек
Коелырлар гөнаһларың.

Әгәр Коран укыр булсаң,
Ишетелсен барчагызга.
Коран белән әмәл кылсаң,
Әҗере булыр барчагызга.

Соңгы сәфәргә чыгабыз,
Тотыек Рәсүл сөннәтләрен.
Кыямәт көне булганда
Ят итәр ул өммәтләрен.

Безнең теләгән теләкләр
Барчабызга да ирешсен.
Без теләгән теләкләргә
Фәрештәләр «амин» дисен.

Кыямәт көн шундый көн ул –
Һичкемсәдән файда булмас.
Хасян белән Хөсәенне
Кылгыл, Раббым, безгә юлдаш.

Кыямәт көне булганда
Бөтен азам тетрәп елар,
Шулвакытта Рәсүлебез
Өммәтем, диеп сорар.

Рәсүлулла сорар безне,
Өммәтемне ярлыка, дип,
Асый булган өммәтемне
Тәмугыңда калдырма, дип.

Йә, Рәсүлуллаһ, диер Аллаһ,
Өммәтеңне ярлыкадым.
Йә Хәбирнең синең хакта
Җәннәтемне багышладым.

Рәсүлулла үзе әйтте
Соңгы сүзен Фатыймага.
Мөэминнәргә кыямәт көн
Син булырсың җан ата.

*Неверкино районы Биги авылында*
*Юнусова Фәридә Абдулла кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Юсеф аләйһиссәләм мөнәҗәте*

Юсеф нәби гүзәл егет булган,
Ходай пигамбәрлек биргән.
Мысырда падиша булган,
Ул да кичкән бу дөньядан.

Аның олы агалары
Алып китеп, коега салды.
Малиг ягур коедан алып,
Аягына богав салды.

Богавланып юлда барган чакта
Анасының кабрен күргән.
Шунда төшеп, Юсеф нәби
Аңсыз калган, бик елаган.

Анасының кабрен төшеп
кочаклаган:
«Я анам, халем мөҗгәл,
Минем халем сиңа мәлүм,
Авырлыгын шуннан белгел.

Кабер өстендә елаганда
Бер кара кол килеп җиткән.
Качкын, диеп, ачуланып,
Камчы белән тәнен ярган.

Ярасыннан каннар аккан,
Күзләреннән яшьләр тамган.
Бер музизя күрсәт, диеп,
Бер Аллага зари кылган.

Яшен яшьнәп, күк күкерәп,
Җилләр искән, яңгыр явган.
Кәрван халкы һәрбересе
Җаннарыннан өмет өзгән.

Малиг ягур йөгреп килеп,
Бу эшне ул сизгән.
Алган гөнаһ бездән булды, диеп,
Юсефне ул кочеп алган.

Богавларын тишендергән,
Якшы киемнәр кигезгән.
Тугай атларга менгезгән,
Мысырга да алып киткән.

Мысырга ул бару белән,
Зеләйха аны сатып алган.
Шулай итеп, Юсеф нәби
Мысырда кол булып калган.

Әя йогач, башың биек,
Нидән яфракларың сыек?
Синеңдәме хасрәтең зур,
Минем көбөк көңөлең сынык?

Әя йогач, яшең ничә,
Яфрагыңны кемнәр кисә?
Киблалардан җилләр исә,
Күрмәдеңме Юсефемне?

Иляһи хәсрәтем авыр,
Ничек итием мин сабыр.
Яна йөрәгем, яна багрым
Бер Ходаем бирсен сабыр.

Әя кояш, күзең күрә,
Минем балам кайда тора?
Кайда үмерләрен сөрә?
Елап сорыймын Алладин.

Әй, Ходаем, кылам сабыр,
Кызыл йөзем булды сары.
Салма гына тамугыңа
Иляһи сыенамын сиңа.

Расульга өммәт булырбыз.
Кәвсәр шәрапларын эчсәк,
Безгә шатлык шунда булыр,
Сират күперләрен кичсәк.

Сират күперенең өстендә
Чалган корбаннарның эзе.
Безне мизянга ишүче –
Хазрәти Фатыйма үзе.

Салаватлар әйтик әле,
Рәсүлуллага ирешкинче.
Мәеткә бик авыр, диләр,
Каберенә иләшкинче.

Азраиль җанымны алыр,
Тәнем тәхаирдә калыр.
Мәнкир-Нәнкир сөаль алыр
Нинди авыр көннәрем бар.

## ***Бәхетле кыл, Тәалалла***

Мием бер мәксудым бардыр,
Раббым, үзеңә мәлүмдер.
Дидарыңны насип әйлә,
Бәхетле кыл, Тәалалла.

Икенче мәксудым шулдыр:
Пигамбәрем – Мөхәммәддер.
Шәрәгатен насип әйлә,
Бәхетле кыл, Тәалалла.

Өченче мәксудым шулдыр:
Бохара юлына күндер.
Мәдинә шәһәренә индер,
Бәхетле кыл, Тәалалла.

Дүртенче мәксудым шулдыр:
Кыямәт көн – каты көнде
Чаһарь ярьләрне юлдаш кыл,
Бәхетле кыл, Тәалалла.

Бишенче мәксудым шулдыр:
Биш вакытның савапларын,
Шәфәгатен насип әйлә,
Шәфиять кыл, Рәсүлулла.

Алтынчы мәксудым шулдыр:
Ата-анамны ярлыка.
Мөхәммәд өммәтләренең
Гөнаһларын афу әйлә.

Йеденче мәксудым шулдыр:
Тамугындин азат әйлә.
Сигез җәннәт сараенда
Бәхетле кыл, Тәалалла.

Сигезенче мәксудым шулдыр:
Сират күперен еңел кичер,
Кәвсәр шарабларын эчер,
Шәфиять кыл, Рәсүлулла.

Тугызынчы мәксудым шулдыр:
Ахирәт анабыз – Фатыйма.
Мизян җиренә барганда
Шәфиятен насип әйлә.

Унынчы мәксудым шулдыр:
Хасян илә Хөсәендер.
Киямәт көн шәфиятен
Насип әйлә, Тәалалла.

*Неверкино районы Бикбулат (Бикмосеевка) авылында*
*Асейдуллина Сания Вахит кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Рамазан ае мөнәҗәте*
### *«Мәрхабә»*

Хак Тәгалә рәхмәт итеп,
Шәһри Рамазан күндерди,
Шәфкать итеп колларына
Рәхмәт аен иңдерди.
Сөекле дустын, хак хәбибен
Мөхәммәдне күндерди
Мәрхабә йа, мәрхабә йа,
Шәһри рамазан, шәһри нур.
Коръән инде ошбу айда,
Аят-аят бәинят,
Хасанәтән тәвдил улып,
Төрле-төрле сәиат.
Алышырлар җөмлә маляк,
Дәһи араһ тәибәт.
Мәрхабә йа, мәрхабә йа
Шәһри рамазан, шәһри нур.
Савса улып, мәләикләр
Җир йөзенә иңәрләр.
Нурдан торып әлләренә
Мөэминнәргә сорарлар.
Кичәләрдә сабак улынча,
Тәсбих итеп торурлар.
Мәрхабә йа, мәрхабә йа,
Шәһри рамазан, шәһри нур.
Җәһәннәмнең капулары
Бу көн мәкам торурлар.
Шайтаннарның әлләренә
Йөз мең җенҗер тагарлар...
*(дәвамы бар)*

*Неверкино районы Исәкәй авылында*
*Бахтиева Румия Ибраһим кызыннан (1962 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Раббым Алла, диде Муся*

Раббым Алла, диде Муся,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Атаң-анаң риза булса.

Раббым Алла, диде Муся,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Кыз кардәшең риза булса.

Раббым Алла, диде Муся,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Күршеләрең риза булса.

Раббым Алла, диде Муся,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Тоткан рузяларың булса.

Раббым Алла, диде Муся,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Чалган корбан кабул булса.

Раббым Алла, диде Муся,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Кылган хаҗларың кабул булса.

*Неверкино районы Дөмавылда*
*Ямбулатова Мөнирә Хәйрулла кызыннан (1941 елгы),*
*Абушаһманова Мәрьям Хөсәен кызыннан (1948 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Мулла иде минем Таҗетдин бабам. Бабамнар өйдә мәйдан йыйыштыралар иде бик күп. Кешеләр чакыралар, и яз көне әбием скәтер йәйә иде, яшь үлән иде. Шунда самавыр куя, чәйләрен куя. Әбиләр-бабайлар бар иде. Шуларны җыенышып, шунда утырып, бер тибәбез – хәзер укыйбыз, ди. Аннан китә мөнәҗәтләр. (Үзенә күрә бер мөнәҗәт-чәй бәйрәме. – *И.Я.)*

Бабам авылдагы кем азанчы, кем яхшы укучы – берничә бабай белән катнашалар, йөриләр иде мәчеткә.

Язның бер тәүлегендә алар китә иде Зимичага, җәяү. Аркаларында мешок, шул мешокта комган, намазлык, йөслекләре, чәйләре-шәкәрләре, әпәйләре. И вот бара – төшәләр, утыралар да чәй эчәләр, намаз укыйлар шундук. Караңгы төшә, кунарга шакыйлар, бер үгә керәләр авыл саен инде. Зимичада ишан бабайга укыганнар. Аларны анда каршы алучы бер бабай булган, мулла кебек, Зимичага килүчеләрне каршы алып, озата булган. И шунда алар мәйдан җыештыра булганнар. Иткән затларны сибәләр дә и таяк белән өшкерә булган чәйләрен, сабыннарын. Анда шифалы бер бабай бар. Әле ишан бабайның олына да йөределәр. Исән чакта ишан бабайның үзенә йөрегәннәр. Бабам 105 яшендә үлде, бабам малайлыкта торган шул ишан бабайда. Малайлыкта хезмәт иткән и шунда укыган Зимичада. Мөнәҗәтләрне аның язуларыннан өйрәнгән идем.

## *Хәзрәт мөнәҗәте*

Хәзрәт мәйдан ачкан, дуслар,
Рәхмәт яусын, дуслар, анарга.
Хәзрәт мәйданнары исемә төшсә,
Тотына йөрәгем янарга.

Тотына йөрәгем әй янарга,
Утырам моңланып еларга.
Зимнича юлыннан барган чакта
Бөдрәләнеп үскән бер бодай.

Хәзрәт кәбәмә бик иректем,
Күрештерер микән бер Ходай?
Барыек, дуслар, хәзрәт алганда,
Үкенербез бармый калганга.

Һавалардан очкан ак кошларның
Канат очкайларын кыймагыз.
Хәзрәт кәбәмә бик иректем
Бер елыем, дуслар, тыймагыз.

Ай-һай, хәзрәт кәбәм, син генә,
Синсез табалмыймын сүз генә.
Хәзрәт азбарына агач үскән,
Аның яфракларын җил кискән.

Иртә дә исемдә, кич төшемдә,
Хәзрәт кәбәм, исмә син төшкән.
Ай-һай, хәзрәт кәбәм, кирәгең,
Ялкынсыз янадыр йөрәгем.

Зимнича урамын өч әйләндем,
Әйләнсәм дә үземә ошамый.
Хәзрәт кәбәмә бармаенча,
Тулган эчкенәем бушамый.

Йомшак, хәзрәт кәбәм, кулгынаң,
Җәннәт бара торган юлгынаң.
Түгәрәккәй куак зур да булмас
Аның арасыннан юл булмас.

Хәзрәт кәбәбез дева кылса,
Девалы балалары буш булмас.
Челтәремнән борылып бакмадым,
Сер сүләргә чын дус тапмадым.

Рәхмәт дәрьясы ага мөлдер-мөлдер,
Уртасында, хәзрәт, бер гөлдер.
Шул мубаряк гөлдән тамчы тамса,
Бал ләззәтле андый тегелдер.

Утта янсын фани дөньясы,
Ахирәткә юктыр файдасы.
Иртә генә торып тышка чыктым,
Азанчы азан атя намазга.

Безнең дә генә дуслар
җыелганнар
Алла әйтә торган авазга.
Ай-һай, хәзрәт кәбәм, син генә,
Синсез табалмыймын сүз генә.

Аерда гына агач, әй, карлыгач
Кайда барып кунар арыгач,
Дөньяны да җәннәт диеп
белер идем,
Хәзрәт мәйданына тарыгач.

Ай-һай, хәзрәт кәбәм, кирәгең,
Ялкынсыз янадыр йөрәгем.

*Неверкино районы Дөмавылда*
*Ямбулатова Мөнирә Хәйрулла кызыннан (1941 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Диде Муся, Раббым Алла*

Диде Муся, Раббым Алла,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Бер Аллаһы Тәгаләм риза булса.

Диде Муся, Раббым Алла,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Пәйгамбәрләр риза булса.

Диде Муся, Раббым Алла,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Ата-анаң риза булса.

Диде Муся, Раббым Алла,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Кыз-кардәшең риза булса.

Диде Муся, Раббым Алла,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муся,
Күршеләрең риза булса.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Абубакирова Һава Харис кызыннан (1954 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Ятимнәрнең хәле

Рәсүлулла димәдеме,
Йәтимнәрне сөймәдеме,
Йәтимлектә, фәкыйрьлектә
Рәсүлулла булмадымы.

Рәсүлулла ятим булган,
Йәтимнәрнең кадерен белгән.
Йәтимнәрнең хәлен сорап,
Аларга шәфият кылган.

Әгәр ятимнәр күрсәгез,
Алар хәлен сорасагыз,
Аларга шәфкать итсәгез,
Сәвап булыр димәдеме.

Кечкенәдә ятим булгане
Олылыкта фәкыйрь булган
Ятимлектә, фәкыйрьлектә
Рәсүлулла булмадымы.

Рәсүлулла вәсиәт иткән:
Сез дә ятимне күрсәгез,
Минем кебек тәбрикләгез
Башын сыйпап, рәхимләгез.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Айзатуллина Һава Исхак кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## Балаларга нәсихәт

Авызлар пешсә дә, күңелләр төшсә дә,
Күрсәк тә күрмәгез, анага
Китмәгез кабынып, яшәгез сагынып,
Ышанган шикелле Аллага.

Ярдәмне кылыгыз, шәфкатьле булыгыз,
Аналар йөрәген саклагыз.
Дөньяның малына, байлыкның барына
Аларның хисләрен саклагыз.

Кылсагыз изгелек, алырсыз бәхиллек,
Бәхиллек – байлыкның зурысы.
Анадан ризалык – сираттан узарлык
Оҗмахка юлларның турысы.

Җирдә ятмаячак, үзеңә кайтачак
Анага күрсәткән изгелек.
Соңларга тырышма, бирелеп тормышка,
Онытма, гомер бер мизгеллек.

Аналар йөрәге belә ни кирәген,
Баланың күзеннән аңлыйлар,
Уйлары изгедә, анадан кем бизгән,
Дөньяда яшәми андыйлар.

*Кузнецк районы Ялгаш авылында*
*Алькаева Сабира Сәет кызыннан (1946 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### ***Дусларымда кунакта***
*(мөнәҗәт)*

Килеп кердем өегезгә,
Тәсбих күрдем чөегездә.
Нинди дога бирим сезгә?
Хәер-дога кылам сезгә.

И, туганнар, сыйладыгыз
Тәмне нәүмәтләрегез белән.
Ходаем сезне сыйласын
Җәннәт нәүмәтләре белән.

Салават әйтсә, бер бәндә –
Тәмыг утыннан бер пәрдә.
Салават әйткән кешенең
Урыны булыр мәкшәрдә.

*(Бу әбиләрдән калган. Әбиләр кунакта, мәҗлесләрдә әйтә.)*

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Вагапова Гүзәл Равил кызыннан (1968 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Сүлим әле, балам, сүлим әле,
Сүзләремдә бөтен моңнарым.
Вафат булсам, балам, укыт Коръән,
Тәрәзәңнән кайтып тыңлармын.

Зинһар әйтәм, балам, укыт Коръән,
Рухым китмәс синең кырыңнан.
Бер хәбәр дә сиңа бирә алмам
Мәңге кайтмас изге урнымнан.

Зинһар әйтәм, балам, укыт Коръән,
Үтенечем сиңа шул булыр.
Миңа атап, Коръән укыталсаң,
Кабер эчләремдә нур булыр.

Юк елама, балам, яшең түкмә,
Аерылып миннән калганда.
Бер Ходаем тел ачкычы бирсен
Нөнкир-Мөнкир сөаль алганда.

Садака бир, балам, җомаларда,
Котылырмын мин дә азаптан.
Изгелегең, балам, савап булыр,
Үзеңә дә кайтыр азактан.

Зинһар әйтәм, балам, туганнарым,
Бәхил булып миннән калыгыз.
Алып барып гүргә иңдергәч тә,
Тәһлил әйтеп, тупрак салыгыз.

Сахраларда ялгыз йөргән чакта
Хозур Ильяс булсын юлдашың.
Тар кабердә ятыр ялгыз башым,
Чын иманым булсын юлдашым.

Зинһар әйтәм, балам, ихляс белән
Уздырыгыз минем өчемне.
Садакалар биреп, дога кылып,
Буш үткәрмә атна кичеңне.

Зинһар әйтәм, балам, уздыр едемне дә,
Кырыгымны да аннан онытма.
Башка кеше өчен берәт булыр
Каберемнән эзең суытма.

Көннәр үтәр, балам, елым үтәр,
Исеңә ал мине тагын да.
Карт-корыга хәер биргәләп тор
Сау-сәламәт булган чагыңда.

Белсәң иде хәлләремне,
Йөрәгем әрнүләрне.
Теге дөньяларда яшәп,
Күрергә тилмергәнне.

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Хәбибуллина Җәүһәр Усман кызыннан (1940 елгы),*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## ҖЫРЛАР

Арыслан айга сикерә
Каршысында яр булса.
Матур йегет һич кайгырмый,
Башы исән-сау булса.

Казарма биек булса да,
Кошлар оя ясамый.
Ал булса да, гөл булса да,
Туган илгә ошамый.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Кузяхметов Усман Аглиулла улыннан (1963 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Сарбаемның чәчәкләрен
Таптамам дигән идем.
Туган-үскән авылымны
Ташламам дигән идем.

Машиналар тау менәлми,
Тау менәлми каплана.
Юлларыңда алсу чәчәк
Мин булырмын, таптама.

Сандугачым да син генә,
Былбылым да син генә,
Бу дөньяда иң яратып
Сөйгәнем дә син генә.

Алай димәгән идем,
Болай димәгән идем.
Яшь гомерем – роза чәчәк,
Үтәр димәгән идем.

Син дә кара каш идең,
Мин дә кара каш идем.
Син ятларга карамасаң,
Мин дә карамас идем.

Эй, кодагый, сиңа әйтәм,
Зәңгәр күлмәгеңне ки.
Олыңны ничек сөясең,
Килнеңне дә шолай сөй.

Куа, куа, җитәлмәдем
Суда йөзгән үрдәкне,
Умрем булса, онытмамын
Сездә булган хурмәтне.

Пижалардан кыраватка
Тимер юл булса иде,
Безнең кебек әбиләргә
Көн дә туй булса иде.

Кода бабай, азбарың,
Азбар тулы казларың.
Үзең сәләпәлә генә,
Нинди матур кызларың.

Сезнең алмагачыгыз,
Безнең алмагачыбыз.
Сезнең алмагачыгызны
Хур итәргә алмадык.

*Неверкино районы Сарбай авылында*
*Вагапова Майзә Исхак кызыннан (1938 елгы),*
*Хәбибуллина Наилә Исмаил кызыннан (1950 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Сарбай җыры*

Машиналар тау менәлми,
Тау менәлми каплана.
Туган-үскән авылыңны
Син бөтенләй ташлама.

Басма өстенә баскан саен
Такталары бөгелә.
Ике еллары тулгачтин,
Кайтып килә иншалла.

*Неверкино районы Сарбай авылында*
*Рахманкулова Тәнзилә Шаһи кызыннан (1935 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Өй алдында шомыртым бар,
Яннарында чияләр.
Шул чияләр, безгә карап,
Сез бәхетле, дияләр.

## *Туй җырлары*

Кодалар-кодачалар,
Сездә ничек, бездә шулай
Ерлап күңел ачалар.

Кода маем, тулган аем,
Тулган ай тик тулгансың.
Күптән инде күргәнем юк,
Сандугач тик булгансың.

Әнә килә автомобиль
Төягәннәр кыярлар.
Бик күтәрмә борыныңны
Чиләк элеп куярлар.

Кода маем, азбарың,
Азбар тулы казларың.
Әмән үзең сәләпәлә,
Бигрәк матур кызларың.

Кода маем, азбарың
Азбарың – сарайларың,
Үзең әмән сәләпәлә,
Бик матур малайларың.

* * *

Кызны алып киткәндә егет ягы җырлый:

Кара сыер кабыргасын
Каерып алырга кирәк.
Әңкәсенең бер кызы бар,
Суырып алырга кирәк.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Мусина Алия Габдрахман кызыннан (1943 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Көймә килә, су чайкала
Көймә килүләренә.
Ышанып та торма аның
Алдап сөюләренә.

Аргы яктан килдеңме?
Бирге яктан килдеңме?
Без сагынганны белдеңме?
Үзең сагынып килдеңме?

Сызлып таңнар аткан чакта
Су өсте матурлана.
Сезне уйлап, яшь йөрәгем
Сулардай дулкынлана.

Агыйделне нигә буйлап
Йөзәсең үрдәккәем?
Өзелгән йөрәккәемне
Белмисең, гүзәлкәем.

Безнең алмагачыбыз,
Сезнең алмагачыгыз.
Безнең алмагачыбызга
Кунды сандугачыгыз.

Сөйдем сезне, сөйдем сезне,
Сөйдем сезне берзаман.
Сөйдем дә сезне берзаман,
Китмисез истән һаман.

Алдым гармун кулыма
Киттем урман буена.
Кызлар белән таныштыр дип,
Әйттем мин гармуныма.

Бии, бии, бии, бии
Кодаларны көтәләр.
Мин дә күккә очар идем,
Ныклап кына төртсәләр.

Алтмышта да биербез,
Җитмештә дә биербез.
Ничә яшь дип сорасалар,
Унсигездә диербез.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре – Абидә.
Бу шатлыкка сикереп төшә
Җитмеш яшьлек әби дә.

Алларын да алдык без,
Гөлләрен дә алдык без,
Күңелебезгә кем ошады,
Шуны сайлап алдык без.

Безнең Рушан кара кими,
Кара кирәкми дия.
Бүләк бирсәң, бүләк алмый,
Гөлсинә – бүләк, дия.

Гармун тавышлары гына
Ача күңелләремне.
Бик кайтарып алыр идем
Үткән гомерләремне.

* * *

Көймә килә, су чайкала
Көймә килүләренә.
Ышанып та торма аның
Алдап сөюләренә.

Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә
Эзе юк.
Хаты гына килә генә,
Сөйләшергә үзе юк.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Абдульмянова Фәридә Каюм кызыннан (1949 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Куфайкыңның чабуларын
Салындырам дисеңме?
Матурлыгыңа таянып,
Ялындырам дисеңме?

Бересендә сугым ите,
Бересендә яровой.
Ни итсәң дә килешә,
Итенешең мировой.

Ал бирәм алганнарга,
Гөл бирәм алганнарга.
Кесәмдәге подаркылар
Озата барганнарга.

Кода маем, син үзең,
Кашыңдин кара күзең.
Бар сандугач сайраган
Синең сүләгән сүзең.

* * *

Сорау:
Яңа салган пичегез
Пешерәме беленне?
Кодагыйдан соралабыз:
Яратамы киленне?

Җавап:
Яңа салган пичебез
Бик уңдыра беленне.
Кодагыйдан явап килә:
Ярата бик киленне.

* * *

Рәхмәт, дуслар, ерладыгыз,
Безне дә зурладыгыз.
Гөл бакчалары булсын
Сезнең урыннарыгыз.

Солдат булды башларым,
Бисмиллясыз ашларым.
Тагынниләр күрер икән
Бу бәхетсез башларым.

Ворошилов портретын
Күргән саен карыймын.
Армияга баруымны
Зур бәхеткә саныймын.

* * *

Менә, дустым, сиңа бер сүз әйтәм,
Ихляс белән тыңла сүземне.
Таулар белән хәсрәт килсә,
Бетермә үз-үзеңне.

*Неверкино районы Мансур (элек Чербулат) авылында*
*Салюкова Хәлифә Илач кызыннан (1926 елгы),*
*Емлиханова Мөнирә Абдул кызыннан (1947 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Комсомоллар бизәнмиләр,
Йөзек-алка кимиләр.
Уникешәр үптермичә,
Үләренә кермиләр.

* * *

Эй, кодалар, кодалар,
Кодалар-кодачалар,
Сездә ничек, бездә шулай
Ерлап күңел ачалар.

Кодача beləгең нәзек,
Суктыр алтын беләзек.
Икәү кодача булырга
Ничә еллар теләдек.

Кайдан килдегез сез безгә,
Батмаинча диңгезгә?
Кадерле кунак сез безгә
Ни хөрмәт итик сезгә?

*Неверкино районы Биги авылында*
*Сатаева Равиля Исхак кызыннан (1948 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Шаулый урман*

Шаулый урман, шаулый урман, җилләр искәндә.
Сагындыра туган авылым, исемә төшкәндә.
Сагындыра әниемнең тегеп биргән күлмәкләре,
Әллә шуны киеп үскәнгә.

Шаулый урман, шаулый урман, җилләр искәндә.
Сагындыра туган авылым, исемә төшкәндә.
Сагындыра әниемнең тирән эчле калушлары
Әллә шуны киеп үскәнгә.

Шаулый урман, шаулый урман, җилләр искәндә.
Сагындыра туган авылым, исемә төшкәндә.
Сагындыра авылымның чакыр-чокыр урамнары
Әллә шунда уйнап үскәнгә.

Шаулый урман, шаулый урман, җилләр искәндә.
Сагындыра туган авылым, исемә төшкәндә.
Сагындыра әниемнең каһәр суккан Уф Алласы
Әллә шуны ишетеп үскәнгә.

*Неверкино районы Биги авылында*
*Юнусова Фәридә Абдулла кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Кода маем, син үзең,
Кашыңдин кара күзең.
Утыз ике теш араңнан
Сайланып чыга сүзең.

*Неверкино районы Бикбулат (Бикмосеевка) авылында*
*Асейдуллина Сания Вахит кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Кодабызның азбарында
Алтын икән бачкычы.
Кодагыйдан сорыемчы,
Кайда сандугач кызы?

Сандал бауларым өзелде
Сандугачлар куганда.
СССРны эзләп чыктым,
Сезнең кебек юк анда.

Карурманга кергән атлар
Йерләрне уяр микән.
Эй, балалар, сезне карап,
Күзләрем туяр микән!

Кайнянама, йөрәгемә,
Коран тутыртыр идем.
Кечерткәннәр арасына
Илтеп утыртыр идем.

Әтнә көе, Әтнә көе,
Әтнә көе – кыска көй.
Берне илдән, берне читтән,
Берне Әтнәдән дә сөй.

Син дә әллә кем түгел,
Мин дә әллә кем түгел.
Синең әллә кем булуың
Әҗәлгә дару түгел.

Алма алай була мыни?
Алма түгәрәк була.
Ялгыз тормыш, тормыш мыни
Тормыш бергәләп була.

Утырсам, уйга батам,
Кулымда кош уйнятам.
Утсыз янган йөрәгемне
Уйнап-көлеп еватам.

Утырмый да булмам инде
Алма коелган йергә.
Ерламый да булмам инде
Дуслар йыйылган йердә.

Санасам-санамасам да,
Гармун теле унике.
Уйласаң-уйлямасам да,
Яшь вакыт килми ике.

Бар иде безнең яшь чаклар,
Кесә тулы борчаклар.
Саламнан салазка ясап,
Ерлап йөрегән чаклар.

Сүдем дә күп, сүдердем дә,
Хәзер сүмим кемне дә.
Яшьлек тилелегем белән
Генә сүдем сине дә.

Алдым гармун уйнядым,
Йөрдем урам буйлярын.
Бер Ходаем миңа салган
Бөтен дөнья уйларын.

Әнием әйтә: кил, балам, ди,
Әтием дә әйтә: кил, балам.
Елаганда еватырга
Юк асыраган анам.

Беләзегем-йөзегем
Киярмен әле үзем.
Ятка бирер ярем түгел,
Сүәрмен әле үзем.

Алма турыйм, алма турыйм,
Алманың түгәрәген.
Нинди ерлар соң бирием,
Мәхәббәт күбәләгем.

Әй, алына, алына,
Былбыл кунган талына.
Егет алсын, кызы барсын
Үзе сүгән ярына.

*Неверкино районы Бикбулат (Бикмосеевка) авылында*
*Фәхретдинова Маһруй Үмәр кызыннан (1934 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Трактырчы, яңгыр ява,
Туктат трактырыңны.
Сөймәгән дә булыр идем,
Белсәм характерыңы.

Фонтаннарга чиләк элдем,
Тула торгандыр инде,
Һәркемгә дә бер мәхәббәт
Килә торгандыр инде.

Ай югары, ай югары,
Айга менәсем килә.
Айга менеп, түбән карап,
Сезне күрәсем килә.

Кимә дигәч, нигә кидең
Шул күлмәгеңне?
Сөймә дигәч, нигә сөйдең?
Яндырып йөрәгемне.

Ак шарыф ни, күк шарыф ни,
Икесе дә барыбер.
Ят авыл ни, үз авыл ни,
Җаның тынса, барыбер.

Ал алам сезнең өчен,
Гөл алам сезнең өчен.
Төшәм Байкал күлләренә,
Югалам сезнең өчен.

*Неверкино районы Исәкәй авылында*
*Бахтиева Румия Ибраһим кызыннан (1962 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Эй, икегез, икегез,
Икегез дә бертигез.
Икегез дә пар килгәнсез,
Тигез гомер итегез.

Кода маем, азбарың,
Азбар тулы казларың.
Үзең сәләпәлә генә
Бигрәк матур кызларың.

*Неверкино районы Исәкәй авылында*
*Бахтиева Сафия Абайдулла кызыннан (1947 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Ай кодалар, сезнең белән
Күтәренке күңелләр.
Күтәренке күңел белән
Үтсен безнең гомерләр.

Кода бабай, азбарың,
Азбар тулы казларың.
Үзең әмән сәләпәлә
Бигрәк матур кызларың.

* * *

Санасам, санамасам да,
Гармун теле унике.
Уйласам, уйламасам да,
Яшьлегем килми ике.

И яшь чагым, яшь чагым,
Яшь чагым – ямьле чагым.
Уйлап карагызчы, дуслар,
Әйләнеп килми тагын.

Яшь вакыт ул ямьле вакыт,
Бар үмергә бер генә.
Кайгы чикмә, уф та димә,
Тик уйна да көл генә.

Яшь чагымда мин йөредем
Кино, театрга да.
Хәзер инде дус-ишләрем
Белми ни атерга да.

### *Әниемә хат*

Бишек йырың синең назлы колагымда,
Күкрәк сөте тәме телемдә.
Изге теләкләрең мине җитәкләде
Адяшырмын дигән көнемдә.
Әнием, күз нурым,
Көт мине, кайтырмын.

### *Туган авылыма*

1. Чыңлы тулы җәелеп ага,
Язгы ташкыннар килсә.
Язгы ташкындай гөрләшеп,
Авылда яшьләр үсә.

Кушымта:
Туган авылым минем каршымда,
Күңлем һаман омтыла шунда.

2. Ераклардан карап киләм
Чыңлы басуларына.
Шул юллардан ямьнәр табам
Күңлем ярсуларына.

3. Шушы кырлар буйлап минем
Яшьлек елларым үткән.

Шул юлларда яшьлек дустым
Елмаеп чыкса икән!

*Неверкино районы Җәлил авылында*
*Исянова Мәфруза Хәлилулла кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Алма алай буламы соң –
Алма була түгәрәк.
Аерым тормыш, тормыш түгел
Тормыш була бергәләп.

Алма алай буламы соң –
Алма була түгәрәк.
Шул түгәрәк эчләрендә
Яшиек, дуслар, бергәләп.

Иртән торып, тышка чыктым,
Яшәргән суганнарым.
Яшәргән суганнар кебек
Яшәгез, дускайларым.

Тәрәз ачып, бодай сиптем,
Ашагыз кошкайларым.
Мәңге рәхәт йер йөзендә
Яшәгез, дускайларым.

Кызыл-кызыл бөрлегәннәр
Су буена тезелгән.
Бармы икән безнең кебек
Сезнең өчен өзелгән.

Әй, кодалар, кодалар,
Кодалар, кодачалар.
Сездә ничек, бездә шулай
Йырлап кеңел ачалар.

Кодагыйдан без сорыйбыз:
Яратамы киленне?
Кодагыйдан йавап килде:
Бик ярата киленне.

Кичен салган пичегез
Пешерәме беленне?
Кодагыйдан без сорыйбыз:
Яратамы киленне?

Кичен салган пичегез
Бик пешерә беленне.
Кодагыйдан хабар килде:
Бик ярата киленне.

Өй алдында, өй алдында,
Өй алдында зур алан.
Кияվемне бик яратам,
Балам янында балам.

Самавырны ни кайната?
Сары нарат күмере.
Кияү белән кызыбызның
Озын булсын гөмере.

Бие, бие, висулай,
Синең биюең шулай.
Синең биюләргә карап,
Без дә биербез шылай.

Биек тауның башларында
Чабышып йөри лиса.
Кайнянамны бик сөямен,
Бераз телләрен тыйса.

Кайнянамны, бәгыремне
Бер генә күрер идем.
Кечерткәннәр арасына
Итеп утыртыр идем.

Алма булса, шундый булсын
Өчкә, дүрткә бүләрлек.
Ярең булса, шундый булсын,
Үзең өчен үләрлек.

Ары баскан аягыңны
Бире бассаң ни була?
Кулъяулыгым калды, диеп,
Кайтып алсаң ни була?

*Неверкино районы Мазарлы авылында*
*Комякова Миясса Әмин кызыннан (1939 елгы),*
*Гульмиярова Мәрьям Җиһанша кызыннан (1959 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Алма бирәм, ашасаң,
Бәхил түгел, ташласаң.
Урның оҗмахларда булыр,
Мине сөя башласаң.

Агыйделгә барма якын,
Барма якын – батасың.
Палитика сөйләтерләр,
Сөйләмә – алдатасың.

Алмагачны утыртабыз,
Алмасы булмаса да.
Балаларны асырыйбыз,
Бәхете булмаса да.

Өстәл өстендә машинкам
Текми дә, йүләми дә.
Әниемнең картычкасы
Көлми дә, сүләми дә.

Ак бит, кар бит, кар бит ак бит,
Карны ашамыйлар бит.
Яр бит җәл бит, җәл бит, яр бит,
Ярны ташламыйлар бит.

Кода маем, дружок,
Уртасында кружок.
Аста бәлчик, өстә бал,
Кодагыем, чыгып ал.

Әлеге машиналарны
Адым белән дә етәм.
Канянама ярамасам,
Олын алам да китәм.

Кодаларым, майларым,
Сезме тулган айларым?
Сезнең белән бергә булгач,
Рахятляна күңелләрем.

Су буйларына төшмәсәм,
Мин сине күрмәс идем.
Син дә мине, күрешмәсәң,
Алмаган булыр идең.

Автобуста барган чакта
Югалттым пирчаткамны.
Әти-әни, еламагыз
Ебәрәм картычкамны.

Армияга алсалар да
Будырмам билләремне.
Кара чәчем агарса да
Онытмам илләремне.

* * *

Ак бүрегем бар дисең,
Нигә аны кимисең?
Сөйгән ярең бар дисең,
Нигә аны сөймисең?

Ал булам, гөл булам,
Көндә янында булам.
Көндә-көндә айлы төндә,
Һәрчакта да бер булам.

Артыбызда чөгендер,
Ашар ашым түгелдер.
Яр өстенә яр сөяргә
Башым ике түгелдер.

Ал булам, гөл булам,
Көн дә янында булам.
Көндә-көндә айлы төндә,
Һәрчакта да бер булам.

Су буенда гөлләр чәчтең
Кошлар ашасын өчен.
Ул кошларның чәчәкләре
Корып бетмәсен өчен.

Ал булам, гөл булам
Көн дә янында булам.
Көн дә-көн дә айлы төндә.
Һәрчакта да бер булам.

* * *

Сания апа суга бара
Уң кулында чиләге.
Су өстендә алтын йөзек –
Сөйгәненең бүләге.

Сания, исле сабын,
Бер сагынмасаң, мине сагын,
Онытып куйма тагын.

Сания басмаларда,
Йөрәгемдә син кайныйсың,
Урын юк башкаларга.

Сания апа суга бара,
Алма-алма чиләге,
Чиләгенә караганда
Үзе кура җиләге.

Кытай границасы,
Бөккәләнмә-чөккәләнмә,
Мухшы карамысласы.

Кытай әтәчләренә,
Сокланмагыз егетләрнең
Кодыра чәчләренә.

Агыйделдән агып килә
Алтын байның курчагы.
Минем ерны яратмасаң,
Үзең ерла, корчаңгы.

## *Каршы уен җырлары*

Киемнәрең,
Киләчәктә теләгәнең белән
Үтсен синең көннәрең.

Зур-зур пылакат
Пичәт итәләрме?
Армияга ярең белән
Прнимать итәләрме?

Ап-ак кына, кар гына,
Ник прнимать итмәсеннәр,
Пожалыста бар гына.

Китергән суларыгыз,
Кайсы йолдыз турасында
Йөрегән юлларыгыз.

Килә еласыларым,
Төшләремә дә кермәде
Болай буласыларым.

Алма бирәм ашасаң да,
Бәхил түгел ташласаң да.
Урның оҗмахларда булыр,
Мине сөя башласаң.

* * *

Безнең артыбызда зур мәдрәсә,
Мәдрәсәдә ике пыласа,
Унөч-ундүрт яшьлек бер йәр сөйдем,
Дускаем, еватырмын еласа.

### ***Нигә чайкаласың?***

Нигә чайкаласың, син нечкә миләшем?
Читәнгә тигәнче, башыңны иясең.

Елга аръягында, әнә юл буенда
Биек имән ялгыз, үсеп тора шунда.

Ничек соң барырга шул имән янына?
Иелмәс, чайкалмас иде ул чагында.

Сыеныр идем мин кочагына аның,
Сердәш итәр идем яшел яфракларын.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Хайрова Фатыйма Исмаил кызыннан (1952 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Кошлар тынды, урман уйга чумды,
Тукталгандай булды агымсу.
Күзләремә бактың, йөрәккә ут яктың,
Булып китте кинәт ямансу.

### ***Абдельман купич***

Абдельман купичның кимәләре килә,
Кимәләре башында сарука.
Абдельман купичны под суд озаталар,
Һичбер купич алмыйдыр парука.

Абдельман купичның йорты тирәсендә
Зың җырларга бәйләгән аюлар.
Абдельман купичны судить итә
Сембер губернасыннан маюрлар.

Аранга бәйләгән акбузатны
Бир аникай, җаным, кенәзгә.
Акча суга торган алтын станокны
Бәр, аникай, җаным, герәзгә.

Абдельман купичның йорты таш түшәгән,
Судьялар йөри-йөри саз булган.
Алты йөккә тиягән алтын акчам
Башкынамны йолырга аз булган.

Кыйгак-кыйгак ниләр кыйгаклыйлар
Абдельман купичның казлары.
Төрмә кыругында елаша йөриләр
Абдельман купичның кызлары.

Абдельман купичның таш думнары,
Сиксән сигездер аның тәрәзе,
Абдельман купичны сорасагыз,
Төрмә каршысында зәрәде.

Минем әтиемнәр утырып, шулай җинау җырлыйлар иде. Яшьләр аны бик җырламый. Әтием җырлый иде минеке. Мин яшь, башка кереп калган.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Айзатуллина Һава Исхак кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Килен алган кодагый
Сикреп-сикреп биидер,
Кызын биргән кодагый
Үкреп-үкреп елыйдыр.

Анна кодагыйны биетәләр, килен ягын.

*Кузнецк районы Пәлдәнге авылында*
*Енгалычева Венера Исмәгыйль кызыннан (1938 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Кышны кайда кышлыйсың?
Анисывый алмагачның
Чәчәгенә ошыйсың.

Тәрәз төбемдә гөлләрем
Тәрәзләргә үреләә.
Бүгенгесен ни әйтием,
Тора-бара күренер.

Кода маем, дыружок,
Уртасында кыружок.
Аста мае, өстә бал,
Кода маем, биеп ал.

Кода маем мыегына
Сандугач оялаган.
Ояласа оясын,
Эчеп куй пиаласын.

Өстәл өстем түгәрәк,
Уртасында күбәләк
Мәйданыбыз бергә булсын,
Күтәриек бергәләп.

Әй, эч тә куй, эч тә куй,
Нужа күрмә никакуй.
Тәрәзәңнән буран керсә,
Ястыгыңны тык та куй.

*Кузнецк районы Ялгаш авылында*
*Әбдерәхимова Мәһира Әнвәр кызыннан (1951 елгы),*
*Амирова Гөлшат Абдул кызыннан (1954 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**Уен-бию җыры**

Әй, алмалар, кая каталыйлар?
Тау астына каталыйлар,
Әләнеп карамыйлар.

Уртада бер кыз икенчене ала да аның белән әләнә уртада:

Әдә гедер, геннә гедер геннәем,
Матур чәчәк атар минем гөлкәем...

*Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында*
*Курмаева Хатимә Хусяин кызыннан (1930 елгы),*
*Мендаева Халидә Хусяин кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Чәйләр ясыйм, чәйләр ясыйм
Чашка түгәрәгенә,
Сез дусларны ошатамын
Сахра күбәләгенә.

Агыйделдән прахуд килә
Чылбырлары бушаган.
Алма алсу, чия кызыл
Сез шуларга охшаган.

Киленнәр килә кинәнеп,
Берлинны алам, диеп.
Кайняналар елап кала
Пленга кала, диеп.

### *Польша сахралары*

Польша сахралары да ни зур сахра,
Сандугачлар сайрый тирәктә.
Әнием-бәгърем, өйгә кайталмадым,
Дошман пуля тиде йөрәккә.

Хазер инде безнең самалютлар
Бик тиз үтә ерак араны.
Әнием-бәгърем, өйгә лә кайталмадым,
Күндералмадылар ярамны.

Январь айларының җиле дә салкын,
Тәрәзәмне дә лә чиртеп үтәләр,
Якын ибдашкаең үлгән диеп,
Сәгать саен әйтеп үтәләр.

*(Бу сугыш ерлары. Элек ерлый идек.)*

### *Шахтюр көе*

Шахтюр көен яратам.
Шахтюр көйләрен тыңнасам,
Бар кайгымны таратам.

Шахтюр егет шахтыйларда
Эчә лә күмер тузанын.
Сиксән сажин җир астында
Сизми лә гомере узганын.

Шахтюр егет шахтыйларда
Кисә лә күмер кисәген.
Гомерем булса ла, таш басмаса,
Кайтырмын, җанкисәгем.

* * *

Алдыр бастун, тектер пальта,
Барырсың киноларга.
Ал утлардин, сал суларга
Бер генә минутларга.

Яшь чагымда күкрәгемә
Чәчкәләр кадамадым.
Чөнки яшьлек үзе матур,
Кирәк дип санамадым.

Яшь вакытта һәркем шулай
Рахят гумер кичерә.
Рахят гумер күпкә бармый,
Тормыш агу эчерә.

Гармун каешларына,
Гармун каешларына.
Булмасын сөйгән ярегез
Кояш баешларында.

Гармуныңны тартып уйна
Без җырлаган көйләргә.
Без җырлаган, сез уйнаган
Калсын сагынып сөйләргә.

*Кузнецк районы Дәхтәрни авылында*
*Мусякаева Рәисә Шакир кызыннан (1945 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### ***Кашкынаем***

Кашкынаем сөрмә күзем күрми,
Әйдә тот, җанкаем, кулымнан.
Син җаныемның хәсрәтеннән
Адашканмын йөргән юлымнан.

Биек тау башында бер биек юл,
Баскычлары бадьян агачы.
Син җаныемның хәсрәтеннән
Бал-шикәр ашасам шул ачы.

Агыйделкәйләрнең өсләрендә
Кыек үрдәкләр дә йөзалмый.
Син җаныемның хәсрәтеннән
Яшь тә йөрәккәем түзалмый.

### ***Дускайларым***
*(уен-бию җыры)*

Эчем пошала микән,
Чыгаем тышларга микән,
Эч серемне кемгә сөйлим,
Дускайларыма микән?

Яңгыр микән, кар микән,
Яумаган җир бар микән?
Бу җиһанда сезнең кебек
Дускайларым бар микән?
Бу җиһанда сезнең кебек
Пар килгәннәр бар микән?

Сез дә килгәнсез микән,
Без дә килгәнбез микән?
Вакыт үткәч, бергәләшеп,
Очрашырбызмы икән?

Эчем пошала микән,
Чыгаем тышларга микән?
Эч серемне кемгә сөйлим,
Дускайларыма микән?
Эч серемне кемгә сөйлим
Очкан кошларга микән?

### *Оныталмыйм*

Түгәрәккәй чишмә суы тулган,
Аның ягасына кош кунган.
Яшь акылым белән сизми калдым,
Сайрар сандугачым шул булган.
Мал биреп алырга малым юк.
Синнән аерылыр хәлем юк.

Талдин тар тартмалар ясар идем,
Талның тамырларын сузалмыйм.
Яшьли хәлләремне сөйләр идем,
Яшьли сөйгәнемне оныталмыйм.
Яфрак яра яшь каен,
Саргайтасың син, маем.

Түгәрәккәй чишмә суы тулган,
Агып тора ике ярыннан.
Кемгә очрасам да, шул әйтәдер:
Ник аерылдым сөйгән ярымнан?
Тал тирбәтсәм, тала беләгем,
Исемә төшсә, яна йөрәгем.

Түгәрәккәй чишмә суы тулган,
Аның ягасына кош кунган.
Яшь акылым белән сизми калдым,
Сайрар сандугачым шул булган.
Мал биреп алырга малым юк.
Синнән аерылыр хәлем юк.

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Шаһвәлиева Венера Зиннәт кызыннан (1983 елгы),*
*Вагапова Гүзәл Равил кызыннан (1968 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### Абдельман купич
*(өзек)*

Абдельман купичның кимәләре килә,
Кимәләре башында сарука.
Абдельман купичны пад суд озаталар,
Һичбер кеше алмыйдыр парука.

## *Көймә*

Кимә генә килә генә,
Кимә генә килә генә,
Кимә генә килә генә,
Эзе юк.
Кимә генә килә генә,
Сүзе генә килә генә,
Сөйләшергә генә
Үзе юк.

Кимәләр терәлгәннәр,
Нахак сүзләр күтәрергә
Без инде өйрәнгәннәр.
Кимә генә килә генә,
Эзе юк.
Кимә генә килә генә,
Сүзе юк.
Кимә килә, сүзе килә,
Сүзе килә, үзе килә,
Сөйләшергә генә үзе юк.

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Бакаева Сания Али кызыннан (1949 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Синең атың алмачуар иде,
Минем атым тимер күк иде.
Аерылышкан чакта сау бул, дустым, диден,
Чиккән яулык бирдең, кул бирдең.

Яулык болгап озатып калдым сине,
Синең матур дустың, юлдашың.
Дошманнарга каршы икәү бергә килдек,
Тимер кылыч алып кулларга.

* * *

Моңайма кош, моңайма кош,
Моңайсаң да аталар.
Мин моңайсам да килешә,
Солдатка озаталар.

Кодагыем-аппагым,
Кызыбызны какма гел.
Дошманнар ни сөйләсә дә,
Кеше сүзенә бакма гел.

Кодагый бәлеш пешергән
Московский кишердән.
Төннәр буе йокламыйча,
Сезгә килен (кияү) үстергән.

Кода маем, син үзең,
Кашыңнан кара күзең.
Ике тешең арасыннан
Елмаеп чыга сүзең.

Син дә булдың кодагый,
Мин дә булдым кодагый.
Кодагыйлар арасында
Төрле эшләр булгалый.

Кукуруз араларыннан
Очып чыкты бер тургай.
Әйтче, тургай, чибәремә
Ялындырмасын шулай.

Америка ыштатларын
Куып җитәрбез әле.
Куып җитеп, узып китеп,
Кызык итәрбез әле.

Кукуруз шулай үсә ул,
Сөйсәң ферма кызларын.
Үземнең дә биек итеп
Үсә кукурузларым.

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Бакаева Сания Али кызыннан (1949 елгы),*
*Вагапова Гүзәл Равил кызыннан (1968 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Үзләренең коесы бар,
Безгә килеп су ала.
Үз ярлары алма кебек,
Ятлар белән чайкала.

Чияләре бар аның,
Чияләре бар аның.
Иялнмәгез анарга.
Ияләре бар аның.

Чияле тау, чияле тау,
Чияле тау итәге.
Чияле тау итәгендә
Бергә булырбыз әле.

Помидормы ашадың?
Йөзләреңә краска сөртеп,
Кеше танымый башладың.

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Хәбибуллина Җәүһәр Усман кызыннан (1940 елгы),*
*Вагапова Гүзәл Равил кызыннан (1968 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### ***Бистән***

Еракларга китсәм, сагындыра Бистән,
Чыкмый истән яшьлегем урамы.
Кайтырга күп сәбәп, көтә зур мәхәббәт,
Калды минем эчәр суларым.

Тау битендә әл дә калын имәннәр дә,
Күпер тора таккан, сәленгеч.
Киселмәгән имән, хәтерләтә миннән
Ялан аяк йөргән чакларны.

Син көтсәң, Гөлбостан, без йөрербез исән,
Тормыш юлы ерак китсә дә.
Әнием тавышын, кизләүләр тавышын
Онытмам күп еллар үтсә дә.

* * *

Кодагый озын кия,
Итәге җиргә тия
Кашы көлә, күзе көлә
Кодагый безне сөя.

Тиңкл-тиңкл тиңклдыйдыр
Сәгатемнең тәңкәсе.
Матур кызны алып киткәч,
Елап кала әнкәсе.

Кисәм – кыска, кимәсәм җәл
Ак батис күлмәегемне.
Сөйсәм ерак, сөймәсәм җәл,
Яндыра йөрәгемне.

Сары каеш делбигалар
Безнең атларда гына.
Иртән торсам, ике күзем
Сезнең якларда гына.

Саный бардым, саный килдем
Сания каберләрен.
Яшьлек, дуслар, ике килми
Белегез кадерләрен.

### *Көймә*

Су буенда көяк үлән,
Коеп аласы иде.
Мәңге сагынмаслык итеп
Күреп каласы иде.

Кимә генә килә генә,
Кимә генә килә генә,
Кимә генә килә генә.
Эзе юк.
Хаты гына килә генә,
Сүзе генә килә генә,
Сөйләшергә үзе юк.

Мәк чәчәкләре коела,
Былбыл кабынган саен.
Мәк чәчәкләренә карыйм,
Сине сагынган саен.

Кимә генә килә генә,
Кимә генә килә генә,
Кимә генә килә генә,
Эзе юк.
Хаты гына килә генә,
Сүзе генә килә генә,
Сөйләшергә үзе юк.

*Сосновоборск районы Бистән авылында*
*Шабакаев Ринат Мәхмүд улыннан (1962 елгы),*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Ачма тәрәз, мин килминче,
Ятларны сөярсең белминче.
Ач тәрәзәң, күтәр пәрдәң,
Нурлы йөзең күренсен.

Сөймәсәң, әйт сөймим, диеп,
Синнән күңлем сүрелсен.

* * *

Ай яктысы якты була
Утрып мәрҗән тезәргә.
Булма куртле, бул бәхетле
Бәхет күркәм күрсәтә.

*Сосновоборск районы Әлмәш авылында*
*Ягудина Наилә Абдулла кызыннан (1941 елгы),*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Челтәрле кай күпер, әй челтәрле...*

Челтәрле кай күпер, әй челтәрле,
Арасыннан җилләр үтәрме.
Бу кайгы-хәсрәтләр әй бетәрме
Әллә яшь гомерләр үтәрме.

Зәңгәр чәчәкләрне җыеп алдым
Салкын чишмәләрнең буеннан.
Бу җырларны сезгә бүләк итәм
Чыгармаска безне уегыздан.

Чаптымдагынай печән, куйдым кибән,
Мунчалакай булып чересен.
Ярныдагынай сөйсәң сөй көчлерәк,
Диванакай булып йөрерсең.

Базарларга барсаң ал киң каеш,
Туры атка йүгән үрербез.
Кече яшьтин бирле йәр сайлисың,
Ярең нинди булыр күрербез.

Базарлардин алган арбузыңны
Эчкенәен ярып бактыңмы?
Мине дә генәй ташлап ятны сөйдең,
Әллә артык җирен таптыңмы?

*(Әлмәш җыры бу. Электән. Сугышка киткәндә җырлаганнар.)*

*Сосновоборск районы Әлмәш авылында*
*Ягудина Наилә Абдулла кызыннан (1941 елгы),*
*Забирова Шафика Кәлимулла кызыннан (1938 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### Челтәрле кай күпер

Челтәрле кай күпер, әй челтәрле,
Арасыннан җилләр үтәрме.
Бу кайгы-хәсрәтләр әй бетәрме,
Әллә яшь гомерләр үтәрме.

Чаптым гына печән, куйдым кибән,
Мунчалакай булып чересен.
Мине genә ташлап, ятны сөйсәң,
Диванакай булып йөрерсең.

Базарларга барсаң, ал киң каеш,
Турай атка йүгән үрербез.
Мине дә генәй ташлап, ятны сөйдең,
Яреңнинди булыр күрербез.

*(Шул ерларны әбиләр өйрәтте үзебезгә.)*

*Сосновоборск районы Сәләмәс авылында*
*Альбекова Алия Исмаил кызыннан (1944 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### Әбделмән купич

Әбделмән купичның 51 ялчысы
Баралар Гылавинга урманга.
Кяфер бәләсендин Ходай коткарсын иде,
Ак куй чалыр идем корбанга.

Кыйгак та кыйгак ни кычкыра,
Әбделмән купичның казлары.
Сембер уездында елаша йөридер
Әбделмән купичның кызлары.

Әбделмән купичның кабак алыннары,
Судлар йөри-йөри баз булды.
Унике пот иде кәгазъ акча гынам,
Башкынаем елырга аз булды.

Әбделмән купичка барып та
Фальшивый акчалар сукмасын.
Унике подвода килеп тә туктагач,
Ничек янгынаем куркмасын.

Әбделмән купичның ник биләндә
Өч кат әйләндергән шәл ука?
Әбделмән купичның нидә икән,
Кемдә ала алмаган парука.

*Спасск районы Шалдавыч авылында*
*Курамшина Рәисә Нәҗип кызыннан (1938 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

### *Алты кыр ашалый...*

Алты кыр ашалый, алты атладым,
Алтысы да бодай межасы.
Матур яр куенында өч кич кунсаң,
Онытыла дөньялар нужасы.

Алмагачтин алма алдым,
Син матур яр дип алдандым.
Алдандым, яшь егет, мин алдандым,
Синнән матур ярләр тапмадым.

Уң да кул гынамда алтын балдак,
Сул да кул гынамда бирюза.
Сөйгән егетемә бара алсам,
Өч ай тотар идем рузя.

*Шемышейка районы Оз авылында*
*Канькова Гөлҗиһан Муся кызыннан (1951 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## БАЛАЛАР ФОЛЬКЛОРЫ

Бау, бау, бау итә
Алисә йокыга китә.
Алисә йокыга китмәсә,
Пәпәләр алып китә.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Исянова РумияУсман кызыннан (1926 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Ак куянның баласын
Ебәр кырга, уйнасын.

Бер уйнасын, ике уйнасын
Аеплаштан булмасын.

*Неверкино районы Али авылында (Алявылда)*
*Сәйфуллина Кадрия Оваз кызыннан (1964 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

**_Бишек җыры_**

*Малаемны пич башына яткыздым, ерлыйм:*

Аллаһу, Аллаһу,
Алла, Раббым,
Тәүбәһу, тәүбәһу.

*Әле минем артымнан олым:*

Әпем, пәпем,
Пәпем пу!

*Неверкино районы Сарбай авылында*
*Вагапова Майзә Исхак кызыннан (1938 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Куяннар, куяннар,
Йөгереп, йөгереп уйнарлар.
Әниләре суга киткәч,
Акрып-бакрып еларлар.

* * *

Гу-гу, күгәрчен,
Әтие кайчан килерсең?
Кесәңдәге конфетыңны (тәмнеләрне)
Балакаңа (или исемен әйтергә) бирерсең.

* * *

Елама, елама,
Елы катык сорама.
Әнисе килер кичкә,
Елы катык пичтә.

*Неверкино районы Сарбай авылында*
*Паздникова Сәйдә Хафиз кызыннан (1965 елгы),*
*Рафикова Кадрия Хафиз кызыннан (1963 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## *Бишек җырлары*

Йокла, балам, йоклачы,
Мине эшсез тотмачы.
Төнне йокым калдырасың,
Көндез кала эшләрем.

* * *

Йокла, йокла, син, балам,
Сине бишеккә салам.
Син йокыга киткәнче,
Үзем янында калам.

* * *

Куяннар, куяннар
Йогыра, йогыра уйнарлар.
Тәпиләре өшегәч,
Утырышып еларлар.

* * *

Аллаһу, Аллаһу,
Кәзәләрне тауга ку.
Кумыйча да китәрләр,
Коерыгын сугып ярырлар.

*(Әби шулай әйтә иде.)*

* * *

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек.
Бер тактага тезелдек,
Таң аткынча юк булдык.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Мусина Алия Габдрахман кызыннан (1943 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Куяннар, куяннар
Йогырышып уйнарлар.
Тәпиләре өшегәч,
Утырышып еларлар.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Абдульмянова Фәридә Каюм кызыннан (1949 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Аллаһу, Аллаһу,
Качкайларны тауга ку.
Тал яфрагын ашасын,
Балам йоклый башласын.

* * *

Куяннар, куяннар,
Йөгерешеп уйнарлар.
Тал төбендә тынык су,
Тынып-тынып эчәрләр.

*Неверкино районы Бикбулат (Бикмосеевка) авылында*
*Асейдуллина Сания Вахит кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Алю-балю тал бишек,
Әти салган тар бишек.
Тар бишектә йоклатма,
Тирбәтүдән туктатма.

* * *

Гу-гу-гу-гу күгәрчен,
Әтисе качан килерсең?
Кесәңдәге канфитыңны
Лилиягә бирерсең.

*Неверкино районы Бикбулат (Бикмосеевка) авылында*
*Фәхретдинова Маһруй Үмәр кызыннан (1934 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды.*

Елама, елама
Елы катык сорама,
Елы катык пичтә,
Әниең килер кичкә.

* * *

Эй, куяннар, куяннар,
Йогырышып уйнарлар.
Аяклары өшегәч,
Акырышып еларлар.

*Неверкино районы Исәкәй авылында*
*Бахтиева Сафия Абайдулла кызыннан (1947 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Куяннар, куяннар,
Йогырышып уйнарлар.
Аяклары өшегәч,
Әбиенә килерләр.

* * *

Гу-гу-гу-гу күгәрчен,
Әнием качан килерсең?
Кесәңдәге канфитыңны
Олыңа бирерсең.

*Неверкино районы Исәкәй авылында*
*Хасянова Майзә Мөхәммәдҗан кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Кечкенә генә кеше идем,
Чиклавыкның төше идем.
Кызлар уен уйнаганда,
Иң кирәкле кеше идем.

* * *

*Бармак белән уч төбенә*:

Путь-путь путянадыр,
Кырда салам купянасы.
Карга килде – как атте,
Савыскан килде – сауме атте,

Тычкан килде – курюгы белән
Ботады, ботады, ботады, ботады...

*(Әнием шулай оланнарны уйната иде.)*

*Неверкино районы Исәкәй авылында*
*Кичуткина Нурия Мөнир кызыннан (1969 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Йокла, балам, йом күзең,
Йом-йом күзең, йолдызым,
Кичен йокыларың кала,
Елап үтә көндезең.

*(Канянам шуны гына ерлый иде. Бишекне селкетә иде, бер кулы белән оланымны ләпи иде. Шул ерны ерлый иде.)*

*Неверкино районы Җәлил авылында*
*Исянова Мәфруза Хәлилулла кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Куяннар, куяннар
Йөгерә, йөгерә уйнарлар.
Әниләре эшкә киткәч,
Кычкырып-кычкырып еларлар.

* * *

Әй тагалы, тагалы,
Тагалары базарда,
Олым укыр Казанда.

*Неверкино районы Мазарлы авылында*
*Кагарева Мөнирә Әмин кызыннан (1942 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Йокла, йокла син, балам,
Сине йокыга салам.
Син йокыга киткинче,
Мин яныңда калам.

* * *

Куяннар, куяннар,
Йөгерешеп йөрерләр.
Тал төбендә тыныч су,
Тынып-тынып эчәрләр.

* * *

Аллаһу, Аллаһу,
Алашаңны тауга ку.
Алашаң япрак ашар,
Мәрьямем йоклый башлар.

* * *

– Кызым, кая барасың?
– Әңгәригә барамын.
– Әңгәридә ни эшең?
– Савысканда йомышым.
– Савыскан сиңа ни бирер?
– Бер кабырга ит бирер.

– Аны кая куярсың?
– Тал төбенә куярмын.
– Тал төбеннән эт алыр.
– Таяк белән кывармын.
– Таяк каян алырсың?
– Бабайлар йортыннан.
– Бабайлар йортында татарлар
Сакалыңны тартарлар.
Кәзә мае сөртәрләр.
Пугрәбкә даңк итеп төртәрләр.

– Ни эзлисең?
– Энә эзлим.
– Энә нигә?
– Капчык ямарга
– Ә капчик нигә?
– Таш тутырырга.
– Таш нигә?
– Оланнарымны тукап-тукап,
Каннарын эчәргә, тыңнамаганда.

* * *

– Акмаки-шакмаки,
Арт кабакны кем шаки?
– Үзем, үзем, әбики.

* * *

Әнчи-мәнчи,
Әни миңа күлмәк үлчи.
Анда чыпчык, монда чыпчык,
Балтаңны күтәр дә чык.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Хайрова Фатыйма Исмаил кызыннан (1952 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Куяннар, куяннар,
Куяннарны куганнар.
Тауга менсәң, таптарлар,
Мылтык белән атарлар.
Уйга төшсәң – урыслар,
Артына җигелгән борзойлар.

* * *

Әлли итәр бу,
Үсеп буйга җитәр бу,
Тырышып сабак укыр бу,
Алим булып үтәр бу.

* * *

Йокла, йокла, күз нурым,
Йокла, йокла син, балам,
Сине бишеккә салам,
Син йокыга киткинче,
Үзем яныңда калам.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Айзатуллина Һава Исхак кызыннан (1937 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Йокла, йокла, син, балам,
Сине бишеккә салам.
Син йокыга киткәнче,
Үзем яныңда калам.

* * *

Яче, улым, йоклачы
Мине эшсез тотмачы.
Йортым тулы эшләрем
Эшемне калдырмачы.

* * *

Әй, куяннар, куяннар,
Йогыра-йогыра уйнярлар.
Әниләре булмаса,
Утырышып еларлар.
Әниләре килгәчтән,
Сикерешеп уйнярлар.

*Кузнецк районы Ялгаш авылында*
*Алькаева Сабира Сәет кызыннан (1946 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Әй, куяннар, куяннар,
Йогырып-йогырып уйнярлар.
Әниләре эшкә киткәч,
Акрып-акрып еларлар.

* * *

Гу-гу-гу-гу күгәрчен,
Тизме әнисе килерсең?
Кесәңдәге мәмәеңне
Галиягәме бирерсең?

*Кузнецк районы Ялгаш авылында*
*Әбдерәхимова Маһира Әнвәр кызыннан (1951 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Әй, куяннар, куяннар,
Йогырып-йогырып уйнярлар.
Әниләре эшкә киткәч,
Акрып-акрып еларлар.

* * *

– Балам, кая барасың?
– Әбиләргә барамын.
– Әбиең сиңа ни бирер?
– Бер йомырка, бер күмәч.
– Аны кая куярсың?
– Тал төбенә куярмын.
– Бүре килсә, нишләрсең?
– Акыртырмын-бакыртырмын,
Сельсоветка чакыртырмын!

*Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында*
*Курмаева Хатимә Хусяин кызыннан (1930 елгы),*
*Мендаева Халидә Хусяин кызыннан (1939 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Путь, путь, путь ана,
Карга килде как итте,
Саескан килде орлады,
Вота, вота, вота каа китте.

*(Култык асларына төртә оланның.)*

* * *

Бер тай, ике тай, өч тай, дүрт тай, биш тай, алты тай, җиде тай, сигез тай, тугыз тай, ун тай, туңкай.

*(Кайсы кала, шул тотына эзләргә, без качабыз инде әмән.)*

*Кузнецк районы Дәхтәрни авылында*
*Мусякаева Рәисә Шакир кызыннан (1945 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

Бүреләр, бүреләр
Төнне-көнне йөриләр.
Елаганны алалар,
Итеп базга салалар.

* * *

Елама-елама,
Елы катык сорама.
Елы катык пичтә,
Анаң килер кичкә.

* * *

Путь, путь, путь ана,
Путь анасы шәрәнә.
Шәрәнә бутка пешергән,
Савыскан килеп май салган,
Карга килеп бутаган,
Кемдер аны ашаган.

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Хәбибуллина Җәүһәр Усман кызыннан (1940 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

## ХАЛЫК СҮЗЛӘРЕ, ПАРЕМИЯЛӘР

Әкият әйттем бер,
Уртасында тел.
Яхшы агайлар акыл бирә
Җитмеш җиде ел.

*Неверкино районы Кырнавар авылында*
*Мусина Алия Габдрахман кызыннан (1943 елгы)*
*И.Ямалтдинов язып алды*

Пусть эте күрсен,
Тау астына төкерсен.

*Кузнецк районы Бистән авылында*
*Хайрова Фатыйма Исмаил кызыннан (1952 елгы)*
*И. Ямалтдинов язып алды*

# ЯШЬТӘН ИСТӘ КАЛГАН ФОЛЬКЛОР

*Рузия Сафиуллина*

Ел саен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белгечләре комплекслы фәнни экспедицияләргә чыгып китә. Әлеге традициягә фольклорчылар дистә еллардан бирле тугры. Илнең татарлар яшәгән төбәкләрендә Институт галимнәрнең төп максат-миссиясе – халкыбызның матди һәм матди булмаган мәдәни мирасын барлау, киләсе буыннар өчен теркәп кую. Халык иҗаты буенча калын-калын томнарга, фәнни китапларга материал архивлардан гына түгел, халыкның үзеннән табыла. Гомумән, фольклорчы, телче, этнографлар, милли сәнгатьнең төрле тармакларын өйрәнүче галимнәр өчен фәнни экспедиция, Г. Ибраһимов исемендәге институт оештырылганнан бирле, изге эш итеп карала. Экспедицияләргә мәшһүр Латыйф Җәләй дә, Хәмит Ярми һ. б. да йөргән. Узган гасырда Г. Бәширов, Н. Исәнбәт, М. Мәһдиев, Э. Касыймов, Ә. Рәшит һ. б. кебек язучыларыбыз да, фольклор җыючылар сыйфатында, экспедиция сукмакларын байтак таптаган.

Комплекслы экспедицияләрдә, ягъни алдан планлаштырылган фәнни сәфәрләрдә төрле белгечләр – борынгы кульязма һәм кабер ташларын өйрәнүчеләр дә, этномузыколог һәм сәнгать белгечләре дә, фольклорчылар һәм диалектологлар һ. б. да катнаша. Сукмаклар кайсы гына төбәккә илтмәсен, фән әһелләре ерак сәфәрләргә энтузиазм, һөнәри кызыксыну һәм милләттәшләргә туганлык хисләре белән юнәлә. Кайвакыт

экспедиция элегрәк эшләгән татар авылларына кабат барып чыгасың. Мәсәлән, Пенза өлкәсенең татар авылларын, атаклы фольклорчы Х. Ярми төркеме чыгуга ярты гасырдан артык вакыт узганнан соң, 2007 елда да, 2021–2022 дә дә гизәргә туры килде. Мондый хәлләр, әлбәттә, язмыш бүләге дип кабул ителә, чөнки галимнәрне эчәсе суы һәм ризыгы гына түгел, истәлекле очрашулар, яңа тәэсирләр, информантлардан язып алынасы фольклор үрнәкләре дә йөртә.

Башта Югары Әләзәндә эшләдек. Авылны икенче төрле Аенбура дип тә атыйлар (төгәл генә мәгънәсен халык белми, әллә ничә төрле фараз бар. Мәсәлән, читтәрәк котырып үскән паслен үләнен *аенбура* дип атаганнар. Авыл исеме дә шуннан калган, имеш).

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты экспедицияләргә буш кул белән чыкмый: авыл мәдәният йортларына һәм мәктәпләргә үзендә әзерләнгән һәм бастырып чыгарылган татарча китапларны бүләк итеп калдыра. Шулай итеп, татарча аңлатмалы, диалектологик, төрле тармак терминнары сүзлекләре, «Милли-мәдәни мирасыбыз» һ. б. серияләрдә дөнья күргән затлы басмаларның иң беренче тупламасы аенбуралыларга тапшырылды.

Бәет, мөнәҗәт, котлау шигырьләре чыгаручы Румия Булатованың өендә булдык. Ул мәктәптә рус теле һәм әдәбиятын укыткан, шактый еллар мәктәп директоры булган. Лаеклы ялга чыккач, мөнәҗәт, бәетләр чыгара башлаган. Бу әсәрләрнең сәнгати кыйммәте төрлечә, шулай да алар Коръән мәҗлесләрендә, авыл кичәләрендә даими яңгырый. Бүгенге мөнәҗәтче үз иҗатын хәтта популяр мессенджерлардагы авыл төркемнәренә куя. Бәетче-мөнәҗәтче әби-апалар һәр авылда диярлек очрады. Алар авылдашларына төрле фаҗигалы хәлләрне үткәреп җибәрергә булышалар, аерым гаиләгә килгән кайгыны күтәрешәләр. Шунысын да онытмыйк: халык көйчеләре көйләгән йөз бәет-мөнәҗәтнең берәрсе оныклары колагына барыбер кереп калыр, дип уйларга нигез бар. Димәк, Румия апа кебек бәетче-мөнәҗәтче ханымнар телебезне саклауга үз өлешен кертә, татар сүзенә, халык иҗатына карата кызыксыну уята.

Маршруттагы икенче авыл – шулай ук Әләзән иде (Әләзәннәр Городище районында өчәү). Урта Әләзән авылы Югарысыннан берничә чакрымда гына урнашкан. Ул Россиядәге иң зур татар авылы санала, анда 9–10 мең кеше яши, кайбер информантлар әйтүенчә, хәтта 12 меңгә җитә.

2007 елда, ТӘһСИ экспедициясе составында Әләзәнгә беренче тапкыр баруыбызда, өлкәнең татар авылларын бик әйбәт белгән милли җанлы Кязим Шаһазам улы Дебердеев (1954–2018) белән танышкан идек. Ул безнең дүрт кешедән торган төркемне (Илсөяр Закирова, Айсылу Садекова, Рузия Сафиуллина, Алёна Фәрхетдинова) өлкәнең берничә авылына алып барды. Заманында зур һәм алдынгы совхоз белән җитәкчелек иткән, Городище районы башлыгы, өлкә губернаторы ярдәмчесе булган зат ул. Урта Әләзәндә Сабан туе үткәрү традициясен дә Кязыйм абый башлап җибәргән, Урта Әләзәннең тарихы һәм шәхесләре, халык иҗаты турында китап нәшер итүне оештырган. Без аңардан мәкальләр, такмаклар да язып алган идек. Кызганыч ки, 2021 елгы сәфәребездә инде аны очратмадык – әлеге фидакяр шәхес, атаклы морзалар нәселе вәкиле бакыйлыкка күчкән иде. Истәлеккә Кязыйм Дебердеевтән ишеткән фольклор үрнәкләре калды, мәкаләдә алар белән беркадәр таныштырырбыз.

Шулай ук авылның дистәләгән кешесеннән төрле фольклор жанрларына караган байтак текст һәм магнитофон язмалары җыя алдык. Өлкән буын, нигездә, бәет һәм озын җырлар җырласа, яшьрәк, пенсия яшенә җитмәгән информантлар такмаклар әйтә иде. Гомумән, әлеге тенденция Урта Әләзәндә генә түгел, Пенза өлкәсенең башка татар авылларында да күзәтелә. Һәм без бу күренеш белән 2021–2022 елларда Пенза өлкәсенә үткәрелгән комплексклы экспедицияләрдә дә еш очраштык.

Экспедициядә йөргәндә һәр авылда диярлек иң элек мәктәптә һәм мәдәният йортында тукталабыз. Гомумән, укытучылар һәм клуб хезмәткәрләре – иң зур ярдәмчеләребез. Кайда гына булсак та, татар теле укытучылары ярдәмгә килә. Алар – өлкән һәм урта буын вәкилләре, татар фольклоры белән яхшы таныш, күбесе студент вакытта үзләре дә экспедицияләрдә йөргән. Шулай итеп, мөгаллимнәр һәм мәдәният хезмәткәрләре

безгә үз хәтер сандыгыннан берничә оригиналь уен (дистәгә якын варианты белән бергә), әкият, такмак һ. б. әсәрләр «алып бирде». Югары Әләзәннән Галия Байбекова, Урта Әләзәннән пенсиядәге укытучы Алия Сәнҗапова, музыка укытучысы Асия Синҗапова, Түбән Әләзәннән Сания Әбхаерова-Кузгунова, Лопатино районының Иске Вершаут авылыннан Дания Алеева, Иске Карлыганнан Рәйсә Мусякаева, Шемышейка районы Оз авылыннан 47 ел стажы булган тарихчы Румия Абкаева, Исса районы Шыкша авылыннан Фәридә Калашникова-га, ана теле укытучылары – Белинский районы Качкарудан (Кутеевка) Гөлнара Дубинага, Каменка районы Кикин авылыннан Равилә Баткаевага һ. б. аерым рәхмәтләремне җиткерәм.

Кикин авылы мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укытучы Равилә Баткаева турында аерым әйтергә кирәктер. Югары белем алып, туган авылындагы урта мәктәптә эшли башлаганнан бирле, ул укучылар белән бергә Кикин халкыннан фольклор үрнәкләре җыя. Елның елында аның укучылары әби-бабайлардан табышмак-мәкаль, мөнәҗәт, әкият, уеннар һ. б. сөйләтә, язып ала, паспортын төзи һәм мәктәпкә алып килеп тапшыра. Бу эштән бер генә укучы да читтә калырга тиеш түгел. Яшьләр өлкән буын вәкилләреннән ишеткәнне гомерлеккә истә калдырсын, халкыбызның мәдәни кодын сеңдерсен, авылы һәм нәсел-ыруы белән горурлансын өчен шулай эшләнә бу. Ә Кикин халкының чынлап та горурланырлыгы бар. Биредә беренче татар прозаигы, «Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә» романы авторы Заһир Бигиев һәм аның энесе – фәлсәфәче, ислам белгече Муса Бигиев туган. Шулай ук кикинлылар атаклы хәрби, патша йомышлысы Арыслан Палкайны да үз авылларыннан чыккан дип саныйлар, аның турындагы фольклор буыннан буынга күчә килә. (Палкай турындагы риваять-легендалар бу як авылларына гомумән хас, һәрберсе әлеге легендар шәхесне үз авылына нисбәтле итәргә тели.)

Билгеле, фольклор җыюда безгә мәдәният хезмәткәрләре дә эчкерсез ярдәм күрсәтте. Авыл мәдәният йортларында эшләүчеләрдән Каменка районы мәдәният йорты методисты Равза Мизитова, Кикин авылыннан Гөлнара Баткаева, Кобылкин авылыннан Альбина Акжигитова, Пачелма рай-

оны Решетин авылыннан Әлфия Таишева һ. б. экспедициягә хәлләреннән килгәнчә булышлык итте.

* * *

Шунысын искәртү мөһим, төрле авыллардагы информантлар безгә татар халык иҗатының бүгенге үрнәкләрен түгел, ә моннан 20–30–50 еллар элек булган хәлләрне сөйлиләр. Алар балачакта һәм яшьлектә уйнаган уеннарын, күңел ачу ысулларын (вечер, утырыш), туй-никах йолалары белән бәйле фольклорны һ. б. искә төшерә.

Уеннар дигәндә, бу экспедициядә балалар уеннары да, үсмерләр һәм яшь-җилкенчәк уеннары да байтак язып алынды. Әгәр бер үк уенның төрле вариантларын да исәпкә алсак, кырыктан артык уен теркәлде. Мәсәлән, «Игеннәр чәчтек без» уены Лопатино районының төрле авылларында гына да 3–4 вариантта уйнала. Аерма – я атамада (мәсәлән, «игеннәр» урынына «бәрәңгеләр»), я уенның барышында (хәрәкәтләрдә, уен тәртибендә, тасвирламасында, сүзләрендә яисә җыр сүзләрендә). Пенза өлкәсе татар авылларына түбәндәге балалар уеннары хас: классик «качыш», «йөзек салыш» һ. б.; күрше-тирә халыкларныкына охшаш уеннар («лапта», «черта» һ. б.); оригиналь уеннар (татар уеннарын өйрәнгән фольклорчылар Н. Исәнбәт, Р. Ягъфәров төзегән җыентыкларда очрамый торганнары). Оригиналь уеннарны берничә авылда язып алдык. Шуларның берсе – «Чәчәк» уены. Совет чоры балалары уйнап үскән аны.

Шунысы игътибарга лаек: уеннар төрле тарихи чорларга карый. Арада борынгыдан килгән һәм балалар фольклоры җыентыкларына классик уен булып кергәннәре дә, совет чорында уйналганнары да бар. Хәзерге чор уеннарын язып алу мөмкин булмады, чөнки информантларыбыз – 40–50 яшьтән узган кешеләр – бүгенге уеннар белән алар буыны, билгеле, таныш түгел. Икенчедән, хәзерге вакытта 15–25–30 яшьлекләрне милли уеннар уйнап үскән буын дип әйтеп булмый, чөнки аларны күбрәк компьютер, смартфон уеннары кызыксындыра. Өченчедән, кайбер балалар һәм яшьләр хәзер хәтта авыл җирендә дә татар телен начар белә, алар белән фәкать русча

гына сөйләшеп-аралашып була. Балалар мәктәптә өйрәнгән яки (сирәк кенә) яшьтәшләре белән рус телендә уйнаган уеннарын аңлатып бирә ала. Кайберләре татарча әкият исемнәрен, персонажларын искә төшерә.

Үсмерләр һәм яшь-җилкенчәк уеннарына килгәндә, аларны шулай ук әби-бабайлар сөйләде, кайбер очракларда хәрәкәтләрен дә күрсәтеп бирде. Әлеге төр күңел ачуларда да тарихи чорларга бүленеш аермачык күренә. Мәсәлән, «Игеннәр чәчтек без», «Без бәрәңге утырттык», «Зеләйлү», «Йөзек салу» кебек уеннар бер-ике гасырлык яки аннан да борынгырак тарихка ия. Бу турыда балалар фольклоры буенча зур белгеч Рәшит Ягъфәров искәртә[1]. Без бу уеннарның берике вариантын Пенза өлкәсе Лопатино районында язып алдык. Шунысын да искәртергә кирәк: әлеге уеннарны яшүсмерләр яки егет-кызлар тулаем уен фольклорына хас рәвештә уйнаса да, соңыннан алар кечерәк яшьтәге балалар фольклорына күчкән. Хәзерге вакытта бу уеннарны башлангыч мәктәп һәм балалар бакчаларына йөрүче балалар да уйный.

Пенза өлкәсендә мишәр татарлары яшәгән якларга хас оригиналь уеннарны теркәдек. Мәсәлән, «Әмбәлүк», «Бишун», «Перәшкә», «Ялкын», «Ике ялкын» һ. б. – шундыйлардан. Аларны җиткән егет-кызлар совет заманында кичләрен уйнаган. Аларның совет чорына каравын егет һәм кызларның шактый тыгыз аралашып уйнавыннан күреп була. Ислам әдәпкагыйдәләре тамыр җәйгән мишәр татарлары төбәкләрендә элеккеге чорларда мондый уеннар, билгеле, уйналмаган.

Милли уеннар В. Всеволодский-Гернгросс классификациясендә зур өч төркемгә (драматик, спорт һәм орнаменталь) бүленүен истә тотсак, безнең экспедициядә аларның һәрберсенә мисаллар язып алынды.

Тупланган материалны (күбесенчә, диктофон язмалары) әлеге мәкаләдә хронологик тәртиптә, авыллар буенча һәм шулай ук фольклор жанрларын да исәпкә алган хәлдә күрсәтеп бару кулай дип табылды.

---

[1] Татар халык иҗаты: Балалар фольклоры / төз., кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Р.Ф. Ягъфәров; ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘТИ. – Казан, 1993. – Б. 18.

## Городище районы Югары Әләзән авылында язып алганнардан

Әлеге авылда иң беренче аралашкан информантыбыз – китапханәче Пономарева Нәҗия Искәндәр кызы (1965 елгы). Ул авыл яшьләренең 1980 елларда ничек итеп күңел ачуы турында сөйләде:

### *Вечер*

*Авылда вечерларга йөри идек. Такмаклар күп белә идек, көлешеп ала торганнарны күбрәк. Вечерларда әтә торган такмаклардан берсе:*

*Галиямә, бәгыремә*
*Газет укытыр идем.*
*Роза гөлләр арасына*
*Итеп утыртыр идем.*

### *Боз озату*

*Яз башы йитә иде, и бездә ташулар була, зур су ага иде. Плотина кебек. Бумабыз ерыла иде, ерылгач сулар агып китә. Ферма бумасы (хазер дә бар), инешне буганнар. Инешебез Әләзән дип атала, елганың нәкъ башланган җире, бездә «тозлык» әтелә. Ул елганың иң ару йире санала, кер чайкарга да бара иделәр. Ну оланнар да егылып төшкәне бар Ферма бумасына. Аннан кечерәге – Бетмә бумасы. Мунчальник бумасы, Сальмушин бумасы, мәчет артында зур бума – Гельдыр бумасы, Орешник бумасы. Корка очы, Салма очы, Бәлчек очы, Рагатка очы, Не хотел очы, Клязьма очы һ. б. Совхозыбыз «Алга» дип атала иде, шул очлардан шул бумаларга боз озатырга бара идек.*

*И шында яшьләр, кызлар, малайлар яр башына китә идек. Картлар да китә иде, таякка таянып. Анда инде уйный идек, йырлар да, биюләр дә була, күргәзә идек нигә сәләтебез барын. Бездә халык такмак әтергә бик оста, такмак әтә идек.*

*Боз озатканда «Наза», «Йөзек салу» уйный идек. Йомырка каталата идек. Карзинга йомырка тийиләр дә алып киләләр. Йомырканы йорт буйлап җыеп йөрмәдек, үдән (өйдән) әниләр алып килә. Шындагы балаларга өләшәләр. Аннан яхшы утырышып каталата идек таудан. Кемнеке тирәнрәк китә, шул*

*җиңә. Кечерәк чакта «Чертадан» уйнадык. «Әмбәлүк» уйнадык зуррак үскәч.*

## Икенче авыл –
## Городище районы Урта Әләзән авылы

Авыллар бер-берсенә якын урнашкан булсалар да, яшьләр һәм балалар уеннары вариантлылыгы белән аерылып тора. Мәсәлән, Урта Әләзәндәге информантларыбыз ***Бухминова Рәйсә Әсәдулла кызы*** (1960 елгы), ***Альмяшева Гүзәл Равил кызы*** (1976 елгы) сүзләренә караганда, алар «Ашык», «Аюдан качу», «Черта», «Ике ялкын», «Кул сугышы», «Перәшкә» кебек уеннар уйнап үскәннәр. Бу уеннар һәр авылда үзенчә уйнала.

«Балалар элке үз күңелен үзе күрә иде, авыл җирендә олыларның олан уйнатып йөрергә булмый иде. “Ашыктан”, “Чертадан” уйный идек. Үскәч, вечерларга барып, зурраклар уйный торган уеннар уйный идек: “Перәшкә” (Номер), “Бишун” һ. б.», – дип сөйләде пенсиядәге педагог Сенҗапова Алия Абдулла кызы һәм кайбер уеннарның хәрәкәтләрен дә күрсәтте.

### *Ашык уены*

*2 бала утырып уни. 5–6 куй сүәге (ашык) кирәк. Ашыкларны югарыга күтәреп ыргытырга кирәк, кайсы артыннан кайсын ыргытырга икәнен белә идек без. Башта берне аласың да икенчесен сикертәсең. Аннан икене аласың да өченчесен кул арыкылы күтәреп ыргытасың. Моны куясың, өчне аласың да тагы кул аркылы сикертәсең. Аннан бишне сикертәсең. Сикергән арада син шул ашыкны икенче кулың белән элеп алырга тиеш. Эләктерә алмасаң, икенче кеше уйный башлый. Ашыклар уртак та була, һәркемнең үзенеке дә була иде.*

### *Вечер*

*Кызлар, вечерларга җыела идек яшь чакта. Ул вечерларны шул вакытта ясыйлар: берәр эш булганда. Качан утын кистерәләр, утын ярдыралар, каз йолкалар һ. б. Өмәдән соң кызларга вечер була. Ул вечерда башта Круг унилар. Кызлар тотыналар үдә, кругтан ерлап-ерлап унилар. Уртада инде ике кеше бии. Утырышалар ыстулларга. Өлгергән кеше утырып кала. Син өлгермисең икән утырырга, басып каласың, ерлаталар.*

*Тагын бер төрле дә унилар иде. Кругка басканнар, уртада тора бер ыстул (урындык), анарга утырган ике кеше, сүләшмиләр, мышсыз утыралар. Урындык тирәли ерлап йөри ике кеше (кыз белән малай или кызлар гына). Ерлап беткәч, утырганның берсе тора, ерларга чыга, аның урынына икенче берсе утыра. Алар ерлап бетергәч, кругтан берсе баса ерларга, берсе стулга утыра. Шылай алмашып-алмашып унилар иде.*

### ***Кул сугышы***

*Күп кеше уни иде. Бер кеше уртага баса, калганнар круг тирәли ыстулга утырган, куллары тездә. Ул кеше кая утыргысы кели, шул кеше каршына бара, тегенең кулына суга. Теге тора, бу аның урынына утыра. Шылай урын алыштыру бара инде. Анысында сүләшәләр дә. Дуслар или берсен-берсе яраткан кыз-малай бергә туры килергә тырыша, аларны кайвакыт юри аерырга да тырышалар. Анда гармонист булса, гармун да уни , уен бик кыза. Урыннарны тиз-тиз алмашалар.*

### ***Перәшкә (Номер)***

*Кызлар утырган, бер йигет чыга перәшкә белән. Ул чалбар билбавы, күлмәкнеке тегел! Каеш! И нибарын (уенчыларны) санап чыга. Һәрберсенә номерларын әтә. Үз номерларын истә калдыралар. Хазер перәшкә тоткан малай ике санны әтә, мәсәлән, 5 белән 11. Болар тиз-тиз утырган урыннарын алмашырга тиеш. Перәшкәле йигет килеп җиткәнче кайсы утырып өлгермәсә, шул кешегә каешы белән берне сыза. Кызганып тормый, ну сугылган кыз барыбер түзәргә, кычкырмаска тиеш. Бервакыт мине дә шылай номер әтеп чыгардылар, каешын тотып килеп җиткән теге артыма сугарга. Мин бастым да каршына: «Сугып бак! – дим, миннән малайлар курка иде – миңа анам сукмады, синнән суктырып тораммы?!»*

### ***Чиядән (Дүртәү бию)***

*Идән уртасына дүртәү басканнар, такмак бии, калганнары утырган, такмак әтә. Аннан икесе кала, тегеләр утыра. Ә бу ике кеше тагы икене үзләре сайлап чыгара. Такмак әтеп биючеләре крест-накрест парлашып бии.*

Асия апа өенә урта мәктәптә математика укытучысы булып эшләүче Уразаева Әлфия Юсеф кызы (1990 елгы) озата барды, ул да үзе белгәннәрне өстәде.

***Черта (Әй)***

*Черта ул тартма белән. «Бака уенына баз казыймын», атеп-атеп уни идек, штоб йиңмәсеннәр үзеңне.*

*Ике яклап дүртәр шакмакны сызасың, сигез квадрат була. Һәр шакмак – бер «әй». (Беренче әй, икенче әй, өченче әй, дүртенче, ... сигезенче әй) . Син, например, унисың, әй бишенче, әй алтынчы.*

*Башлап киткәндә, беренче әй яныннан 1ле язылган квадратка сикерәләр. Аягы белән сызыкка сикереп басмаса, тартмасы да тимәсә, сызыкның тышына чыга да икенче әйгә сикерә. Беренче әйне үттең – аннан шылай, 3, 4... 8 әйгә дә җитәргә мөмкин.*

*Тартма эченә (консерва калае, монпасье конфет тартмасы да була иде) балчык тутырасың да сикерә-сикерә шуны аягың белән төртеп йөрисең. Төрткәндә яхшы карарга, «әй» сызыкларына тартмаң да, аягың да тимәсен. Линияга тисә, тартма яна, шул ук әйеңдә каласың, например, беренче класста. Ераграк сикерә алсаң – яхшырак. 8 нче әй ерак бит, баскан урыныңнан сикереп, тартмаңны төртер өчен бик каты тырышырга туры килә. 4–5 кеше уни идек.*

Совет чорында үскән буын әле халык иҗатын күңелендә саклый, оныкларына да тапшыра:

*Бала чакта табышмаклар, әхиятләр, мәкальләр атеп күңел ача идек, олылардан ишетеп алабыз да. Балалар бездә әле хәзер дә табышмак, мәкаль ишетеп үсә.*

Табышмак:

*Әкият әйттем бер: уртасында тил, акылсызга акыл эрәттем алтмыш алты йел. (Бизмән)*

*Үзе шардай, эче балдай. (Карбыз)*

Мәкальләр:

*Кем эшләми, ул ашамый. (Бездә моны бик еш атялар, ялкауларны яратмыйлар бер дә.)*

*Ялкауга – ян. (Эштән качып йөрүчегә атялар.)*

*Үзеннән артык чагасын (баласын) мәче дә ашый.*
*Кеше ни әйтми, Аллаһ югалтмый.*
*Малай анасы – санат, кыз анасы – ус..к солдат.*
*Һәр сарайның эче буш түгел.*
*Югары бак та фикер ит, төпкә бак та шөкер ит.*
*Һәр гаиләнең үз музыкасы бар, бер өй дә тормый кайгысыз.*

2021 елда җыелганнарга өстәп, шушы урында әлеге мәкаләнең керешендә искә алган Кязим Шаһазам улы Дебердеевтән 2007 елгы экспедициядә язылган диктофон язмасыннан кыска гына өзек китерүне кирәк таптык. К. Дебердеев сөйләвенчә, совет заманында авыл яшьләре кичләрен вечерларга чыккан.

*Кичке уеннарда биегәндә, туйларда такмак әйтү бар иде. Бик оста такмак әйтүчеләр бар иде, берне җырлаган саен, тагын искә төшә. Бу үзенә күрә ярыш кебек тә булган. Такмакта мактаганнар да, кайвакытта тәнкыйтьләгәннәр дә. Авыл яшьләре, такмакларга җавап итеп, такмак әйтә идек. Җавап тапмасаң, оятка да калдыралар.*

*Кызлар артыннан чабасың,*
*Авыртмыймы тәпиең?*
*Вечерларда йөргән өчен*
*Орышмыймы әтиең?*

*Олылардан ишеткән мәкальләр бик истә. Бездә сүзне мәкаль-әйтем белән бетереп кую бар иде, яшьтән колакка кереп калган:*
*Гаепләгән гаеп таба, эшләгән кеше эш таба.* (Мәкаль)
*Атың тартканда утырт.* (Әйтем)

Әләзәннәр – өчәү дигән идек бит әле. Өченчесе – **Городище районы Түбән Әләзән авылы.**

Әлеге авылда безне җиккән-бизәлгән ат, гармуннар белән авыл башына ук чыгып каршы алдылар. Авылда мәдәният йортында «Каз йолку» фольклор-йола күренешен сәхнәләштереп күрсәттеләр. Халыкның милли-мәдәни мирасына да, татар халык иҗатына да бик уңай мөнәсәбәтнең мисалын күрдек монда. Мәдәният йортына татар халык иҗатын белүче кешеләр

төркеме җыелган, хәтер сандыкларының төбеннән милли хәзинәләребезне барлап, безне инде көтеп торалар иде.

Яшьләрнең күңел ачу ысуллары – Югары һәм Урта Әләзәннәрнеке белән бик охшаш, уен атамалары («Перәшкә», «Бишун», «Ялкын», «Ике ялкын», «Черта» һ. б.) кабатлана. Вечерлар да шундыйрак «сценарий» буенча узган. Шулай да берничә үзгәрәк кызыклы мисалны карап китик. Алар турында, нигездә, мәктәп директоры булып эшләгән, хәзер пенсиядәге укытучы Абхаерова-Кузгунова Сания Ибраһим кызыннан (1953 елгы) язып алдык:

***Вечер***

*Уеннардан бу авыл өчен «Чәчәк йөзеш» (биюле уен) хас. Вечерда, егетләрне армиягә озатканда или туйдан соң или просто яшьләр җыелганда уйный идек. Вечерга иң якын кызлар килә, ә малайлар – кем тели, барысы да.*

*Анда куела өстәл, кунаклар саны чикләнгән, например, 100 кеше. Ашарга куялар. Гармун, баянга да ерлыйлар, бииләр, магнитофон да куялар иде. Аерым такмаклары истә калган:*

*Сандугачлар югары,*
*Югарыда юллары.*
*Каршымдагы өстәлләрдә*
*Утырган җәннәт хурлары.*

*Чаадайны су баса,*
*Чаадайны су баса,*
*Әләзәнне басар иде,*
*Матур кызлар булмаса һ. б.*

***Өченче артык***

*Йорт уртасында 5 ыстул, 6 уенчы. Музыка (баян) уйнаганда йөриләр урындыклар тирәли. Музыканы кинәт кенә бетерәләр. Утырырга өлгермәгән кеше уеннан чыга.*

Бу авылда байтак такмак, шулай ук хәзерге заманда чыгарылган бәетләр язып алдык, аларны олы яшьтәге апалар төрле мәҗлесләрдә, кайвакыт хатемнәрдә башкара икән. Мәкаләбезнең темасына туры килмәгәнгә, әлеге фольклорны киләчәктә языласылары өчен калдырып торырга булдык.

Лопатино районында шулай ук татар авыллары бар. Зур авылларның берсе – Селәү (Суляевка). Селәү халкының үз тарихына, традицияләре һәм көнкүрешенә, атаклы кешеләренә мөнәсәбәтен күрсәткән «Суляевка в краю родников. История татарского села. Саратов, 2020» китабын нәшер иткәннәр бирәдә. Авторы – тарих фәннәре кандидаты Артур (Али) Әхәт улы Хәбибуллин. Китапта бераз җирле фольклор үрнәкләре дә бар: дини-фәлсәфи эчтәлектәге мөнәҗәтләр, «кыз елату» җырлары, никах-туй йолалары. Әлеге фольклор белән тулырак итеп Туктарова Кадирия Сәфәр кызы (1939 елгы) таныштырды. Ул Иске Вершауттан килен булып төшкән, пенсиягә чыкканчы сыер савучы булып хезмәт куйган.

*Кызлар кияүгә чыкканда ызба киендерү бар. Иң якын берике кыз килә, канигәч. Ерлый-ерлый киендерәләр иде. Ызба киендергәндә 12 йөзлек (чиккән сөлге) тага идем. Җәйгеч, намазлык, йөзлекләр, челтәрләр үзем эшләгән. Намазлыкны кайнанама бирдем.*

*Шагыйрь Мөнир Мазунов ыруы без, куяным. Ул Казанда эшләде, без яшь чакта кайтып йөри, уеннарыбызны да карый, кайчакларда кызыксынып үзе дә катнаша иде. Бу авылда да яшьләр күңел ачарга чыга иде, «Зеләйлү» уйный идек без.*

### *Зәйлел-Зеләйлү*

*Кич җиткәч, киенеп-ясанып уйнарга төшә идек. Ташу багарга төшкәч тә, шуны уйный идек: болында «Зеләйлү». Ике рәттән баса идек. Егетләр дә булса, – егетләр бер рәт, кызлар бер рәт. Ике рәт кара-каршы ерлап килә идек.*

Блокнот-дәфтәрен яки диктофонын тотып авыл урамын урап килергә уйлаган кешегә фольклор хәзинәсе гел очрап тора. Шөкер, татар авылларында әле әңгәмә корырлык әбибабайлар, апа-абыйлар җитәрлек. Селәү урамы буйлап клубтан бераз ары киткәч, капка төбендәге эскәмиядә ял итеп утыручы Туктаров Әнвәр Мостафа улын (1940 елгы) очраттык. Ул шушы авылда туып үскән, шунда 6 сыйныф бетергән, комбайнчы хезмәтендә эшләп, пенсиягә чыккан. Бала, үсмер чакларында авылда нинди уеннар уйнап үскәннәре турында сөйләде.

### ***Чүрәкәдән***

*Чиратлашып таяк белән чүрәкә суга идек. Җиргә баз казый идек, тирәнне түгел. Чүрәкә – 20 сантиметрлы түгәрәк таяк, утыртып куя идек аны базга. Чүрәкә тирәсенә чыбык белән җиргә черта сыза идек: 2×2 метрлы квадрат инде. Үз палкаң (бер метр озынлыктагы таяк) белән астан эләктереп алып, чүрәкәгә сугасың. Ераграк очарга тиеш, чертаның тышына чыгып. Кемнең чүрәкәсе квадрат эченә төшсә, ул яңадан суга. Чертага килеп төшсә, аның чираты башка уенчыга күчә.*

*Тегендә бер кеше чүрәкәләрне биреп тора. Әгәр ул биргәндә чүрәкә кешегә тисә, башка кешене дежур итеп куялар.*

*Уен чиратын болай билгели идек: фуражка эченә малайлар исемнәрен кәгазьгә язып салабыз. Бер малай карамыйча гына кәгазьне ала да исемне укый. Аннан икенче, өченче кешенекен һ. б.*

### ***Ташу киткәндә***

*Боз өстенә саламга ут кабызып йибәрә кидек. Ярдан бакканда уеннар да уйнадык.*

### ***Кулёк (Клюк)***

*Трубанымы, таякнымы кисәләр, 80 см буладыр. Юналар, бер башын очлы итеп. Утыртып куялар түгәрәк уртасына. Ул кулёк була. Бер малай шынарга (шуңа) үз таягы белән сугарга тиеш. Нинди арадан бәрергә икәнен алдан сүләшеп куялар. Суга торган кеше как можно ераграк кулёкны ыргытырга тырыша. Аннары таягын үзе барып алырга дип, тегендә чаба. Ул барып алган арада калганнар тырыша тизрәк килеп җитәргә монда. Шабага тартып чират билгели идек: фуражкага малайларның исемнәрен язып салабыз, бер кеше тартып чыгара, кем чираты икәнне укый.*

### ***Вайнадан***

*Ике команда кара-каршы якта. Аралары 30 метр булыр. Команда булуга, кара-каршы чабалар бер-берсен пленга алырга. Пленга кайсы команда алдан алып бетерә, шул җиңгән була.*

### *Перәшкәдән*

*Үсә төшкәч, вечерларга да бара идек. Анда инде кызлар да була. Егетеме, кызымы, барысы да утырганнар. Бер кешенең кулында перәшкә (каеш). Перәшкәсе белән берәр кешегә китерә дә суга. Суктырасы килмәсә, ул кеше, торып, тиз генә урынын бирә. Урынын биргән кеше каеш белән үзе суга.*

Еш кына информантларыбыз балачаклары – сугыш елларына, яшьлекләре сугыштан соңгы авыр чорга туры килүен искә төшереп, күңел ачарга, уеннар уйнарга туры килмәвен сөйли. **Пенза өлкәсе Исса районы Югары Салмука авылында** информантлар белән очрашу да шулайрак башланды. Шадырахманова Абибә Ибраһим кызы (1939 елгы) түбәндәгеләрне сөйләде:

*Яшь вакытта кеңел ачырга безгә булмады шул, маем. Гел эш эшләттеләр безне, атасыз үстек. Әбидән девалар (догалар) ишеттек, шыларны кабатладык. Кич утырганда да кул эшләре эшләп утырдык, әби яныбызда, девалар укый идек. Ерламадык, биемәдек.*

*Яттым Хак янына, сыгындым Сөбханыма.*
*Иртән торып сәлам бирдем*
*Рәҗәб атлы дусларыма.*
*Уң янтыгымда Коръаным,*
*Укыйм изге Китабым.*
*Хәсән-Хөсәен туганым,*
*Әйшә-Патыйма сеңелем.*
*Үләрменме, калырмынмы –*
*Хак белсен,*
*Иманым анык булсын,*
*Фирештәм танык булсын.*
*Тирә-ягым тимер казык,*
*Аягым очында картлык.*

### Исса районы Югары Салмука авылы

*Безнең авылда олан чактан ук аерым уйнау булмады, кызлар – малайлар бергә уйнап үстек. Ирем белән бергә уйнап үстек, бер класста укыдык, 12 яшьтән бирле гашыйк булып, 10 ел йөреп өйләнештек. (Башта Мәскәүгә мин киттем,*

*аннары, өйләнешкәч, ирем дә килде. Җәйләрен төп нигезгә кайтып ял итәбез). Без уеннарны күп уйный идек. Хәзерге балалар уйнамый выт алар, телефонга багып утыралар.*

*Элеке шулай лапта уйный идек.*

### *Лапта*

*Ике командага тигез итеп аерыласың. Командага бүлешү дөрес и тиз булсын өчен, зур түгәрәк ясап баса идек. Бер кешене кучарка[1] итәбез, ул тугыз ун-адым алгарак китеп, түгәрәккә карата аркасы белән баскан. Без инде күмәкләшеп:*

*Кучарка, кучарка,*
*Тоталмыйсың никогда! –*

*дип кычкырабыз.*

*Кучарка түгәрәккә арты белән атлап якыная, аннары берәребезнең сыртына килеп бәрелә. Шул кеше кругтан ары китеп баса. Кучарка кругка таба берничә тапкыр килә, бәрелгән балалар китә баралар. Ике тигез командага бүленгәч, калган уенчылар бире кала.*

*Аннары инде уен башлана. Җиргә бик зур круг сызасың, бер команда шунда керә. Икенче командада мәч (туп), алар тегендә мәчкә суга, круг эчендәге команда монда тота. Тотсалар, үзләренә очко санала. Бар бик каты сугучылар, мәч әллә кая очып китә. Бар тиха[2] гына сугучылар. Аннары урыннарны алмашасың, круг эченә икенче команда керергә дә мәчне тотарга тиеш. 14–15 яшьләргә тикле яратып уйнадык әле без бу уенны.*

*Сәитова Рауза Искәндәр кызыннан (1954 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

## Лопатино районы Иске Вершаут авылы

Биредә яшьлек белән бәйле байтак җыр-такмак язып алынды, уен коллекциябезне дә тулыландырдык.

### *Елан*

*«Елан» уенын уни идек. Нибарча егет-кыз чылбыр кебек бер-бер артлы тезелеп, тотынып басабыз. Ике кеше тегендә (4–5 метрда), кулларын күтәреп, капка ясап баскан.*

---

[1] Кучарка (рус. кочерга) – мич бутый торган кисәү.
[2] Тиха – әкрен.

*И пузатор, регулятор,*
*Магынитый карбиратыр,*
*Эрдиатор, юлы такыр.*
*Задний мусты, арт калюча*
*Әйләнә шылдыр-шылдыр.*

*Шуны ерлап, ике кеше арасыннан елан шикелле боргаланып-боргаланып чыга идек, яшьләргә бик кызык.*

*Кичке уеннарда күп такмак ерладык:*

*Бишмәтеңнең биш төмәсе,*
*Нигә төмәләмисең?*
*Арабыз да ерак түгел,*
*Нигә килгәләмисең?*

*Бишмәтемнең биш төмәсе,*
*Алтынчысы – каптырма.*
*Тавы биек, баскычы юк,*
*Сагынганда карарга.*

*Поезд килә, поезд килә,*
*Сигзән бер вагон белән.*
*Сигзән икенче вагонда*
*Сөйгәнем гармун белән.*

*Тракторчы, яңгыр ява,*
*Туктат тракторыңны.*
*Сөймәгән дә булыр идем,*
*Белсәм характерыңны.*

*Кимә батинки, ки чабата,*
*Чабата җиргә бата.*
*Сөймә байны, сөй уңайны,*
*Уңай күңелгә ята.*

*Яшь вакытта һәркемнең дә*
*Бик күп була сүгәне.*
*Ләкин арада бер була*
*Гомерлеккә дигәне.*

*Яшь вакытта яшьнәргә дә,*
*Күкрәргә дә көч җитә.*
*Ләкин кадерен белү кирәк,*
*Яшь вакытлар тиз үтә.*

*Чәчем озын, чәчем озын,*
*Тарагым юк тararга.*
*Алыр идем, багар идем,*
*Рәсемең юк карарга.*

*Каты каен күмере лә,*
*Каты каен күмере.*
*Кияү белән кызыбызның*
*Озын булсын үмере.*

*Каршыбызда бакчада*
*Үскәндер кызыл карбыз.*
*Кадерле кунак булдык,*
*Инде үзегез барыгыз.*

*Әнә килә автомобиль,*
*Төягәннәр пудыра.*
*Безнең авыл егетләре*
*Юлда тузан туздыра.*

*Әнә килә автомобиль,*
*Төягәннәр огурцы.*
*Безнең авыл егетләре*
*Кием эчендә бурсый.*

## *Вечерда «Зеләйлү»не җырлау*

*Кичке уенда да, эш эшләп утырганда да «Зеләйлү»не ерлый идек:*

*Зеләйлү дигән тавыш,*
*Аннан тавыш, моннан тавыш*
*Ай, Зәйлел-Зеләйлү,*
*Сөйгәнең белән кавыш.*

*Йүгәннәре булмаса да*
*Йүгәннәре булмаса.*
*Вечерда да уйнамыйлар*
*Сүгәннәре булмаса.*
*Ай, Зәйлел-Зеләйлү,*
*Сөйгәннәре булмаса.*

*Вечерга йөргәндә куфайка кияләр иде кызлар-егетләр. Башка кием булмаган бит инде, иң зат ише кием саналган. Авыррак тормышта яшәгәннәрнең анысы да булмаган әле, йә искене кигән, йә кешенекен. Андыйларны хурлап та ерлыйлар иде.*

*Куфайкасы зәләмә дә,*
*Куфайкасы зәләмә.*
*Куфайкасы зәләмәгә*
*Бер Ходаем бәләмә.*

*Киемнәре озын диеп,*
*Озынлыктан кистеңме?*
*Тилиграм баганасы*
*Булам диеп үстеңме?*

*Ак наски да киясең,*
*Күк наски да киясең.*
*Тәрәзәгә буең җитми,*
*Син дә кызлар сүәсең.*
*Ай , Зәлел-Зеләйлү,*
*Син дә кызлар сүәсең.*

*Тарелкага салып куйдым*
*Балык белән чи маең.*
*Егет сайлый-сайлый,*
*Юк битеңдә чыраең.*
*Ай , Зәлел-Зеләйлү,*
*Юк битеңдә чыраең.*

*Сәетгазова Алимә Мөхтәр кызыннан*
*Р. Сафиуллина язып алды*

Шул ук авылда Әбүзәрова Мәрфуга Хәлил кызы (1929 елгы) белән очраштык. 4 класс белемле, колхозда төрле эшләрдә эшләгән.

*Балачакта эш эшләп үстек, уенга вакыт калмый иде. Әбибабай дога, мөнәҗәт өйрәтте. Шыларны ерлый идек. Иртә кияүгә чыккач, миңа кеңел ачулар эләкмәде. Кеңел ачу – олан багу булды, анысы да эш арасында.*

*Әлли бәлли бәбкәсе,*
*Кая киткән әнкәсе.*
*Каенлыкка, җиләккә,*
*Балакаема бүләккә.*

*Әбидән мөнәҗәтләр күп ишеттем, күңел тулганда шаны ерлый идем. Яшь чакта ишеткәннәр истә.*

*«Миңа җәннәт булыр микән?» – диде Муса.*
*«Сиңа җәннәт булыр, Муса, ата-анаң риза булса».*

*«Миңа җәннәт булыр микән?» – диде Муса.*
*«Сиңа җәннәт булыр, Муса, туганыңны якын күрсәң».*

*«Миңа җәннәт булыр микән?» – диде Муса.*
*«Сиңа җәннәт булыр, Муса, атаң-анаң кадерен белсәң».*

*«Миңа җәннәт булыр микән?» – диде Муса.*
*«Сиңа җәннәт булыр, Муса, намазларың кабул булса».*

*«Миңа җәннәт булыр микән?» – диде Муса.*
*«Сиңа җәннәт булыр, Муса, догаларың кабул булса».*

*«Миңа җәннәт булыр микән?» – диде Муса.*
*«Сиңа җәннәт булыр, Муса,фарыз намазларың кабул булса».*

*«Миңа җәннәт булыр микән?» – диде Муса.*
*«Сиңа җәннәт булыр, Муса, чалган корбаннарың кабул булса».*

Авылның олы яшьтәге кешеләре янына безне мәктәптә татар һәм рус телләрен укыткан Алиева Дания Рәис кызы (1979 елгы) алып барды. Дания ханым фикеренчә, Иске Вершаут авылында татар халык иҗаты күбрәк өлкән буында сакланган, чөнки урамда җыелышып уеннар уйнарлык балалар күп түгел. Әйе, оптимизация биредә дә авыл мәктәпләренә кагылган, ана теле сәгатьләре җитәрлек булмагач, ул, мәсәлән, утыз чакрым ераклыктагы мәктәпкә йөреп эшли. Ул яшьтән уйнап үскән бер уен белән таныштырды.

### *Артыбызга бәрәңге чәчтек*

*Уенны уйнар өчен башта ике командага бүленергә, кайсысының җырны беренче җырлый башлавын билгеләргә кирәк.*

*Командаларга болай бүленергә мөмкин: ике кеше читкәрәк китеп баса да сөйләшәләр болар, «мин машина, син трактор», дип, мәсәлән. Чиратлашып, башка балалар алар янына килә дә, болар тегеләрнең һәркайсыннан колакларына пышылдап кына сорыйлар: «Машинамы, трактормы?» – дип. Кайсын сайлыйлар инде, шул командага берәм-берәм барып басалар.*

*Кеше күбрәк булган саен әйбәтрәк, егерме-егерме биш кеше дә уйный ала. Ун-унбиш метр ара калдырып, ике төркем дә кара-каршы тезелеп баса. Аннары беренче рәт җыр башлый:*

*Артыбызга бәрәңгеләр чәчтек без, чәчтек без.*

*Ике рәт кулга-кул тотынышып баса да җырлый-җырлый бер-берсенә кара-каршы атлап килә. Икенче рәт, җавап итеп, икенче юлны җырлый, бу юлы командалар бер-берсеннән ерагая. Җырның һәр юлы шул тәртиптә дәвам итә.*

*Без аларны таптарбыз, таптарбыз.*
*Ниләр белән таптарсыз, таптарсыз?*
*Атлар менеп таптарбыз, таптарбыз.*
*Каян атлар алырсыз, алырсыз?*
*Йөз сум биреп алырбыз, алырбыз.*
*Йөз сум түгел, мең сумга да бирмәбез, бирмәбез.*
*Ә соң сезгә ни кирәк, ни кирәк?..*
*... исемле малай кирәк, кирәк. (Яки кыз исемен әйтәләр.)*

*Чакырылган бала ыргылып бара, берәр пар арасын өзә. Үзе теләгән яктан бер кешене алып килә. Өзә алмаса, үзе каршы рәттә кала. Шулай бер рәт икенче рәт уенчыларын үзенә җыеп бетереп, каршыда бер генә уенчы калганчы уйныйлар.*

*Бу уенны урамда, мәктәптә, балалар белән яки вечерларда уйный идек.*

### ***Чүрәкә***

*Уртада мәрә сызып куя идек – круг, диаметры 1 метр булыр. Бер водящий керә ул мәрәгә. Унбиш-егерме сантиметрлы палка ала идек, кырыйлары очлы юнган, шул чүрәкә була. Авыш киселгән, 30 градус итеп. Шул чүрәкәне 50–60 см таяк белән астыннан эләктереп сугып җибәрергә кирәк. Бер ягына палка белән сугасың да ул оча. Чүрәкәсе яхшы очмаганнарга җәза бирелә, ул уеннан чыга иде.*

*Давыдова Фирдәвес Ринат кызы (1964 елгы),*
*Мамкеева Фәүзия Җәфәр кызы, Иманкулова Гелшат Дамир кызы,*
*Алеева Дания Рәис кызыннан Р. Сафиуллина язып алды*

Аларның уеннары – Пенза якларына хас «Перәшкә» һ. б. да булган, җырлап биюне дә «уен» дип атаганнар.

*Авыл такмаклары бар иде бездә, яшь чакта да, әле дә туйларда ерлыйбыз:*

*Кәзә, кәзә, кәзәкәй,*
*Кермә безнең бакчага,*
*Кысылырсың, үләрсең,*
*Тәңкә ярым түләрсең.*

*Кермә суга, кермә суга,*
*Яр ягында су салкын.*
*Ара ерак берни түгел,*
*Булсын кеңелләр якын.*

*Лампочкагыз якты яна,*
*Әллә себердегезме?*
*Күргән саен күргем кели,*
*Әллә сүдердегезме?*

*Яңа алган плитагыз*
*Пешерәме беленне?*
*Кодагыйдан сорыйбыз:*
*Яратамы киленне?*

*Яңа алган плитабыз*
*Пешерәдер беленне.*
*Кодагыйга без әйтәбез:*
*Яратабыз киленне!*

*Өстәл өсте эскәтер,*
*Эскәтергә уймак уелган.*
*Ашагыз да, эчегез дә,*
*Сезнең өчен куелган.*

*Ары ефәк сузаем,*
*Бире ефәк сузаем.*
*Хозяиннарга рәхмәт әйтеп,*
*Үз уемә сызаем.*

*Теге очтан бу очка*
*Очып килә йомычка.*
*Эшләпәңне кыегайтып,*
*Йөрмә син безнең очка.*

*Марусялар, Маруськалар*
*Кияләр саручкалар.*
*Марусяларга йөреп,*
*Калмады получкалар.*

*Агыйделнең аръягында*
*Калды минем йөгәнем.*
*Калмады минем йөгәнем,*
*Калды минем сөйгәнем.*

*Иләктә дә борчак,*
*Чиләктә дә борчак.*
*Идәнебез уртасында*
*Ята матур корчак*
*(бала турында).*

*Әй дөм кара, дөм кара,*
*Әтиең кебек син кара.*
*Кара булыр карлыгач,*
*Сары булыр сандугач.*
*Минем кызым, минем кызым*
*Мәскәүгә очар, зур булгач.*

*Яшь вакытта күкрәгеңә*
*Чәчәкләр кадамадың.*
*Чөнки яшь вакытта*
*Чәчәкләр табалмадың.*

## Шемышейка районы Оз авылы

Бу авыл кешеләре үзләре белгән бәет-мөнәҗәтләрне, җырларны, уен-табышмакларны барлап, безнең экспедиция төркеме белән очрашу өчен авыл клубына җыелган иде. Монда да фольклор хәзинәсе шактый бай булып чыкты. Шулай ук,

күпчелек авыллардагы кебек, биредә дә халык иҗатын фольклор китапларыннан укып өйрәнәләр икән. Анда фольклор ансамбле эшли. Үзенчәлекле әсәрләрдән Рәуза Харис кызы Якупова (1955 елгы, 8 класс белемле) сөйләп күрсәткән балалар фольклоры үрнәкләре (юаткыч) кызыклы тоелды. Информант аларны балачагында ук олылардан отып алган:

*Әлли-бәлли-бәй итәр,*
*Дамир йокыга китәр.*
*Дамир йокыга китмәсә,*
*Му-мулар алып китәр.*

Яки:

*Ай куяннар, куяннар,*
*Куяннарны куганнар.*
*Куяннарны тотарлар,*
*Дамирга тун тегәрләр.*

***Алдавыч әкият***

*– Эчпошыргыч әкият сөйлимме?*
*– Сөйлә.*
*– Син дә сөйлә, мин дә сөйлим.*
*– Мин әкият белмим.*
*– Алайса эчпошыргыч әкият сөйлимме?*
*– Сөйләмә.*
*– Син дә сөйләмә, мин дә сөйләмим.*

**Исса районы Шеркәвич (Кильмаевка) авылы**

*Безнең малай вакыттагы уеннар болай иде:*

***Таяктан***

*Бер метр диаметрында круг сыза идек. Шуның уртасына таяк кадап куялар. Башка бер таяк белән (30–40 сантиметр озынлыгында) таякка чиратлап бәрәләр. 10–15 метр ераклыкка китеп баса идек. Кем эләктерә инде. Ега алса, җиңүче була. Һәр кешегә өчәр мәртәбә ыргытырга шанс бирелә. Кругтагы таякны вак ташлар, пыяла кисәкләре җыеп (һәркемнең кесәсендә йөз таш булырга может) аударырга тырыша идек.*

### *Чүрәкәдән*

*Чиратлашып таяк белән чүрәкә суга идек. Җиргә баз казый идек, тирәнне түгел. Чүрәкә – 20 сантиметрлы түгәрәк таяк, утыртып куя идек аны базга. Чүрәкә тирәсенә чыбык белән җиргә черта сыза идек: 2×2 метрлы квадрат инде. Үз палкаң (бер метр озынлыктагы таяк) белән астан эләктереп алып, чүрәкәгә сугасың. Ераграк очарга тиеш, чертаның тышына чыгып. Кемнең чүрәкәсе квадрат эченә төшсә, ул яңадан суга. Чертага килеп төшсә, аның чираты башка уенчыга күчә.*

*Тегендә бер кеше чүрәкәләрне биреп тора. Әгәр ул биргәндә, чүрәкә кешегә тисә, башка кешене дежур итеп куялар.*

*Уен чиратын болай билгели идек: фуражка эченә малайлар исемнәрен кәгазьгә язып сала. Бер малай карамыйча гына кәгазьне ала да исемне укый. Аннан икенче, өченче кешенекен һ. б.*

*Юсупов Фәрит Ибраһим улыннан (1931 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

## Каменка районы Кикин авылы

Әлеге авылда күренекле тарихи шәхесләр – татар язучысы Заһир Бигиев, җирле халыкның горурлыгы хәрби Арслан Палкай туган. Авылның теләсә кайсы кешесе, балалар һәм үсмерләрдән башлап, атаклы авылдашларын белә, алар белән бәйле тарихны сөйләп бирә ала. Шунысы игътибарга лаек: яшь буынны милли-патриотик рухта мәктәп тәрбияли. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Равилә Баткаева авыл мәктәбенең һәр укучысын әби-бабайлардан фольклор әсәрләрен язып алу эшенә тарта. Информантларның да, фольклор җыючыларның да исемнәре югалмый, Равилә ханым аларны кадерләп саклый. Халык иҗаты жанрлары, информантлар белән әңгәмә кору, әсәрләрне язып алу турында балалар хәбәрдар. Әлеге кыйммәтле материалларны туплап, укучылар альбомнар төзи. Киләчәктә бу авыл кешеләре туплаган материаллар аерым китап булып нәшер ителсен иде, дигән теләктә калабыз.

### *Арслан Палкай турында риваять һәм бүгенге чынбарлык*

*Арслан Палкай легендасын һәр авыл үзенчә сөйли. Берсендә патша Арсланга батырлыклары өчен алтын-көмеш бирим*

*дигәч, баш тарткан һәм сораган җир. Патша аңа рөхсәт иткән җир алырга, күпме ул атта үтә ала. Качкару әйтер сезгә таңнан кояш батканчыга кадәр күпме җир үтә алса, шуның хәтле дип. Үтә алган җирнең кырыйларында алмагачлар утырткан, имеш. Шул алмагачлар бар, диләр, кыр буенда. Тагын бер нәрсә. Монда алты авыл бергә урнашкан: Мочали, Кикин, Качкару, Кобылкин... Боларны алты авыл дип түгел, алтын авыл дип тә әйтәләр. Ягъни ул бит алтын алмаган, җир – аның өчен алтын. Шундый фараз да бар. Ну без аларны алты авыл дип йөртәбез, чөнки алар төрле районнарга керә. Арслан Палкай шул авылларга нигез салган.*

*Арслан Палкай хөрмәтенә урнаштырылган стелада һәм беразастарак урнашкан каберендә Палкай улы да дип язылган, Палкасы да диелгән, Палкаев та. Мин Палкай дигәнен дөрес саныйм. Аның кушаматы «полк» белән бәйле, полк белән идарә иткән. Ник фамилия кебек язылган дисәгез, бездә бик күп фамилия кушамат белән бәйле. Әгәр без килсәк шул фаразга, Акъегетов, Акбулатов – болар чик сакчылары булган. Ак, димәк аларның бөтен хисләре, кылычлары, булатлары пакь, сугыш ниятләре юк, илнең чиген саклаганнар бит. Ил сакчылары дигәнне тагын бер нәрсә раслый. Безнең якта сабан туйлары үткәрелмәгән. Гомер-гомергә булмаган андый нәрсә. Туксанынчы елларда гына кереп китте әле ул. Келәүләр булган, кайчан менә яңгырлар яумагач, яңгыр сорарга чыкканнар.*

*Яңгыр яу, яңгыр яу,*
*Иләктән, чиләктән,*
*Пәрәмәчкә, коймакка.*
*Арыштан, бодайдан,*
*Без сорыйбыз Ходайдан.*

*Арыштан, бодайдан, дигәч, бу инде борынгыдан, мәҗүсилек чорыннан калган. Җир анасыннан сораганнар алар. Яңгырга үзенә мөрәҗәгать иткәннәр.*

*Арслан Палкай кабере турында риваятьләр, имеш-мимешләр йөри иде халыкта. Мәсәлән, аны алтын хәнҗәре белән, тагын ниндидер байлыклары белән күмгәннәр дип. Кайчандыр акылга җиңелрәк бер адәм моның каберен казымакчы булган.*

*Имештер, биредә күмелгән Арслан Палкай үзенең алтын хәнҗәре һәм коралы белән. Шуны казып алмакчы булган. Легенда буенча, шул ук минутта аяк-куллары тораташ булып катып калган, шуннан инде бүтән аякка баса алмаган ул. Әллә булган ул хәл, әллә юк, Мочалиныкылар шул риваятьне сөйли иде. Моны бер укучым картлардан язып алган.*

*Кабердән ерак түгел чишмә – Палкай коесы /чишмәсе. Родник диләр бездә. Торба сузылган, агып тора. Бераз өстәрәк беседка. Анда Арслан Палкайның бу җирдә дошманнар кулыннан шәһит китүе, кабергә карата хөрмәт күрсәтергә кирәклеге язып куелган. «Арслан Палкайны искә алып дога кылыйк. Исерткеч эчеп күңел ачудан, чүп-чар ташламыйча, батыр каберен пычратудан сакланыйк». Аның каршысында өсте ябулы кечкенә генә корылмада комганнар, сөлгеләр куелган.*

*Комганнар, сөлгеләр – Арслан Палкай каберенә барыр алдыннан таһарәт алыр өчен. Кабер өстендә конфет ник куелган? Безнең татарларда андый гадәт бөтенләй юк. Бу мөселман гадәте түгел. Яшьләр куеп калдырган булса инде. Электән чичи акча – фаянс чашка, савыт-саба ватыкларын куйганнар. Кайбер төрки халыкларга хас әйбер диләр, ул бездә бар.*

*Бездә бер чишмә бар, Чишмә диләр. Аның суы бик салкын. Ахын коесы диләр.*

### ***Авыл очлары турында***

*Чигану электән буш урам иде (йортлар юк) ары киләләр иде таборлары белән чиганнар. Авыл зурая башлады, авыл зурайгач, монда да йортлар салдылар. Шулай итеп, бу урамга Чигану исеме берегеп калды. Укучылар өчен беркайчан да үзем әби-бабайлар янына барып йөрмәдем. Үзләренә юнәлеш кенә бирә идем. Менә син шул урамда торасың, аның исеме ник болай. Фәлән бабай беләдер, аңардан сорап кара әле син, дип. Укучы начар укыймы, яхшымы, татарча сүзләрне дөрес язамы хаталымы – бара, картлар белән сөйләшә, тикшеренү эшен язып китерә. Котылдым (кайнанамнан), Нежюри урыс авылы аерылып чыккан, не журите нас сүзеннән) Шибай очы (аугa йөри торган булган), Аргамаковка, Алпаут – атамаларыннан ук күренеп тора.*

Равилә Баткаеваның укучылары язып алган фольклордан кайбер кызыклы үрнәкләр китерәбез:

*– Песәкәй, песәкәй, нәк килдең?*
*– Сөт сорарга.*
*– Чашкаң кая?*
*– Тышта калды.*
*– Перис, перис, бар китер!*

*Канеева Сафия Мөхәммәтҗан кызыннан язып алынган*

*– Кызым, кая барасың?*
*– Әбкамнарга барамын.*
*– Әбкаң сиңа ни бирә?*
*– Таш башлы кырчак бирә.*
*– Аны кая куясың?*
*– Тал төбенә куярмын.*
*– Кычык алса нишләрсең?*
*– Акыртырмын, бакыртырмын,*
*парткомга чакыртырмын!*

Яки:

*Чап-чап чабыкай, пич башында әбекай,*
*Пич башыннан егылган, пич астына тыгылган.*

Яки:

*Әреш-бәреш, кандалага салма.*
*Крыйсага ярма,*
*Балам – алтын алма!*

*Патеева Рауза Зәкәрия кызыннан язып алынган*

*Шундый бер мәзәкме, әллә булган хәлме, сүлиләр иде. Безнең якның бер килене, кияүгә чыккач, әтисе хәлен белергә келәп сораша икән. Тормышым начар түгел дә, мин өйдә гел коры сөлгегә сөртенә идем, ә монда гел юеш йөзлек куялар, ди икән. Әтисе аңа: «Кызым, ә син таң атканчы тор да иң беренче булып сөртен, коры булыр», – дип киңәш әткән. Дөрес тә элек озак йокламаганнар. Озак йокласаң, төтен җәелә, балалар пич башында йоклаган булса, аларны да төшергәннәр.*

*Девликамова Равилә Билял кызынан (1962 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

***Авыл атамасы, очлар турында***

*Бу посёлка Кикин авылыннан 1929 елда аерылып чыккан. Аерым колхоз булып әлеге буш җиргә 1 укытучы, предколхоз (колхоз рәисе), кладовщик күчеп килгәннәр. Сталин исемендәге колхоз оештыралар, аннары совхоз була. Аннары авылдан башка кешеләрне дә китерәләр инде. Үзләренә мельнича, конюшня ясыйлар. Җил мельничасы була инде, башка авыллардан да он тарттырырга киләләр. Соңыннан Барыбер Кикин белән кушылганнар, бер колхоз булган. Моны Отчаянка урамы дигәннәр. Кайсы яктан карасаң да отчаянный халык яшәгән биредә: эшләү, ырлау, эчү ягыннан да. Урам гөрләп тора иде дә бит, хазер инде пенсионерлар гына калды. Яшьләрдән бер эв калды. Китеп бетте халык. Туксанынчы елларда колхоз таралды, кешеләргә эш калмады. Халык таракан кебек тырмашканга, бер урамга Тараканщина кушаматы ябышты. Безнең мәхәллә мәчетен 2007 елда салдылар. Авылыбыздан чыккан Муса Бигиев ягада үлә бит, аның янтыклары кала. Әстерханда аның братының балалары яшәгән. Менә шул прапра әллә кайсы буын пләмәннигы кайтып төшә авылга, Усман Ибраһим улы Бигиев. Беренче мәхәллә мәчете тау башында безнең, күргәнсез. Анда көн саен таудин менәргә бик авырсына, саулыгы булмый. Авыл бабайларына да анда бару авыр булганны күрә дә, мәчетне биредә салдырырга була. Гомер буена эшләп җыйган акчасын бирә, хатыны да куша, үзенең алтын йөзекләрен сата. Усман Ибраһим улы бу зәрәттә күмелде, нигез-йортлары да шул авылда.*

*XVII гасырда алпавыт хатын Кикина (Лермонтовның апкасы) моннан өч чакрымда урыс авылына килеп урнашкан. Аргамаковлар авылына Гырмаку дип әйтелә. Шуннан безнең авылны да Кикино дип йөртә башлаганнар. Атлар һәркайсы азбарда икешәрне тотканнар, тайлары да. Берсен җигүгә, берсен, симертеп, көзгә ашарга асраганнар.*

*Урман ягарга ташый идек саляска белән. Теңнә колхоз саламнарын ырларга йери идек. Авыллар бетте, урыннары бетте. Зур авыллар иде.*

*Авылның икенче мәчете имам хатыйбы Акбулатов Хәлилулла Нәбиулла улыннан Р. Сафиуллина язып алды*

*Бер бабай бар иде, Сабир атлы. Кушил сукыры кушаматы белән үзен бөтен Пенза өлкәсе белә иде. Бик күп җыр, бәет белгән, үзе чыгарып ерлаган.*

*Кырда үсәдер бодай,*
*Бер бодайга – мең бодай.*
*Сезне безгә, безне сезгә*
*Кавыштырды бер Ходай.*

*Сезнең дә алтын алма,*
*Безнең дә алтын алма.*
*Икесе дә алтын алма –*
*Мәхәббәт бирсен Алла.*

*Кимә итек, ки чабата,*
*Чабата җиргә ята.*
*Сүмә байны, сү уңайны,*
*Уңай кеңелгә ята.*

*Алтын беләзек килешә*
*Кыз бала беләгенә.*
*Кыз бала бәхетле була*
*Барса теләгәненә.*

*Ай су юлы, су юлы,*
*Су юлы таулар тулы.*
*Сөеп алган яр кочагы*
*Төлке туныннан елы.*

*Әнә килә автомобиль,*
*Төягәннәр валинки.*
*Егет алган, кызы барган,*
*Наше дело маленький.*

*Самавырымны кайната*
*Каты каен күмере.*
*Кияү белән кызыбызның*
*Озын булсын үмере.*

*Кан'ан'ма бәгыремә,*
*Бәлеш ашатыр идем.*
*Кечерткәннәр арасына*
*Итеп утыртыр идем, –*

*дип шаяртып та ерлый кайбер усалрак киленнәр.*

*Акбулатова Румия Усман кызыннан (1955 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

### ***Никах-туй йоласы***

*Кыз эвенә башкода килә. Башкода – ул егет ягыннан бер кеше, атасының яки анасының якын туганы. Кызның ата аналары белән никахның бөтен шартларын, көнен, бирнәсен, мәгәрен (мәһәр), ике яктан да ничә кеше буласын килешәләр. Аннары кыз ягында никах укыйлар. Кыз ягында әпәй-тоз белән чыгып, «Хуш киләсез, кадерле кунаклар!» дип каршы алабыз. Никах табынына ике каз куела. Егет ягы каз ботларына күк (зәңгәр) лента бәйли, кыз ягы – кызылны. Егет ягыннан китергән казны үзләре дүрткә кисәләр, аннары инде, өлешләп кисеп, хуҗалар табынга чыгара. Мулла никях укый. Кызның мәгәрен куялар – сатып алалар. Безнең якларда «Кыз мәгәре куйдан ким булмасын, сыердан артык булмасын», диләр иде. Минем өчен совет*

*акчасы белән 101 сум бирделәр. Хәзер конвертка салып 1100 сум бирәләр бугай, 5100 дип тә ишеткән бар.*

*Никахтан соң кодалар кызның урын-җирен алып китәләр, кыз атасының эвендә кала. Кичен кияү белән бергә егетләр кызны алырга килә. Төрле җырлар, такмаклар җырлыйлар, биешәләр дә.*

*Туй ике якта да уза. Элке туйлар бишәр көн була иде, хәзер ресторанда бер көн генә үткәрәләр.*

*Беренче көне – никах, икенче көне – дембер (исеменнән аңлашыладыр инде, анда җыр-бию күп, яшьләр дә, тирә-күрше дә чакырыла). Бу туйда кеше күп була.*

*Өченче көне – икенче җома – кодаларга баралар, хатем (Коръән) укыталар. Моны «иҗат кабул», диләр.*

*Дүртенче көне – ызба киендерү. Монда хатын-кызлар гына катнаша, яшь килен алып килгән бирнәләр белән эвне бизиләр. Чаршау-кашагалар, тәрәзә элеңгеләрен эләләр. Ызбаны киендергәч, хатын-кызлар утырып ашыйлар-эчәләр.*

*Бишенче көн – арчи. Егет эвендә үз якыннарың, янтыгың белән үткәрелә торган туй. Яшьләргә бүләкне күбесенчә никахта ук бирәләр. Кыз янтыгы үзенә бирә, егет янтыгы – үзенә. Хәзерге заманда уртак касса ясыйлар, анысы язылышкан көнне.*

*Кызын кияүгә биргән гаиләнең расхутлары элкедән күп булган. Кызсыз да, акчасыз да каласың, киемнәр, бирнәләр дә хәзерлисең, туй үткәрәсең. Әле яшьләргә тормыш башлап җибәрер өчен һәртөрле зат кирәк. Шуңа күрә кыз биргәч, «Ухватың да җый, ату алып китә», дип әтәләр иде.*

*Бирнәне кыз вакытта үзебез хәстәрли идек. Туку становогы булган кешеләр, бер кышка биреп торса, йеслекләр тукый, бәйли, чигә идек. Кыз ягыннан бит бүләккә бирергә затлар бик күп кирәк. Без тугыз бала үстек, авырлык белән яшәдек. Туку станогы үзебездә бар иде, бөтен бирнәне үзем хәзерләдем.*

### *Үги кыз Гөлчәчәк (әкият)*

*Борын борын заманда әби белән бабай торганнар. Хатынның да, бабайның да икесенең дә үз кызлары икән. Бабайның кызы булган Гөлчәчәк исемне. Үги анасы Гөлчәчәкне бер дә яратмый икән. Бер көнне әтә иренә: «Теләсәң нишләт*

*кызыңны. Күземә күренмәсен. Урманга итеп (илтеп) адаштыр!» – дигән.*

*Бабай нишләсен инде. Кызына әтә, син җиләк җыярсың, имеш. Таң белән алаша җигә, Гөлчәчәкне утырта да урманга китә. Кызны урманда төшереп калдыра. Кыз үги анасы янында артык икәнен аңлый инде. Аллага тапшыра да кала атасын озатып. Китә бер сукмак белән атлап, елый-елый. Җиләк тә җыелмый, бүре ашармы, аю ашармы – бер Алла белә. Шулай бара-бара Гөлчәчәк бер бик иске генә ызба янына килеп чыга. Ызба сәләмә, янтаеп беткән. Ишекне шакып кына эчкә керә. Ызбада бер әби бар ди. Бик карт икән, хал'сез. Исәннәшә, әбигә сәлам бирә. Әби дә кызның сәламен ала.*

*«Әби , берничә көн булса да синдә торыйм әле. Кая да барыр урыным юк», – ди Гөлчәчәк.*

*«Ну ярый, кызым. Нәрсә, ашарга пешерә беләсеңме? Пешер әле», – ди. Ярый, кыз ашарга пешерә, әбине ашата. Бер дә тик тормый. Әбинең ызбасын ештыра (җыештыра).*

*«Кызым, башым бик кечи. Чәчемне тарамассыңмы икән. Анда ишек төбендә гыраблә тора, шының белән тара!» – дир әби.*

*«Юк инде, тарак белән тарыйм», – ди Гөлчәчәк.*

*Чәчен тарый башлый. Әбинең чәч төбе саен алтын, көмеш акчалар икән. Гөлчәчәк аларга тими. Мунчадан әбине калып кайта. Урынына утырта.*

*«Яхшы, кызым. Биергә осталыгың бармы? Биеп тә күрсәт инде», – ди. Гөлчәчәк бик оста бии икән. Әби дә бик риза булып утыра. Бер зат та коелмый, кыз акчаларны алмаган.*

*Әби бит карт, хальсез. Гөлчәчәк аны жәлләп, юындырырга уйлый. «Әби мунчаң бармы? Мунча кертер идем сине», – ди. «Бар, – ди карчык. Мунчага суны каршыдагы лужыдан гына ташы». Гөлчәчәк ерактагы чишмәдән су ташып, мунча ягып йибәрә, әбине күтәреп кенә алып бара.*

*«Йә, кызым, мине инде себерке сабы белән чап әле», – ди.*

*«Юк әле. Мин сиңа каен себеркесе ясыйм», – ди, яхшылап чабындыра, юындыра. Күтәреп кайтара. Бер атна әбидә куна, карап тәрбияли. Аннан инде кызга кайтыр юлны күрсәтә. Кызга рәхмәт йөзеннән бер сундук бирә. «Только ул сундук-*

*ны үгә баргач кына ачарсың», – дир. Гөлчәчәк әби атькәнне тыңный инде, кат'ып йиткәч кенә сундукны ача. Ачса... нинди генә энҗе-мәрҗән, йөзек-беләзек, колак алкалары, муенсалар, кыйммәтле ташлар белән ни генә юк!*

*Яшь хатынның кызы да бу байлыкка күз сала, бик кызыга. «Мине дә илтеп куегыз ул карчыкка!» – дир. Бабай илтеп куя хатынның үз кызын теге убырлы карчыкка. Кыз килеп керәкерүгә кычкырып җибәрә: «Давай, карчык, миңа да сундук бир!» – ди. «Нинди сундук?» – дип сорый карчык? «Гөлчәчәккәниндине бирдең, миңа да шундыйны», – ди кыз. «Андый сундукны надо заслужить, – ди әби. – Син башта ашарга пешер миңа, башымны тара, мунчада аркамны чап. Аннан соң сиңа да булыр».*

*Бу кыз әбинең башын тарарга була. «Тарагың кая?»– дип сорый. «Ишеккә терәткән гыраблә булыр, шуның белән тарарсың», – ди. Әбинең чәч төпләрендәге теге алтынкөмешләр тагын күренә бит. Кыз аларны тойгызмыйча гына кесәләренә тутыра. Аннары әбинең чәчен үреп куя. Әби ат'ә: «Яхшы, хазер биеп күрсәт миңа». Биергә тотынган иде, кызның кесәләреннән алтыннар чылтыр-чылтыр коела! Әби бернәрсә toймаган кебек утыра, сүз ат'ми. «Ярый, кызым, инде мине мунчага чап, – дир. – Суны каршыдагы лужыдан ташысаң да ярый». Кыз шылай эшли дә. Мунча узды. Әби кызга «Мин үзем атлый алмыйм инде, типкәли-типкәли илтсәң, барып җитәрмен», – ди. Кыз: «Ни белән чабыйм?» – дип сорагач, «Иске себерке бар, шуның сабы белән чап», – ди. Кыз шулай эшли. Типкәли-типкәли алып кайтып яткыра әбине. Әби икенче көнне кызны озата. «Мә, кызым, сундук сиңа. Эвеңә кат'кач кына ачып кара», – ди. Кыз саубуллашып та тормыйча чыгып чаба.*

*Урманны чыгуга эве күренә башлый. Сундукның эчендә затлар Гөлчәчәкнеке кебекме, юкмы – беләсе килә моның хазер. «Теге карчык күрми барыбер» дип, сундукны ачып җибәрә. Аннан кара елан чыга да кызны чәнчеп үтерә. Шылай итеп, саран һәм олыларны хөрмәт итмәгән кыз үзенә җәзаны үзе эзләп таба.*

*Баткаева Гөлнара Хәмзә кызыннан (1978 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

## Каменка районы Мачали авылы

Әлеге авылга барганчы ук, Кикин авылында китапханәче булып эшләүче Тактарова Алия Равил кызы (1962 елгы) белән очрашып сөйләштек. Ул элегрәк урта мәктәптә математика укыткан, җирле тарих белән кызыксына. Алия ханым болай диде: «Минем бабайның записной книжкасында язылган иде, XVII гасырда ук бу безнең Алты авыллар булган. Мачали да – үзе атаклы авыл, Мачалилар күп. Әстерхан өлкәсендә, Самара өлкәсендә, Пенза өлкәсендә ике Мачали бар, берсе бездә, берсе Вадинский районда».

Авыл ханымнары белән яшь чакларда уйнаган уеннары турында сөйләштек.

### *Вечерлар*

*Вечерларга без мәктәпне бетергәч чыга идек. Уеннар уйнадык. Әле кияүгә чыкканчы да чыга идек. Иптәшем армиядән кайткач, шунда очраша идек, шуннан үләнештек.*

### *Перәшкәдән*

*уни идек. Егетләр, кызлар утыра урындыкка. Кеше саен бер урындык. Аерым-аерым.Ведущий китереп суга каешы белән бер кешегә, кемгә тели. Ятканына да. Яратмаганына да, болай гына, сәбәпсез суга. Ул суккан кешегә кулындагы перәшкәсен бирә. Суккан кеше башка берәр кешегә суга, үзенә суккан кешегә сугарга аның хакы юк. Аннары каеш башка кешеләргә күчә бара, үзенә суккан кешегә беркем дә китереп сукмый, үзгәгә кирәк. Каты сукмыйлар. Бу вакытта гармунчы гармун уни, егетләр-кызлар ерлый торалар.*

*Ай югары, ай югары,*
*Айга менәсем килә.*
*Айга менгәч, түбән карап,*
*Сине күрәсем килә.*

*Карама матур айларга,*
*Ай булалмассың инде.*
*Кая матур, анда күңелем,*
*Яр булалмассың инде.*

### *Йөзек салу*

*Утырасың тезелеп тә, бер кешенең кулында йөзек имеш, ул аны утырганнарга салып чыга. Барсына да юри гына, берсенә чыннап. Аннары әтә: «Кемдә йөзек, йөгереп чык!», ди. Йөзекнең кемдә икәнен тоеп, аны башкалар тотып калырга тырыша. То-*

*тып алсалар, кире урынына барып утыра. Тотып алмасалар, йөзек салучы үзе була. Тотып калмаган күршесен инде йә ерлаталар, йә биетәләр. Янындагысын ала биергә юлдашка.*

*Әй дустым, кил әле,*
*Икәү әйләник әле.*
*Кичәләрне, кичәләрне*
*Бергә үткәрик әле.*
*Кичәләрне, кичәләрне*
*Бергә үткәрик әле, –*

*дип ерлый идек.*

*Алларым аллар ата,*
*Гөлләрем гөлләр ата.*
*Сезне сагынып ята-ята,*
*Сызылып таңнар ата.*
*Сезне сагынып ята-ята,*
*Сызылып таңнар ата.*

*Тәрез төбе – ике гөлем,*
*Берсе – сөекле гөлем.*
*Шул сөекле гөлем кебек*
*Сезгә якын күңелем.*
*Шул сөекле гөлем кебек*
*Сезгә якын күңелем.*

*Ал булсыннар үзеңә,*
*Гөл булсыннар үзеңә.*
*Син матур, синнән матурлар*
*Яр булсыннар үзеңә.*
*Син матур, синнән матурлар*
*Яр булсыннар үзеңә.*

*Әйдә дустым, җырлап багыйк,*
*Килмәс микән кевебез.*
*Ник килмәс икән кевебез,*
*Бертуганнар үзебез.*
*Ник килмәс икән кевебез,*
*Бертуганнар үзебез.*

*Туйда такмаклар ерлаша идек. Тен ката ерласак та бетми иде.*

*Алай да бергә-бергә,*
*Болай да бергә-бергә.*
*Яшик, яшик, яшик бергә,*
*Һәм яшәрбез дә бергә.*
*Яшик, яшик, яшик бергә,*
*Һәм яшәрбез дә бергә.*

*Кодачалар килдегез,*
*Исәнлекне белдегез.*
*Роза чәчәкләре кебек*
*Күзләргә күрендегез.*
*Роза чәчәкләре кебек*
*Күзләргә күрендегез.*

*Безнең дә алтын алмабыз,*
*Сезнең дә алтын алмагыз.*
*Безнең алтын алмабызны*
*Хур итәргә алмагыз!*

*Безнең дә алтын алмабыз,*
*Сезнең дә алтын алмагыз.*
*Сезнең алтын алмагызны*
*Хур итәргә алмабыз.*

*Кодаларым, бергә яшик.*
*Бергә яшәү күңелле.*
*Бергә яшәп шәп үткәрик*
*Чәчәк кебек үмерне!*
*Бергә яшәп шәп үткәрик*
*Чәчәк кебек үмерне!*

*Әй кодалар, кодачалар,*
*Кодалар, кодачалар.*
*Ничек килдегез сез безгә,*
*Батмыенча диңгезгә!*

*Кодалар, кодачалар,*
*Кодалар, кодачалар.*
*Кадерле кунак сез безгә,*
*Ни хөрмәт куйыйк сезгә?*

*– Өстәл өстендә кыраем[1],*
*Ашар булсаң кураем.*
*– Ашар өчен без килмәдек*
*Ачык булсын чыраең.*

*Аккошлар очар көзгә,*
*Канатын күлдән эзләп.*
*Аккош юллары шикелле*
*Ак бәхет телим сезгә.*
*Аккош юллары шикелле*
*Ак бәхет телим сезгә.*

*Тау бирергә чыгарсалар, чыгып икәү басалар. Ер ерлый.*

*Тау бирү – кияү-киленне туйда котлыйлар, кайвакыт эчәргә дә кыстыйлар иде. Кияү, кәләш икәү чыга, һәр кунак каршына килә. Килен үзе эчми иде, хәзер дә эчми – бик оят эш. Туйда җыелган акчаны тапшыру түгел ул. Анысы аерым. Җыелган бүләкләрне Питраста (яшьләр туенда) бирәләр.*

*Питрас – зурлар туеннан соң яшьләрне кыз эвенә алалар. Анда эчү дә була иде.*

*Малый ягыннан баралар кыз ягына. Кунакларны алырга. Анда инде өстәлләр тезелгән була, утырышалар. Бу Питрас туенда яшьләр генә. Яшьләр җыела беркөн. Утыралар, ашыйлар-эчәләр, унилар, ерлашалар, биешәләр, бик озак тормыйлар кыз эвендә. Аннан кыз монда дуслары, кардәшләре – яшьләр белән генә килә. Кияү-егетләргә чиккән кулъяулыклар бирәләр. Ике егет ике тарелка белән стаканнарны чыгара. Өсте кулъяулык белән каплаган. Чиккән кулъяулыкны кияүгә кыз үзе бирә. Закускага читлавык, конфет чыгаралар иде. Кияү-киленгә шында акча да бирәләр иде. Элекке вет акча күп түгел иде, халеннән килгән хатле салалар иде инде.*

*1. Кыз сүләшергә киләләр иде башкодалар. Анда кунаклар күп булмый, иң якыннары гына 1–2 пар. Башкодага туйда бирәләр иде бүләкне. Яхшырак күлмәк, күлмәклекме анда.*

*2. Кияү киленне алырга барганда бугасынды бирәләр иде. Кияү бит ат дилбегәсен үзе тотмый, кучеры була иде. Шул кучер «Дуга сынды!» кычкыра иде. Анарга инде муенына* ***йеслек*** *бәйлиләр.*

[1] Краең (край) – ит кисәге турында сүз бара булса кирәк. – *Р.С.*

*3. Туйда алаша киендерү бар иде. Безнең туйда ничә алаша бар иде. Атларны бизиләр: алдысына пәртүк бәйлиләр, бугазына йеслек эләләр, дугасына – чоңгыл. Кызны алганда эвеннән куймы, кучатмы урлап китү гадәте бар иде. Нәрсә эләктерә алалар инде кияү ягыннан. Бушлый итмиләр кызны, «бирнә»се белән апкитәләр. Тимер тарелка, тимер кашык булса да урлый иделәр, яшьләрне вет саклап бетереп булмаган. Шуның өчен хуҗалар аш белә начаррак савыт сабаны «ырлый бирсеннәр, барыбер ырлыйлар» дип атлап (махсус) та чыгара иде. Элек савыт-саба күп тә булмаган, ә гадәте шул булгач, ачуланмаганнар.*

*4. Яшь киленне төшергәндә бала-чагага конфет, вак акча сибәләр иде. Кияү-килен өстенә түгел, җиргә учлап-учлап сибәләр иде. Яшь килен ягына да сибәләр иде кайчак. Ну мин качып чыктым, миңа сипмәделәр. Эвдә анамнар белми дә калдылар, яшь идем әле. Андый вакытта әтә баралар. Канигәчем иртән, барып, аталарыма этте. Кичен этмиләр бездә, иртә әтәләр. Әтә баручыны чәй эчерәләр, бүләк бирәләр. И ул әтә инде: «Бүген иҗат кабул укытабыз», ди. Кияүгә урланып, качып яки сүләшеп чыкканның икенче көнендә безнең якта иҗат кабул укыталар. Ул Коръән хатеме була. Никах булмаган әле, никахсыз торырга ярамый. Шуңа күрә укыталар. Кыз ягыннан карт кешеләр килә.*

*Яшь киленгә канигәчләрме, каенсеңелләрме иртүк, караңгыда торып, мунча ягалар. Кияүләр мунчадан чыгарга тиеш, аннан иҗат кабул.*

*5. Яшь килен төшергәч, су юлын күрсәтәләр. Су алгач, киленнең аягы астына су сибәләр.*

*6. Бирнә сайларга баралар аннан кыз эвенә. Бездә шылай бер җома (атна) туктамый туй.*

*Такмакларны бездә гел ерлыйлар, кара-каршы ерлаганда төрлесе эләгә инде, үпкәләп тормыйсың.*

*Ерла, ерла, тәре гурла,*
*Бер ерлаганнан ни була.*
*Синең ерлаган ерларың*
*Минем кеңелемә тула.*

*Чия матур, чия матур,*
*Чия матур үзенә.*
*Чиядән дә матурырак*
*Күренәсең күземә.*

*Чияме, алмагачмы да,*
*Чияме, алмагачмы?*
*Уртадагы парочкалар*
*Былбылмы, сандугачмы?*

*Тирәз төбем яшел агач,*
*Чияләре бар аның.*
*Ияләнмәгез анарга,*
*Ияләре бар аның.*

*Ак шәл, мамык шәл,*
*Мамыкларын коялар.*
*Ышкулга да бармас идем –*
*Икелекләр куялар.*

*Турникама су сибәм,*
*Су сибәм турникама.*
*Нинди соң җырлар җырлыем*
*Кадерле тудыкама?*

*Сорасалар да бармагыз*
*Кара тарактаристка.*
*Моңайган кеңелне ача,*
*Барыгыз гармонистка.*

*Новикова Алия Муся кызы (1950 елгы); Тактарова Асия Заһидулла кызы (1962 елгы); Тинчурина Сания Сабир кызы (1941 елгы); Макуева Гелҗиһан Салах кызы (1932 елгы); Макуева Фәридә Муся кызыннан (1946 елгы) Р. Сафиуллина язып алды*

## Каменка районы Тәләтен (Телятино) авылы

Бу авыл хәзер инде бик кечкенә: мәктәп, клуб, балалар бакчасы, почта, хәтта кибет тә юк. Бары тик атнага бер көн Мочалейкадан китапханәче Фәния Такташева килеп, хезмәт күрсәтеп китә. Ул Тәләтендә туган, үзләрендә эш булмагач, Мочалеевка авылында эшли. Шуңа күрә башта Фәния безне Тәләтен авылында, икенче көнне Мочалеевкада озатып йөрде. Авылдан бөтенләй үк буш кул белән кайтып китмәдек, чөнки Тәләтендә кайчандыр уеннар да, аларны уйнарлык балалар да байтак булган. Әле хәтерләрлек кешеләре дә бар булып чыкты.

### *Йомырка*

*Урамга һәрбер бала буяган пешкән йомырка алып чыга иде. Урысларның паскысы вакытлары булгандыр инде. Кеше саен өчәрнеме анда, кем күпме булдыра инде. Унбиш-егерме сантиметр тирәсе баз казый идек, киңлеге дә шуның кадәр. Бер кешене сайлап куялар, кулына мәч (туп) ала. Алдына җиргә йомырка куя. 3 метр ераклыктан туп бәреп, йомырканы базга тәгәрәтеп кертергә тырыша. Кертсә, йомырканы үзенә ала.*

### *Таяк (городки)*

*Бабайлар, оланнар урамда аптырап йөрмәсеннәр дип, безгә таяк, пуляннар ясап бирәләр иде, эшсез чапканчы уен уйнасыннар дип. Пуляннарны бастырып куябыз җиргә. Пуляннар бишәү*

*була. Ун метр пуляннан китәбез дә таякны пулянга төзәп ыргытып җибәрәбез. Таяк пулянны аударырга тиеш. Барлыгы биш тапкыр ыргыталар. Кем күбрәк тидерә. Тидергән кешегә очко бирелә. Бу уенны үзебезнең Ади очта малайлар да, кызлар да уйный идек. Кемнең очколары күбрәк, шул җиңә.*

### *Очлар*

*Олан вакыт авыл очларында үтә иде. Бөтен уеннар шында булган бит. Ади оч – иң зур урам. Ади атлы кеше атына кушылгандыр. Ахын очы – Ахын йорты, Ахын каумы булган дип аңгарырга кирәктер.*

*Кушкин (азбар атына күрә шылай атаганнар) оч, Халюк оч. Халык үзара Нахаловка дип йөртә торган урам бар иде. Анда ата-ана йортыннан аерылып торган яшьләр урнашкан. Совхоз вакытында аларга йортны совхоз куеп биргән, үзләре нужа чикмәгән, имеш, йорт куймаган, шуның өчен Нахаловка очы.*

*Нагаев Кязыйм Кәбир улыннан (1959 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

### *Чукмар*

*Баз түгәрәк казый идек. Кәкре таяк белән бәреп, агачтан ясаган чукмарны базга төшерергә кирәк. Баз янына ике кеше баскан, алар керттермәскә тырыша. Базга кертә алса, очко бирелә. Өч тапкыр ыргыта. Аннары базны саклаучыларның берсе бәрергә килеп баса, уртадагы кеше аның урынына сакларга килә. Очколарны саныйлар кем күп җыйган, шул беренче урынга чыга.*

*Дасаев Фәрит Исмаил улыннан (1939 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

*Яшь чакларда радиодан ишеткән җырларны җырлый идек. «Сарман буйлары», «Умырзая» һ. б. Оста биюче идем. Ерлый-ерлый да биедек. Такмак әтә идек:*

*Тыпыр-тыпыр биюче,*
*Кара итек киюче.*
*Әй биюче, биюче, ди,*
*Кара итек киюче.*
*Итекләрем базарда,*
*Итекләрем базарда ла,*
*Сәүгән ярым Казанда.*

*Әй биюче, биюче,*
*Тагалы итек киюче.*
*Тагалары базарда,*
*Сәүгән ярым Казанда.*

Сәгыйрә әби «Сак-Сок» бәетен, мөнәҗәтләрне ишеткәне бар, яшьрәк чагында үзе дә җырлаган. «Сак-Сок» бәетенең эчтәлеген «Ике кыз» бәете белән кушып сөйли:

### *Сак-сок*

*Ике ятим бертуган кыз булган. Алар бергә үсәләр дә беркөнне аерылылалар. Аралары бозылып түгел, язмышка буйсынып. Кыямәт көнгә кадәр аларга бергә кушылу юк. Гаиләләре дә булмаган, кызлар ялгыз. Сагышларын басар өчен, аларның бере «Сак», дип кычкыра, икенчесе – «Сок», дип.*

### *Арслан Палкай*

*Арслан Палкай (Полковник) кабере Кикин авылы янындагы урманда. Ел саен анда 1–2 мәртәбә барабыз. Кем шунда, Алладан сорап, садака куеп китә. Без ике рәкәгать намаз укыйбыз, дога кылабыз, үзебез өчен сорыйбыз.*

*Аннары кемнең нинди хаҗәте бар, тау башыннан су агып тора, ком арасыннан, вак кына ташлары да коелып тора. Ул урман Кикин авылына җитмәенче, Полковник кабере тирәсендәге тегел. Шунда барып, Аллага дога кылабыз, догаларыбыз кабул була. Шишаларыбызга су тутырып кайтабыз, файдасын күрәбез.*

*Тактарова Сагыйрә Алимҗан кызыннан (1929 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

Арслан Палкай – бу яктагы авылларның яраткан каһарманы. Аның турында һәр авылда гына түгел, хәтта һәрбер информант үзенчә сөйли.

*Ул татар кешесе булган, Екатерина II гә хезмәт иткән. Батырлыклары өчен Екатерина II анарга җир биргән. Бер сутка (тәүлек) эчендә күпме җир әләнәсең, шул җир синеке, дигән, имеш. Атларын алмаштара-алмаштыра 1 сутка чаба. Шул ерләр әле Палкайныкы була. Бире татарларны китерә, алты авыл булып урнашалар. Арслан Палкайны Пенза яклары кешесе булган, диләр. Һәр татар авылы үзенеке дип саный, Каменка да, Белинский да, Вадин районы да үзләренеке диләр. Дөресен инде әле бер Алла белә.*

*Арслан Палкайның управляющие Шибай атлы татар кешесе булган. Бик каты тоткан, имеш, бик яхшы идарәче бул-*

*ган. Кикин халкы аны үзенеке дип тә әтә, Кикинда һаман Шибай очы бар. Шибай алты авылның алтысына да ни белән шөгыльләнергә икәнен боерган. Безнең авыл халкына бозаулар карарга кушкан. Баштан ук безнең авылда халык бозаулар үстерү белән шөгыльләнә. Авылыбыз исеме шыннан калган. Кобылкинда алашалар үрчеткәннәр. Мачалида мунчала ясаганнар һ. б.*

*Такташов Шамил Шакирҗан улыннан (1943 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

Шамил Шакирҗан улының өендә аның хәләл җефете белән дә әңгәмә кордык. Хәдичә Юныс кызы яшь чакта ишеткән халык иҗаты турында сорагач, «хәтергә килми» диде, шулай да бу яклардагы дини-көнкүреш йолалар белән рәхәтләнеп таныштырды. Кешенең дөньяга килү һәм дөньядан китүе белән бәйле иң мөһим гореф-гадәтләр монда нинди традицияләргә бәйле? Шушы сорауга җавабы белән танышыгыз:

### *Баланы каршы алу*

*Баланы кайнана эвендә каршы алалар. Бирედә оланга балмай каптыру йоласы бар. Кайнана бисмилла әтеп, баланың авызына бал-май сөртә инде бераз. Аннары ат куштыру бар. Мулла килеп азан әткәч, элке хатем (Корьән) мәҗлесе була иде. Бәбәй чәе дә диләр иде, туган-тумача җыела, балага бүләк китерәләр иде. Хазер инде табынсыз гына. Мулла азан әткәч, садакасын бирәләр.*

### *Кешене бакыйлыкка озату*

*Мәет янына кичен хатыннар җыела. Мәетне караватка яткырганнар, ширма (чебыльдек корылган). Элке бик күп кеше килә иде. Әле инде кеше әз. Әбиләр җыела, салават укыйлар, тәсбих тарталар. Кемдер кычкырмыйча гына Корьән, китап та укый. Арыгач, мөнәҗәтләр укып алалар.*

*Элке мәетне юарга коедан чиләкләр белән су китерә идек. Су эвдә булгач, хазер инде анысы да бетте.*

*Күмгәч, өч кич, җиде кич, кырык, илле бер кич, елы дип Корьән мәҗлесләре уздыралар. Бабай (ире Шамил Шакирҗан улы. – Р.С.) спурлаша (бәхәсләшә), алар Корьәндә юк, мин үлгәч, «кичәләр» үткәрмәгез, хатем генә укытыгыз, дип. Малай*

*хазрәт булгач, чакырган ергә бармый хале юк*. (Аларның улы Кикин авылының яңа мәчетендә имам хатыйб. – *Р.С.*)

*Такташова Хәдичә Юныс кызыннан (1946 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

### *Бала уйнату*

*Баланың уч төбендә үз бармагын түгәрәк буйлап әйләндереп йөртә, балага карап*:

*Тирмән күзендә маем бар иде,*
*Ул кая китте?*
*Теськан ашады.*
*Теськан кая киткән?*
*Суга чумды.*
*Су кая?*
*Үгез эчте.*
*Үгез кая?*
*Пычак чалды.*
*Пычак кая?*
*Кузничта.*
*Кузнич кая?*
*Янды.*
*Көле кая?*
*Очты! (Баланың ике кулын ян-якка җәйдерә дә*
*кытыклап ала, бала кете-кете көлә).*

*Баланың бармакларын берәм-берәм бөкли:*

*Баш бармак,*
*Балан үрдәк,*
*Терми термәк,*
*Серми сермәк,*
*Кечелү-үүк бармак!*
*Чап-чап чабыкай,*
*Пич башында әбекай,*
*Пич башыннан егелып төшкән,*
*Ике теше пич артына кысылган,*
*Ике тешен сындырган.*

*Тактарова Фәзилә Равил кызыннан (1971 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

Шушы авыл балалары уйнаган уен:

***Чәчәк***

*Без үскәндә уенчыклар күп булмагач, үзебезгә уйнарлык затларны урамнан эзләп таба идек. Пыяла банкага каплаган калай капкачлар эзли идек. 7–8 яки күбрәк капкач тапсак, «чәчәк» уенын уйнадык. Ничә бала уйнаса, шуның саныча җиргә акбур яки таяк белән ромашка липистукларын (таҗларын) ясыйбыз. Чәчәк уртасына калай капкачларны багана итеп тезеп куябыз. 12 капкач булса яхшы. Бер бала алып баручы була, кулына туп ала да капкачларга бәрә. Капкачлар очып китә. Бөтен балалар да тиз генә капкач эләктереп калырга тырыша. Эләктергән капкачларын һәркем җирдәге чәчәк таҗларына куя. (Бер таҗга – бер капкач). Капкачсыз калган яки, эләктереп тә, аны таҗга куярга өлгермәгәннәр уеннан чыга. Аннан капкачларны санымйлар, иң күп капкач җыя алган бала җиңә.*

*Такташева Фәния Равил кызыннан (1970 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

**Каменка районы Кобылкин авылы**

Пенза якларында келәү, яки келәү корбаны дигән йолага тап булдык. Аны Кобылкинда да үткәрәләр икән:

***Келәү***

*Иртәнге сәгать сигездә ир-атлар зиратка чыгалар, мулла, ата-бабаларны искә алып, хатем укый. Соңында унынчы яртыда мулла белән хатем әтәләр. Зираттан соң киләләр барысы да авыл клубы янына. Бире тантаналы өлеше, алдынгы эшчеләрне бүләкләү була. Көрәш, балалар өчен уеннар үткәрәләр. Бездә ирләр көрәшми, балалар гына көрәшә. Баганага менү бар, очына ук менеп җитүчегә кучат бирәләр. Үлә (өйлә) намазы укыла. Көндезге сәгать бердә корбан чалынып, эшти пешерелә.Спонсорлар ярдәм итә, кем тана чала, кем – куй. Итне чабарга ирләр чыга, хатыннар аш пешерә.*

*Тәкбир әткәч, корбан ашын ашыйлар, аннан Аллаһтан яңгыр, яхшы урожай сорыйлар. Шулай ук җир йөзенә тынычлык, гаиләләргә татулык, саулык һ. б. сорап, дога кылалар.*

*Тинчурина Рауза Исмаил кызыннан (1947 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

Кобылкин авылы гөрләп торган клубы, фольклор ансамбле, татар халык иҗатын әйбәт белүче, җор телле халкы белән истә калды. Авыл һәм аның кешеләре белән таныштырып йөрүче оста белгеч булганда гел шулай ул. Дасаева Зөлфия Зәйдулла кызы (1975 елгы) Кобылкинда туган. Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлаган кыйммәтле белгечләрнең берсе, Казандагы остазларын җылы хисләр белән искә ала. Зөлфия Зәйдулла кызы татар фольклорын әйбәт белә һәм хезмәтендә куллана. Һөнәре, белгечлеге буенча түгел, авыл мәдәният йортында эшли. Авылның абруйлы кешесе буларак, ул безне Кобылкин кешеләре янына алып барды һәм аннан уен да язып алдык:

***Кәпәч***

*Бу уен безнең авылның «Сандугачлар» фольклор ансамбле репертуарында да бар.*

*10–15 кеше уйный. Уен өчен бер кәпәч (бу якта түбәтәйне шулай атыйлар) кирәк. Бөтен уенчылар түгәрәккә басканнар. Музыка уйный, түгәрәктәгеләр күмәк җырлап тора. Кәпәчне кулдан кулга түгәрәк буйлап тапшырып йөртәләр. Җыр туктаганда кәпәч кемнең кулында кала, шуңа берәр җәза бирәләр. Кайвакыт җәзаны үзе сайлап алырга да мөмкин. Гадәттә, түгәрәктән әйтәбез: йә җырла, йә бие, шигырь сөйлә, әтәч булып кычкыр, дибез. Ни әйтәбез, шуны эшли. Аннары кәпәчне тагын түгәрәк буйлап җибәрәбез. Шулай 8–9 тапкыр кәпәч йөртеп чыгабыз.*

***Авыллар тарихы турында.*** *Гырмаку (Аргамаково) белән Кикин авылы арасыннан аккан елганы Поп елгасы диләр. Ул елга граница булып тора, татарлар ул якка чыкмый идек. Гырмакуда урыслар яшәгәч, анда поплар, имеш, чукындыралар. Поп елгасының аты шыннан калган.*

*Үзебезнең авылда ишеткән бер мәзәкне дә сүлим әле.*

*Бер бабайның улы бар икән, гел яңа төрле фуражка кия. Бабайның бервакыт хәле начараеп киткән, бальничага алып барган малае. Вырач боргалап тормый, өмет юк инде, ди. Чыккач, атасы сорый:*

*– Ни диде вырач? – ди.*

*Малай турыдан ярып:*

*– Син үләсең, – ди.*

*Атасының бик хатере кала.*

*– Фуражкаң гына үзгәргән, акылың үзгәрмәгән синең, – дип орыша.*

*Юмаева Зәйтүнә Якуб кызыннан*
*Р. Сафиуллина язып алды*

### *Арслан Палкай һәм авыл тарихы*

*Арслан Палкай бу алты авылга нигез салган бит әле. Екатеринага хезмәт итмәгән ул, Николай патшага. XVIII гасыр булган бу. Яхшы хезмәте өчен Николай аңа, легенда буенча, бер сутка эчендә узып чыгарлык җир биргән. Шул территориядә Арслан Палкай алты татар авылына нигез салган. Аның Ковылкин фамилияле ярдәмчесе булган. Кобылкин атамасы шул Ковылкин фамилиясеннән ясалган. Бирегә халык Мордовия якларыннан күчеп утырган булса кирәк. Мордовиядә бүген дә Ковылкино районы бар. Халкыбыз авылдан күчкәндер.*

*Патшага кагылышлы бер риваять сүлиләр иде.*

*Моннан Мәскәүдән Петербурга Мочалей аша юл булган. Николай II шуннан узганда Мочалей авылында тукталган. Бер йортка кереп ял итәргә булган. Шулвакыт бу кешеләрнең баласы елап йибәргән. Патша булса да, иелеп, аны бишектән кулына алган. Шуңа күрә, «бала еласа, аның каршында патша да иелә икән», диләр безнең якта.*

*Алеев Рәшит Исхак улы (1950 елгы),*
*Алеева Нажҗия Хәсән кызыннан (1956 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

### *Шешә*

*Мондый уен уйныйлар иде. Таяк ясый идек ике янтыгын юнып, очлап, шомартып. Озынлыгы 20 сантиметр. Тагы бер таяк ясый идек, анысы сугарга, 50 сантиметрлы. Шешәне билгеләгән җиргә яткырып куясың, таягы белән бер очына сугасың. Суккач, очып китә шешә. Билгеләгән җирдән шешәгә тикле күпме ара бар – суккан таягың белән саныйсың. Әйтик, 17 метр. (Безнең таяк 50 генә сантиметрлы, ну без аны метр дип ала идек). Кемнең таягы күпмегә очкан – шул кешегә*

*шуның кадәр очко. Иң күп очко җыйган кеше бу уенда җиңә. Уен тәртибен үлчәшеп (шобага тотып) билгеләп була.*

*Икенчеләп бәрәсең шешәгә, ерактан торып. Шешәгә эләксәң, тагын бу уенны дәвам итәсең. Эләктермәсәң, икенче берәүгә күчә.*

*Кич утырырга чыга идек, 7–8 нче классларда чыга башладык. Анда чигү-бәйләү, йеслек чигә идек. Йеслек тугый идек, шул вакытта егетең булыша, тотышып, төзәткәләп тора. Утырыш диләр, малайлар да килә, тәртипле генә утырдык. 19 яшемдә пәртүк, караваt җәйгече чиктем.*

### ***Самавыр***

*«Самавыр» уенын уйный идек.*

*Бөтен кеше икәү-икәү кулга-кул тотынып, бер-бер артлы тезелеп, тотынышкан кулларын өскә күтәреп баса. Алар «самавыр» була, ерлап торалар. Бер кеше ялгыз кала. Ул самавырның артыннан, күтәрелгән куллар астыннан алга таба килә, кеңеленә ошаган кешене эләктерә килә.*

### ***Туйлар, никах йоласы***

*Туйлар бер атна уйнала иде бездә.*

*Беренче көн – башкода.*

*Икенче көн – килештерү (кыз эвендә, әгәр ырлап китсәләр...).*

*Өченче – көн – бирнә сайлау. Йеслек, хатыннарга күлмәклек, ирләргә күлмәк һ. б. бүләкләр бирәләр. Кыз эвендә булды.*

*Дүртенче көн – егет эвенә ызба киендерергә баралар. 25–30 хатын-кыз бара. Аларга падарка хазерлиләр – баш яулыклары. Кайнана-кайната йортына кыз әйбирләрен илтә баралар, йортта булган кешеләргә бүләкләр куялар. Яшь килен кайнанага покрывал, престина, намазлык кебек бүләкләр бирә. Кайнатага – кәпәч, башмак ишеләрне. Падаркалар яхшы, кыйбатлы булсын, ату пинәлиләр, риза тегелләр. Кияүнең кардәшләренә бүләкләрне бирнә диләр, киленнең кардәшләренә бүләкләрне – күренмәлек.*

*Бишенче көн – никах. Никахта куйган күренмәлекләрне, бирнәләрне тапшыралар. Егет ягы кыз ягына акча, алтын бирә. Кыз ягы андыйны бирми. Пар каз куела (ике яктан да берәр каз).*

*Алтынчы көн – язылышкан көн – коймак. Башта егет эвендә.*

*Җиденче көн – язылышканның икенче көнендә – тагын кыз эвенә алалар.*

*Сигезенче көн – егет ягына алалар. Монда да пар каз куела. Ике якта да кияү белән киленгә берәр каз боты бирәләр.*

### *Угол*

*Биш кеше уйный. Ызбаның һәрбер эчке читенә берәр уенчы чыга, бер кеше уртада кала. Аның күзләрен томалап бәйлиләр. Бәйләгәч, ызба буйлап бер круг әйләнә, кеше ярдәм итми, үзе кабашланып әкрен генә йөри. Шуннан бер читтәге кеше мыш кына килеп, моның аркасына җиңелчә генә суга. «Кем арка?» дип сорыйлар. Уртадагы кеше кем сукканын дөрес әйтсә, үзе аның урынына баса, суккан кеше – уртага. Әгәр дөрес әйтмәсә, йә бер мәзәк сөйли, йә җырлапмы, биепме бирә һәм бер кешенең урынына баса. Ул кеше үзе теләк белдерә ала яки санамыш белән санап куялар. Болай да була: кем арка икәнен дөрес әйтә алмаган уенчыга.*

*Дасаева Зөһрәхан Нәсибулла кызыннан (1948 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

## Каменка районы Кочалейка авылы

Биредә халык җырга оста, авыл клубындагы чараларны да халык иҗаты белән бәйләп үткәрәләр. Җыр, такмак, бәет чыгарырга оста кешеләр электән үк булган. Авыл клубы хезмәткәре Канеева Наилә Юнис кызы (кыз фамилиясе) әнисе Равза Айнулла кызы иҗат иткән җыр-бәетләрне кадерләп саклый, безгә дә күрсәтте. Равза Канеева вафат инде. Ул яшьтән үк шигъри сәләткә ия булган. Дәфтәрләрдән, сайлап, байтак җыр-бәет күчереп алдык. Вафаты алдыннан Равза апа гел балаларын искә ала, шуңадыр, иҗаты халык бәетләре белән аваздаш (сүзләр язылышын оригиналдагыча бирүне кулай таптык):

*Сагенам сезне, алтыннарем,*
*Сагенамын бик часта.*
*Таген сагенерга кемем бар,*
*Сез җаннаремнан башка?*

*Сандугачлар унар-унар,*
*Унарлап талга кунар.*
*Качан бергә кушелербез,*
*Шунда җаннарем тынар.*

*Тәрәздән баганада*
*Күренә вокзал утлары.*
*Сезне уйламыйча үтә микән*
*Сәгатьнең минутлары?*

*Өстәлгә эскәтер җәйдем,*
*Читләрен салындырып.*
*Китмисез күңелләремнән,*
*Торасыз сагындырып.*

*Чиләк алып суга барсам*
*Сулары тулар микән?*
*Каршы килеп куллар биреп,*
*Күрешер көн булыр микән?*

*Өстемдәге күлмәгемнең*
*Бидәрләре ямь-яшел.*
*Үткән көннәрем уйласам,*
*Әл дә түгелә яшем.*

## Белинский районы Качкару (Кутеевка) авылы

Качкару авылы – Арслан Палкай тарихы белән бәйле Алты авылның берсе – зур, төзек һәм ландшафт-рельеф ягыннан да үзенчәлекле, матур. Биредә Институт галимнәрен урта мәктәптә каршы алдылар, авыл кешеләре белән безне укытучылар Караяков Арифулла Заһидулла улы һәм Дубина Гөлнара Равил кызы очраштырды. Җәйге экспедицияләрдә безгә еш кына, үзләренең мең төрле мәшәкатьләрен читкә куеп, кайвакыт чираттагы ялларыннан чыгып, укытучылар ярдәмгә килә. Качкару авылындагы эшебез гаҗәеп дәрәҗәдә оештырылган төстә үтте. Билгеле, һәрбер мәсьәләне күз уңында тоткан, кирәк чагында үзе дә информант буларак Казан галимнәренә мәгълүмат биргән урта мәктәп директоры Караякова Лилия Кәрим кызына аерым рәхмәт әйтәсебез килә. Бу авылда иң элек элеккеге китапханәче Сания апа белән очраштык. Ул безгә балалар фольклорыннан кайбер тормышчан һәм гамәлдәге мисаллар китерде.

### *Оятсыз кучат*

*(әкият-мәзәк)*

*Әби белән бабай яшәгән. Боларның азбар тулы тавыгы, гаярь кучатлары бар икән. Беркөнне кучат калюса таба. Кучат әтә бабайга:*

*– Әдә алыштырабыз, мин сиңа калюса бирәм, син миңа бодай бир, – ди. Бабай риза була, кучатка калюса бирә. Кучат бодайны ашап бетерә. Әле инде ашап бетергәч, бабайдан калюсаны кире үк сорый. Сорый-сорый бабайны биздереп бетерә.*

*Бабай әйтә әбигә:*

*– Йә, кая, шул кучатны чалыйм да, пешереп бир.*

*Бабай чалырга алып барганда да кучат һаман:*

*–Кикирикук, кикирикук! Калюсамны бир! – дип кычкырып бара икән. Бабай чала әтәчне, әби кучат итеннән эшти пешерергә куя. Казанда кайнаганда да кучат һаман: «Калюсамны бир!» – дип сикерә икән.*

*Инде бабай кучат итен ашый. Тын алырга диванга ята, шул вакытта корсагыннан кучат тавышы килә:*

*– Кикирикук, калюсамны бир!*

*Кучатның оятсызлыгыннан гаҗиз булган бабай әйтә әбигә:*

*– Әдә, инде мин тышка чыгам, син зур пычак белән янымда саклап тор, к...ттән кучат күренүгә, башын кисеп төшерерсең.*

*Бабай тышка чыгып утыра, әби «кучат»ны саклый. Башы күренү белән пычагын бөтен көченә селдәве була, пелдирушы киселә, тагын кучат тавышы килә:*

*– Кикирикук, кикирикук! Итемнән эшти пешертсәм пешерттем, бабайның пелдирушын кистерттем! Шулай итеп, биргәнен кире сораучы кучат аркасында бабай күпме зыян күргән.*

### ***Әби белән бабай ничек сыер алырга барган***

*(алдавыч әкият)*

*Оныкны йоклатканда болай сүли идем:*

*Әби белән бабай торганнар. Алар картлар икән инде, тешләре дә юк, күзләре дә яхшы күрми. Бабай әтә:*

*– Әдә, әби, сыер алыек, каймак, май ашарбыз, – ди. Күрше авылга сыер алырга китәләр болар. Акчасын түлиләр, алып кат'алар сыерны. Бабай алдан бәләүдән тартып бара, әби арттан чыбык белән куып кат'а (кайта).* (Мәкаләдә диалекталь авазларның күбесен информантлардан ишеткәнчә бирергә тырыштык. – *Р.С.*)

*Сыер урынына үгез алганнар икән болар. Үгез шак-шок атлап кат'а. Берсәк барган саен пес итәргә туктый. Бабай әтә:*

*– Ку, тизрәк ку инде, караңгылата.*

*Үгез тагын туктый.*

*Пес, пес...*

*(Карыйм, баланың күзләре йомыла башлады инде. Тагын да тихарак дәвам итәм.)*

*...Шулай катьалар болар. Үгез тагын пес итәргә туктый.*

*Пес, пес... (Оныкның күзләре йомыла).*

*Күрше бүлмәдән зуррак онык тавышы килә:*

*– Тимур әллә кайчан йоклап киткәндер инде, әле үгез һаман кат'маган!*

**Табышмаклар:**

*Көндез тагылып тора, тенңә ялтырый (лампа)*

*Багасын, баккач ике буласын (көзге)*

*Башымны күтәреп баксам – бер анасы, унбиш баласы (түшәм: матча, такталар)*

**Кич утырулар**

*Яшь чакта утырулар була иде, йон каттык, эрләдек, чиктек.*

*Каз өмәләре тәртибе. Казларны суеп, йолкып, эшкәртеп бетергәч, кызларны ашаталар иде. Өстәлдән җыештырып алгач, уеннар башлана. Биш кыз каз йолыкса, алар һәркайсы уенга ахирәтләрен дә чакыра.*

*Утын кискәч тә өмә. Соңында – уеннар. Кызлар да, егетләр дә килә иде.*

*Кругтан уйный идек. Егетләр-кызлар түгәрәккә баса, гармунчы татар көйләрен уйный, без ерлап йерибез. Бер кеше уртага чыга, такмак ерлый, биеп китә. Парлап биергә бер кешене кругтан чыгара, икәү әйләнәләр, теге кеше аның урынына баса. Яңа чыкканы да шулай бии, тагын берәрсен чыгара, икәү әйләнәләр.*

**Ике ярым җитмеш биш**

*Яшьләр «Ике ярым җитмеш биш» уйный идек. Уртага буйлырак, күреклерәк кенә бер малый чыга да биленнән каешын алып: «Ике ярым җитмеш биш уйныйбыз!» дип кычкыра. Берәр сорау бирә, мәсәлән, табышмак. Җавап бирә алмаганнарның йомшак җиренә каешы белән суга.*

*Тумеркина Сания Идрис кызыннан (1952 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

**Круг**

*Кругта кызлар, егетләр басабыз. Бер кеше уртада. Ул башлап җибәрә, без кушылабыз. Кругта ерлаган такмакларның кайберләре истә.*

*Талы, талы,*
*Талы бөгелеп тора.*
*Талы бөгелеп тора да,*
*Йөрәк өзелеп тора.*

**_Без бәрәңге чәчтек_**

*Яшьләр җыелганда еш уйнадык. Бала вакытта да уни идек. Яшьләр ике командага аерыла. Ике команда ике якка басалар. Кара-каршы берәр рәт тезеләләр, кулга-кул тотынышалар. Бер команда ерлый:*

*– Бәрәңгеләр чәчтек без, чәчтек без.*

*Икенче команда ерлый:*

*– Без аларны таптарбыз. Таптарбыз.*

*Шулай кара-каршы ерлыйлар:*

*– Ниләр белән таптарсыз, таптарсыз?*

*– Атлар белән таптарбыз, таптарбыз.*

*– Атларыгызны йөз тәңкә биреп алырбыз.*

*– Кирәкми тәңкәгез, кирәкми!*

*– Ни кирәк соң сезгә, ни кирәк?*

*– ... атлы кыз (малай) кирәк!*

*Теге кеше чабып барып, каршы командадагы ике кешенең арасыннан узып чыгарга тиеш. Уза алмаса үзе дә шунда кала.*

*Без бик азгын идек, хәрәкәтле уеннардан туя белмәдек, олылардан гел эләгеп тора иде. Әле оланнар бик тәртипле: тәрәзә төбендә утыралар, телефоннарын тотканнар. Бүтән төрле уеннарны белмиләр дә.*

**_Бер шәехнең улы белән сүләшкәне турында_**

*Ничек барса барсын дөнья – кая терәлер икән...*

*Юклык белән үскәндә булдырырга омтылу бар.*

*Бер шәехтән сорыйлар, син ничек шундый бай? «Минеке бабай, – эткән, – дәвәдә йөргән. Атам йөргән машинада. Минем самолётым бар. Минем балаларым йөрер дәвәдә».*

*«Ник алай этәсең?» – дигәннәр. «Атам эшләргә тырышкан, машина алырга халеннән килгән. Мин тагын да яхшырак эшләргә тырыштым. Инде безнең балалар әзергә-бәзер яши, аларның халеннән берни булдырырга килми, үзләре*

*тырышмагач, мин булдырганнар бетәр дә, алар тагын дәвәдә йөрер көнгә калыр», – дип аңлаткан шәех.*

*Караяков Арифулла Заһидулла улыннан (1961 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

## ***Кызыл йомырка***

*Урысларның паскасында без кызыл йомырка уздырабыз. Бер баланы эвгә дәшәбез. Бала белгән догасын укый. Фатиха сүрәсенме анда, Ихлясныймы, үңгәсенме. «Йомырка» уены була яз башында.*

## ***«Әйни Кәрәм» бәете турында***

*«Әйни Кәрәм» дигән бәет бар иде, бала чакта ук ишетеп үстек. Яшь чакта кияүгә чыккач та искә төшкәч елый идем, язмышы бигрәк кызганыч. Үз язмышым да авыр булганга искә төшә иде шул:*

*Әйни Кәрәм, айный кәмәл,*
*Буйны кәмәл.*
*Ничек тудың анадин?*
*Син тумадың анадин,*
*Елама җаным, каты елама,*
*Үзем карармын үзеңне.*

*Үзем дә искә төшкән саен ерлый идем дә, хәзер онытылган шул. Кайгыны күп күрдем мин. Бәеттә дә ишеткән юк мондый хәлләрне. Ике ятим бактым, берсенә 1,5 яшь, берсенә 4 яшь. Ул болай булды.*

*Кикиннан килен булып төштем. Мине кияүгә «егеткә чыгасың» дип алдап алдылар. Кияү йортына китерделәр. Кич белән чардактан бишек төшерде әби (кайнана), карап торам. Түшәмгә элде. Карап торам, нигә икән миңа бишек?*

*– Яшь киленгәме сәленергә? – дип көлеп әттем. Аннан кайнана оланны китереп салды. Аннан 4 яшьлеген дә китереп кертте. Аллаһ биргәнгә түзәргә кирәк. Ирем яхшы булгач, язмышыма түздем.*

*Әлеге үрнәкләрне Канеева Айшә Шакир кызыннан (1926 елгы)*
*Дубина Гөлнара Равил кызы (1971 елгы) язып алган.*
*(Мәктәптә ана теле һәм әдәбиятын укытучы Гөлнара ханым әле без Казанга кайткач та авылдашларыннан байтак фольклор үрнәкләре яздырып алып җибәрде. Экспедициябез исеменнән аңа зур рәхмәт!)*

### *Айшә әби мәзәге*

*Айшә әби – авылда иң карт кешеләрнең берсе. «Малыем тугач, атын Рафик дип кушарга килештек. Ирем шатланды инде, иптәшләре белән бәйрәм дә иткәннәр бераз. Авыл советына документ алырга баргач, ирем малыебызның исемен оныткан бит. Тел очында тора, исенә төшерә алмый. « Раф... Раф...» дип кабатлап тик тора икән. Секретарь: «Рафаэльмы аты?» – дип сораган. Ир әле бәйрәм иткәннән соң хатерләми. «Йә, шулайдыр инде», – дигән дә, оланны Рафаэль дип язып куйганнар. Кайткач, документын карасак, малый Рафик язылмаган бит. Без барыбер үзебезчә – Рафик дип йөрдек инде.*

*Беренче класска укырга баргач, малый шук, укытучы сөйләгәндә тыңламый утыра икән. Укытучы: «Рафаэль, тактага кара», – дип әтә. Ну малай колагына да элми. Бер әтеп, ике әтеп тә аңгармагач, теге килгән дә малыйны торгызып кирәген биргән.*

*Эвгә кайткач, Рафигым: «Әни, мин шкулга бармыйм!» – дип әтә. «Нәк бармыйсың?» – дим. «Анда миңа «Рафаел» дилә-әәр», – дип акырып елап йибәрде. Икенче көнне икәү киттек шкулга, малыйның атын укытучысына да, оланнарга да аңгарттым.*

### *Әбделмән купич*

*Әбделмән купичның илле бер ялчысы*
*Баралар гылавныйга урманга.*
*Шушы бәлялардин Ходай коткарсын иде,*
*Ак куй суяр идем лә корбанга.*
*Әбделмән купичның тройка аты*
*Сембер губирналарында җигәргә,*
*Унике пот ярым кәгазь акчам иде,*
*Аллам насыйп итмәде биләргә.*
*Әбделмән купичның таза да катыны,*
*Кигән киемнәре лә чын ука.*
*Купичлар арасында*
*Мин мактаулы купич идем,*
*Ник берсе дә алмый парука?*
*Һай-һай-лай гына һай-һай-һай,*
*Әбделмән купичның казлары.*

*Сембер урамында елаша йөриләр*
*Әбделмән купичның кызлары.*
*Таштан салдырдым ла ак мәчет,*
*Шыгырдан иленә дан өчен,*
*Шыгырдан халкына барып әтегез,*
*Коткарсыннар Алла хак өчен.*
*Уникедер минем тирмәнем,*
*Туарларым күп иде,*
*Изгесен күрмәдем,*
*Малымнын зәкятын бирмәдем.*
*Әбделмән купичның йорты кругына*
*Як-ягына бәләгән аюлар.*
*Әбделмән купичны судит итәләр,*
*Сембер губирнасында майурлар.*
*Бусагаларында мрамыр таш кына,*
*Судлап йөреп лә йөриләр баз булды,*
*Судлап йөреп лә йөри баз булды.*
*Унике пот үлчәгән кәгыз акчам гына,*
*Башымны йолырга аз булды.*
*Үзем йөри торган сивый айгырымны*
*Бирче, әни кәбәм, итеп кенәзгә.*
*Акча суга торган алтын ыстанукны*
*Әни кәбәм, чыгарыгыз герәзгә.*
*Әбделмән купич таш мәчет салдырган*
*Сембер губернасына дан өчен,*
*Әбделмән купичны Себер озаталар*
*Фальшивый сугылган мал өчен.*

Информант сүзләренә караганда, бәетне ул бала чагында ук олылардан ишетеп үскән, бу авылда әлеге әсәрне белүчеләр күп булган.

*Ишмаметова Мөнәвәрә Рәхим кызыннан* (*1931 елгы)*
*Гөлнара Дубина язып алды*

## Пачелма районы Решетин авылы

Авылга 1713 елда нигез салынган, диләр. Решетин турында хаклы рәвештә «Бай авыл, Әләзән кебек» дигән сүзләр йөри. Халкы сәүдәгә һәм эшкә маһир, территориясе дә зур.

### ***Тау башында***

*Тау башында яшьләр җыела идек, ул елларда радиодан ишеткән ерларны отып калып, барын да ерладык. Колхозга эшкә барганда да бик ерлый идек, хәзер инде онытылган. «Ак чәчәкләр», «Сарман буйларында», «Рамай», «Кыр казлары артыннан», «Мәтрүшкәләр»не җырлый идек.*

Бу турыда Бариева Фәния Әхмәджан кызы (1940 елгы), Бариева Рауза Зәкәрия кызы (1937 елгы) сөйләделәр, җырларын да ишеттек.

*Такмаклардан күп белә идек. Истә калмаган.*

*Монголиянең урамын*
*Таптамам дигән идем.*
*Туган-үскән җирләремне*
*Ташламам дигән идем.*

### ***Әбәктән***

*Балачакта әбәктән уйнадык, чабыштан. Бер кешене сайлап куялар, башкаларны куып тотарга дип. Үзләре чабалар. Әгәр ул берәрсен куып тотса, аркасына сугып, «әбәк синдә» дип әтә.*

### ***Әйтемнәр***

*Капкан кисәгеңне сыер ялады. – Үзеңнән артмаса, оланнар яратмый.*

*Пензага йомырка күтәреп бара идем сатарга. Урыс, йомырка сорап, каршыңа килеп баса, син анарга санап биргәнче, ул бер-икесен ырлаган була.*

*Әле яхшыга чыдамыйбыз, актан ак, күктән күк кирәк.*

*Тураева Заһирә Сәлимҗан кызыннан (1930 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

### ***Мәкальләр***

*Кардәшең ерак-еракта булса да, күңелеңә якын булсын.*

*Яшь чакта ирең жәл, картайгач, ирең белән бергә җыйган йортың жәл (калдырып китәргә).*

*Сүләмә күп, тавыклар да чүпләп бетерә алмас.*

*Өстен япкан ризыкны шайтан яламас.*

*Кар эресә, бозы кала, боз эресә, эзе кала.*

*Күлмәкне ямарсың, тамак ямалмый (сүз йөртү, күп сөйләү турында).*

***Кыр келәве***

*Кыр келәве җәй аенда, чәчүләр чәчеп беткәч була иде.*

*Зәрәтләр янына, күпернең теге ягына чыга иделәр дә Аллаһ Тәгаләдән яңгыр сорыйлар иде. 1924 елдан бирле үк уздырганнар. Мин бала вакытта ул келәү бар иде инде, карт-коры ел саен үткәрмичә калмады, сугыш вакытында келәү туктап тормады. Окольчага ает алдыннан чыга идек.*

*Хөрмәтләп каршы алдың,*
*Ерладың да зурладың.*
*Синең зурлап ерлавыңны*
*Күңел биреп тыңнадым.*

*Сиратның күперен кичиек,*
*Кәүсәр елгасының суын эчиек.*
*Ул су сөттән аграк иде,*
*Балдан татлырак иде.*

*Аннан фирдәвес җәннәтен насыйп ит,*
*Андагы хөлляларны киярге насыйп ит.*
*Андагы җимешләрне авыз итәргә насыйп ит.*

*Шылай бәрәкәт әтә идек. Ашаганнан соң дога кылуны безнең авылда «бәрәкәт әтү» диләр.*

*Раббым, гөнаһларымны ярлыкагыл:*
*Җаным-тәнем илә кылганым.*
*Гомеремдә күптер хата-ялгышым.*
*Иман булсын юлдашым.*

*Җаным тәнемнән аерылганда,*
*Газраил каршымда басып торганда*
*«Лә иләһе иллә Аллаһы»ны онытмырма,*
*«Мөхәммәд рәсүлулла»ны онытмырма.*

*(Казеева Сания Әхмәдҗан кызыннан (1936 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды)*

## *Бала йоклату*

*Бала йоклатканда, әгәр «үзем генә йокларга куркам», дисә, әтә идек:*

*Бисмилла, бисмилла!*
*Шайтаннар, китегез,*
*Фәрештәләр, килегез.*
*Тәмле йокы бирегез!*

*Таишева Гөлсем Ибраһим кызыннан (1955 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

## *Яшь егет (малый) белән келәү үткәрү*

*Кызыл йомырка көнне бусагалый чакыралар бер яшь, өйләнмәгән малайны. Атабыз* (ягъни сөйләүченең ире. – *Р.С.) безнең малайга да өйрәтте. Юына, таһарәт ала да кешенең йортына керә. Дога укый. Ни белгәнен, мәсәлән, Әлхәмне укый. Аннан теләк тели: сыерларыгыз сөтне күп бирсен, тавыкларыгыз йомырка күп салсын, куйларыгыз бәрәнләсен, туарларыгызның бәрәкәте булсын һ. б. Егетнең догаларына «амин» диләр, садака биреп чыгаралар.*

## *Кыр келәве*

*Кыр келәвен үткәрү гадәте иң элек безнең авылдан чыккан. Йөз ел элке корылык булган ике ел рәттән, ачлык. 1924 тә, картлар сөйләвенә караганда, аны беренче кат уздырганнар. Аллага ялынып дога кылгач, яңгырын биргән, урожай да булган. Аннан башка авыллар да кыр келәвен күтәреп ала. Тирәякын татар авылларында да үткәрәләр. Кобылкин. Кикын (Кикин) белән аралашып яшибез, келәүне алар да зурлап уздыра. Ул әле дә үткәрелә. Корбанга авыл белән әзерләнәбез, һәрберебез йортларын чистарта, юа. Акча җыелышып, корбан өчен куйлар алабыз.*

*Кыр келәве (келәү корбаны) ул корбан гаете түгел. Мөселманнарның дини бәйрәме – Корбан гаете елның теләсә кайсы аена туры килә ала. Ә безнең авылдагы кыр келәве җәй аенда гына, яңгырны шулай келәгәннәр.*

*Таишева Әлфия Касим кызыннан (1984 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

Әлфия ханым Решетин авылында безнең экспедицияне оештыру өчен җаваплы кешеләрнең берсе иде. Яшьлегендә махсус урта белем алып, авыл мәдәният йортына эшкә кайта, шунда хезмәт куя, әллә ничә төрле вазифа башкара. Үзе белгән фольклор белән дә бик теләп уртаклашты.

## Спасск районы Шалдавыч авылы

Әлеге кечкенә татар авылында «татар фольклорын белә» диярлек кешеләр чагыштырмача аз очраса да, авылның иң мәртәбәле затларыннан берсе – Юлгушева Гелҗиһан Осман кызының (1940 елгы) өендә булдык. Ул югары белемле, урта мәктәптә география укытучысы булып эшләгән, хәзер пенсиядә. Хәтер йомгагын сүтә торгач, Гелҗиһан апа балачак уеннарын искә төшерде:

### *Ашык*

*Куйның ашыгы белән уйный идек. Ашыкны инде сүәкләр белән булгач, ничә сүәк икәнен хәтерләмим, ыргытырга кирәк иде.*

### *Чүрәкә*

*Круг сыза идек палка белән җиргә, 1 метр чамасы. Бер кешене сайлап куя идек тә, ул кереп баса эченә. Кыскарак палка ала идек, шул чүрәкә була. Чүрәкәне озынрак таяк белән эләктереп бәреп җибәрергә кирәк. Палка белән суккач, ул оча. Чүрәкәсен очыра алмаганнар уеннан чыга иде.*

### *Перәшкә*

*Яшьләр уйный идек Перәшкәдән. Бер кеше водящий була, кулында перәшкә – каеш. Утыра идек эскәмиядә. Бер егет әйтә:*

*Миңа фәлән кыз кирәк!*

*Шул кыз чабып барып, теге егетнең итәгенә утыра. Шул арада каеш тоткан егет кызга перәшкә белән сугарга өлгерсә, кыз йә җырлый. Водящий алмаша, бүтән кешеләр дә перәшкә тотып чыга.*

### *Җеннәр турында әхият*

*Әхиятне әбиләр сүли иде. Оланнарны куркытырга, тыңнатырга теләгәннәрдер. Йә үзләре дә дөрес дип белеп уйлаганнардыр.*

*Имеш, пич башында җеннәр булган да, шуның өчен оланнарга пич башына менеп йокларга кушмаганнар. Җеннәр баланы идәнгә төртеп төшермәсен дип. Әби-бабайлар үзләре яткан инде, алар бисмилла әйткән, җеннәр килмәгән. Тагын шылай авылда бер арусыз йир булган дип сүләгәннәр. Имеш, төнлә аннан узган кешеләргә җеннәр чыкканны күргәннәр. Мин шулдан соң да кайта идем, төнгә тикле эшләгән чаклар да булды. Миңа бер дә җеннәр очрамады, әллә имеш-мимеш сөйләүчеләрнең күзенә генә күренгән.*

Шалдавыч авылында җәйләрен дә халык күп яшәми икән. Без Сучкова (кыз чагында Кикичева) Наилә Фәттях кызы (1965 елгы) белән очрашып сөйләштек. Ул махсус урта белемле, Ростов шәһәрендә азык-төлек кибетендә кассир булып эшләгән, хәзер пенсиядә, ата-бабалары гомер иткән авылга кайтып төпләнгән. Аннан кушаматлар турында кызыклы мәгълүмат алдык. Авыл кешеләренең кушаматлары күпне сөйли: Әбеш, Шаян, Хромой, Мыкач, Кубыр (кобра сүзеннән). Наилә ханымнан уеннар да яздырдык.

### *Дүртле бию*

*Клубта уйный идек. Или кызлар/кызлар, или кызлар/егетләр. Калганнар кругка баскан, кулга кул чаба, такмак әтә. Уртада дүртәү басканнар, пар-пар булып әйләнеп бии. Аннан икесе кала, алар урынына яңа пар чыга. Тагын бииләр, баштагы икесе кереп баса кругка, алар кругтан тагын бер парны сайлап чыгара. Башта һәр ике пар үз пары белән әйләнә, аннан парларын алмашалар. Тагын бер пар кругка баса, алар урынына тагын яңалары биергә чыга.*

## Спасск районы Белоозерка авылы

Авыл кечкенә, халкы аз булса да, аларда да татар халык иҗатына кагылышлы беркадәр мәгълүмат саклана, экспедициябез моңа канәгать кала.

### *Чүчек*

*5 камешка кирәк. Ташның берсен югарыга ыргытасың, ул очканда берсен алып өлгерергә кирәк. Аннары тагын*

*ыргытасың, дүртесен дә шулай алып өлгерергә. Алып өлгермәсәң, җиргә төшерсәң, уен башка кешегә күчә.*

*Элеккеге укытучы Утемишева Мәрьям Әрифулла кызыннан (1961 елгы) Р. Сафиуллина язып алды*

### *Перәшкә*

*Кругта басканнар икешәрләп, бер лишний йыгыра йери. И теге должен бер кеше алдына басарга. Баса, теге кеше йыгыра китә, каешны теге кешенең артына ыргытып китә. Ыргыткач та китеп өлгермәсә, йомшак җиренә каеш белән сыптыра.*

*Тинчурина Кадрия Әхмәдҗан кызыннан Р. Сафиуллина язып алды*

## Пачелма районы Татар Никольское авылы

### *Авыл тарихыннан*

*Имеш, кенәз Мамин булган. Ул монда килеп утырган. Шуннан калган инде бу авылда Мамин фамилияләре күпчелек. Шулай ук Мамлеевлар, Бигловлар, Муджуковлар һ. б. булган. Авыл хәзер Русское Никольское белән кушылган, кайчандыр биредә татарлар күпләп яшәгәнне әлеге дә баягы фамилияләр һәм гамәлдәге мәчет (мулласы да бар), мөселман зираты искәртеп тора. Кушылу, нигездә, совет чорында башланган, 1920 елларда. Бу авыл 1926 га кадәр Шишали булган. Революциягә кадәр Татар очы һәм Урыс очы булган. Совет чорында да биредә татар мәктәбе булмаган, бөтен фәннәр урысча укытылган. Авылда хәзер 140 кеше исәпләнсә, даими яшәүчеләр яртысыннан ким. Татарлар тагын да кимрәк.*

Информантлар әйтүенә караганда, катнаш гаиләләр күп. Халык үзен, «без инде урыслашкан» дип саный.

*Чынлап торып катнаш гаиләләр кору, ассимиляцияләшү 1973–1975 елларда башланган. Бирегә бер-ике урыс гаиләсен – инженер һәм кайсыдыр башка белгечләр гаиләсен китереп утырталар, колхоз аларга йортлар бирә. Шуннан китә инде буталу.*

*Мамина Алия Али кызыннан (1953 елгы) Р. Сафиуллина язып алды*

*Без яшь чакта «Уракчы кыз»ны , «Шахтёр» көен, яшь кызны карт бабайга кияүгә бирүләре турында яратып җырлыйлар иде.*

*Яшь чактан ук олылардан мәкальләр отып калганбыз:*

*«Дошманыңа баз казыма, үзең ары элэгерсең».*

*«Хуҗаның төрлесе булган кебек, кунакның да төрлесе була». Ягъни каселарын (кайсыларын), озатканда, «тагын килегез» дип чакырып калалар. Каселарына хаерле юл гына телиләр, моннан бер шутка килеп чыккан:*

*– Сау булыгыз инде, без китәбез.*

*– Хаерле юл.*

*Шук кеше инде хуҗаның тел төбен аңласа да сер бирми, шутка белән җавап кайтара:*

*– Киткәннәрдән дә хәбәр юк, – ди.*

*Армиягә киткәндә егетләр ерлый иде:*

*Дулкынлы диңгез,*
*Ап-ак пароход.*
*Мине озаталар*
*На Дальний Восток.*

*Семенеева Сара Фатих кызыннан*
*Р. Сафиуллина язып алды*

## Вадинск районы

Гадәттә, экспедиция көннәрендә без авылларга чыгып китеп эшлибез. Шулай да кайвакыт информантлар белән очрашулар район үзәкләрендә дә була, һәм алар оешкан төстә үтә. Вадинск районына килгәч тә, татарлар белән башта район үзәгендә җыелып сөйләштек, аннан соң авылларга чыктык.

Мондый очрашуларның бер үзенчәлеге бар: татар фольклорын белергә тиешле кешеләр монда төрле-төрле авыллардан җыелган була. Күбрәк рус телле тирәлектә тормыш иткәч, район үзәгендә көн күрүче информантларның татар халык иҗаты һәм милли традицияләр белән элемтәне җуя башлавы да сизелә.

*Кечкенә оланнарны шылай тынычландыра идек:*

*Баш бармак,*
*Балан үрдәк.*

*Терми-терми,*
*Серми-серми,*
*Кечерәк кенә бармак. Тырнакларны, бармак очларын шулай дип уабыз.*

*Әхиятләрне без ишетеп үсмәдек тә, китаплардан Шүрәлене, Су анасын белә идек.*

*Батракова Сафия Хасән кызыннан (1954 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

*Качыштан, лаптадан, вайнадан унядык. Хазер яхшы хәтерләмим инде, онытыла башлаган.*

### *Качыштан*

*Таяк (шобага) тота идек, кемнең кулы өскә чыга, шул мается. Стенага или агачка терәлеп бите белән, күзен томалап баса. Саный 10 га хатле. Тегеләр качалар кем кая. Теге әтә, бетте санадым дир и китә эзләргә. Бу урыннан кузгалганны качкан кешеләр күтеп кенә торалар, чабалар, шул стенага или агачка китереп сугалар куллары белән. «Шыкытый, шыкытый син калдың», имеш. Бу каселарын үзе күрсә, тизрәк агачка үзе китереп суга: «Мәнсур анда, или Ариф, күрдем имеш, сине. Шык-шык!» Эзләп тапса, шул табылган кеше мается, ә бу үзгәләр белән кача. Тапмаса или «шык-шык» итәргә өлгермәсә, тагын бер кон башка качучыларны эзли.*

*Считалкалар да әтә идек, урысча күбрәк. Татарлар белән татарча сүләшеп унядык, урыслар белән урысча.*

*Утемишев Арифулла Усман улыннан (1956 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

*Әллә нинди аерым уеннар уйнамадык без. Лапта уенын уни идек. Ызба ясый идек комда. Качыш уни идек. Мин Чудовкадан, Чудилка дип тә атялар иде аны. Авыл кечкенә иде хазер бетте инде.*

### *Качыш уены*

*Малыйлар, кызлар уни идек. Алтышар-җидешәр кеше дә була идек. Күбрәк тә. Урыс-татар бергә, урысча считалкалар атә идек. Бер кеше водящий була. Калганнар кача. Унга тикле саныйбыз да качучыларны эзлибез.*

### ***Черта***

*Черта уенын уйнадык. Ул «классики», 10 шакмакка очертлап сикерә идек. Кем сикерә алмый, чертага аягын тидерә – ул уеннан чыга, башка кеше сикерә.*

### ***Сикерү***

*Аркан белән сикерә идек, сикергеч юк. Берең анда, берең бу якта. Шулай тоталар да, берсе уртада сикерә.*

### ***Сукыр***

*Күзгә яулык бәйләп, качкан кешеләрне дә эзли идек. Анысы «Сукыр» булгандыр инде. Тегеләр мыш була, или бик озак эзләсә, кулга кул чаба.*

### ***Ташу озату***

*Яз башында ташу киткәнне карарга төшә идек. Зур-зур бозларны озатканда: «Бозлар туктамасын! Ары аксын!» дип кала идек. Елга агып бара иде безнең авылдан, елганы да Чудилка атәләр иде, шуның янында тора идек.*

### ***Казлар очканны күргәч, теләк әйтү***

*Язын казлар очканны күрсәк, өйдә утырган каз астына салам куя идек. «Кыр казлары күбәү оча, безнең каз бәбкәләре дә шулчаклы булсын», дип.*

*બездә язын кызыл йомырка буяганнар, балалар җыялар иде. Аннан урамга, тау башына чыгып, йомырка каталата идек.*

*Һәр кеше үеннән йомырка алып чыга, бернеме анда, берничәнеме. Казып куйган базга каталап төшсә – ота, әгәр оттырса – елый да.*

*Татар Лакасы авылында Васикова Райсә Сафиулла кызыннан (1948 елгы) Р. Сафиуллина язып алды*

## **Вадинск районы Мучали авылы**

Монда өч йорт бар. Мәскәүдән кайтып, ата-бабасы нигезенә йорт салган бер байның өен саклаучы да бар. Тагын бер йортта информант белән аралашу насыйп булды.

Мифтахетдинова (Кильдеева) Мәнсура Халүй кызы (1953 елгы) Ленинградта туган, 1 яшеннән 14 яшенә кадәр Мучалида яшәгән, әти-әнисе шушы авылныкы.

*Әби мөнәҗәт әйткән, дини китаплар һәм башка китаплар укыганны хәтерлим. Бер мөнәҗәтнең фрагменты истә калган:*

*Килер Газраил җаным алыр,*
*Кызыл йөзләрем саргаеп калыр.*
*Мин үлгәндә, җаным чыкканда*
*Якын тормагыз. Ашыктырмагыз,*
*Ачык тотмагыз.*

*Әби таһарәт ала да безне, оныкларын, килнесен, кызын янына җыеп утырта, атна саен җома чагында Коръән укый иде. Тыңлагыз, дия иде.*

**Балачак уеннары. Кызыл йомырка. Әтелгән йоласы**

*Урамда оланнар белән күп уеннар уйнадык. Язын пятачокта җыелганнар. Һәр йорт каршында такталар, бүрәнәләр булган. Шунда утырып, йөзек салыш уйнаганнар. Ремень уйнаганнар. Тагы лапта, йомырка каталату. Келәү булган.*

*Йомырка каталатырга көннәр җылыткач китә идек. Баз казыйбыз, тирән түгел, 15–20 см. Пешкән йомыркалар бар һәрберебездә, шул базга кемнеке төшеп китә, шул кеше башкаларныкын да үзенә ала.*

*Безнең авылда бер йола яши иде, аны башка җирдә очратмадым. Мин ул йола белән балачактан таныш. Әбиләрнең яшь чагыннан шулай килә булган.*

*Кайчандыр (революциягә кадәрме, анысын белмим) Дәүләткилдеев дигән алпавыт яшәгән. Мин дә шуның нәселеннән булам. Ул зарок биргән: һәр кызыл йомырка көнендә ул суяр каз. Каз бәйрәме ясар, шылай әтелгән булган.*

*Шулай итеп, һәр паскага казмы, үрдәкме суя торганнар иде алар нәселе. Весь авылны чакырып хатем (Коръән уку) була иде. Барлык Дәүләткилдеев нәселләре каз асрый. Ноябрь-декабрь айларында суйсалар, элеп, эченә тоз тутырып куялар да хатем өчен саклыйлар, апрельдә шул йомырка бәйрәменә эшти пешерәләр иде. Нәзерне бездә «Әтелгән» диләр. Хатемдә саулык-сәламәтлек сораганнар. Дәүләткилдеев бабайның ни өчен нәзер әйткәнен белмибез. Аның уллары тугызау булган, кызлары булмаган, бәлки шуның өчендер. Фамилиябездән «Дәүләт» төшеп калган, «Кильдеев» кына калганбыз. Совет заманында шулай бабайларыбыз кыскарткан.*

## Вадинск районы Татар Шуриновкасы авылы

*Безнең авыл Татар Шуринкасы. Рус Шуринкасы да булган, ерак түгел. Степан Разин восстаниесен татарлар поддержали, аларны расселили. Биш брат булган, чукындырудан качып, берсе монда килгән. Шуринка дип шыннан калган, диләр.*

*Мәктәп монда улмаган, 4 сыйныфка кадәр Рус. Шуринкасында, аннан соң Вадинскида укый идек. Мин тукучы булырга укыдым, кияүгә чыгып, Ленинградка киттек. Үзебезнең нигезгә җәй көннәрендә ялга кайтабыз. Берничә йорт бар, аларда кеше яшәми. Авылыбыз турында үз җырыбыз бар:*

*Шуринка – безнең илебез,*
*Уртасында күлебез.*
*Отпускагызга килегез,*
*Падыручком йөрербез.*

*Джамаева Кәшифә Заһидулла кызыннан (1955 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

*Балачакта йорт каршында һәркемдә бүрәнәләр, такталар өеп куйган була иде. Без шул бүрәнәләрдә утырып уеннар уйный идек. Утырып берәр уен (ватык телефон) уйнасак, аннары тотына идек чабышырга, салки (әбәк), качышны күп уйнадык.*

### *Ватык телефон*

*Утыралар такта өстенә тезелеп, бер кешене сайлап куялар уртага чыгарга. Ул балалар каршына чыгып баса да төрле хәрәкәтләр күрсәтә башлый. Мәсәлән, бәрәңге утыртканны, көтү көткәнне һ. б. Башкалар аның ни күрсәткәнен белергә тиеш. Иң беренче дөрес әйткән кеше үзе аның урынына чыга.*

### *Ремешок*

*Кызлар-егетләр пар-пар булып утыралар, берсе парсыз утыра. Ул кулына каеш тота да әтә: «Миңа шул-шул кеше кирәк!» Исеме чыккан кешене аның янында утырган кеше җибәрергә теләмәсә, кадерле булса, «Җибәрмим!» ди. Парсыз кеше аңа: «Җибәрмәсәң, каеш белән китереп сылыйм», ди. «Ярар», – ди җибәрмәгәне. Аның янындагы кешедән водящий сорый: «Ничәне бирим? Җылымы? Кайнармы? Уртачамы?» – дип сорый. Мәсәлән, «Биш кайнарны!», дип җавап бирә. Җылы*

*булса – сугу урынына сыйпап кына ала, уртача булса – суга, кайнар булса – кызганмыйча суга. Әгәр янында утырган кешесен җибәрсә, водящий беркемгә сукмый. Янындагысына суктырасы да, җибәрәсе дә килмәсә, ул кеше каешны үзе кабул итә.*

*Янгулова Галибә Касим кызыннан (1974 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

## Лунино районы Шыкша (Синорово) авылы

*Яшь чакта вечерга чыгарга сорый идек әти-әнидән. Эш күп булгандыр инде, әнинең җибәрәсе килми. «Утырган уза, йөрегән туза» – дип, халык мәкале белән сүзенә пичәт баса иде.*

*Вечерда җырлый торган такмаклардан берсе:*

*Әнә килә автомобиль,*
*Төягәннәр курькалар.*
*Быел егетләр үләнми,*
*Ашатудан куркалар.*

*Килен үз авылыңныкы булырга тиеш, дип әйтәләр иде безнең якта: «Яхшы сыер үз авылыннан читкә чыкмый».*

*Яшь чакта каз өмәсенә йөри идек. Каз йолыкканда тиресе ертылса, «ирең рябой була», диләр иде.*

*Кыз чакта суга бара идек бит. Су ташыганда итәгең суга төшеп китсә, «ирең исерек була» дигән сынамыш әйтәләр иде.*

*Яшь чакта әбидән (Фатыйма Ашир кызы, 1884–1980) ишеткән мәкальләрне хәтерлим: «Ирдән иргә йөргәнче, гүрдән гүргә йөре». Һәм «Сабыр иткән – морадына җиткән. Түзәлмәгән – гүргә кергән».*

*Кияүгә чыккач, кайнана төнге икедә йокыдан көйләп уята иде:*

*Тор. Тор, кызым, тор инде,*
*Йокың туйгандыр инде.*
*Матур кызлар чәй сывыннан*
*Кайта торгандыр инде, – дип, суга җибәрә иде.*

*Апкаева Раисә Мәхмүт кызыннан (1950 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

*Бала бакканда:*

*Әлли-бәлли син, балам,*
*Йокла син, куянчыгым.*

*Әниең эштә, әтиең ил саклый,*
*Ә син миңа тагылган, –*
*дип көйләп йоклата идек.*

*Калашникова Фәридә Руфаил кызыннан (1969 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

*Такмаклар әйтә идек:*

*Әнә килә автомобиль,*
*Төягәннәр лишата.*
*Үлән, егет, ник куркасың?*
*Әле (хәзер) кызлар ашата.*

*Сезнең очтан безнең очка*
*Очып килә йомычка.*
*Бүрегеңне кыңгырайтып,*
*Йөремә безнең очка.*

*Курмашева Дилә Хәмзә кызыннан (1970 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

* * *

Пенза өлкәсе татар авылларында җыелган фольклор материалларыннан күренгәнчә, монда 85–95 яшьлек информантларның бик сирәге генә уйнаган уеннарын яки яшьлегендә кечке уеннарга йөргәнен исенә төшерә. Гадәттә, әби-бабайлар: «Безнең яшьлегебез бик авыр елларга (вайнага, сугышка) туры килде (әтисез үстек), гел эшләп уздық», – диләр. Ятимлек ачысын татыган, авыр сугыш елларында үскән, колхоз эшеннән арып кайткан ялгыз аналарына булышкан, үзләре дә бала килеш бала баккан сабыйларга күңел ачу, уйнарга чыгу бәхете һәркөн тимәгәндер дә. Чорына туры китереп, уеннары да «Вайнадан», «Чүрәкә», «Ашык», «Таяк» (клёк, клюк) дип аталган. Әмма хәзерге 60–85 яшьлек кешеләр буынының балачактагы, үсмерлек чоры һәм яшьлектәге уеннары, күңел ачулары төрлерәк, күбрәк вариантлы булуына игътибар итми мөмкин түгел. Шулай да, мишәр җирлегенә хас булганча, бу яклардагы уеннарның атамаларында русча сүзләр күп очрый: лапта, городки, клюк, черта, ремешок, перәшкә (пряжка) һ. б.

Тагын шунысы ачыкланды: җирле халык, ислам дине белән бәйле йолаларны (гает, ураза һ. б.) үтәү белән беррәттән, христианлык белән бәйле яисә мәҗүсилектән килгән гореф-гадәтләргә, димәк, шуларга барып тоташкан фольклорга да игътибар бирә. Әйтик, бу якларда кызыл йомырка, паскы (паска), йомырка каталату, төрле keләүләр үткәрәләр, аларда балалар һәм яшьләр актив катнаша.

Авылларда халык электән үк (хәтта әле бүген дә) очларга оешып яши. Очларның хәзер дә төгәл атамалары бар – өлкән буын кешеләренең балачак уеннары, яшьлектәге күңел ачулары шушы топонимик локацияләр белән тыгыз бәйләнгән. Һәм мәкаләдә дә әлеге темага җитди игътибар бирелде. Шул ук вакытта, өлкән яшьтәгеләр ассызыклавынча (әби-бабайлар, ата-аналар), хәзерге яшь буын инде буш вакытын урамга чыгып, бүтән балалар белән хәрәкәтле, җырлы-биюле яки акыл-зирәклек уеннары уйнап уздырмый. Яшь-җилкенчәк тә «Кич утыру», «Вечер» «Круг уены»нда күңел ачмый. Чөнки «җанлы» милли уеннарыбызга алмашка гаджетлар килде – яшь буын шуларга мөкиббән. Әйе, авыл җирлегендә мәдәният йортында, мәктәпләрдә, балалар бакчаларында (шушы оешмалар сакланып калганнарында) балаларны әле өлкәннәр татарча уеннар уйнарга да өйрәтә. Ләкин бу күренешне, кагыйдә булудан бигрәк, искәрмә дисәк, дөресрәктер. Тагын бер күзәтү: Пенза өлкәсенең татар авылларында әкият сөйләүчеләр очрамады диярлек. Кешеләр, билгеле, балаларына-оныкларына әкият сөйләми тормый. Алар китаплардан укыган әкиятләрне сөйли. Информантлардан язып алынган «Гөлчәчәк», «Оятсыз этәч» әкиятләре – шул күренешкә мисал. Югыйсә, узган гасырда гына бу төбәк татар дөньясындагы иң атаклы әкиятчеләрнең берсе Абдулла Кротовны биргән. Пенза якларына 1956 елгы фольклор экспедициясе җыелган материал ягыннан бик төрле һәм бай.

Өметсез – шайтан, ди. Пенза өлкәсе Каменка районы Кикин авылында мәктәп укучыларының (оештыручысы – Равилә Баткаева) милли фольклорны бөртекләп җыюларын ишетеп, тупланган материалларны үз күзләребез белән күреп кайткач, хәлләр алай ук өметсез түгел әле дип сөендек.

Халык монда бигрәк тә җор телле, мәзәк, такмакларны күп беләә. Чөнки эшкә оста халык, әлбәттә, күңел ачканда да ихлас була. Һәр авылда диярлек такмак әйтү-әйтешүне яздырдык. Мишәр татарларының такмаклары назлы итеп баштан да сыйпый, кайвакыт үтемле генә чеметеп тә ала. Туй, никах йолалары белән бәйле текстларның күплеге дә киләчәкнең өметле булуына ишарәли.

Татар авылында бәет, мөнәҗәт ишетмәсәң, гаҗәп булыр иде. Бәетләрне хәзер дә чыгарып кына тора халык. Дөрес, әлегә алар телдән телгә йөреп «шомармаган», күбрәк кәгазь битләрендә, җыр дәфтәрләрендә теркәлгән килеш саклана. Шуңа күрә аларга игътибар бирелмәде. Мөнәҗәтләргә килсәк, алар һәр авылда башкарылды, тик оригиналь дип тапкан, ишетелмәгән-укылмаганнары – юк дәрәҗәсендә.

Гомумән алганда, фольклор экспедициясе татар халкын, аның күңел байлыгының бүгенге торышын бик ачык күрсәтә. Халкыбыз, бернигә карамастан, үзенең тарихын, рухи кыйммәтләрен белергә тырыша. Һәр авылда диярлек язып алган очлар, урамнар, топонимик локацияләргә бәйле риваятьләр, авыл тарихлары – моңа дәлилдер.

Шунысын да искәртергә тиешбез: экспедицияләрдә җыеп алынган барлык материалны бер мәкаләгә сыйдырып бетерү мөмкин түгел. Шуңа күрә Пенза өлкәсендә язып алынган һәм әлеге мәкаләгә керми калган уен фольклорын мәкалә ахырында аерым туплап бирдек.

## Уен фольклоры: Пенза өлкәсенә оештырылган комплекслы экспедицияләрдә язып алынган уеннар һәм санамышлар

*(2007, 2021–1922 елларда тупланган материаллар буенча)*

### *Наза*

*(I вариант)*

Уенчылар парлашып, кулларын югары күтәреп, тотынып ике рәткә басалар. Артта бер кеше парсыз кала. Ул куллардан хасил булган «капкалар» астыннан алга таба иелеп уза. Узганда рәттәге бер кешене үзе белән эләктереп китә. Алар алга барып

басалар, кулларын күтәреп, «капка» ясыйлар. Ялгыз калган кеше тагын иелеп алга атлый, үзе белән берәүне эләктереп алга барып баса. Күмәкләшеп һәрвакыт җырлап торалар:

Наза, Наза,
Наза матур кыз бала.
Наза дигән пионерка
Һәрвакыт алда бара.

Яки:

Наза дигән кыз баланың
Чиләкләре бөрлегән.
Көн дә, көн дә «Наза» уйнаганга
Бер дә чыкмый күңелдән.

*2021 елда Городище районы Югары Әләзән авылында*
*Байбекова Галия Рәүф кызыннан (1977 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

***Наза***
*(II вариант)*

Балалар бер-бер артлы тезеләләр. Бер бала парсыз, ул уенчылыр каршысына чыгып баса. Балалар, җырлый-җырлый, баскан җирдә аякларын-кулларын хәрәкәтләндерәләр:

Наза дигән кыз баланың
Бөрлегәне түгелгән,
«Наза» дигән уенны без
Уйныйбыз чын күңелдән.
*Кушымта:*
Наза, Наза,
Наза матур кыз бала.
Наза тырыш, уңган бала,
Зирәк, акыллы бала.

Кушымтаны җырлаганда, парсыз бала каршыдагы уенчылар арасыннан биеп үтә, үзенә пар сайлый, һәм алар икенче башка барып басалар. Парсыз калган бала уенны дәвам итә.

*2022 елда Белинский районы Качкару (Кутеевка) авылында*
*Дубина Гөлнара Равил кызыннан (1971 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

## ***Күпер***

Аулак өйләрдә уйнала торган уен. Егетләр-кызлар парлашып кара-каршы басалар, кулларын өскә күтәреп, күпер хасил итеп, һәркайсы үз парлары белән тотынышалар. «Күпер»ләр бер-бер артлы рәткә тезелә. Парсыз калган берәү «күпер» уртасыннан уза. Яшьләр җырлый:

Күпере, күпере,
Күпереннән үтүе.
Күңелле бүләк итүе,
Авыр ташлап китүе.

Башка шаян җырларны, такмакларны да җырларга була.

*2021 елда Городище районы Урта Әләзән авылында*
*Мукаева Алия Искәндәр кызыннан ( 1961 елгы)*
*Р.Ф. Сафиуллина язып алды*

## ***Почта***

Бу уенны без бала вакытта да, борынга ис керә башлагач, кичке уеннарда да яратып уйный идек. Кәгазь-каләм булырга яки хатлар алдан язылырга тиеш. Хаты бер-ике сүз генә булырга да мөмкин, адресаты төгәл күрсәтелсен! Хатны яхшылап төрепябыштыргач, яшереп кенә почтальонга тапшыралар. 7–8 кеше утыра, күбрәк тә ярый. Берәү почтальон була, ишек шакый.

– Тук-тук!
– Кем бар?
– Почта!
– Каян киләсең?
– Аембура авылыннан.
– Ни китерәсең?
– Хат.
– Кемнән кемгә?
– Камилдән Мәдинәгә.

Кыз хатны алса, җавапка җырлый:

Шкулга[1] барам, шкулга барам,
Түгелә карам, карам.
Үзе алса, Аллаһ кушса,
Обязательно барам.

[1] Шкул – мәктәп.

Хатны алмаса да, җавап итеп җырлый:

Мә сиңа тозлы кишер,
Мә сиңа тозлы кишер.
Ал хатыңны, кит обратно,
Үз сөйгәнемнән китер.

Яки:

Мә сиңа тозлы кыяр,
Мә сиңа тозлы кыяр.
Ал хатыңны, кит обратно,
А то[1] сөйгәнем тояр.

Кайвакыт хатны алса да, дәшми калган уенчылар була. Башка уенчылар моны үзләренчә юрап, күмәк җырлыйлар:

Эскерипка-барабан,
Эскерипка-барабан.
Хак сүзгә җавап табалмый –
Күңеленә яраган.

### *Әмбәлүк*

Уенчылар ике командага бүленеп, унбиш-егерме адым китәләр һәм кара-каршы якка басалар. Кулга-кул тотынышалар. Бер як икенчесенә кара-каршы әйтешә (җырлый):

– Күктә-күктә ниләр бар?
– Ямбар[2] белән шикәр бар.
– Ямбарыңны сат миңа.
– Ник сатыем мин сиңа?
– Әмбәлүк!
– Ни кирәк?
– Кара кашлы, зифа буйлы Мәрьям
(яки башка исем әйтәләр) атлы кыз кирәк.

Мәрьям чаба-чаба барып, каршы яктагы ике кешенең кул арасын өзәргә тиеш. Өзсә, теләгән кешесен сайлап, үз командасына алып китә. Өзә алмаса, үзе дә шунда кала. Уен шул рәвешле дәвам итә.

*2021 елда Городище районы Югары Әлләзән авылында*
*Байбекова Галия Рәүф кызыннан (1977 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

---

[1] А то – югыйсә.
[2] Ямбар – имбирь.

## *Ялкын*

«Ялкын»ны вичерларда[1] уйный идек, яшьләр җыела, түгәрәккә баса. Идән уртасына чыга идек тә, ике кеше урындыкка утыра, тагын ике кеше – алар тирәли әйләнә идек. Утырганнар кыз белән егет була инде. Берсен берсе ярата, икесенә бер ыстулда (урындыкта) утыралар, йөрәкләре җитсә, сүләшәләр яки дәшмичә генә утыралар. Әйләнә торган егет белән кыз берәр озын җыр җырлый, башта егет йөри, аның артыннан кыз ияргән.

Җыр беткинчә тегеләр бер урындыкта утырырга тиеш. Җыр бетүгә, утырганнар түгәрәккә баса, хәзер инде җырлап әйләнүчеләр икесе бер урындыкка утыра. Әйләнергә тагын бер пар чыга да, уен тагын башлана. Атына[2] яратышып йөргәннәрне чыгаралар иде, әгәр белсәләр. Белмәсәләр, теләсә кем белән дә чыга. Кыз белән кыз да булырга мужыт. Такмаклар да ерлый идек:

Кодалар, кодачалар да,
Кодалар, кодачалар.
Сездә ничек, бездә шулай
Ерлап күңел ачалар.

Яшь вакытта һәркемнең дә
Бик күп була сөйгәне.
Ләкин арада бер була
Гомерлеккә дигәне.

Яшь вакытта яшьнәргә дә,
Күкрәргә дә көч җитә.
Ләкин кадерен белү кирәк,
Яшь вакытлар тиз үтә.

*2021 елда Городище районы Югары Әләзән авылында*
*Жаркова Сафура Али кызыннан (1945 елгы, Урта Әләзәндә туган)*
*Р. Сафиуллина, И. Ямалтдинов язып алды*

## *Ике ялкын*

Авылда өмә үткәргәч, әти-әни кызларга вичер (кичә, кич утыру) ясарга рөхсәт бирә иде. Шундый вичерларда уйналган уеннарның берсе бу.

[1] Вичер – яшьләрнең кич утыруы яки кичке уеннар («вечер» сүзеннән).
[2] Атына – махсус.

Уртада бер ыстул тора, анда ике кеше утыра. Алар ничек тә сыярга тиеш. Алар тирәсендә тагын ике кыз биеп әйләнеп йөри. Биючеләр һәркайсы берәр ер[1] яки такмак башкара.

Әләзән, Әләзән,
Туган авылым Әләзән.
Безнең яшьлек елларыбыз
Әләзәнгә бәйләнгән.

Шаян такмакларны бигрәк тә яратып ерлый идек:

Ике арыш, бер бодай,
Ике арыш, бер бодай.
Уртадагы парочкага
Мәхәббәт бирсен Ходай.

Яки:

Галиямә, бәгыремә
Газет укытыр идем.
Роза гөлләр арасына
Итеп[2] утыртыр идем.

Ерлап бетергәч, утырганнар торып китә, алар урынына ерлаган пар утыра. Тагын бер пар утырган пар тирәсендә ерлап йөрергә чыга. Әгәр бу уен егетләр дә, кызлар да җыелган җирдә уйналса, яшьләрнең бер-берсенә хисләрен башкалар да чамалый ала. Яки уртага махсус берсен берсе ярата, дип уйланылган, ләкин хисләрен ачып салырга ашыкмаган егет белән кызны чыгарганнар. Яшьләр кемнең нинди ер ерлаганыннан да, утырган парның үзен ничек тотуыннан да тиешле нәтиҗәне ясаган.

*2021 елда Городище районы Урта Әләзән авылында*
*Сенҗапова Асия Фәттях кызыннан (1964 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

### *Зеләйлү*

Кич җиткәч, киенеп-ясанып уйнарга төшә идек. Болында «Зеләйлү» уйный идек. Ике рәттән баса идек. Егетләр дә булса – егетләр бер рәт, кызлар бер рәт. Ике рәт кара-каршы ерлап килә идек.

Зеләйлем дигән тавыш,
Аннан тавыш,

[1] Ер – җыр.
[2] Итеп – илтеп.

Моннан тавыш,
Сөйгәнең белән кавыш.
Ай, Зәйлел-Зеләйлү,
Сөйгәнең белән кавыш.

Е г е т л ә р е р л ы й:

Сандугачлар югары,
Югарыда юллары.
Каршыдагы рәттән килә
Авылыбызның нурлары.
Ай, Зәйлел-Зеләйлү,
Авылыбызның нурлары.

Га р м у н ч ы ерлата инде. Аның да үзенә атап ерлыйбыз.

Уйнат, егет, гармуныңны,
Үрләргә менгәндә дә.
Онытмамын үлгәндә дә,
Гүрләргә кергәндә дә.
Ай, Зәйлел-Зеләйлү,
Гүрләргә кергәндә дә.

Г а р м у н ч ы д а е р л ы й:

Гармун уйныйм, гармун уйныйм,
Уйнасам беләгемдә.
Чыгып тулган айга карыйм
Сиңа йөрегәнемдә.
Ай, Зәйлел-Зеләйлү,
Сиңа йөрегәнемдә.

Рәттән кара-каршы ерлагач, парлап әйләнә идек. Кыз белән кызмы анда, егет белән кызмы.

*2021 елда Лопатино районы Селәү авылында*
*Туктарова Кадирия Сәфәр кызыннан (1939 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

### ***Кузна***

Балалар элек, карлар эреп беткәч, җыелып, кузна уйныйлар иде. Уйнаучылар саны күбрәк булса, уен кызыграк. Сыерның яки куйның берничә маталыйшкасын[1] әзерләп куярга кирәк. Ул кузна була. Җиргә 1–2 метр ян-яклы квадрат сызыла. Шуның уртасына кузнаны утыртып куярга кирәк. Җиргә сызыклар

[1] Маталыйшкасы – тез сөяге.

сызалар. Шул рәвешле, кузнага нинди ераклыктан таяк ыргытырга кирәген билгеләп куялар. Әлеге сызыклар артына басып, бер таяк (уклау) белән шакмак эчендәге кузнага ыргыталар. Кузнаны авыктырырга[1] кирәк. Һәр кеше үз чираты җиткәч, өч-биш тына (мәртәбә), алдан ук сөйләшеп куеп, кузнага суга. Икенче бер уенчы суккан һәм очып киткән кузналарны җыеп, уен җиренә китереп торырга тиеш. Аннары алар урыннарын алмаша.

*2021 елда Городище районы Урта Әләзән авылында*
*Мукаева Алия Искәндәр кызыннан (1961 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

## Кабыстабаш

Зуррак малайлар-кызлар зур түгәрәккә басалар. Һәркайсы баланың алларына кечерәк балалар чүгәләп утыра. Эчтәге түгәрәктәгеләр (кечерәкләр) «кабыста» була, зурраклары аларны, имеш, кәҗәдән саклый. Берәү уенны алып баручы, көтүче. Ул тышкы түгәрәккә баскан уенчының терсәгенә кагыла. Алар икесе ике якка чабалар. Утырган бала шул арада торып, чабып киткән бала урынына , буш җиргә баса. Беренче чабып килгән бала буш урынга утыра. Урынсыз калганы көтүче була.

*2021 елда Городище районы Урта Әләзән авылында*
*Бухминова Раисә Әсәдулла кызыннан (1960 елгы)*
*Р. Сафиуллина, И. Ямалтдинов язып алды*

## Кәбестәбаш

Барлык уенчылар парлаша да икешәр-икешәр урнашып, зур түгәрәк ясый: берсе баса, аның алдына икенчесе утыра. Бер кеше парсыз кала – уенны алып баручы була. Басып торучыларның артыннан түгәрәк буйлап әйләнгәндә ул бер баскан уенчының җилкәсенә кагыла яки кулына сугып ала. Ул кеше бер якка, парсыз кеше икенче якка түгәрәк тирәли чабып китәләр. Кем алдан килеп җитсә, шул буш урынга «кәбестә» булып алга утыра, ә элек утырган бала аның артына баса. Өлгермәгәне уенны алып баручы була.

*2021 елда Городище районы Югары Әләзән авылында*
*Байбекова Галия Рәүф кызыннан (1977 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

---

[1] Авыктыру – аудару.

### *Чүрәкәдән*

Чиратлашып таяк белән чүрәкә суга идек. Җиргә баз казый идек, тирәнне түгел. Чүрәкә – 20 сантиметрлы түгәрәк таяк, утыртып куя идек аны базга. Чүрәкә тирәсенә чыбык белән җиргә черта сыза идек: 2×2 метрлы квадрат инде. Үз палкаң (бер метр озынлыктагы таяк) белән астан эләктереп алып, чүрәкәгә сугасың. Ераграк очарга тиеш, чертаның тышына чыгып. Кемнең чүрәкәсе квадрат эченә төшсә, ул яңадан суга. Чертага килеп төшсә, аның чираты башка уенчыга күчә.

Тегендә бер кеше чүрәкәләрне биреп тора. Әгәр ул биргәндә чүрәкә кешегә тисә, башка кешене дежур итеп куялар.

Уен чиратын болай билгели идек: фуражка эченә малайлар исемнәрен кәгазьгә язып сала. Бер малай карамыйча гына кәгазьне ала да исемне укый. Аннан икенче, өченче кешенекен.

*2021 елда Лопатино районы Иске Карлыган авылында*
*Туктаров Әнвәр Мостафа улыннан (1940 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

### *Черта*

Җиргә икегә дүрт рәт итеп сигез шакмак сызалар. Аргы баштагы ике шакмак башына ярымтүгәрәкләп купол – «гөмбәз» ясап куялар. Бире баштагы сул як шакмак (сигезенче) астында калын сызык уздыралар. Ул – «яна» торган урын (анда аягы белән баскан, яки тартмасы эләккән кеше уенны яңадан беренче шакмактан сикереп башлый). Түгәрәк крем яки кечкенә генә конфет тартмасын этә-этә бер аякта сикерәләр. Ике шакмаклы рәтнең уң ягыннан сикерә башлап, шакмакларның аргы башына җитәләр, аннан әйләнеп, кире бу якка сикереп киләләр. Аяк та, тартма да бер генә сызыкка эләгергә тиеш түгел. «Яна» торган урыннарга тисә, штраф бирелә (янә беренче шакмактан башлап сикерә). Беренче кат хатасыз сикергән кеше икенче кат сикерә башлый. Бу юлы – уң яктагы икенче шакмактан. Хаталанмыйча ахыргача сикереп бетерсә, тагын бер шакмакка алгарак сикереп керә, рәттән шулай сигезенче шакмакка кадәр җитеп башларга мөмкин.

*2021 елда Городище районы Урта Әләзән авылында*
*Бухминова Раисә Әсәдулла кызыннан (1960 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

## Чик алыш

Бу уенда алты-җидедән алып егерме-утыз кешегә хәтле катнаша ала. Билгеле, малайлар өчен кызыклырак.

Барысы да түгәрәккә баса. Ике командага бүленәләр. Мәсәлән, бертигез санда «1» һәм «2» дип язылган кәгазь кисәкләре әзерлиләр. Берәрсенең фуражкасына бушаталар. Һәрбер уенчы нинди сан язылганын карамыйча гына берәр кәгазь ала. Кайсы сан эләксә, шул командага кушыла.

Шобага салып та уйнарга була. Мәсәлән, ике кеше читкәрәк китеп, бер-берсенә «син бакча бул, «мин акча булам» дип үзара килешә. Һәрбер кеше янына килеп, сорау бирәләр:

– Тау буе бакча кирәкме?

Табак тулы акча кирәкме?

Шулай итеп, һәр кеше үзенә команда сайлап ала. Командалар тупланып беткәч, болар бер чик сызалар. Һәр команда, озын чылбыр булып тотынышып, шушы чик янына килеп туктый. «Бер, ике , өч!» дип кычкыруга тартыша башлыйлар. Берсе бер якка тарта, икенчесе икенче якка. Кайсы команда каршы як команданы үз ягына тартып чыгара, шул җиңүче була. Аннары командалар урыннарын алмашып уйный.

*2007 елда Городище районы Урта Әләзән авылында*
*Дебердеев Кязим Шаһазам улыннан (1953 елгы)*
*А. Садекова язып алды*

## *Кулалмаш*

Алты-җиде-ун яки аннан күбрәк бала уйный. Күбрәк кеше уйнаса, кызык. Эв (өй) тирәли круг буйлап тезелешеп утыралар. Бер кеше утырмыйча кала, ул уенны алып баручы була. Теләсә кайсы бала янына килә дә аның кулына сугып ала. Алып баручы эллә күпме кешегә сугарга мөмкин. Ә кем дә булса кулына суктырасы килмичә, кулын тиз генә тартып алса, аңа бер төрле җәза бирелә: кучатча яки ишәкчә кычкырырга, хахылдап көләргә, урамга чыгып керергә әйтергә мөмкин. Теге кеше урыныннан тора, җәзаны үти. Аннары алып баручы аның урынына баса. Шулай дәвам итәләр.

## *Ташлар*

Шобага салып «ташчы» белән «таш алучы»ны сайлыйлар. Башка балалар «ташлар» була.

Таш ала торган бала ераграк китеп тора. Ташчы дигәне һәр уенчыга, колагына пышылдап, берәр төсне әйтеп чыга. Мәсәлән, кызыл, яшел, сары, кара һ. б. Сатып алучы килә дә ишек шакый.

– Миңа бер матур таш кирәк!

– Кайсы төслесе?

– Кызылы!

– Бар, куып тот!

Үзенә бирелгән төсне ишеткән бала чабып китә. Әгәр куып тотса, үз «эв»енә (өенә) алып китә дә «бикләп» куя. Куып тота алмаса, «таш» кире үз командасына кайта. Шулай «таш алучы» бөтен «таш»ны алып бетерә.

### *Елга*

Моны җәй кызуында инештә, елгада уйныйлар. Су бик сай булган урынны эзләп табарга кирәк башта. Балаларга тездән, боттан югарырак булмасын. Бер баланы багучы итеп сайлап куялар, ул бага. Балалар су чәчрәтеп, суда чаба-чаба уйнап йөри. Кинәт кенә багучы кычкырып җибәрә:

– Елга, тукта!

Бөтен балалар баскан урыннарында «катып» калырга тиешләр. Багучы карый инде, елга агымы кемне урыныннан кузгата, селкетә. Андыйлар уеннан чыгып китә. Уен шулай берничә тына (мәртәбә) кабатлана. Су агымына бирешмәгән, хәрәкәтләнмичә урынында барысыннан да озаграк басып тора алган бала җиңүче була.

### *Кул йөзеш*[1]

Моны вечерларда уйный идек. Ике команда булып сузылып басалар уенчылар, кара-каршы якка. Командалар озын чылбыр кебек сузылып, тотынып баскан. Учларын бер-берсенең каты кысып торалар. Әтешәләр[2]:

– Күктә-күктә ниләр бар?

– Янфар[3] белән шикәр бар!

– Янфарларны кем алыр?

– Асия алыр!

---

[1] Йөзеш – өзү.

[2] Әтешәләр – әйтешәләр.

[3] Янфар – янтарь, гәрәбә.

Яки берәр уенчы үзен әйтә:

– Янфарны үзем алам!

Командадан аңарга кем белән кем арасыннан узарга, кемне алып кайтырга икәнен әйтәләр. Үз теләге белән дә сайларга мөмкин. Йөзә (өзә) алса, бер янтыкны[1] үзе белән ияртеп алып китә. Йөзә алмаса, үзе дә икенче командага барып баса. Шулай уен дәвам итә.

### *Биш-ун*

Вичерга җыелганда бер егет бил каешын сала да «Кызлар, адягыз «биш-ун» уйныек!» ди. Кызлар-егетләр ызба тирәли эскәмияләргә, утыргычларга утыралар. Теге егет рәттән һәр кеше каршына килә дә, урталай бөкләгән каешы белән җиңелчә сугып, биш, ун, унбиш... утыз биш, кырык һ. б. номерлар әйтә. Уенчылар үз номерын истә калдырырга тиеш. Номерлар һәрвакыт бишәргә арттырып әйтелә. Номерлар кушып бетергәч, бер кыз (егет) янына килә. Каеш тоткан егет сугарга өлгергәнче, кыз берәр санны мәсәлән, егермене, әйтә, үзе шушы санлы уенчының урынына барып утыра. «Егерме» санлы уенчы да, каеш белән сукканчы, бик тиз утырып өлгерергә ашыга. Элек вечерларда кайбер егетләр кызганып тормаган, аеруча берәрсендә үче булса, әйбәтләп эләктергән. Әмма каеш төшкән җир авыртса да, кычкыру, сер бирү хупланмый. Яшьләр кайвакыт шулай бер-берен дә сынаганнар: кем җитез, кем сабыр-тыныч холыклы – сыртына каеш төшсә дә, сер бирми, кем сабырсыз, кемнең холкы үч алучан һ. б.

*2021 елда Городище районы Урта Әләзән авылында*
*Сенҗапова Асия Фәттях кызыннан (1964 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

### *Кыргавай*

Иркен урында мәч (туп) белән уйнала торган уен. Ике командага бүленәләр, бер команда уртага баса. Икенче команда тагын тигез итеп икегә бүленә дә, уртадагылардан ун-унбишәр адым ераклыкка китеп, ике якка баса. Кырыйдагы уенчылар мәч белән бәреп, уртадагыларга тидерергә тырыша. Уртадагылар, киресенчә, мәчтән кача. Мәч тигән кеше уеннан чыга.

[1] Янтык – тараф; уң яки сул яктагы кеше.

Әгәр уенчы мәчне тотып алса, уртадагыларга бер очко бирелә яки мәч тиеп уеннан чыккан кеше кире керә. Тагын тотса – тагын бер кеше кире керә. Әгәр өчтән күбрәк очко җыелса – очколар «яна». Кырыйдагы команда уртадагы бөтен кешегә мәч тидереп уеннан чыгарып бетерсә, командалар уеннарын алмашалар. Уен яңадан башлана.

*2021 елда Городище районы Урта Әлзән авылында*
*Бухминова Раисә Әсәдулла кызыннан (1960 елгы)*
*Р. Сафиуллина, И. Ямалтдинов язып алды*

### ***Перәшкәдән***

Яшьләр клубка җыелгач, «Перәшкәдән»уйный идек. Утыра идек, түгәрәкләп, клубның бөтен эстәналары буйлап, эскәмиядә. Бер егет әйтә:

– Миңа фәлән кыз кирәк!

Шул кыз чабып барып, теге егетнең итәгенә утыра. Шул арада уен хуҗасы кызга перәшкә белән сугарга өлгерсә, димәк, кыз я җырлый, я бии, я бүтән төрле җәза үти. Кызлар суктырмаска тырыша, чөнки каеш сыртка каты төшәргә дә мөмкин, чыдап кына тор. Сугарга өлгермәсә, уен хуҗасы алмаша, бүтән кешеләр дә алып баручы була.

*2021 елда Лопатино районы Иске Вершаут авылында*
*Давыдова Фирдәвес Ринат кызыннан (1964 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

***Санамышлар*** – уен фольклорының алыштыргысыз бер өлеше. Халык иҗатының әлеге төре уеннар вакытында чираттәртип билгеләү, шулай ук бала-чага һәм яшь-җилкенчәкнең күңелен ачу бурычын үти. Соңгы еллардагы экспедицияләрдә шул ачыклана: уеннар халыктан шактый еш язып алынса да, санамышларны информантлар бик сирәк, меңгә бер генә искә төшерә. Бу, бердән, санамышларның универсальлеге белән бәйле булса (дистәләгән уенны уйнар өчен дә 1–2 санамыш җитеп тора), икенчедән, санамышларның сирәк кулланылуы белән дә бәйле. Монысы инде әлеге фольклорның борынгырак заманнарда формалашып, хәзер онытылып баруына ишарәли булса кирәк: «Кара елан, ары елан...», «Төлке кия кызыл тун».

Санамышларның уен тәртибен билгеләүдә сирәк кулланылуына конкурент күренеш – шобага тоту, шобага әйтешләре дә сәбәпче. Пенза якларында, мәсәлән, уен тәртибен-чиратын билгеләү өчен, еш кына «таяк тотканнар», ягъни шобага салганнар. Димәк, санамыш икенчерәк планга күчә барган, һәм аны белүчеләр хәзерге заманда бик сирәк очрый.

### *Санамышлар*

Әке, бәке,
Кыек пәке.
Карга, чыпчык –
Син кал, син чык.

*2021 елда Исса районы Югары Салмука авылында*
*Муратова Фәридә Ибраһим кызыннан (1940 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

Бер, ике, өч, дүрт, биш,
Алты, җиде, сигез, тугыз, ун;
Төлке кия кызыл тун.
Бер – койрыксыз әтәч,
Ике – кылый чәүкә.
Өч – борының туң,
Чык моннан, болтун.

*2021 елда Шемышейка районы Оз авылында*
*Якупова Рәуза Харис кызыннан (1955 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

Ак елан,
Кара елан,
Сары елан
Өчәү куышты,
Берсе тиз шуышты,
Берсе таш астына ятты,
Өченчесе чыгып качты.

*2021 елда Лопатино районы Берлек авылында*
*Мусякаева Мөнәвәрәдән (1940 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

Чык, чык, чык,
Чы хәрефе, чык.

Чы хәрефе юк монда,
Ды хәрефе чык.
Ды хәрефе чыкмаса,
Ә хәрефе чык!

(Уенда катнашучы балалар исемнәренең беренче хәрефләрен әйтеп саныйлар).

*2021 елда Лопатино районы Иске Карлыган авылында*
*Ялагин Тяфик Хайрук улыннан (1956 елгы)*
*Р.Ф. Сафиуллина язып алды*

Бер, ике... ун,
Төлке кия каеш тун.
Ә сиңа – мунча ташы,
Төлкегә – тавык башы.

*2021 елда Лунино районы Шыкша (Синорово) авылында*
*Калашникова Фәридә Руфаил кызыннан (1969 елгы)*
*Р. Сафиуллина язып алды*

## КИКИН АВЫЛЫНДА ӘЙТЕЛӘ ТОРГАН МӘКАЛЬ ҺӘМ ӘЙТЕМНӘР

*(Баткаева Равилә Фәрит кызы тупламасыннан)*

Кем эшләми, шул ашамый.
Ут бул, ут булмасаң, юк бул.
Язгы бер көн ел ашата.
Ипи корсак артыннан йөреми.
Урны курмы сорамый.
Эш беткәч, уйнарга ярый.
Аз сөйлә, күп эшлә.
Бүгенге эшне иртәгә калдырма.
Ерак куярсың, якын алырсың.
Яхшылык юлда калмас.
Кул ярасы төзәлә, тел ярасы төзәлми.
Кешегә баз казысаң, үзең төшәрсең.
Иле барның теле бар.
Картларның сүзләре китапка керер, китаптан чыкмас.
Урманга ни кычкырсаң, шуны ишетерсең.
Урман – колак, кыр – күз.
Агач җимеше белән – кеше эше белән.

Ямаусыз йомырка.
Алтын белән мактанма, акыл белән мактан.
Эшләгәнең безнең өчен, өйрәнгәнең үзең өчен.
Сыерлар су эчкәндә, бозаулар боз ялый.
Күрше күрмәк – күчермәк.
Таш белән бәргәнгә, аш белән бәр.
Акыл яшьтә түгел – башта.
Эш сөйгәнне ил сөяр.
Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс.
Ир кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.
Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар.
Ни чәчәрсең, шуны урырсың.
Башлаган эшне ташлама.
Илгә таянган Идел кичәр.
Сабыр төбе – сары алтын.
Иле барның теле бар.
Синнән эш көткән кеше Алладан бәла көтсен.
Каш төзәтәм дип, күз чыгарма.
Күз курка, кул эшли.
Сүз сүзне чыгара, йодрык күзне чыгара.
Иренчәк ике эшләр.
Күзең ач, тамагың тук.
Ят үз булмый, тишек күз булмый.
Телдә сөяк юк.
Майламаган арба кебек шыгырдый.
Мал малны таба.
Чанасының төбе тишек.
Калган эшкә кар ява.
Без капчыкта ятмый.
Бит күрке – күз, тел күрке – сүз.
Озын аркан, киң тышау булып йөремә.
Малны таба белмәгән тота да белмәс.
Арба күреп, аягы аксады.
Иртәнге чыпчык күзен ача.
Тырышлык бәхет китерер, ялкаулык ачтан үтерер.
Эшне башлама, башласаң – ташлама.
Эшнең тәме ахырында.
Бер йомырканы биш кат санама.

[1] По словам респондента Ф.И. Музяфарова (1936 г. р.), с. Бикмосеевка.
[2] С. Сулеймановка.

не таких бутонов три. С обеих сторон по вертикальным краям изделия находятся фрагменты изгибов стебля. По всему полю нагрудника рассыпаны пайетки. Они мерцают на синем фоне, словно звезды на вечернем небе. Сходная композиция золотной вышивки украшает нагрудник, хранящийся в школьном музее с. Индерка. На черном поле в центре находится завихренная солярная розетка, в окружении восьми чередующихся трилистников и меандров.

Сельчанки шили платья свободного кроя с оборками по нижнему краю. Обнаруженные нами экземпляры были выполнены из ткани розово-сиреневого спектра различной интенсивности тонов. Сохранившийся в с. Пенделка камзол (сонябят) или, как называют данное изделие местные жители, жилет (сенебети) выполнен из темно-синей саржи и простеган в мелкую строчку. В каждом селении были швеи-мастерицы. Например, в с. Мансуровка респонденты сообщили о Ряхимовой (Хайровой) Махруй Хусяиновне (1907 г. р.), чья искусная работа запомнилась многим поколениям.

Традиционный костюм пензенских татар описан такими известными специалистами, как Р.Г. Мухамедова и С.В. Суслова. Наши изыскания дополнят их исследования.

Внешний облик нарядной пензенской татарки дополняли ювелирные украшения. Особо ценились заколки для тастаров[1] *«кашлинә»* [Суслова, 2023]. Большей частью, изделия были покупными. Однако некоторые предметы, например, сережки[2] были выполнены местными умельцами. Так, в с. Октябрьском работал ювелир-самоучка Бикмуллин Мутый.

Таким образом, в исследованных районах Пензенской области выявлены следующие традиционные виды домашних ремесел: обработка дерева и металла, лозоплетение, войлоковаляние, ткачество, вышивка (в т. ч. золотная), ушковая аппликация, лоскутная мозаика, вязание, искусство народного костюма, известного в двух вариантах (сельский и городской).

---

[1] Тастар – узкое головное покрывало.

[2] Абдуллин Шихабутдин (1920-е годы), с. Сулеймановка.

В настоящее время угасли ткачество, золотная вышивка и войлоковаляние. Мало осталось вышивальщиц и мастериц лоскутной мозаики, ныне бытующей в виде техники «пэчворк». Редко встречается ушковая техника и лозоплетение. В народных традициях еще продолжает развиваться художественная обработка дерева и металла. В каждой деревне существует вязание, адаптированное к новым общепринятым эстетическим нормам.

Население татарских деревень проявляет интерес к национальной культуре, люди дорожат изделиями, созданными мастерами-односельчанами прошлых лет и стараются приобщить к народному искусству своих детей.

Выявлены мастера:

ТКАЧЕСТВО

*с. Алеево*
Кузахметова Равиля Давыдовна (1938 г. р.)

*с. Карновар*
Абдулова Мялика, Хайрулловна (1905 г. р.)
Салюкова Халидя Халиулловна (1936 г. р.)

*с. Мансуровка*
Айнепьхаят

*с. Бигеево*
Акчурина Мунира Салиховна (1935 г. р.)

ВЫШИВКА

*с. Алеево*
Шавалеева Сайраха Шигаповна (1925 г. р.)
Салиева Халида Хамзиевна

*с. Сулеймановка*
Рахманкуллова Танзиля Шагеевна (1939 г. р.)
Рафикова (Хабибуллина) Таскиря Шагеевна (1933 г. р.)
Поздникова Сяидя Хафизовна (1965 г. р.)

*с. Карновар*
Абдульманова Фарида
Абузярова Зайтуна (1941 г. р.)
Абузярова Мастюра (1908 г. р.)
Мухаметжанова Румия Джафаровна (1946 г. р.)

Хаметова Румия Загриевна (1950 г. р.)
Акчурина Рукия Давыдовна (1942 г. р.)

*с. Мансуровка*
Ряхимова Алия Нязыфовна (1930 г. р.)
Ряхимова Фатыма Нурмухамедовна (1882 г. р.)
Ряхимова (Хайрова) Махруй Ряхимовна (1907 г. р.)

*с. Бигеево*
Сатаева (Агишева) Рукия Хусяиновна (1917 г. р.)
Акчурина Мяфтюха Хамидулловна (1928 г. р.)

ЛОСКУТНАЯ МОЗАИКА

*с. Бигеево*
Сатаева Равиля Исхаковна (1948 г. р.)

ШИТЬЕ

Мухаметжанова Румия Джафаровна (1946 г. р.)
Аюпова Мастюра (1946 г. р.)

*с. Бигеево*
Мансурова Халида Юсуповна (1956 г. р.)

ВЯЗАНИЕ

*с. Алеево*
Салихова Светлана Мунировна (1978 г. р.)
Вергазова Гульсине Рашидовна

*с. Карновар*
Аюпова Фаиля Кяшафовна (1937 г. р.)
Акчурина Рукия Давыдовна (1941 г. р.)
Дашкина (Ряхимова) Эльвира Равилевна (1986 г. р.)

НАРОДНЫЙ КОСТЮМ

*с. Алеево*
Мягруб Мянзелина, XIX век
Ряхимова (Хайрова) Махруй Ряхимовна (1907 г. р.)

УШКОВАЯ ТЕХНИКА

*с. Алеево*
Салихова Светлана Мунировна (1978 г. р.)

ОБРАБОТКА ДЕРЕВА

*с. Алеево*
Абдуллин Закария Шигапович (1965 г. р.)
Тяпаев Кадим (1930 г. р.)
Юсупов Ханяфи (1964 г. р.)

Юсупов Низям (1929 г. р.)
Сайфуллин Халиулла (1940 г. р.)
Сайфуллин Мунир (1969 г. р.)
Абдрахманов Джафер (1952 г. р.)
Юсупов Низям (1929 г. р.)
Насыров Агдям (1958 г. р.)
Хайров Абдулхак (1956 г. р.)
Фахретдинов Расим (1956 г. р.)
Насыров Махмут (1952 г. р.)
Абдрашитов Равиль (1970 г. р.)

*Сулеймановка*
Рахманкулов Мунир Абдрахманович (1932 г. р.)
Ямбулатов Равиль Сулейманович (1923 г. р.)
Хаников Кяшаф Абдуллович (1926 г. р.)
Вагапов Хафиз Мусиевич (1932 г. р.)
Рахмитуллин Альфред Мунирович
Рахмитуллин Нязых Мингачевич
Давыдов Юсуп Аминович (1965 г. р.)

*Мансуровка*
Бикиняев Закария Идрисович (1946 г. р.)
Бикиняев Мударис (1930 г. р.)

*Бигеево*
Уйбиков Юсуп Умярович (1937 г. р.)

Строили в период с 1960-х по 1980-е годы:

Чавкин Рашит Хайруллович
Акчурин Махмут Ахмедович
Мансуров Аллям Махмудович

ЛОЗОПЛЕТЕНИЕ
*Алеево*
Мухаметзянов Сулейман (1952 г. р.)

*Мансуровка*
Аитов Ибрагим Аряфеевич (1935 г. р.)

ОБРАБОТКА МЕТАЛЛА

*Алеево*
Халитов Рашит (1950 г. р.)
Халитов Рафаэль (1970 г. р.)
Шихабетдин Абдуллин (1920 г. р.)

ВОЙЛОКОВАЛЯНИЕ

*Джалилово*
Ряхимов Назыф Абдуллович (1907 г. р.)

## СПИСОК ИСПОЛЬЗОВАННОЙ ЛИТЕРАТУРЫ

1. *Адикаева Д.Н.* Темниковское княжество в соответствии с историческими источниками XIV–XVII вв. // Сборник статей по материалам Всероссийской научно-практической конференции «Языки культуры в контексте исторического наследия»: к 100-летию со дня рождения Э.Р. Тенишева. Пенза, 2021. С. 220–222.

2. *Акчурин М., Ишеева М., Абдиева А.* Эпоха татарских князей в Мещере (XV–XVII века). Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2021. 316 с.

3. *Зеленеев Ю.А.* Гончарный горн города Мохши (по результатам исследований 1989–1990 гг.) / Ю.А. Зеленеев, Е.Е. Филиппова // Вестник Чувашского университета. 2011. № 4. С. 44–52.

4. *Иконников Д.С.* Гончарное ремесло города Мохши XIII–XIV вв. // Известия Российского государственного педагогического университета им. А.И. Герцена. Сер.: Общественные и гуманитарные науки. СПб., 2008. № 12 (86). С. 78–81.

5. *Иконников Д.С.* Хозяйственный инструментарий города Мохши XIII–XIV вв. // Средневековый город Мохши и Наручатская земля: итоги 95-летнего изучения: материалы Всерос. науч. конф. (23–24 сентября 2010 г.). Пенза, 2010. С. 100–144.

6. *Иконников Д.С.* Вклад А.Е. Алиховой в изучение золотоордынского города Мохши (историографический обзор) // Археология Восточноевропейской лесостепи: сб. материалов III Междунар. науч. конф., посвящ. 110-летию со дня рождения российского археолога А.Е. Алиховой (7–8 декабря 2012 г.). Пенза, 2013. С. 389–400.

7. *Иконников Д.С., Баишева М.И.* Деревообрабатывающие инструменты с территории Наровчатского городища и его окрестностей // VII Халиковские чтения: Средневековые археологические памятники Поволжья и Урала: проблемы исследований, сохранения, музеефикации: материалы Всерос. науч.-практ. конф., посвящ. 50-летию Билярской археологической экспедиции (1–4 августа 2017 г., Казань – Болгар – Билярск). Казань, 2017. С. 138–144.

8. *Иконников Д.С., Баишева М.И.* Топография золотоордынского города Мохши XIII–XIV вв. // Вестник Пензенского государственного университета. 2018. № 1 (21). С. 82–90.

9. *Кротков А.А.* К вопросу о северных улусах золотоордынского ханства // Известия Общества обследования и изучения Азербайджана. 1928. № 5. С. 71–79.

10. *Плетнёва С.А.* Кочевники Средневековья: поиски исторических закономерностей / отв. ред. акад. Б.А. Рыбаков. М.: Наука, 1982. 190 с.

11. *Суслова С.В.* Татарский костюм в музейных собраниях России // Историческая этнология. 2023. Т. 8. № 2. С. 202–221.

# ЕРАК ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ

**Пенза өлкәсенә әкиятле, җырлы сәфәр**

*(1958 елгы экспедиция буенча архив материалларына күзәтү)*

---

*Рузия Сафиуллина*

1958 елның август ае башында Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор экспедициясе Казаннан Пенза өлкәсенә кузгала. Хәмит Ярми аның җитәкчесе итеп билгеләнә. Поезд белән чыгып киткән галимнәр төркеме Пенза өлкәсендәге татарлар компактлы яшәгән районнарда эшли. Экспедициядә фольклорчы галим Хәмит Ярми, лаборант Халидә Гатина, яшь галим Илбарис Надиров (отряд җитәкчесе), Х. Нәҗипова һәм Р. Шәрипов (студентлар яисә аспирантлардыр, ихтимал), шулай ук бүлек аспиранты, язучы прозаик Эдуард Касыймов белән студент, шагыйрь Әхмәт Рәшитов катнаша.

Институт галимнәре өлкәнең Сосновоборск, Кузнецк, Неверкино, Городище, Лопатино, Шемышейка, Беднодемьяновск районнары авылларында кечерәк төркемнәргә бүленеп эшли.

Пенза өлкәсенә экспедиция материаллары 64 нче коллекция булып теркәлеп, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә саклана. Әлеге материаллар калын 3 папкага тупланган.

Беренче папкада (1–21 саклау берәмлеге) экспедициянең гомуми хисаплары, галимнәрнең лекцияләр укуы турында белешмәләр, лекторларга отзывлар бар.

Совет заманында экспедиция вакытында галимнәрнең авыл халкы өчен кичләрен я концерт оештыруы, я лекцияләр белән чыгыш ясавы мәгълүм (хәзер инде бу гамәлдә түгел). Беренче

папкадагы белешмәләргә караганда, «М. Җәлилнең иҗаты һәм батырлыгы» гомуми лекция темасы итеп алынган булса кирәк. Һәрхәлдә, Х. Ярмигә һәм Э. Касыймовка бирелгән документларда шушы тема билгеләнгән. И. Надировка язылган белешмәдә лекция темасы «Бәхет турында сөйләшү» дип күрсәтелгән. Мондый белешмәләрдә шулай ук лекцияне үткәрү урыны (гадәттә, авыл клубы ), аны ничә кеше тыңлаганлыгы да теркәлгән (авыл саен 100–150 кеше). Галимнәр колхоз җитәкчеләреннән дә лекцияләр укуның еллык планнар буенча исемлеге күрсәтелгән мәгълүмат алып кайтканнар. Мисал өчен, ул елларда «Дөньяның яратылышы», «Халыкара хәлләр», «Ленинча тыныч яшәү принциплары – СССРның тышкы политикасы нигезе», «Совет хөкүмәте яшьләргә нәрсә бирде?» кебек темаларга лекцияләр укылган, диелә. Моның өчен партком секретаре, клуб мөдире кебек кешеләр җаваплы булган. Әлеге мәгълүмат тиешле органнарга тапшырылганмы, әллә «болай гына»мы – бу кадәресенә җавап билгесез булып кала бирә.

Гомуми хисаплар дигәндә, һәр отрядның экспедиция дәвамында халык иҗаты жанрлары буенча күпме материал җыйганын күрсәтә торган белешмә характерындагы таблицаларны күздә тотабыз. Мәсәлән, Х. Ярми төркеме Неверкино, Кузнецк, Сосновоборск районнарында, бөтен вариантларын кертеп, 400 дән артык җыр язып алган. Монда барысы да – борынгы, тарихи, сюжетлы, кыска һәм озын җырлар, йола (туй) һәм уен җырлары кергән. Такмаклар, бәетләр бу исәпкә керми. Х. Ярми төркеме 7 бәет, 50 ләп такмак, 2 әкият теркәп куйган (шуның берсе әкият-мәзәк дип күрсәтелә). Халык уеннары – 1. Шулай ук 3 авыл тарихы, 2 мәзәк бар. Риваятьләр жанры каршында сызык тора. Афористик жанрларга килгәндә, дәфтәрләрдә берничә мәкаль генә очрады.

Документларда күрсәтелгәнчә, Э. Касыймов отряды 172 җыр (шулай ук борынгы, тарихи, сюжетлы, кыска, йола һәм уен җырлары) яздырган. Бәетләр – 16, такмаклар – 30 дан артык. Әкиятләр – вариантларын да кертеп, 73. Халык уеннары – 3. Авыл тарихлары – 13 (нигездә, алар патша йомышлысы, Алты авыл территориясеннән чыккан Арыслан Палкай турында). Ике дистәгә якын табышмак һәм мәкаль теркәлгән.

Бәетләр хәзинәсе бу якларда шактый бай булган дип санарга мөмкин. Соңрак татар халык иҗаты җыентыкларына кергән «Җәлүк азанчы», «Урта Әләзән», «Әбделмән купич» һ. б. бәетләр нәкъ шушы экспедиция вакытында табыла, диярга нигез бар. «Җәлүк азанчы» бәете иҗат ителү тарихы буенча һәм территориаль яктан Неверкино районы Мазарлы авылына караса да, аны Х. Ярми һәм Э. Касыймов төркеме төрле районнарда язып ала. Өстәвенә, Городище һәм Шемышейка районнарында (Э. Касыймов төркеме йөргән яклар) әлеге бәеткә тулырак шәрехләмә алына).

Беренче папканың эчтәлегенә карата түбәндәгеләрне әйтеп була.

3–5 саклау берәмлекләреннән экспедиция эшенең (Х. Ярми төркеме) Кузнецк районында башланганын күрәбез. Ялгаш авылында Шәмгунов Сабир сөйләгән әкиятләр – барысы да машинкада бастырылган. Бу – аларның инде редакцияләнгәнлеген, халык әкиятләре җыентыкларына кертелүен дәлилли торган факт. Чыннан да, папкадагы әкиятләрнең һәммәсе – балачактан ук таныш. (Мәсәлән, «Әкият-мәзәк» дигәне – бер авыл агаеның базарга сыерын сатарга баруы, юлда алдакчыларга очрап, алдануы турындагы мәгълүм әкият. Намуссыз бәндәләр агайга, «сыер дигәнең – сарык бит», дип тәкрарлый-тәкрарлый, тәмам ышандыралар.)

Әлеге папкадагы дәфтәрләр арасында шулай ук Мазарлы авылыннан укытучы Салиев авторлыгында «Прошлое и настоящее села Могилки. Большие перемены» дигән 6–7 битлек язма бар. Фольклорчылар практикасында еш очрый торган күренеш: кайбер авылларда, кешеләрдән авыл тарихын сорагач, документаль язмалар тапшыралар. Билгеле, информантлардан сораштыру моның белән генә тәмамланмаган, фольклорчлар төркеме һәрбер өлкәнрәк, мәгълүматлырак кешедән авыл тарихы турында белешә. Язма авыл тарихы да булгач, әлеге тема Мазарлы авылында шактый өйрәнелгән, аның белән махсус кызыксынучылар да бар, дип нәтиҗә ясый алабыз.

6–12 саклау берәмлекләрендә кыска һәм сюжетлы җырлар урын алган. Шулар арасында яшь буын информантлардан язып алынган, кызларның җыр дәфтәрләреннән күчерелгән

җырларның шактый күп булуы күзгә ташлана. Аңлашылсын өчен кыска гына мисал (11 саклау берәмлеге, 6 нчы дәфтәр):

Көзгегә багып карау – масаеп карау бит ул,
Яр өстенә яр сөюче – ертыкка ямау бит ул.

*Неверкино районы Дымавыл (Дёмкино) авылында*
*Ярочкина Сарадан (1937 елгы)*
*Х. Ярми язып алган*

Х. Ярми – Х. Гатина папкасында теркәлгән бердәнбер уен игътибарга лаек, аны биредә тулысы белән китерергә булдык:

**Рәм-рәм-Рәмилә**
*(халык уены)*

Безнең урам аркылы
Ага суның салкыны.
Су сипсәң дә басылмыйдыр
Яшь йөрәкнең ялкыны.

*Кушымта:*
Рәм-рәм-Рәмилә,
Килә диләр Әминә.
Акылларын сынамыйча,
Сокланмагыз яменә.

Алып бирим батис күлмәк,
Бәйрәмнәрдә киярсең.
Ташлаганчы, сал суларга,
Агып китте, диярсең.

*Кушымта.*

Ал гөлләрем булмаса да,
Исле гөлем бар минем.
Үзем синнән аерылсам да,
Аерылмый күңелләрем.

*Кузнецк районы Ялгаш авылында*
*Баишева Рәисә Масут кызыннан Х. Ярми язып алган*

Әлеге яшьләр уенының көе мәгълүм түгел, шулай да җырның эчтәлеге авыл яшьләренең совет чорындагы көнкүрешен, аралашуын да беркадәр гәүдәләндерә, димәк, хәзерге заманда гамәли әһәмияткә ия. Дөрес, экспедиция материаллары арасында халык уеннарының (балалар уйный торганнары да, яшь-җилкенчәк өчен булганнары да) гаять сирәк очравы уйландыра. Чынлыкта уеннарның берән-сәрән генә булуы – бу як халкы бөтенләй уйный белми, дигән сүз түгел. Алтмыш ел узганнан соң шул ук районнарда яңадан фәнни экспедициядә булырга туры килде: уеннарның ниндиләре генә юк икән Пенза татарларында! Сәбәп башкада, дип фаразларга нигез туа: ихтимал, татар фольклорчыларының кайберләрен ул чорларда халык иҗатының барлык жанрлары да кызыксындырмагандыр.

Мәсәлән, дини фольклор (мөнәҗәтләр, дини эчтәлекле бәетләр һ. б.) мифологик фольклор төрләре, кайбер паремияләр һ. б. гадәттә язып алынмаган. Яки, язып алынса да, Институт архивына тапшырылмаган. Галимнәрнең аерым жанрларны архивка тапшырыла торган хисапка кертмәвен идеологик сәбәпләр белән дә бәйләп була торгандыр.

Экспедициядә язып алынган уеннарда фольклорчыны күбрәк җыр тексты кызыксындыргандыр, дигән фикер туа: жанры «уен» дип классификацияләнсә дә, без аның эчендә ялгыз яки кара-каршы башкарылган җыр текстларын гына күрәбез, ә тасвирламасы, уйнау тәртибе язылмаган. Н. Исәнбәт әйтмешли[1], уен жанры һәм, гомумән, балалар фольклоры белән бәйле жанрлар дистә еллар буена «вак» жанрлар саналып, галимнәрнең игътибарыннан читтә калган, бик озак еллар дәвамында фәнни өйрәнелүдән мәхрүм ителгән.

Бер мәкаләдә барлык материалларны иңләү, анализлау мөмкин түгел, шулай да 1958 елгы экспедициягә хас кайбер тенденцияләрне атап үтәргә кирәк. Мәсәлән, җырлар инде дәфтәрләргә «чистага» күчергәндә үк классификацияләнеп, хәтта тематик төрләргә аерып бирелгән. Аерым калыпларга башланган җырлар аерып тупланган: «Иртән торып тышка чыксам», «Әнә килә автомобиль», «КЙИ» («Кулымдагы йөзегемнең исемнәре» – дәфтәрләрдә ул шулай кыскартып кулланыла) калыплары белән башланган җырлар һ. б. аралаштырылмый. Алар төгәл һәм пөхтә итеп төркемләнгән. Тагын бер күзәтү: архив кәгазьләре арасында такмаклар сирәк очрый – аларның эстетикасы «гадирәк» дип саналгандыр, мөгаен. Билгеле, җырларда һәм такмакларда, чорына күрә, советча яшәүгә игътибар сизелә:

КЙИ
Бибигайшә,
СССРның күләмендә
Беренче булып яшә.

КЙИ
Рәисә,
сиңа ошаган бер гөл үсә
Райком тирәзәсендә.

*Сосновоборск районы Индерка авылында*
*Абляскина Сара Ариф кызыннан (1933 елгы)*
*Х. Ярми язып алган*

---

[1] *Исәнбәт Н.* Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен. Казан, 1984. Б. 432.

13–21 саклау берәмлекле 9 нчы дәфтәр «Сюжетлы җырлар» дип исемләнгән.

Экспедиция материалларында җырларның кушымтасы төрлечә аталган: кушымта, тагылма, ер арасы. Информантлардан ничек язылып алуына карап теркәлгән, күрәсең.

Кайбер җырларга исем куелган, кайберләре исемсез генә бирелгән. Архаик сүзләр һәм формалар, диалектизмнар җырның җирле һәм элеккеге чыгышына ишарәли, хәтта мөнәҗәтләрне хәтерләтә. «Хак Тәгалә» төшенчәсе кергән җырның цензурага эләкми калуы беренче карашка гаҗәп тоела. Әмма тирән мәгънәсе, шигъри кыйммәте аны идеологик киртәләрдән өстенрәк иткән:

* * *

Карада гына каршы ак гурнича,
Аның тоткычлары җиз микән?
Без ике матур кавышырга
Хакның вәгъдәсе тиз микән?

*Кушымта:*
Кудра сачны биштән үрмиләр,
Сәүгән ярны ятларга бирмиләр.

Күзкенәем төште ак йөзеңә,
Гаҗәпкә калдым сүзеңә.
Хак Тәгалә язмышын белмәссең,
Бәлки яр булырмын үзеңә.

*Кушымта:*
Кудра сачны биштән үрмиләр,
Сәүгән ярны ятка бирмиләр.

Безнең каршыбызда ел′ милчәсе [1]
Көненә йөзәр потлай тартадыр.
Әй Раббым Алла, ни кылаем,
Көннән-көнгә гыйшкым артадыр.

*Кушымта:*
Алый бирим укалы салфетка,
Алырмын җанашым кайгыртма...

---

[1] Ел′ милчәсе – җил тегермәне.

## Эскәтерем бер генә

Эскәтерем бер генә,
Өстәл белән тиң генә.
Күңелемдә һичнәрсә юк,
Хаҗәтемдә син генә.

*Тагылма:*
Люблю тебя, возьму себе.
Пар золотой дам тебе.
Пар золотой не дам тебе,
Замуж возьму за себя.

Ак эскәтер җәйдем мин,
Хәтфә камзул печәргә[1].
Җитмеш төрле кошлар сайрый
Сез киләсе кичләрдә.

*Тагылма.*

Сандугачның балалары
Ер′еләген[2] ашамый.
Бәхетле ана баласы
Туган ерен ташламый.

*Тагылма.*

Ашар идем бал булса,
Эчәр идем бал булса.
Дашламам, җаныем, дашламам,
Газиз башым сау булса.

*Тагылма.*

Алмагачның ботагындин
Кашык ясыйм мин сиңа.
Уналтыда, унҗидедә
Гашыйк булдым мин сиңа.

*Тагылма.*

Хәтфә камзул ефәк буйлы,
Кемгә диеп тегәсең?
Кашың кара, буең зифа,
Кем бәхетенә үсәсең?

*Тагылма.*

Чибәр бәлешләр пешергән,
Чибәр булган, чи булган.
Өч яшәргә[3] бер-бер яшьми,
Бу чибәргә ни булган?

*Тагылма.*

*Кузнецк районы Ялгаш авылында*
*Шабакаев Хәйретдиннән (1890 елгы) Х. Гатина язып алган*

Х. Ярми төркеме язып алган бәетләргә килгәндә, Җәлүк азанчы турындагы бәетне аерым билгеләп үтәргә кирәк. Ул Неверкино районы Мазарлы авылында Меликов Әхмәтҗаннан (1888 елгы) һәм Яналеева Мәрьямнән (1899 елгы) язып алынган. Ләкин бу вариант – бәетнең фрагменты гына, һәм эчтәлегеннән күп нәрсә аңлашылмый. (Икенче папкада исә әлеге бәетнең тулырак варианты да табылды, анысыннан да өзекләр бирербез. Ул Э. Касыймов төркеме туплаган папкада саклана.)

---

[1] Печәргә – *биредә:* тукымадан кием кисәргә.
[2] Ер′еләге – җир җиләге.
[3] Яшәргә – диал.: эндәшергә.

**Җәлүк азанчы[1] турында**

Мәктәпнең бакчасында үсә микән егачлар?
Әллә аларны да андан кисәр микән дошман?

Мәктәптә бездән артык укый микән шәкертләр?
Әллә аларны да аннан кысты микән дошманым?

Мәктәпнең бакчасында сайрый микән сандугач?
Әллә аларны да аннан куды микән дошманым?

Бу шигырьне кая барып язганымны белсәгез,
Рәхми килер, таш-агачның шул урынны[2] күрсәгез.

Исме имам, җисме иван, кыйлмаган эшләр кыйла.
Бәлки анлар кыйлмас иде – кулларында зур сила.

Без күрмәсәк, яшьләр күрер хөрриятнең килгәнен,
Кояш калкып, нуры балкып, һәр бинага тулганын.

Аллага мөшкел имәсләр, хәляс итсә безләре,
Безгә казган базларына төшсә иде үзләре.

64 нче коллекциянең икенче папкасында 22–37 саклау берәмлекләре теркәлгән.

Э. Касыймов һәм Ә. Рәшитов төркеме туплаган әлеге папкадагы документлар, даталарына күз салсак, Лопатино районы Иске Карлыган авылында туплана башлаган.

Э. Касыймовның күпсанлы әкиятләр язып алуы турында югарыда сүз булган иде инде. Бераз табибларныкын хәтерләткән вак кына хәрефләр белән язылган берничә дәфтәрдә әкиятләр төрләргә аермыйча, информантлардан ишеткән тәртиптә бирелгән, күрәсең. Бу әсәрләрнең кайберләре машинкада басылып һәм редакцияләнеп, алдагы саклау берәмлекләрендә дә кабатлана. Дәфтәрләрдә билгесез, җыентыкларда басылып чыкмаган әкиятләр дә булырга бик мөмкин, чөнки язуын төшенү авыр, укыр өчен шактый вакыт таләп ителә. Ә гомумән алганда, әкиятләрнең күбесе инде әкият китапларында дөнья күрде, алар укучыга таныш: «Абдулла бай», «Азанчы малай»,

[1] Җәлүк бабайга выселка бирделәр, өйгә килмәде. Әхмәд авылында өч елдан соң үлде. (Информант аңлатмасы. – *Х. Гатина.*)

[2] Мунчада язган.

«Еланнар», «Персиян кызы», «Көтүче», «Ходай сакчысы солдат», «Көтүче Зариф», «Солдат Имәчә», «Зирәк агай», «Өч сорау», «Мәрьям» (вариант), «Алмас патша улы», «Ярлы Билал», «Кандай солдат», «Мулла белән Иван» (Городище районы Аенбура авылында Медведев Үмәр Хәлимулла улыннан (1895 елгы, колхозчы) язып алынган); «Патша кияве солдат», «Карунбай» һ. б. (Городище районы Аенбура авылында Дашкин Үмәрдән (1910 елгы) язып алынган); «Ятим бала», «Нурсылу», «Зөһрә», «Куян», «Көтүче Ярук» һ. б. (Лопатино районы Селәү авылында Нарбиков Абдулладан (72 яшь) язып алынган).

Шул ук папкада Карлыган авылында язылган дәфтәрдә (№ 3 А) табышмаклар бар:

Яшел чапанлы, сары кушаклы. *(Себерке)*

Ак бия, башы түшәмгә тия. *(Мич)*

Шушы ук икенче папканың 28–37 саклау берәмлекле дәфтәрләре, язулардан күренгәнчә, Ә. Рәшитов тырышлыгы белән тупланган.

Лопатино районы Иске Вершаут авылында язып алынган кайбер үрнәкләр:

**Бәхетсез бала бәете**

Кош сайрый агачта, мин тыңлыйм сайравын.
Дустым, син белмисең эчемнең янганын.

Үтәдер көннәрем, үтәдер төннәрем.
Бәхеттә, рәхәттә яшиләр тиңнәрем.

Бәхетсез баламын, ялкында янамын.
Тиңнәрем артыннан кызыгып каламын.

Сандугач, болында сайрама, бәбкәем,
Күз өстендә каш кебек асраган әнкәем.

*Бәет Янбулатова Надирә Шәриф кызының истәлек дәфтәреннән күчереп алынды. 7 класс укыган. Бәетнең махсус көе дә бар. – Ә. Рәшитов иск.*

Калын дәфтәр тышлыгында «Дәфтәр № 2 – Сюжетлы җырлар» дигән язуны укыйбыз. Болары да – Ә. Рәшитов туплаган материаллар. Шунысына игътибар итәргә мөмкин, сюжетлы

җырларны яздырганда яки истәлек дәфтәрләреннән күчергәндә фольклорчы заманча тенденцияләрне дә күрсәтергә тырышкан. (Гомумән, Э. Касыймов һәм Ә. Рәшитов яшь информантлардан да шактый күп материал язып алганнар).

Мисал өчен:

**Ак каен**

Дошман солдатлары ак каенга
чибәр кызны бәйләп куйдылар.
Каен тузы кебек тиресен суеп,
күкрәгенә йолдыз куйдылар...

*Лопатино районы Берлек авылында*
*Хәирова Мәхдүмә Мәхмүт кызының (1935 елгы)*
*истәлек дәфтәреннән Ә. Рәшитов күчереп алган.*
*8 август, 1958*

Х. Ярми төркеме туплаган материалларга күзәтү ясаганда телгә алынган «Җәлүк азанчы» бәетенең бүтән вариантыннан өзекләр китерәбез.

**Җәлүк азанчы**

Вольскийга көчкә җиттем, төштем фатир муллага,
Ачык йөзлә, фәсих сүзлә кабул итте мулла да.

Мулла үзе урта яшьтә, гыйльме дә чибәр генә.
Сүзләрендә аять, хәдис, аңласаң сибәр генә.

... Иртә торып мулла жандарм полконикка[1]
Барып явит ителгән, чакырып алды янына.

Көн буенча допрос алгач, хөкем итте төрмәгә.
Өстегездән күп донос бар, тиеш сезгә төрмәгә.

Эшләрнең барсыны күндердем губернаторга,
Сезгә ул ни хөкем итәр – сөргенгә йә атарга.

...Сырос һава, салкын бүлмә, йөрим идән буйлата.
Төрле уйлар уйланубән сәгать үтте төн ката.

...Йә кадирсән, йә рәхимсән мән гөнаһкяр бәндәңне,
Йә хилас ит, йә җанымны ал, кабул ит фөрьядымны.

[1] Дәфтәрдә язылган мисалларны үзгәтмичә китерәбез. *(Р.С.)*

...Бары күргән михнәтләрне язмыйм әле дә барчасын.
Кудка җаным кулга кушмый, язуым Аллаһ сакласын.

Тышы мәгърур, эче җәбер-золымилә булган аның,
Тар бинада ята шунда сәясиләр бар җаным.

Сәясиләр тар бинада аеры-аеры бүлмәдә
Юк укырга, юк язарга, егълама да, көлмә дә.

...Тәһарәткә каравылдан башка ялгыз йөрмә,
Уңга-сулга карамагыл, өең түгел бу, төрмә.

Бу зинданда шунсы авыр, сәясигә күп җәбер.
Кыен күрми аз көн үтә, Хода, биргел син сабыр.

Бән фәкыйрь дә шул җәфаны иртә-кичә күрәмен,
Әллә чыгам, әллә чыкмыйм, менә шунда үләмен?

...Бу зинданда ятмадымы нәбиләр дә изгеләр?
Бу заманда тагы күбрәк нинди җәбер күрмиләр.

...Сәясиләр крепоста 45 адәм яталар.
Шырпы тартма эченә куеп, бер карандаш аталар.

Шырпы диеп уйлап алдым. Баксам, эчендә
шырпы кадәр бер карандаш, шырпы тартма эчендә.

Шатлыгымнан якты булды тар бинаның эчләре,
Тәкрар яздым бу шигырьне көндезен һәм кичләре.

...Алты айлар үтеп бара. Бән ятамын бичара.
Һич эшемнең билгесе юк, түзмәенчә ни чара.

...Вольскийның төрмәсендән бу шигырьне күндерәм,
Ничә хәйлә, мең мәшәкать берлә моны үткәрәм.

...Туган илем – Морзалыдыр, Кузнецки өязем.
Саратудыр вилаятем, дәхи юкдыр ниязым.

Исмем асдыр җим ләмәлиф ләм, дәл яунүн,
Фамилиям нөн, гаен, мим, ба, әлифләм – ләм яунүн.

Ебәрәмен моны пальтом эчендә,
Зар кыйлам Ходага һәр кичендә.

...Ничә еллар гомерем милләт юлына сарыф итеп
Ахырында мәҗбүр булдым, китә инде берек итеп...

*Лопатино районы Селәү авылында*
*Абдулла Нарбиковтан язып алынган*

1958 елгы экспедициянең Неверкино районында эшләгән төркеме дә (Х. Ярми, Х. Гатина) шушы әсәрнең ике вариантын язып алган. Селәү авылында Э. Касыймов – Ә. Рәшитов төркеме исә әлеге бәетнең үзен генә түгел, язылу тарихын да теркәп куйган:

«“Җәлүк азанчы бәете”н заманында Нигъмәтуллин Җәләлетдин иҗат иткән булса кирәк. Ул Неверкино районы Мазарлы авылы кешесе булган. Бәет турында аңлатмада да вакыйганың нәкъ шушы авылда баруы турында әйтелә. Нигъмәтуллин Җәләлетдин биредә азан әйтүче булып хезмәт куйган. Ул мөгаллимлек белән дә шөгыльләнгән. Дин сабагы укыту белән беррәттән математика, география, табигать белеме кебек фәннәрне кертергә тырышкан. Бу эш искечә укыту тарафдарларына ошап бетмәгән. Шуңа күрә аның өстеннән 14 мулла Петербург жандармериясенә прошение язган. Өстәвенә, Җәлүк ярлы халык арасында патша самодержавиесенә каршы листовкалар, брошюралар тараткан, дигән мәгълүмат та бар. Шуннан соң жандармерия аны кулга алган, аннан Петербургка алып киткәннәр».

Ә Х. Ярми төркеме туплаган папкада Мазарлы авылы кешеләренең Җәлүк азанчының шуннан соңгы язмышы турында сөйләгәннәре теркәлгән: «Суд булганны көтеп тә, суд булгач та ул төрмәдә шактый изаланган. Төрмәдән чыгаргач та, авылына кайтырга рөхсәт булмаган – аны выселкага сөргәннәр. Выселкада 3 ел яшәгәннән соң, Җәлүк азанчы авырулардан вафат була». (Бу аңлатманы Э. Касыймов язган булса кирәк.)

Югарыда китерелгән мисаллар – фольклор әсәрләренең байтак территориядә әйләнештә йөрүен һәм вариативлыгын гына түгел, ә төрле вариантларның бер-берсен тулыландыруын, шулай ук әсәрнең иҗат ителү тарихларын язып алуның фән өчен никадәр мөһим булуын дәлилли торган фактлар.

64 коллекциянең соңгы – 3 нче папкасына күчик. Андагы материаллар (38–45 саклау берәмлекләре), башлыча, Городище

районы авылларында тупланган. Бу якларда кияүгә китәсе кызларга багышланган җырлар, ягъни *кыз елатулар* еш очраган, Ә. Рәшитов һәм Э. Касыймов туплаган дәфтәр-папкаларда моны ачык күрәбез:

**Кыз елату**

Чебелдекләрем генә чуп-чуар,
Чебен генә кунса кем куар?
Бүген генә түгел, һәркөн кич,
Ах, кәбәм анакай,
Минем куначамда кем кунар?

Чебелдегемне кордыгыз.
Чәчәк саен тордыгыз.
Ни гаебемне тойдыгыз,
Яшьли муенымны бордыгыз?

Әтекәемнең түрендә
Утырыр гына урыным бер такта.
Уйнаган гынам, көлгән генәм
Кала тудыкайлар бер якта.

Тастымал гынам киң түгел,
Ябыныр гына идем. Иң түгел,
Уйлар гына идем, көләр идем,
Ян юлдашкынам тиң түгел.

Йөрерсең, апакай йөрерсең,
Буш куначага керерсең.
Буш куначада мин булмам,
Сары май кебек эрерсең.

*Городище районы Түбән Әләзән авылында*
*Дулатова Рәйсә Летфулла кызыннан*
*Э. Касыймов язып алган*

Экспедиция материаллары – халык иҗатының байлыгын һәм торышын да, Институт фольклорчыларының эш ысулларын, стилен күрсәткән төп-төгәл һәм катгый тарихи документ та. Алардан күренгәнчә, фольклорчы галимнәребез халыкның борынгыдан килгән иҗатына гына түгел, замана тенденцияләренә дә сизгер булган. Кайбер информантлардан эстетик кыйммәте ягыннан беркадәр зәгыйфь, ләкин чорның рухын тояр эчен кызыклы әсәрләр язып алынган. Папкада архаик сүзләр һәм формалар белән чуарланган, ләкин шул ук вакытта советка мәдхия җырлаган әсәргә юлыктык. Эчтәлектән аңлашылганча, яңа тормышның искесеннән аермасы – ахыр чиктә бостон кәчтүм киюгә генә кайтып калса да, халык арасында ихлас патриотик хисләр белән бәет чыгаручылар булган бит!

**Иске тормыш белән яңа тормыш бәете**

Иске тормыш белән яңа тормышларны
Үлчәп, яза башлыйм бәетләр.
Иске тормышларны күргән кешеләр, иптәшләр
Дөрес язган диеп уйларлар.

Мин яшь идем, беләм ул тормышны,
Уйлап хәтеремә китерәм.
Яңа тормыш белән чагыштыргач,
Иске тормышыма үкенәм.

Син дә белсәң, иптәш, ул тормышны,
Дөрес язган диеп уйларсың.
Баштан нинди тормыш үткән диеп, иптәшем,
Искә төшкән саен еларсың.

Хәзер инде безнең яңа тормыш
Иске тормышларны бетерде.
Авыр тормышларны ул бетереп, иптәшләр,
Җиңел тормыш китерде.

Иске тормышларда без кем идек?
Колга кол булганга тиң идек.
Хәзер көн дә кигән киемнәрне, иптәшләр,
Бәйрәм көннәрдә кими идек.

Хәзерге тормышны мин сөямен,
Иске тормыштан көямен.
Киндер киемнәрне кигән башым, иптәшләр,
Бостон киемнәр дә киямен.

Колга кол итү дә тормыш булган,
Ул тормышка ничек түзгәннәр?
Кайсыларны алып, кайсын сатып, иптәшләр,
Ир-хатынны шулай изгәннәр.

...Хәзер сиңа, иптәш, шуның берлән
Бәет язуымны бетердем.
Иске тормыш белән бу тормышны, иптәшләр,
Уйлап хәтеремә төшердем.

*Городище районы Түбән Әләзән авылында*
*Хисаметдинов Мөхәммәткәрим Рәхмәтулла улыннан (1891 елгы)*
*Э. Касыймов язып алган*

Авторны танылу омтылышымы, әллә тормыш итәрлек акча юнәтү максаты йөрткәнме, билгесез, һәм безнең мәкаләнең максаты да моны ачыклау түгел. Шулай да, информант турында Э. Касыймов кулы белән өстәп куелган мәгълүмат үтә кызыклы һәм түбәндәге юлларда галимнең аңарга шәхси мөнәсәбәте дә ярылып ята: «20 ел укыткан, хәзер имам булып тора 11 ел инде. Бәетне 1958 елның маенда чыгарган. Бәетне ахуннар, мөритләр дә ярата икән. Гонорар турында бик сорашты». Фольклорчыларның сүз уңае гына язып куйган кыска һәм оста комментарийлары хәзерге заман укучысында аерым кызыксыну тудыра. Киләчәктә әлеге теманы тулырак ача торган фәнни эзләнүләр үткәрелә башласа да, бик урынлы булыр иде кебек.

Әлеге информант шактый бәетләр чыгарган булса кирәк. Э. Касыймов дәфтәргә аның тагын берничә әсәрен теркәгән.

**Кызларны укыту турында бәет**

*(«Туган тел» көенә)*

Кызлар, сезгә нәсыйхәтем –
Яшьләргә хат язмагыз.
Язсагыз да, нык булыгыз,
Күңел биреп алмагыз.

Яшьләр сезгә хатлар язса,
Кире җибәр үзенә.
Торып тагын хәйлә язар,
Ачуланмаң сүземә.

...Кызлар сезгә нәсыйхәтем –
Ашыгып хатын булмагыз.
Кызлык вакыты ике килми,
Зинһар гафил булмагыз.

Яхшы гына укыгыз сез,
Яхшы урынга керерсез.
Яхшы укып белем алгач,
Тормыш кора белерсез.

*(1957)*

38–45 нче саклау берәмлекле кайбер дәфтәрләр «Ә. Рәшит» дип имзаланган. 38 нче саклау берәмлекле кара тышлы гомуми дәфтәрнең титул битенә ул болай дип язып куйган:

«Бу якларда, 1940 елда булса кирәк, Х. Шабанов була (диалектология экспедициясе белән). Ул шушы якларның тарихын да өйрәнгән. Институтта аннан калган материалларны карарга. Х. Шабанов үзе Мочалейка авылыннан. 8.08.58. Кутеевка».

39 саклау берәмлекле дәфтәрдәге җырларның байтагы Белинский районы Кутеевка авылында Акъегетова Нәҗиядән

(1938 елгы), Ишбердиева Раузадан (1935 елгы) язып алынган. Авыл кызлары җырлый торган җырлар арасында лирик җырлар, мәхәббәт хисләре, аеруча җавапсыз (яшерен) гыйшык тоту турындагылары хәтсез, аларны артык үзенчәлекле дип әйтеп булмас иде. Шулай ук йола җырларыннан «Уҗикәрәм» текстын оригиналь һәм замана укучысының игътибарына бик тә лаеклы дип таптык.

**Уҗикәрәм** [1]

*(Гармун белән. Үзенең көе бар. Кияү әйтә кыз өчен)*

1 җыр

Уҗикәрәм, буҗикәрәм,
Ничек тудың анаңдин?
Син тумадың бит анадин,
Тудың асыл һавадин.

2 җыр

Келәтеңнең башкынасын
Такта белән япканнар.
Ни аебыңны тапканнар,
Кыз янына япканнар.

3 җыр

Кара сыер кабыргасын
Каерып алып киттеләр.
Әнкәсенең бер бәбкәсен
Суырып (аерып) алып киттеләр.

4 җыр

Болыт тамырланадыр
Кулың камырланадыр.
Кияү белән кыз күрешкәч,
Кияү шадырланадыр[2].

Һәр җыр артыннан припев әтелә.

*Белинский районы Кутеевка авылында*
*Кайбеков Карибулла һәм Масаутов Ибраһимнан*
*язып алдым. – Ә. Рәшит иск.*

**Әбделмән купич**

Әбделмән купичның илле бер ялчысы
Барадыр Головинга урманга.
Бу да гына бәлалардин котылса идем,
Йөз куй суяр идем корбанга.

Әбделмән купич икедер кайләле,
Кигән киемнәре шау ука.
Купичлар арасында иң зур купич идем,
Һичберсе алмыйдыр порука.

---

[1] Уҗикәрәм – кызны алып киткәндә, егетләр җырлый торган җырларга әйтелә шулай дип. – *Ә. Рәшитов иск.*

[2] Шадырланадыр – шатланадыр.

Гайгылда гына гайгыл
Әбделмән купичның казлары.
Шыгырдан илендә елаша
Әбделмән купичның кызлары.

Таштан гына салдырдым мин ак мәсет,
Шыгырдан иленә дан өчен.
Шыгырдан халкына әйтә дә узыгыз,
Коткарсыннар мине Аллаһ өчен.

Бусагасы төбе вак таш кына,
Судлар йөри-йөри баз булды.
Ике капчык минем алтын акчам,
Башымны йолырга аз булды.

Кара да гына айгырымны
Мин подарить итәмен князьгә.
Акча суга торган станогым
Чыгарып бәрәмен грязьгә.

*Белинский районы Кутеевка авылында*
*Кайбелева Оркыядан (1924 елгы)*
*язып алдым. – Ә. Рәшит иск.*

**Круг уены[1]**

Ике якка: кызлар бер якта, егетләр бер якта. Аралаш та була. Кара-каршы басып, башта бер як җырлап бара, соңыннан – икенче як.

1. Бакчабызга бәрәңге чәчтек без.
2. Атлар белән таптарбыз, таптарбыз.
3. Атлар каян алырсыз, алырсыз?
4. Йөз сум түләп алырбыз, алырбыз.
5. Йөз сум түгел, мең сумыгыз кирәкми, кирәкми!
6. Сезләргә соң ни кирәк, ни кирәк?
7. Зифа буйлы, кара кашлы кыз кирәк, кыз кирәк.

---

[1] «Круг уены» дигәндә, информант ялгышкан булса кирәк. Бу уенны, тасвирламасына караганда, түгәрәк ясап уйнамаганнар. «Бәрәңге чәчтек без» уенының бер варианты булырга охшаган.

8. Ни атлы соң ул кыз, ни атлы?
9. Кара кашлы, Мәрьям атлы кыз!

*Белинский районы Кутеевка авылында*
*Ачаева Хәернисадан (1937 елгы)*
*Ә. Рәшит язып алган*

Шушы авылда яшь галим Узбеков Алимҗаннан (1876) авыл тарихын, Арслан Палкай турында, шулай ук «Кыз елату җыры» вариантларын, «Ямщик җыры»н һ. б. язып алган.

Акъегетова Нажия (1938 елгы) «Киндерләр җәйдем» җырын, шаян җырлар һәм такмаклар, Качекаева Рауза (1938 елгы) – «Алтын алмам, ятларга каласың»ны тапшырган.

Мишәр якларында «Кузырлыкай санка» җыры еш очраган булса кирәк, шушы исем белән текстларны Х. Ярми, Х. Гатина, Ә. Рәшитов дәфтәрләрендә күрәбез. Укучы игътибарына 38 нче саклау берәмлегеннән бер вариантны тәкъдим итәбез:

**Кузырлыкай санка**

Кузырлыкай санка (чана), әй кузырлы,
Кая да гына булдың, кая йөрдең?
Алма битләреңне өшетеп.
Үзең әйтмәсәң дә, кешеләр әйтә,
Үләнәсең, диеп ишеттем.

*Ер арасы[1]:*

Тал тибрәтсәм, тала беләгем,
Исемә төшсә, яна беләгем.

Кузырлыкай санка, әй кузырлы,
Аның эчләренә кем яткан?
Кичә хәтерләрең калган иде,
Бүген хәтерләрең кем тапкан?

*Ишмаметов Сабирдан Ә. Рәшитов язып алган*

42 нче саклау берәмлегеннән башлап, шулай ук әкиятләр теркәлгән.

---

[1] Ер арасы – кушымта.

Э. Касыймов дәфтәрләрендә әкиятләр бик күп. Бу папкада таныш, яратып укыла торган әкиятләрдән: «Гүзәл кыз Хәдичә», «Нурсылу» һ. б. Аларның күбесе машинкада басылган, димәк, алар элегрәк ТӘһСИ тарафыннан әзерләнгән һәм нәшер ителгән җыентыкларда, халык иҗаты томнарында лаеклы урыннарын күптән алган булырга тиеш.

Әлеге дәфтәрдә алга таба «Әбделмән купич», «Урта Әләзән бәете»; «Солдат бәете» кебек танылган бәет текстлары; «Сәхибҗамал җыры», «Мәфтуха җыры», шаян җырлар, такмаклар, «Разбойник җыры» һ. б. очрады. Хрестоматик әсәрләр халык иҗаты томнарына кергән.

Шемышейка районы Оз авылында «Хәдичә кыз бәете», «Япон сугышы бәете», «Севастополь сугышы» кебек тарихи әсәрләр язып алынган.

48 нче саклау берәмлекле дәфтәр «Җырлар» дип атала. Җырларны биредә бирүне мөмкин түгел дип таптык, чөнки алар инде элек чыккан китапларда бар. Шулай ук текстта куплетлары «Кыз», «Кияү» дип билгеләнгән җырлар бар. Каракаршы әйтешеп җырланганнары туй җырлары белән кушылып киткән.

Еллар узгач, татар галимнәре үз куллары белән язып тотырган дәфтәрләр безнең буын өчен гаять кадерле тарихи документ та, татар филологиясендә лаеклы эз калдырган шәхесләр турында истәлек тә булып тора. Билгеле, без бу архив документларыннан кыйммәтле фәнни чыганак буларак файдаланабыз, шул ук вакытта, папкалардагы кәгазьләр аркылы фольклорчыларыбызның элегрәк эшләгән буыны, аларның эш методлары, фольклор язып алу ысуллары белән якыннан танышабыз. Һәм хәтта галимнәрнең холкы-фигыле дә күпмедер дәрәҗәдә ачылып киткәндәй була. Бу кадәр мәгълүматны шәхесләрнең рәсми биографиясендә һәм мемуарларда табып булмас, ә саргайган кәгазь юллары арасында, җентекләбрәк караган кешегә, әлбәттә, байтак нәрсәләр күренә. Мисал өчен, һәр татар фольклорчысының «яраткан» жанрлары булган икән.

Мәсәлән, Х. Ярми информантлардан әкият сөйләтергә һәм язып алырга оста булган, дип уйласак та, чынлыкта, олпат га-

лим җыр жанрын үз күргән. Ул аларны, магнитофонга яздырыр алдыннан информантлар белән репетицияләр үткәрә-үткәрә, йөзәрләп яздыра. Дөрес, Пенза экспедициясе материаллары арасында Х. Ярминең җырларны магнитофонга да яздыруы турында хәбәр очрамады.

Ә дөньядан шактый иртә киткән прозаик Э. Касыймовның, мәсәлән, «яраткан» жанры әкиятләр булган, дип нәтиҗә ясый алабыз. Барыбызга да балачактан яхшы таныш әкиятләр белән бергә, дәфтәрләрдә гомер ишетмәгән-күрмәгәннәре дә байтак! Шул ук вакытта Э. Касыймов тарихи һәм сюжетлы җырлар язып алырга да өлгергән. Архив кәгазьләреннән күренгәнчә, ул эшне тиз һәм төгәл алып барган, җыйган әсәрләрне түкмичәчми, кайвакыт шәхси комментарийларын да өстәп, информантлар турында тиешле мәгълүматны тулы итеп язып алып барган.

Ә. Рәшитов исә, шагыйрь буларак, халык иҗатының тезмә жанрларына өстенлек биргән, дигән фикер туа. Бәетләр, җырлар, такмаклар... Шулай ук авыл тарихлары да аңарда зур кызыксыну уяткан булса кирәк. Ул әсәрнең паспортын гына түгел, тарихын да ачыкларга тырышкан.

Шулай итеп, архивтагы папкалар фәнне фольклор әсәрләре белән баетып кына калмыйча, хәзерге заман укучысына узган гасыр уртасы рухын тоярга, танылган шәхесләребезнең эш алымнары белән танышырга ярдәм итә.

# АВТОРЛАР ТУРЫНДА КЫСКАЧА БЕЛЕШМӘ

**Бәдртдинова Алсу Әнис кызы,** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының нәшрият бүлеге редакторы.

**Булатова Миңнира Рәхим кызы,** филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

**Зәйниева Гөлнара Нургали кызы,** филология фәннәре кандидаты, текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре

**Нургаянова Наилә Хәбибулла кызы,** педагогика фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты

**Сафиуллина Рузия Фәһим кызы,** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фәнни хезмәткәре.

**Усманов Венер Мөдәррис улы,** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре.

**Фәйзуллина Фәния Галимулла кызы,** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәре.

**Шәйдуллин Рафаил Вәли улы,** тарих фәннәре докторы, профессор, ТР ФА М.Х. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының энциклопедистика үзәге мөдире.

**Шкляева Людмила Михайловна,** сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

**Ямалтдинов Ильмир Илдар улы,** филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире.

**ЭЧТӘЛЕК**

ПЕНЗЕНСКИЕ ТАТАРЫ: ИСТОРИЯ И СОВРЕМЕННОСТЬ
*Рафаиль Шайдуллин*
28

ТАТАРСКИЕ ЭПИГРАФИЧЕСКИЕ ПАМЯТНИКИ ПЕНЗЕНСКОЙ ОБЛАСТИ
(по результатам экспедиций ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ)
*Венер Усманов*
49

ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ЯЗМА МИРАСЫ: ЭКСПЕДИЦИЯ КӨНДӘЛЕГЕ ЭЗЛӘРЕННӘН (ПЕНЗА ӨЛКӘСЕ)
*Гөлнара Зәйниева*
64

ЯЗМА ЯДКӘРЛӘРДӘ – ХАЛЫК ХӘТЕРЕ
*Фәния Фәйзуллина*
92

ТАТАР ТЕЛЕ КӨНБАТЫШ ДИАЛЕКТЫНЫҢ КУЗНЕЦК СӨЙЛӘШЕ ҺӘМ ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ
*Миңнира Булатова*
111

ПЕНЗА ӨЛКӘСЕНЕҢ ГОРОДИЩЕ, ЛОПАТИНО, ШЕМЫШЕЙКА, ИССА, ЛУНИНО РАЙОННАРЫНДА ЯШӘҮЧЕ ТАТАРЛАР СӨЙЛӘШЛӘРЕНЕҢ АВАЗ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ
*Алсу Бәдртдинова*
158

ПЕНЗА ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ ФОЛЬКЛОРЫ
(Халык иҗаты үрнәкләре)
*Ильмир Ямалтдинов*
167

ЯШЬТӘН ИСТӘ КАЛГАН ФОЛЬКЛОР
*Рузия Сафиуллина*
313

ЭТНОМУЗЫКАЛЬНЫЕ ТРАДИЦИИ ТАТАР ПЕНЗЕНСКОЙ ОБЛАСТИ
*Неля Нургаянова*
403

ТРАДИЦИОННЫЕ РЕМЕСЛА ПЕНЗЕНСКИХ ТАТАР
*Людмила Шкляева*
444

ЕРАК ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ
*Рузия Сафиуллина*
458

Научно-популярное издание

*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

Двадцать четвертая книга

**Национально-культурное наследие**

**ТАТАРЫ ПЕНЗЕНСКОЙ ОБЛАСТИ**

Фәнни-популяр басма

*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе*

Егерме дүртенче китап

**Милли-мәдәни мирасыбыз**

**ПЕНЗА ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ**

Редакторлар: *Д.Р. Галиуллина, Л.Г. Шәрифуллина*
Корректор *Л.Г. Шәрифуллина*
Компьютерда биткә салучы *Н.Т. Абдуллина*

*Китапта А.И. Әхмәтова, М.Р. Булатова, Л.М. Шкляева, А.Ф. Борһанова фоторәсемнәре файдаланылды*

*Тышлыкның беренче битендә:*
*Пенза шәһәре җамигъ мәчете. Кочеткова Валерия Алексеевна фоторәсеме*

Басарга кул куелды: 26.12.2024.
Офсет кәгазе. Форматы 60×84 $^1/_{16}$. Times New Roman гарнитурасы.
Нәшер-хисап табагы 23. Шартлы басма табагы 27,9. Тиражы 200 д. Заказ

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде
420111, Казан, К. Маркс ур., 12

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан, Бауман ур., 20